ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.2006





**Сара Садыйкова**
**(1906 –1986)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2006

# 11

(1009)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*


*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**


---


✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

### ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Салисә ГӘРӘЕВА. *Шигырьләр.* ... 5
Вакыйф НУРИЕВ. Җиденче палата. *Повесть.* ... 9
Бикә РӘХИМОВА. Ятимнәр. *Шигырьләр.* ... 30
Рәфкать КӘРАМИ. Олы юл да сикәлтәле. *Роман.* ... 34
Рөстәм КУТУЙ. Ватаным дип елыйлармы? *Шигырьләр* (Р. Фәйзуллин кереш сүзе белән). ... 63
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Үзем хөкем итәм. *Роман.* ... 69
Хәмит ЛАТЫЙПОВ. Галәми гамь. *Шигырьләр.* ... 121
Йолдыз МИҢНУЛЛИНА. Шәһәр чаганнары. *Шигырьләр.* ... 125

### ПУБЛИЦИСТИКА

Рафаэль ХӘКИМ. Татар рухы. ... 128

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тәлгать ГАЛИУЛЛИН. «Бәрелде җан, сугылды җан ярсып». ... 133

### КИТАП КҮЗӘТҮ

Рашат НИЗАМИ. ...Яшисе килә. ... 144
Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ. Тукай турында. ... 146

### ФӘН

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ... 149
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ... 153
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ... 178

### САРА САДЫЙКОВАНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Рафис ӘХМӘТ. Сандугачтай Сара апабыз. ... 159

### ТАТАР ТЕАТРЫНА 100 ЕЛ

Әзһәр ШАКИРОВ. Язмыш һәм узмыш. (Р. Юныс кереш сүзе белән) ... 164

### ХӘТЕР

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ. Көндәлек сәхифәләре. ... 170

### ГАБДЕЛНАСЫЙР КУРСАВИНЫҢ ТУУЫНА 230 ЕЛ

Раиф МӘРДАНОВ. Кыйммәтле ядкәрләр. ... 174
Габделнасыйр КУРСАВИ. Шигырьләр. ... 175

### НӘҖИП ХӘЛФИННЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Нәҗип ХӘЛФИН. 1913 нче елда татар шагыйрьләре. ... 176

### АЛЬБЕРТ ЯХИНГА 75 ЯШЬ

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ. Формулалы әдәбият. ... 182

Бер сорауга—бер җавап. ... 156
Алхәбәр. ... 68, 127, 155, 158, 181
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ... 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: романы Р. МИР-ХАЙДАРОВА «Судить буду я» (продолжение), Р. КАРАМИ «Тернистый путь» (продолжение), повесть В. НУРИЕВА «Седьмая палата»; стихи С. ГАРАЕВОЙ, Б. РАХИМОВОЙ, Х. ЛАТЫЙФА, Ю. МИННУЛЛИНОЙ.
«К 70-летию Р. Кутуя»: статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА «Яркий талант» и баллады Р. КУТУЯ.
«Публицистика»: Р. ХАКИМ. «Метаморфозы духа» (продолжение).
«Литературная критика»: статья Т. ГАЛИУЛЛИНА о творчестве С. ХАКИМА.
«Книжное обозрение»: рецензия Р. НИЗАМИЕВА на книгу Ф. ЗИЯТДИНОВОЙ; М. АХМЕТЗЯНОВ. «О Тукае...»
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение); Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (продолжение).
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«К 100-летию С. Садыковой»: статья Р. АХМЕТА.
«К 100-летию татарского театра»: воспоминании А. ШАКИРОВА (с предисловием Р. ЮНУСА).
«Память»: М. МАГДЕЕВ.«Страницы из дневника».
«К 230-летию Г. Курсави»: статья Р. МАРДАНОВА, стихи Г. КУРСАВИ.
«К 120-летию Н. Халфина»: Татарские поэты в 1913 году.
«К 75-летию А. Яхина»: статья А. ГИМАДИЕВА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Первый снег»; писательница Шаида Максудова.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novels by R. MIR-HAYDAROV «I will judge» (continuation), R. KARAMI «Thorny way» (continuation), story by I. NURIEV «Seventh room»; verses by S. GARAEVA, B. RAHIMOVA, H. LATYF, U. MINNULINA.
«To 70th anniversary of R. Kutuy»: article by R. FAIZULLIN «Bright talent» and ballads by R. KUTUY.
«Publicism»: R. HAKIM. «Metamorphoses of spirit» (continuation).
«Literary criticism»: article by T. GALIULLIN about S. Hakim's creativity.
«Book review»: review by R. NIZAMIEV on book by F. ZIATDINOVA; M. AHMETZANOV. «About Tukay...»
«Science»: A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation» (continuation); F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Pages from «Tatar encyclopedia».
«To 100th anniversary of S. Sadykova»: article by R. AHMET.
«To 100th anniversary of Tatar theatre»: memoirs by A. SHAKIROV (with foreword by R. YUNUS).
«Memory»: M. MAGDEEV. «Pages from diary».
«To 230th anniversary of G. Kursavi»: article by R. MARDANOV, verses by G. KURSAVI.
«To 120th anniversary of N. HALFIN»: Tatar poets in 1913.
«To 75th anniversary of A. Yahin»: article by A. GIMADIEV.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «First snow»; writer Shaia Maksudova.

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 23.10.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 3–930. Тираж 6032.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2006 ел.



Салисә
Гәрәева

## Биеккә чакыру

Биектә—кыя очында
Бөркетләр канат какты.
Үз итте җаным, бөркеттәй,
Тау-ташлы кырыс якны!..

Болытлар акты биектә –
Куышып, таралышып...
Үкенечләр басты җанны,
Ярага яра кушып!

Урал бөркете шикелле
Җәй иде канатларны!
Күр иде—җилләр яшенле
Давылны таратканны!..

Кун иде яшен утының
Якты сәнәк очына...
...Җаным биеккә, бөеккә,
Горурлыкка чакыра!..

## Нинди бөек бу җир

Нинди бөек, нинди иркен бу Җир!
Һәр ягында җилләр исәләр.
Су буенда, тауда, ташлыкларда
Иелеп-сыгылып гөлләр үсәләр...

Зәңгәр күлләр күккә күзен төби.
Елгаларның йөгерек тасмасы!
Аркылыга-буйга иңли җирне,
Кайсы якка юлын сапмасын!..

Салисә ГӘРӘЕВА—*шагыйрә; "Уралым", "Тау сукмагы", "Офыклар" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Тау очлары күксел болытларны
Ничә тапкыр тишкән үтәли.
Вулкан булып ишетелә безгә
Янар тауның утлы ютәле!..

Гейзерларын ата Җир күкрәге,
Кайнарланып магма утында;
Мәгънә биреп бөтен тормышыма,
Үз йөрәгем тибә, сулкылдап.

Үз баласын җирем сынау аша
Алып чыга язмыш утыннан,—
Ишеттереп чишмә сулкылдавын
Күкрәгемнән—йөрәк турыннан!..

***

Ырымнарга ышану юк инде ул,
Кеше Айда йөргән заманда!
Тик нindiдер сихри, бөек Көчнең
Сулышы бар кебек һаман да!..

Табигатьнең законнары камил:
Кешегә дә гадел, утка да!
Ник соң кеше, сихерләнгән кебек,
Матурлыкны күреп туктала?!

Яманлыктан килә котыласы,
Ырым яки тылсым кулланып.
Сизә күңел каргыш яшьләренең
Аңлашылмас көче булганын!..

Ырымнарга ышану—көлке кебек,
Кеше Айда йөргән заманда.
...Тик нindiдер сихри бөек көчнең
Сулышы бар кебек һаман да!..

## Вертуаль тормыш

Галиҗәнаб Вакыт ирексездән
Алып керде яшь-яшь гасырга.
Белми торам кемгә эндәшергә,
Кайсы кнопкага басырга?

Чөнки миңа яңа туган гасыр
Таныш түгел—серле кодлары:
Чордашларым бакый йортка киткән,
Күзгә күренгәннәр—ят бары!..

Болар үзгә: тыйнак, сабыр түгел -
Күпкә чая, күпкә һавалы!
Куеннары тулы—утлы корал,
Күзләр—усал, шәфкать—чамалы...

Яшәү дөньялары—интернетта,
Тормыш итүләре—виртуаль!
Йөрәкләре сайт та, файл гына:
Ачкыч ярат, «тычкан» кертеп ал!..

Маузерлары—лазер көчәнешле,
Ялангачлык, секс—гадәттә!
ХИТлар, Роклар, мобиль телефоны –
Бары да сайрый шул үк сәгатьтә!..

Галиҗәнаб Вакыт ирексездән
Алып керде яңа дөньяга.
Гаҗәпләнеп, хәтта бераз шүрләп
Карап торам бүген мин аңа!..

## Ай өстендә канатлы ат

Айлы төннәр—минем иҗат чорым:
Илһам уты иңә Галәмнән!
Тылсым тулы—йолдыз тулы күкләр
Илһам чишмәсенә әйләнгән!

Яна утым. Каләм шигъри дәртен,
Ак кәгазьгә кунгач, арттыра.
Төнге Күккә карыйм: Ай өстендә
Канатларын җәйгән ат тора!..

Очып төшәр кебек, болытлардан
Болытларга кунып, җилдереп;
Каршылыклы, хәтәр заманымның
Золым киртәләрен җимереп!..

Һәм мин көтәм аны!
Серле төннең
Йолдызлары җиргә атыла.
...Айга карыйм.
Анда—Ай өстендә
Канатларын җәйгән ат тора!..

## Казакъ даласында

Казакъ даласында атлар утлый.
Ялларында уйный таң җиле.
Исе китеп мондый иркенлеккә,
Туктап калган Урал-тау иле!..

Казакъ даласында көмеш кылган –
Көмеш чыңнар чыга таңнарда.
Дала җилләренең җиләслеген
Тик далада мөмкин аңларга...

Казакъ даласында елкы ирке—
Көмеш кылган, көмеш ай нуры...
Ялларында эссе җил уйнатып,
Дулый монда дала айгыры!..

Муеннарын салып муеннарга,
Тук биятәр бергә серләшә.
Тояк сынап дала такырында,
Колыннары уйный янәшә...

Ә үткәннәр... миңа эндәшә!..

***

Каеннардан җиңел моң тарала—
Ялкынлы, ак, дәртле, дулкынлы...
Ә ерактан килә чыршыларның
Чәер исе сеңгән хөр тыны...

Ераклардан, торна тавышыдай,
Наратларның килә сагышы.
Самими һәм рәхәт, сокландыргыч
Шул көйләрнең бергә агышы.

Тукран аңа куша барабанын,
Кошлар исә—чут-чут сайравын.
Җил югында әле белеп булмый
Күлнең нинди тембр сайлавын...

Төсле музыкадай, тау өстеннән
Ай урагы калка—сизәмсең?
...Галәм тыңлый гүя Табигатьнең
Җан тетрәткеч симфониясен!..

***

Гомер чиге якынайган саен
Ялт-йолт итә хәтер яшене:
Ниндидер сүз кинәт яктыра да,
Хәтерләтә якын кешеңне.
Рәшә кебек, ачылып—янып куя
Яшьлегеңнең татлы чаклары.
Балкып куя хәтер рәшәләре,
Ишетелә яшен чатнавы!..

Тормыш үзе тулы тустаганын
Төбенәчә сиңа эчертә.
Мәхәббәте, дәрте, янулары
Утлы шәраб кебек исертә!..

## Күк чәчәк

Буынчәчәк, күкчәчәк
Зәңгәрләгән яланны!
Шул яланда илһам килде—
Яңа хисләр ярралды!..

Сөрмәт буе—туган як,
Суга казлар куган як.
Таулар , сулар , болыннар
Миңа холык уйган як!..

Арыш кыры серкәдә,
Урман буе – чәчәктә!
Насыйп итсен авылга
Кайтырга киләчәктә!..

Буынчәчәк – күкчәчәк,
Сокланырга яралы.
...Шул зәңгәрлек эченнән
Гүя әнкәй карады.
Әткәй бармак янады!..



Вакыйф
Нуриев

# ҖИДЕНЧЕ ПАЛАТА

ПОВЕСТЬ

*Кайгының ни сүз икәнен*
*Белмәгән сабый бала!*
*Ни булды сиңа, гүзәлем,*
*Йөзләрең сарылана?*

*Синең дә бардыр, күрәсең,*
*Әрнүләр, җәлләүләрең;*
*Яшьләрең юа ләбаса*
*Күзеңнең зәңгәрләрен...*

Х.Туфан

Сорау: Бүген өлкәннәр балаларны иң әүвәл кемнән-нәрсәдән якларга-сакларга тиеш? Сугыш чукмарларыннанмы, террорчылардан-мы, наркоманнарданмы?.. Ачлыктанмы, бәла-казалардан-мы?

Җавап: Өлкәннәрнен үзләреннән.

(Халыкара балаларны яклау көне унае белән бер телевизион тапшыруда яңгыраган сүзләр.)

—Бүген мәктәпкә барганда улыгыз Ардуанны машина таптаган. Аны «скорый» белән 12 нче бульнискә алып киткәннәр. Безгә шылтыраткан хатын тагын нәрсәдер әйтте инде. Тавышы калтырый иде, соңгы сүзләрен аңлап булмады. Хатыныгыз эшкә килеп җитмәде әле, шуңа күрә сезгә шалтыратабыз.

Иртән эшкә килүгә, менә шундый аяктан егарлык хәбәр алдым. Шып итеп урындыкка утырдым. Хәлем китте, күз алларым караңгыланды. Башта бер генә сорау: улым исән микән? Чабарга, тизрәк бульнискә чабарга! Безнен редакция урнашкан Язучылар берлеге йортының ишегалды машина белән тулы була торган иде. Бүген бер «Волга» да бер «Джип» кына. Үзебезнеке эш белән киткән иде. «Волга»—бер дус мөхәррирнеке. Ана керәм. Хәлне аңлатам.

—Их, машинаны бик бирер идем дә, срочно барасы җир бар,—ди ул сәгатенә карап һәм йөзенә мул итеп интегүле-газаплы теләктәшлек билгеләре чыгара.

«Джип»ның хуҗасы—Семен атлы бер эшкуар. Аны белмим. Шулай да аңа әйтеп карарга җөрьәт итәм. Семен минем ни йомыш белән йөрүемне ярты сүздән аңлады.

---

Вакыйф НУРИЕВ (1958)—*прозаик; «Бүре кадәр бүрек», «Ана догасы» китаплары авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

—Киттек!—диде ул ике дә уйламыйча. Безгә аның хезмәттәше Айрат та иярде.

Кызыл «Джип» Казан урамнарындагы машиналар ташкынын, вак ташлар арасыннан шуышып барган кәлтә елан кебек, ера-ера алга чаба. Әмма ул миңа барыбер акрын барган кебек тоела.

—Тизрәк, Семен! Зинһар өчен тизрәк!

Кызыл утка туктап калганда, мин җанымны кая куярга белмим. Шушы минутларда улым үлем белән тартышып ятадыр да, мин генә аны әҗәл тырнагыннан тартып алып калырмын кебек.

Башымда утлы уйлар өермәсе. Иртән телефоннан алган йөрәк өзгеч хәбәрнең һәр сүзен күнел иләгеннән үткәрәм. «Улыгызны машина таптаган». Көпчәк астында калган була ич инде бу. «Безгә шылтыраткан хатын тагын нидер әйтте инде. Тавышы калтырый иде. Соңгы сүзләрен аңлап булмады» дигәне, «улыгыз үлде», дигән хәбәр түгелме соң инде.

—Семен, ашыкмасагыз да була. Һай, Аллам, шул бердәнбер улымны да күпсенденмени соң?

Семен белән Айрат миңа борылдылар:

—Син кайгырма. Тынычлан.

—Ул бүлнистә морг бит. Зур морг. Апам шунда ятканда мәетләрне китерүләрен үз күзләрем белән күреп тордым. Исән булса, аны Казанның бер башыннан икенче башына алып китмәсләр иде. Югыйсә РКБ безнең янда гына бит. Коткарып калырлык булса шунда гына алып керерләр иде.

Йөрәгемнең тагын хәле китте. Күкрәгемне кайнар дулкын кысты.

«Беләм мин ул моргны. Эшләми ул. Ремонтта».—Семенның шушы сүзләрен ишеткәч тынычлангандай булдым.

Караңгыда адашмас өчен юлчыга бер шәм яктысы, салкында өшемәс өчен кечкенә генә бер учак җылысы да җитә, дигән әдип. Ә менә кайгы-хәсрәткә чумган кешенең өмет учагын тергезеп җибәрергә бер сүз җитә икән.

Рәхмәт сиңа, Семен!

Миңа бүлнискә синең белән барырга Ходай үзе кушкандыр. «Морг ремонтта» дип әйтүең күнелдәге сүнеп килгән күмерләргә өреп җибәргәндәй булды.

Тик бу юаныч әлләни озакка бармады. Бактың исә, шофер бүлнискә юлны белми икән бит. Юлны белмәгәч, моргның эшләмәгәнен каян белә ул?! Соцгородка җитәрәк сулга борыласы булган. Ә без егерме икенче завод янына китеп барганбыз. Йөри торгач бүлнискә әйләнгеч ясап, Шималь, Коры Елга бистәләре ягыннан килеп төшәргә мәҗбүр булдык. Бу араны үтү миңа Мәскәүгә барып кайткан кебек тоелды. Әнә бүлнис. Чү, морг эшли түгелме соң?! Ишеге ачык. Аннан аз гына читтәрәк «скорый» да тора. Улымны алып килгән машина шушы микәнни инде? Эчем тагын «жу» итте. Тәнем чымырдап куйды. Күкрәк эчендәге меңнәрчә кыллар чытыр-чытыр килеп өзелде.

Ах, син, Семен, алдагансың ич!

Йөрәгемне учыма кысып бүлнис ишегалдына уздым. Ә җирдә яз. Апрель кояшы җиһанны нурга күмә. Их, яшисе дә яшисе бит әле. Юк, аякларымның һич кенә дә моргка таба атлыйсы килми. Үземнең «приемный покой»га килеп керүемне сизми дә калдым.

Стена буенда носилка. Аңа ак халатлы бер егет, ике хатын-кыз иелгәннәр. Кем ятканын һич күреп булмый. Менә берсе чүт кенә читкәрәк тайпылды. Шул мизгелдә дер-дер калтырап торган иреннәрне шәйләп алдым. Бу кипкән, зәңгәрсу иреннәр—минем улым бит!

—Улым!—Носилка өстенә капланып, Ардуанның үземнеке төсле каты-куе чәчләреннән сыпырам.

Анын сул як чигәсе кара янган. Ияге сыдырылган.

—Улым, син исән! Аллага шөкер! Аллага шөкер!! Аллага шөкер!!!

Мин тагын аның киребеткән чәчләреннән, йомшак кулларыннан сыпырам. Хикмәти Хода, Ардуанның иреннәре калтыраудан туктый. Әле генә тешетешкә тими иде бит. Үзе дәшми. Монсу күзләрен бер ноктага төбәгән дә уйга калган.

—Улым, әйтче, кайда, ничек булды бу хәл?

Ардуан әллә ишетә мине, әллә юк. Ул арада ак халатлы егет кулы белән җилкәмә кагылып ала.

Мин читкәрәк китәм. Семен белән Айрат та монда икән. Китмәгәннәр. Шатлыгымны уртаклашучы беренче кешеләр—алар.

—Сез малайның әтисеме?—каршымда кулына микрофон тоткан бер чибәр генә кыз тора. Ә уң яктан безгә «Эфир» дип язылган камера төбәлгән.

—Әйе, әтисе булам.

—Улыгыз ничәнче класста укый?

—Өчтә.

—Ул мәктәпкә һәркөнне үзе генә чыгып китәме?

—Үзе генә. Беләсезме, мәктәпкә кадәр берниндн юл чыгасы юк ана. Фәкать тротуардан гына барасы. Анын өчен җаныбыз тыныч иде. Кайда бәргән аны машина? Башыма сыймый.

Без сөйләшеп торган арада Ардуанны рентгенга алып кереп киттеләр. Коридорда сумкасы белән бутыйлары гына аунап калды. Бутыйларын пакетка салдым. Сумкасын алыйм дисәм, китаплары, дәфтәрләре коелып төште. Һай, улым, ничек исән калдың син. Сумкаң төбе тетелеп беткән бит. Җепләре генә калган. Аны бүлнисснен чүплегенә чыгарып ташлаудан башка чара юк. Кем белә, бәлки нәкъ менә аркаңа аскан шушы сумка саклап калгандыр әле сине.

Улымның исән калуына ышандым. Инде хәлен беләсе килә бит. Башына зыян килмәгәнме? Аяк-куллары бик нык имгәнгән булып гарип калмасмы? Үпкә, бөер, бәвел куыгы, ят җире ни хәлдә?

Бераздан барысы да ачыкланды.

—Улыгызның баш мие селкенгән, таз сөяге сынган,—диде травматология бүлеге мөдире.

Әлегә буш караватюк икән. Күтәп торырга куштылар. Көтәбез. Сулда—табиблар бүлмәсе, унда—операция залы. Ардуан яткан каталка белән рәттән тагын бер каталка тора. Анда бер абзый ята. Ул менә-менә операциягә кереп китәргә тиеш. Шунда аның түшәмгә текәлеп уйга чумган нурсыз күзләренә, кәфен төсле агарып чыккан кызгандыргыч йөзенә игътибар иттем. Юк инде, чырай юк. Мәет тә мәет, бу да мәет. Абзый борчыла, курка, көрәсен. Менә аны алып кереп тә киттеләр. Ходай түземлек бирсен сина, абзый.

Отыры улым йоклап китте. Биш минут черем итте микән, «дерт» итеп куркып-сискәнеп уянды.

—Сумка, минем сумка кайда?

—Борчылма, улым. Монда сумкаң, монда.

Шөкер, улымның гаме бар икән әле. Шушы хәлдә дә сумкасын сорап ята бит, бичара.

—Улым, әйтче, зинһар. Кайсы төштә, нинди машина бәрдерде сине? Ничек?—дип сорыйм Ардуанның кулын учыма алып.

Ул кулын җәлт кенә тартып алды. Иреннәре кысылып куйды. Ияге шадраланып чыкты. «Нервылар кысылган» дип уйлап алдым эчтән генә. Димәк, әлегә баланы аптыратмавын хәерле.

Шулвакыт носилка янына буе белән дә, яше белән дә нәкъ улым чамасындарак, кинчә борынлы, куе кара кашлы бер малай килеп басты. Ул

чәчләрен маңгаена кыеклатып төшереп тараган. Өстендә—фасонлы кара майка. Муенында—керләнгән муенчак. Ул самими күзләрен улыма текәгән. Бу малайга ни-нәрсә булды икән, дип кызыксынып йөрүеме, әллә улымны кызганып басып торуымы? Ардуан аның шулай чекерәеп карап торуын яратмады. Карашлары очрашуга башын читкә борды. Ә мин улымның ачуын чыгарып тормасын әле дип, бу малайга сүз катарга булдым:

—Нинди муенчак асып йөрисең син?

Малай минем эндәшүне генә көткән диярсең—яныма ук килеп утырды. Чит кеше белән сөйләшү аңа тансык, күрәсең.

—Ә минем, абый, умыртка сөяге бит... Беренчесе, икенчесе, дүртенчесе хөрест. Чана шуганда сикертмәдән очып сальто ясаганмын. Ә бу малайга ни булган?

—Машина белән сөзешкән.

Муенчаклы малай әүвәл миңа сәерсенеп карап куйды, аннары ихлас елмайды.

—Аны безнең палатага салалар. Жиденчегә.

—Шулаймыни? Димәк, бергә ятачаксыз. Ә син ни атлы буласың соң? Исемең?

—Исемем икәү минем. Башта Жаншет идем. Хәзер—Нияз.

Сәгать-сәгать ярымлап көткәннән соң, урын бушады. 7 нче палатаның түрдәге караваты. Ардуанны каталкадан анда күчерү шактый кыен булды. Улым сул аягына бармак белән дә кагылдырмый. Әрнидер инде. Аптырагач, җәймәсе белән күтәреп салдык. Салып сулыш алырга да өлгермәдек, шәфкать туташы—чәчләре чаларган, өлкән яшьтәге бер апа—каталка белән шалтыр-шолтыр тагын кереп житте.

—Нуриев, операциягә!—диде ул.

Ардуанны караваттан янә каталкага күчердек. Аның «ой,ой» дигән әрнүле тавышы йөрәккә тиеп алды.

Носилканы дөбер-шатыр алып чыгып китте әлеге апа. Аллага тапшырдык. Тик аның малайны алып чыгып китүе кая да кире әйләнеп керүе кая. Операцияне ясамаска булганнар.

—Яшь организм. Таз сөяге үзе ялганачак ул,—диде табиб.

Палатага тагын бер матрас алып керделәр. Аны тыгызлап төрделәр. Ардуанның аякларын күтәртеп шул матраска куйдылар. Бер ай буена менә шулай селкенмичә ятарга тиеш икән бу бичара.

* * *

7 нче палата. Зур тәрәзәле, диварларының аскы өлеше караңгы яшел белән зәңгәрне кушып буяуга буялган бер бүлмә. Биш караватта—биш малай. Иң түрдәгесендә, тәрәзә буенда—5 яшьлек Ярослав. Ул әтисе белән уйнаганда муенын имгәткән. Ардуанга каршы яктагы стена буенда муенын чана шуганда авырттырган Азат ята. Хәер, сез аларны ята дип уйлыйсызмы? Палатаны, коридорны бер итеп чатыр чаба алар. Бүлнис халкы да, шәфкать туташлары да бу самими карашлы, сөйкемле малайларны ярата, үз итә кебек тоелды миңа.

Ә менә Ардуанның баш очында яткан малайның исеме Гадел икән. Ул да улым кебек җиде-сигез яшьләр тирәсендә булыр. Машина көпчәге астында калган. Ишегалдында «Газель» өстеннән чыгып, сул аягын тез түбән чәрдәкләгән. Монда шул аякны кыйпылчыклардан җыеп улакка салганнар да караваты башына тарттырып куйганнар. Өченче атнасын инде, ни уңга, ни сулга борыла алмыйча, аягы тышауланган килеш ята икән мескен бала. Бик нык тартылган, суырылган. Аның очлаеп чыккан ияге, тырпайган колаклары, борынындагы чекерәйгән сипәк-мипәк сипкелләре, эчкә баткан зәңгәр күзләре, нечкә муенында һәм агарынып калган йөзендәге тармакланып киткән

зәңгәрсу-соры тамырлары кызгану хисе уята. Әнисе тун йөрәкле, каты бәгырьле хатын, ахры. Шул шыр сөяккә калган малайны гел кагып-сугып тора. Юк, карап-карап торам да, күнелгә бер дә ошамый әле бу хатын. Палатадагыларнын барысын да үз кубызына биетмәкче. Төшке аштан сон «Тихий час. Барыгызга да йокларга!»—дип әмер биреп ята, субакы. Үзе улы янына төнле. Галел исә, жилкәләрен куырып, стенага сыланды. Күр әле, нишли бит, ә?! Үз өендәмени! Күрсәтергә иде сина әлченне!

Палатада телевизор да бар. Азатның әтисе өеннән алып килеп куйган. Сәгать жиделәр тирәсендә «Эфир»ны кабыздык. «Перехват» программасыннан Ардуанны да күрсәттеләр. «Малай иртән мәктәпкә барганда бик ашыккан. Юлны чыкканда унга-сулга карамаган. Нәтиҗәдә машина астына эләккән», дип бирделәр. Нинди юл икән сон ул? Бернинди юл чыгасы юк иде бит ана? Шулай баш ватып утырганда палата ишеген шакыдылар. Урта яшьләрдәге бер ханым: «Бүген машина бәрдергән малайның ни хәле бар икән дип керүем иде»,—диде.—Безнең стройка янында булды бит ул хәл. Инвалидлар өчен төзелә торган йорт янында. Без шунда идек. Монда ирем янына килдем дә, тукта, минәйтәм, кереп чыгыйм әле. Атна кич шушы бүлнис дежурит итә бит. Аны да монда салган булырга тиешләр, минәйтәм».

—Нинди машина бәрдерде аны?

—Жигули. Ак төстә.

—Ничек бәрдерде сон?

—Без килгәндә шофер малайны күтәргән дә нишләтергә белми әрле-бирле йөренә иде. Ай-яй курыкты инде ул үзе дә. Аннары ГАИ килде, «скорый» килде.

—Нишләп юлга чыкты икән соң ул, шайтан малай?

—Тротуар пычрак бит. Үтеп булмый. Шуна күрә машина юлына чыгып, шуннан үтәләр.

Хатын килгәч, мин өйгә кайтып киттем. Кайтышлый, әлеге төзелешкә сугылдым. Төзелеш димәсән, хәтере калыр, анын коймасы да юк икән бит. Шуна бөтен урамны пычраткан инде ул. Кая анда тротуар?! Аны археологлар килеп казысалар да табарлык түгел. Бөтен тирә-як тездән саз. Монда машина юлына чыкмый хәлен юк. Тиздән ул юл да балчыкка күмеләчәк. Пычрак анын да уртасына кадәр жәелгән.

• • •

12 нче бүлнисsucc травмотология бүлегенә килеп керсән, бөтен кеше имгәнеп беткән икән, дип уйларсын. Палаталарны әйтмим дә инде, коридорда да буш урын юк. Авыруларга сәлам биреп, 7 нче палатага таба барыш. Бер абзый туктатты:

—Син улына әйт әле, нишләп операциядән курка ул. Әйт әле, курыкмасын. Менә мин ясаттым. Курыкмадым. Кулбашымның бер тамыры өзелгән булган. Дачада кар көрәгәндә катырак селтәнеп жибәргәнием. Әйт әле, әйт яме, операциядән курыкмасын. Теге Юан әйбәт ясый икән ул.

Бу абзыйны кайда күргәнем бар сон? Йөзе таныш. Бәй, төнәген без палатада урын бушаганын көтеп утырганда аны операциягә алып кереп киттеләр бит. Кан качкан иде анын йөзеннән. Ә бүген, күрәсезме, Берлинны алган кебек йөри. Операциягә алып кергәндә улымны ярты юлда боруларын үзенчә анлаган инде бу.

Мин дә ана табибларның кире уйлауларын әйтеп тормадым әле.

• • •

Төш вакыты житте. Ардуанга утырырга ярамый. Яткан килеш ашатасы. Ике кашык шулпаны матур гына шудырдым. Тик өченче кашыкның яртысы

авызына эләкмәде, иягеннән агып төшеп муенына китте. Улымның йөзе сытылды, иреннәре кысылды, күзләре дымланды. Башын стенага таба борды. Дүртенче кашыкны, күпме генә кыстасаң да, капмаячак иде инде.

Нервыланып яткан улыма күз күегә булмыйм әле дип, читкәрәк китеп утырдым. Азат белән Ярослав вак-вак шакмаклардан нәрсәдер төзеп әвәрә киләләр. Гаделнең әнисе кроссворд чишә. Улы ана баядан бирле нидер әйтмәкче:

—Әни, әни, дим...

—Комачаулама!..

—Әни, тыңлап тор инде. Бүген мин төштә әтине күрдем.

—Йә шуннан...

—Бүген әти килмәс микән?..

—Каян белим мин. Башымны катырма.

Ниязның исә эшләр хутта. Муенчагына гер асып, шуны башы-ияге белән күтәреп ятарга тиеш булган бу малай аркасын стенага терәгән, аякларын бөкләп куйган да рәхәтләнеп китап укый. Аңа карап-карап торам да уйлап куям: «Йа Хода, Нияз кебек тә укып була икән бу дөньяда китапны. Малайның күзен очландырып, йотылырдай булып утыруы—бер хәл. Әле сез аның авызыннан чыккан авазларны ишетсәгез: ах, уф, һай, хи-хи-хи-хи, ха-ха-ха, ой, ба-а-а, во... Ул әсәрнең геройлары белән утка керә, суга сикерә, карурманнар чыга, чүлләр кичә, борчыла, сөенә, яна, көя, сугыша, җиңелә, кабат сугыша, җиңә, үлә, терелә, тагын үлә, тагын терелә... Күр әле, малайның маңгаеннан тир бәреп чыкты, аркасыннан пар күтәрелгән кебек булды. Нияз китапны ябып күкрәгенә кысты да моңсу күзләрен бер ноктага төбәп уйга калды. Байтак шулай йомылып утыргач, ул торып үзенә ашарга хәзерләү хәстәренә керешә. Малай бүлнис ашларын ашамый икән. Ул аларны теге усал хатынга биреп бара. Ана өстенә кайнар су салгач өч минутта пешеп чыга торган вермишель булсын. Малай су кайнатып, ыгы-зыгы килеп йөргән арада сорап куйдым:

—Китап укырга яратасың, ахры?

—Бик яратам, үлеп яратам.

—Нәрсә яратасың соң? Юмормы, фантастикамы?

—Барысын да.

—Шигырьнедәме?

—Обожаю.

Туктале, минәйтәм, әдәбиятка мөкиббән бу малай үзе дә кулына каләм алып кәгазь тырнаштыргаламый микән?..

—Бәлки әле үзең дә шигырь язасыңдыр, шагыйрь Зөлфәт әйтмешли, «Такташ калыбына дыңгычлап».

Нияз беравык мина гаҗәпләнеп карап торды, аның бит алмалары кыңгыр эш өстендә тотылган малайныкыдай кызарып чыкты. Аннары яныма килеп, колакка пышылдады:

—Абый, сез минем шигырь язганны каян белдегез? Әйе, язгалаштыргалыйм мин. Кешегә генә күрсәтмим. Бер классташ кызга күрсәтеп караган идем, көлде генә.

Шулвакыт палатага буе уртачадан бераз калкурак булган, сызылып киткән кара кашлы, почык борынлы чибәр генә хатын килеп керде.

—О-о-о!.. Әни килде. Әнием!..—Нияз йөгереп килеп аны кочаклап алды.—Әнием! Әйдә әле, мин сине күтәрим әле.

—Кит әле моннан, кит! Кеше көлдермә. Так, син нишләп караватыңда түгел? Нишләп ятмыйсың?

Нияз тиз генә караватына сузылып ятты һәм керләнгән муенчагына гер асып үзен арканлап та куйды. Макарон онытылды. Әнисе киткәнче селкенәсе түгел, менә шулай кымшанмыйча, сабыр гына ятасы икән ана.

Күренеп тора: малай әнисе белән бер күрешеп сөйләшүне тансыклаган. Ул аннан әтисен, өй хәлләрен сораштыра. Тик әнисенең ачылырга әлләни исәбе юк. Әңгәмә ялганып китә алмый. Чибәр ханымның җаваплары бер-ике сүз белән чикләнә.

Нияз укыган китаплары турында сөйли башлагач җай табып әйтеп куйдым:

—Сезнең улыгыз да шигырьләр яза икән...

—Хи, шигырь тагын ана. Ул хәчтерүшкә.

Анын сүзләре Ниязның күңеленә төртеп алды, күрәсең.

—Алай димә, әни, язгалыйм мин,—диде ул һәм әнисенең сүзләренә аз гына хәтере калды булса кирәк, башын диварга таба борды.

—И хәчтерүш. Кайчан язганың бар? Хәер, бер күрсәткән иден шул. Тик рәте-чираты юк иде ул шигыреңнең.

Ул арада «кунагыбыз» китәргә дә җыена башлады. Нияз: «Китмә инде, әни. Аз гына утыр инде»,—дип ялваргач, тагын бераз юанырга булды. Малай гер асып көн буена ятарга да риза, тик әнисе генә янында булсын.

—Юк, улым, китим әле мин. Барасы җирләрем бар. Ә син торма, ят. Менә вермишельләрең.—Ханым барыбыз белән дә елмаеп хушлашты да җәт кенә чыгып та китте.

Ә бер-ике минуттан Нияз арканнан ычкынган бозау кебек коридорның бер башыннан икенче башына чаба иде инде.

• • •

Бүген төнлә бүлнистә Ардуанны саклаган хатыныма эшкә иртүк китәргә кирәк булып, мин улым янына иртәнге ашка ук барып җитәргә тиеш идем. ГИБДДга кереп-йөреп соңга калдым. Улымның мине көтә-көтә күзе күгәреп беткәндер инде. Ашыйсы-эчәсе килми микән? Кысталып ятмый микән? Шушы сораулар юл буена баш миен игәүләп барды. Йомышын кешегә әйтергә ояласян, читенсенәсен беләм бит инде.

Килсәм, Ардуан: «Мин ашадым инде, әти, чәй дә эчтем»,—дип ята. Күңеле дә үсә башлаганга охшаган.

—Кем ашатты соң сине?

—Гажилә апа.

Адәм баласына күп кирәкмени, теге усал хатын дигәнемнең улы Галелне ашатканда Ардуанга да өлеш чыгаруына күңелем булды. Ә мин, юләр, ана сырт кабартмакчы булып йөрим тагын.

• • •

Бүген Ардуанны апасы карый. Төнгә дә ул калачак. Мина килеп тормасам да була иде инде. Бала бит, эштән соң хәлен белеп кайтыйм, дидем. Көндез бүлнискә ГИБДДдан килгәннәр. Сорау алганнар. Ардуан: «Юлга чыкканда унга борылып карадым, сулга карамадым»,—дигән. Аның бу сүзләрен язып алганнар да апасыннан кул куйдырганнар. Шулай итеп, бөтен гаепне малайга чәпегәннәр. Югыйсә, мине капитан: «Сездән башка беркемнән берни дә сорамаячакбыз»,—дип ышандырган иде. Ярар инде, хәерлегә булсын. Улым исәнме? Исән!

Ә кичен өйгә кайткач телевизорны кабызсам экранда—Казан шәһәре эчке эшләр идарәсенең ГИБДД бүлеге башлыгы Ш.Юмаев. Турыдан-туры элемтә. Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, ди. Тиз генә телефон трубкасын алып «Эфир»ны җыям. «Иманлек урамында инвалидлар өчен йорт төзелә. Төзелешнең коймасы да юк. Шуңа күрә тирә-юне тездән пычрак. Янәшәдә ике мәктәп. Укырга баручы балалар машина юлына чыгып үтәргә мәҗбүр. Шушы көннәрдә монда 9 яшьлек бер малайны машина бәрдерде инде. Мондый фаҗига тагын кабатланмас дип кем ышандыра ала?!»

Хәлбуки, минем сорау эфирда яңгырамады.

* * *

Бүлнискә килеп керүгә улыма операциядән курыкмаска кушкан абзый каршы алды:

—Сине көтәләр анда. «Эфир»дан килделәр, «Эфир»дан! Улыңа әйт әле, операциядән курыкмасын!

Төнәген Юмаевка биргән сорау галәмәтедер инде бу. Малайны гына гаепле итеп калдырган телевидение дә үзенең хатасын төзәтергә җыена.

Ардуан интервью бирергә әзер. Урын-җире тәртиптә. Хатын иртүк эшкә киткән. Тагын Гаҗиләгә рәхмәт инде. Мендәрне кабартып, унайлап куйган. Хәтта тышлыгын да алмаштырган. Малайга өр-яңа футболкасын табып алып киерткән.

—Ничек булды бу хәл? Сөйлә, Ардуан!—хәбәрче кыз улыма юан микрофонын сузды.

—Юлга чыкканда унга карадым, сулга карамадым. Һәм мине машина бәрдерде.

И шайтан малай. Тагын шулай сөйләп тора бит. Юк, бу юлы «Эфир»га мондый җавап кирәкми.

Ниһаять, тырыша торгач Ардуаннан «Анда бик пычрак. Үтеп булмый» дигән сүзләрне әйттерә алдылар. Ә кичен чибәр Айгөл Мирзаянова «Город» программасын болай башлады: «9 яшьлек малай Казанның Имәнлек урамында инвалидлар өчен төзелә торган йорт яныннан үткәндә, шушы төзелеш аркасында үзе чүттән генә инвалид булмый калды...»

* * *

Вакыт дигәнең бүлнистә дә үтә тора. Аллага шөкер, улымның әрнүсызланулары басыла төште. Альбом, карандашлар соратып алды. Яткан килеш рәсем ясый. Малай кеше нәрсә ясасын инде—солдатлар да корабльләр. Нияз-Жаншет аның иҗатын читтән генә күзәтеп йөри. Үзе дә кулына каләм алып, нидер сызгаларга тотына. Шигырь яза икән. Берсен миңа да күрсәтте.

Әй, солдат, солдат,
Алып бир мина бер ат!

—Йә, ничек?..—малай күзләрен миңа төбәде.

—Рифмасы бар. Тик мәгънәсе юк. Сиңа каян, нинди ат алып бирсен соң ул солдат? Акчасы юк аның. Үзе дә ачлы-туклы.

Нияз килеште. Баш какты. Менә тагын Ардуанның альбомына күз салды.

—О-о-о. Титаник,—диде ул һәм, тумбочкасы янына утырып, тагын кәгазь-каләмгә ябышты.

Борыны очына тир бәреп чыкканда шигырь әзер иде инде:

Әй, «Титаник», «Титаник»,
Ерак бармыйк, тукталыйк...

—Монысында рифма да, мәгънә дә бар,—дидем мин малайның башыннан сыйпап.—Гүя, «Титаник»ның һәлакәткә дучар булачагын алдан сизәсең. Шуңа күрә кешеләрне кисәтәсең, уяу булырга чакырасың.

Шушы сүзләремнән соң малайның башы күккә тиде. Ул шигырен күтәреп коридорга очты. Аны тагын кемнәргәдер укытып кайтты бугай. Тик менә кире бүлмәгә кергәндә кәефе төшкән иде. Бактың исә, «операциядән курыкмый» торган абзый: «Иртә әле сиңа шигырь язарга. Шагыйрь булу

өчен башта йә университетта, йә академиядә укырга кирәк»,—дип малайның бөтен уй-хыялларын челпәрәмә китергән.

Кешегә шигырь язу сәләтен Ходай гына бирә, мин әйтәм. Нияз тагын яныма килә, күнелен үстерерлек, өметле сүзләр көтеп, күзләрен мина бага. Без анын белән коридорга, ишек катындагы буш кушеткага чыгып утырабыз.

—Нияз,—минәйтәм,—бәлки әле, Аллаһы Тәгалә үзе сина шагыйрь булырга кушкандыр. Хәтта псевдонимын бар. Жаншет. Бәлки әле киләчәктә зур сәхнәләрдә мондый сүзләр янгырар: «Сейчас прозвучат стихи великого татарского поэта Жаншета».

Шаяртып әйтәм, билгеле. Бернинди Жаншет, Манжетлар кирәкми. Нияз. Нинди матур исем бит инде!

Шагыйрь, зур сәхнәләр, дигәч Нияз үзе дә «О-о-о!..»—дип куйды.

—Беләсезме, абый,—малай күзләрен тутырып карады һәм сөйләргәме-сөйләмәскәме дигәндәй, пауза ясап торды,—без Горкида ундүртенче катта яшибез. Безнен тәрәзәдән Идел күренә. Ә Иделнен теге ягында биек тау. Мин жәйге эссе көннәрдә лоджийга чыгам да тауга карап торам. Шунда бер чишмә бар. Әйе, әйе, мин аны өй тәрәзәсеннән үк күрәм. Ышанасызмы? Их, шул чишмәнен суын бер эчәсе иде. Менә шулай, кеше күрми торган нәрсәләрне күрәм мин. Беләсезме, тагын нәрсә күргәнем бар минем? Минем әби: «Кеше ышанмаслыкны, чын булса да сөйләмә»,—ди. Сезгә генә сөйлим, абый.—Нияз тагын мина сынаулы караш ташлап беравык карап торды.—Безнен ишегалдында бер эт яшәде. Аягы гарип иде анын. Үзе шундый матур. Борыны кара, үзе дә кара, тәпиләре генә ак. Ак итек кигән кебек. Без ана оя ясадык. Өйдән ашарына ташып тордык. Мин әни бүлеп биргән ашны ашыйм, ә итен сиздерми генә кәгазьгә төрәм дә эткә алып чыгып бирәм. Ә беркөнне чыксам, ни күрим, этебез юлда кан эчендә ята. Машина таптап киткән. Үзе шабыр тир булган. Көч-хәл белән сулый. Күзләре ачык. Мин аны нишләтергә дә белмим. Бер-ике тапкыр тирән итеп сулады да кулымда үлде мескен. И жәлләдем дә инде. Мин шул вакыт анын гәүдәсе өстендә ниндидер томан кисәге эленеп торганын күрдем. Шушы этнен жаны булган бит ул, абый, име?!

—Булмас димә... Кеше жанын үлчәп тә карадылар түгелме сон инде...

—Кешенен жаны да күренәдер шул, име, абый. Шоферны әйтәм. Шул аксак этне нигә таптатырга инде. Машинасынын тормозлары бардыр бит. Юк,таптаткан да качкан. Жүнсез! Әле кичә генә бер китап укыдым. Бер утрау турында. Кечкенә генә бик матур утрау. Һәм менә шунда кешеләр дә бик матур яшиләр. Бер-берсеннән көлмиләр, бер-берсен обижать итмиләр, бер-берсенә матур сүзләр генә әйтәләр. Этләр, мәчеләр анда рәхәтләнеп йөри, кошлар да рәхәтләнеп оча. Утрауда закон бер генә: һәркөнне һәркем яхшылык эшләргә тиеш. Бездә дә шулай булсын иде. Их, минем дә шул утрауда яшисем килә.

«Ты, не дури!»—колак төбендә янгыраган һушынны алырлык, таш ярырлык тавыштан икебез дә сискәнеп киттек. Бактын исә, Ниязнын әтисе килгән икән. Ул да улы башына гер асып караватта ята дип уйлый бит инде. Ә Нияз бүген хәтта муенчагын да салып аткан. Тиз тапты аны тагын үзе. Жәһәт кенә киде дә герләрне асып та куйды. Әтисенен акыру-бакыруларын ул инде ятып тынлый иде. Дөрес, озак ятарга туры килмәде үзенә. Әтисен ай күрде, кояш алды. Ул арада төшке аш вакыты житте. Аштан сон Гажиләнен кырыс тавышы янгырады:

—Тихий час. Барыгызга да йокларга!

Минем сәгать дүрткә кадәр вакыт бар. Эшкә барып килергә кирәк. Баскычтан төшкәндә бер агай игътибарымны жәлеп итте. Дөресрәге, үзе түгел, кулындагы таягы. Күпме таяк күргән бар. Мондыйны күргән юк иде әле. Чәчәкле-чуклы таяк бу. Агай аны үзе ясаган. Һәр бизәген иренмичә юнып-чокып, күпме күз нурын түгеп утырган.

Тик сабы гына юанрак булган булуын. Бераз юкарткан тәкъдирдә кулга тагын да җайлырак булыр иде.

—Андый-мондый һөҗүм итә калсалар, саклану чарасы да бу, энем,—ди агай.

—Синә кем тисен инде, абзый.

—Алай димә—дөнья бу!.. И энекәш, 45 нче елны фронтка китеп бер фашистны да кыйный алмыйча кайттым мин. Үзем—десантник. Псков дивизиясендә хезмәт иттем. Йөз житмеш прыжок минем чутта. Өйрәнүләрдән баш чыкмады. Кая гына ыргытмадылар безне.

Урманга төшү бик хәтәр иде. Төнлә бит. Очлы чыршыга эләксәң шампурга киертелгән ит инде син. Күпмесе шулай харап булды. Фашист өстенә төш иден ул. Төш тә тукма иден үзләрен. Юк, без сугышка соң алынгач, өлгерә алмый калдык шул. Кул кычытып калды. Аның каравы, күрде безнең дә башлар. Сугыш беткәч тә, җиде ел хезмәт иттем әле.

* * *

Бүген кич өйгә кайтканда әлеге дә баягы инвалидлар өчен төзелә торган йорт янынннан үттем. Бәй, төзелешнең коймасы пәйда булган. Тротуарны да, юлны да чистартканнар. Балчыгын кырганнар. Кулдан килерлек эш икән, югыйсә. Шуның өчен бер гөнаһсыз малайны машина бәрдереп китүен көтеп ятарга кирәк булды микәнни! Шундый шул инде без: башка бәла килгәч кенә селкенә башлыйбыз.

Өйгә кайтып почта әрҗәсе ачсам, хат ята. Казан шәһәре эчке эшләр идарәсенен ГИБДД бүлеге начальнигы Юмаевтан. Хатны укыйм. «Җир казу эшләре кагыйдәләрен бозган өчен «Казанхимстрой»ның 2 нче төзү-монтаж идарәсе начальнигы И.Локмановка һәм «Гидроспецстрой» житәкчесе А.Муравьевка дәгъва белдерелде». Тагын укыйм. «Татарстан Республикасы Президентының «Шәһәрләрдә һәм башка торак пунктларында төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү турындагы Указының 11 маддәсен бозган өчен «Гидроспецстрой»ның участок начальнигы А.Соловьевка административ материал җибәрелде, шулай ук «Гидроспецстрой»ның баш инженеры В. Кругляк «наказать» (ничек «наказать» иткәннәр икән соң? Шелтә белдерелгәнме, штраф чәпегәннәрме, әллә бу—күзгә төтен җибәрү генәме?) ителде.

Бу төзелешнең нигә коймасы булмаганын аңладым хәзер. Нәчәлникләр күп. Түрәләр күп. Ә чын хуҗа кем соң монда? Син дә—мулла, мин дә—мулла, атка печән кем сала? Эзләп кара хәзер гаепле кешене. Эт—эткә, эт—койрыкка. Бездә шулай инде: чиновниклар күп, эшләүче юк. Ике хуҗага—бер ишәк.

Туктале, бу хат белән мавыгып китеп, онытып торам икән. Мин Гаделнең әтисенә шалтыратырга тиеш бит. «Әти, әти», дип өзгәләнә бит инде бичара малай, әнисен дә алҗытып бетерә. Көн туды исә, башында бер генә сорау: «Бүген әти килмәс микән?» Ай ярым вакыт узып киткән, әтисе ник бер күренсен. Малайны таптаткан шофер да бер күренгән дә юкка чыккан. Башка әтиләрнең уллары янына килеп йөрүен Гадел күрми дисезмени?! Аның да йөрәге өзгәләнми дисезмени?! Аптырагач Гажилә ханым менә шушы номерны бирде: «Бүлнистә телефон юк. Өйгә кайткач шалтырата алмассын микән. Әтисен әйтәм, бер килеп китсен иде инде». Каударлана-каударлана Гажилә язып биргән саннарны җыям. Трубканы, тавышына караганда өлкән яшьтә булса кирәк, бер карчык алды.

—Исәнмесез! Сезгә шалтыратуымның сәбәбе шул, минем улым белән оныгыгыз Гадел 12 нче бүлнистә бер палатада яталар. Жиденчедә.

—Сезгә нәрсә кирәк?

—Мин дөрес эләкмәдем, ахры,—үзем жыйган саннарны кабатладым.— Сезнең номерыгыз шушымы соң?

—Әйе.

—Сез Гаделнең дәү әнисе буласыздыр ич.

—Шуннан...

—Сезнең оныгыгыз бүлнистә ята. Аның әтисен күрәсе килә.

—Әнисе котыртып ятамы?! Бездә әнисенең бер әйберсе дә юк.

—Юк, ул сездән әйбер сорамый. Ул Гаделне әтисе белән күрештерергә генә тели.

—Молодой человек! Тагын бер тапкыр әйтәм, аның монда бер әйбере дә юк.

—Юк, ана бер әйбер дә кирәкми. Ул фәкать...

Сөйләшү шушы урында өзелде. Әңгәмәдәшем трубканы куйды.

Кәефем китте. Мин дә Гаделнең үзәге өзелгәнен күрмиммени?! Мин дә аның гажизләнеп авыр сулауларын, уфылдауларын ишетмиммени?! Минем дә аның әтисен бүлнискә, улы янына китертәсем килмимени?!

Аягым тартмый бүген бүлнискә. Килүгә Гажилә: «Шалтыраттыңмы?»— дип сораячак. «Әти киләме?»—дип Гадел дә монсу күзләрен миңа багачак. Ни дип жавап бирим соң? Ә мин барырга, төн буена улым янында булган кызымны алмаштырырга тиеш. Бүлниснең ишеге төбендә үк Нияз очрады. Чәтертән малай мине тәрәзәдән күргән дә, каршыма йөгереп чыккан. Житмәсә, ул да шул сорауны бирә:

—Гаделнең әтисенә шалтыраттыгызмы? Киләме? Килсә, мин сез палатага кереп житкәнче аннан сөенче алам.

Их, Нияз, Нияз! Синең дә Гаделне куандырасың киләдер шул инде. Күңелең һаман игелек эшләүдә. Ни дип әйтим соң? Айлар буена бүлниснең тынчу палатасында интегеп яткан Гаделнең һәм Гажилә ханымның күңелләрен жылытасы да килә. Шул ук вакытта аларны кысыр өмет белән яшәтүдән дә ни мәгънә?! Беравык аптырашта калып торганнан соң Ниязга турысын әйттем:

—Кистереп вәгъдә бирүче булмады шул...

—Ә сез номерны дөрес жыйдыгызмы?

—Дөрес жыйдым кебек.

Аһ, Нияз, Нияз! Ничек чыга белдең әле каршыма. Әйбәт сорау бирдең. Мин дөрес жыйсам да, Гажиләнең дөрес язып бирмәве ихтималмы? Ихтимал!

Палатага керә-керешкә Гажиләгә үзем сорау бирдем:

—Син, дустым, телефонны дөрес язып бирмәгәнсең, ахры?..

Әйе, шулай дигән булам, гәрчә үзем кәгазь кисәгендәге ул саннарның дөреслегенә һич кенә дә шикләнмим.

—Дөрес,—диде Гажилә ике дә уйламыйча һәм иреннәрен кысып тын гына торганнан соң сорап куйды.—Трупканы каенана алдымы?

Мин дәшмәдем.

—Аңлашылды.

• • •

Обход вакытында без коридордагы кушеткага чыгып утырдык. Бу юлы Гажилә белән.

—Нишләп сез көне-төне монда ятасыз,—диде Гажилә һәм нәрсәгәдер гажәпләнгәндәй күзләрен зур итеп ачып миңа төбәде.—Сез бит—эш кешесе. Ә минем беркая да барасым юк. Ардуанны үзем карармын.

—Әйтүең өчен рәхмәт. Сине күпме интектерергә була.

И Гажилә, Гажилә... Үзе дә тәмам туйгандыр инде бу бүлнистән. Без әле улымны хет чиратлашып карыйбыз. Әнисе, апасы, мин. Туганнар көн саен

диярлек хәлне белешеп тора. Авылдан әни килеп, оныгы янында бер тәүлек утырды. Улымны бәрдергән шофер да кереп йөри. Гажилә көне-төне берүзе. Анын да өенә кайтып, юынып, йомшак, иркен түшәктә ял итәсе киләдер бит инде. Сабыр, нык хатын икән. Улы белән җәфа чигүләре житмәгән, Ардуанны да үз канаты астына алмакчы була бит әле.

—Син үзен, Гажилә, өенә кайтып берәр көн ял итеп кил. Мондагысын без үзебез жайларбыз, көйләрбез.

—И-и-и кая кайтыйм сон мин... Киров урамындагы тугыз квадрат метрлы бер бүлмәдә торабыз инде без. Анысы да бер белгән хатынныкы. Йортны бүген-иртәгә сүтәргә тиешләр. Кешеләр яна фатирга күченә. Ә безгә юк инде. Прописка булмагач. Каенана үзләренә яздырмады. Дүрт бүлмәледә малае белән икесе генә яшәсәләр дә. Йортка килен булып төшкән көненнән үк фатирны бүлеп алырга килдең, дип үзәк бәгырьләремә үтте. Прописка турында авызымны да ачканым булмады, югыйсә. Ә улы—әнисе малае. Анын бер сүзеннән чыкмый. Авызына гына карап тора. Каенана белән бер елга якын этле-мәчеле яшәгәннән сон, имчәк баламны күтәреп чыгып киттем. Берни сорамадым. Әле ярый әнә шул бүлмәсен биреп торган иптәш хатын булышты. Горшокка кадәр алып бирде. Әтисе баштарак килгәләп йөрде. Хәзер эзе суынды. Гаделне машина таптаганын белгәч, бөтенләй югалды. Үзем эшләп торганда очын-очка ялгап бара идек әле. Пароховойда эшләдем. Кыскарттылар. Цехыбыз белән киттек. Базарга чыгарга мәжбүр булдым. Кульяулыктыр, оектыр-черттыр сатып тордым. Ялланып инде. Көнгә 30 сум бирәләр. Ярап тора иде әле үзе. Бу чурт побери малай болай булып куйды да, менә хәзер анысы да юк инде. Пароховойда хет больничный барыр иде.

Ярый әле авылда энекәш бар. Берүзе яши. Әти-әни—мәрхүмнәр. Шул энекәш сыер, сарыклар асрый. Тавык-чебеше дә байтак. Ел буена безне иттән өзми. Бәрәнге дә шуннан. Эремчеккә кадәр ясый. Өйләндерәсе иде үзен. Пеләшләнеп бетте инде, башында ике бөртек чәче калды. Ә менә башлы-күзле булу турында уйламый да. Хәер, кемгә өйләнсен сон ул?! Һәр ике өйнен берсендә буйдак. Безнең авылда гына да утызны узган утыз ир-ат бар ди. Бер көнне авыл советы персидәтеле егерме тугызны санаган. «Утыз, дигәннәр иде, берсе кайда сон?»—дип баш кашый икән. Баксан, үзен санамаган.

Кызларны әйтәм, берсе дә авылга чыгарга атлыгып тормый. Хәер, чыгып нишләсен сон ул анда?! Ни эше, ни акчасы. Колхозның сарыклары бетте. Сыерлары кысыр. Алары да бетүгә таба бугай. Пред кирәк-яракка дигән булып машинасына сала да чыгып китә, сала да чыгып китә ди. Сыер алып киткәндә рульгә үзе утыра. Сыерсыз киткәндә шоферын ала. Үзен мал асрамасан, колхозныкын көтеп ятсан, ачка үләсен. Үлүен үлмәссен анысы, һич югы бәрәнге ашап та торырга була. Тормыш булгач өс-башы да кирәк бит. Ә колхоз акчаны елга ике генә бирә. Сабантуйга—100 сум, көзен День колхозникага—300 сум. Халык яши үзе. Ә минем авылга һич кенә дә күнелем тартмый. Жаным бизеп, гайрәтем чигеп киттем аннан. Өч ел әтине карадык. Каты авырды. Авыруы—теге «өч хәреф» инде. Ул үлә дип торганда, әни үлеп китте. Йөрәк белән. Әнидән сон да әти ел ярым ятты әле. Өйләребез, каралты-кура да бик начар калды. Энекәш сипләтергә дип йөри йөрүен. Әлеге дә баягы шул акчасы юк инде.

Бу арада энекәш тә килә алмый. Бүген-иртәгә чәчүгә чыгарга торалар. Ярар, эшләсеннәр, салып кына йөрмәсеннәр. Сонгы вакытта чирткәли башлады. Эчсә дә малларны карый үзе. Хи-и-и, кем эчми сон анда? Тик менә теләсә нәрсә эчәләр. Шунысы куркыта. Агуланып үлүчеләр дә булды инде.

* * *

Көннәрдән беркөнне палатабызның ишеге (ул көн буена ачык) төбенә, коридорга бер караватт куеп, кырык-кырык биш яшьләр чамасындарак бер хатынны салдылар. Аның ун кулын бинт белән урый-урый тәпәч иткәннәр. Нияз вермишель өчен суга чыгып кергән иде. Белеп кергән: бу хатын кулын эшендә станокка кыстырган икән.

И бу тормыш... Балалар, оныклар кочарга, аларның чәч-башларыннан сыпырып торырга яратылган нәфис куллар станок рычагларына ябышырга, кувалдалар тотарга, шпаллар күтәрергә мәҗбүр.

Ә менә бу яшь хатын монда ничек килеп эләккән. Палатасында ятмый. Коридор буйлап әле бер башка, әле икенче башка тыз-быз йөреп тора. Чибәр, каһәр. Сызылып киткән нечкә каш, күккә чөелгән почык борын, янып торган күзләр. Озын-куе керфекләре, гүя, күзләрдәге әнә шул очкын-ялкынны читкә-миткә әлләни чәчрәтмичә саклар өчен яратылган. Күр әле син аны, күкрәген киереп, артларын уйнатып кәс-кәс атлап ни фурмылый йөри бит.

Чибәркәй—Утлыкүз беркем белән дә сөйләшми, аралашмый. Үзенә сүз катсалар да, колак артыннан шудырып җибәрә. Аның турында беркем берни белми. Төп-төзек бу хатынның травматология бүлегендә йөрүе беренче карашка гаҗәп тә. Кыйнаганнар икән, тәнендә «ушиб» икән, дигән имеш-мимешләр бар барын. Шайтан белсен. Ара-тирә йөзен сытып бөер турыларын сыйпаштыргалап ала ул үзе.

Хикмәти Хода, бүлнисснең һавасын, мохитен үзгәртеп җибәрде бит әле бу Утлыкүз. Яралары төзәлә, хәле азмы-күпме арулана баручыларның һәм, әлбәттә, авыру карап утыручы ир-атның тынычлыгын алды. Ыңгырашулар, «ах-вах» килүләр кимеде. Хәзер ир-егетләрнең аягына баса алганы коридорга чыгарга тырыша. Утлыкүз бер болайга үтә, бер тегеләйгә. Палатасына да керсә, шул «тихий час»та гына керә. Үзенә төбәлгән күз-карашлардан ләва, ләззәт ала бугай ул. Әйдә йөрсенсәнә. Ана карап мөкиббән киткән ир-ат халкына да сүз әйтмәгез. Матурлыкка карап сокланунын ни гаебе бар?! Кайбер авыруларга әрнү-сызлануларын оныттырып тору өчен бүлнисләрдә махсус чибәркәйләр штаты булдырсаң да ярар иде әле ул. Үлем-китем дә кимер иде. Әнә Казаннан фронтовик, журналист Нәгыйм Мөхибуллинның сөйләгәне бар. Госпитальдә үлем түшәгендә ята икән. Беркөнне ул бөтенләй начарлана. Ә монда тәртип шундый: өзелер алдыннан шәфкать туташлары авыруны ваннага алып кереп юалар. Нәгыйм агага да чират җитә. Аны алып чыгып киткәндә палатадашлары: «Татарину пора к Мухаммеду»,—дип калалар. «Бер мәлне күземне ачсам,—ди фронтовик,—каршымда күкрәкләре ачык, чибәр кыз тирләп-пешеп мине юа. Аның ялтырап торган туп-тулы ике «алма»сына, җилкәсенә агып төшкән сары чәчләренә, зәңгәр күзләренә карыйм. Үләсе килми генә бит. Юк, үлмәдем. Менә ярты гасырдан артык вакыт узды инде. Әле һаман яшим».

* * *

Соңгы бер-ике көндә коридорда тыз-быз йөрүчеләр күбәеп китте. Барысы да—типсә-тимер өзәрдәй егетләр. Һәркайсы бүлнис киеменнән. Нинди җилләр ташлаган соң аларны монда? Монда бәла-казага дучар булып имгәнгән өтек-сөтек кешеләрне генә салалар түгелме соң? Көчен кая куярга белмәгән бу егетләрнең монда ятуы һәрхәлдә, сәер, бик сәер. Теге «операцияне ошаткан» абзый аларга «диагнозны» бик тиз куйды. Армиядән качып, чирлегә сабышып керәләр алар монда, диде ул ике дә уйламыйча.

Гөнаһысына кермим, кемдә нинди чир булмас. Тик менә аларның монарчы тыныч кына, иплә генә барган бүлнис тормышында бер кирәкмәгәнгә ыгы-

зыгы тудырып, үз хәлен үзе генә белгән, әрнү-газапларга тешен кысып, сабыр булырга тырышып яткан авыруларның саруын кайнатып йөрүләре генә ошамый. Коридор буйлап урык-сурык йөрүләренә дә түзәр идең әле. Аш өләшкәндә чиратсыз керәләр бит. Кулсыз, аяксызлар алдына керәләр. Әстәгъфирулла. Сары ыштанлы, камыл кебек каты чәчлесе бигрәк оятсыз.

Шунысы беркөнне теге десантник абзыйга болай дип әйтеп тора:

—Синең урының, старый, зиратта инде. Хет үзенә кабер урыны алып куйдыңмы соң әле?

—Зираттан урынны күптән алып куйган идем инде мин, энем. Тик менә синең кебек ябь-яшь егетләр мина анда да «мишайт итәләр». Урынны алып куюым гына була, алар минем урынга керәләр дә яталар, керәләр дә яталар.

...Бүлнистә режим шундый: кичке уннан соң коридорда да, палаталарда да ут сүндерелә. Йокларга! Ай ошамый да инде мондый тәртип теге әзмәверләргә. Яшь кан. Жегәр бар. Эш юк. Энергияне кая куярга белмиләр. Хәер, режим сиңа ошыймы-ошамыймы, килешергә мәжбүрсең. Бүлнис бу. Шәфкать туташларының бер-ике тапкыр кырыс кисәтүеннән соң тегеләр ятарга мәжбүр.

Бүген дә «отбой»дан соң тынлык урнашты. Тынлык дип инде монда авыруларның ыңгырашулары, әрнүле-газаплы авазлары, «ай-вай»лар, «ах-ух»лар беркайчан да тынып тормый. Минем ятар урын юк. Коридорга, палата ишеге төбендәге кушеткага, чыгып утырдым. Кушетка бүген буш. Кайбер төннәрне анысы да эләкми. Аякларны бөкләп чүмәштем. Өстемә пәлтәмне япкан сыман иттем. Йомышы төшсә, Ардуан үзе дәшә. Мин көн буена эштә бит. Арылган, күрәсең. Чүт кенә авышып, башны төрткән идем—йоклап киткәнмен.

Күпме черем иткәнмендер. Уяндым. Мин генә түгел, бөтенесе уянды. Кемдер бүлнисне яңгыратып укшый-коса. Күрше палатада ятучы бер абзый икән. Интегеп, газапланып укшый. Нинди генә тавышлар чыкмый үзеннән. Кизү торучы табиб, шәфкать туташлары чатыр чаба. Аларның ашыгу-кабалануларына, бер-берсенә өзек-өтек жөмләләр белән, кызу-кызу дәшүләренә караганда, авыруның хәле шәптән түгел. Коридорның теге башында торган каталканы да жәһәт кенә алып килделәр. Абзыйны шуңа салып жәһәт кенә алып чыгып та киттеләр. Кая? Нәрсәгә? Абзыйга ни булган? Бераздан, колактан-колакка күчеп, бөтен палаталарны, коридорны бер сүз кисеп үтте: йөрәк!..

Йокы качты. Барыбызның да уенда әлеге абзый. Үз палатасына исән-имин әйләнеп кайта алырмы ул? Ни дисәң дә йөрәк уен-муен түгел.

Теге сөрхәнтәйләргә генә йөрәк ни дә, өрәк ни. Әлеге ыгы-зыгы аларга ошады гына. Көндез йокларга, төнлә йөрергә күнеккәннәр, күрәсең. Тартырга гына ничә тапкыр чыгып керделәр. Ат азгыны тайга ияргән, ди. Утлыкүз дә алардан калмый.

Ярты сәгать чамасы узгач күпне күргән каталка коридорда тагын пәйда булды. Шөкер Ходайга, абзый исән. Үзен палатасына алып кереп салдылар. Шәфкать туташының аңа әйткән: «Борчылмагыз. Тыныч кына ятыгыз. Йокларга тырышып карагыз»,—дигән сүзләре ишетелде.

Утлар тагын сүндерелде. Медсестраның «Марш караватларыгызга!»—дип бер-ике тапкыр кистереп әйтүеннән соң, тегеләр дә барып яттылар.

Тагын тынлык. М.Мәһдиев әйтмешли, йоклагыз, адәм балалары! Авырулар, сезгә йокы бик кирәк. Табиблар, шәфкать туташлары! Кешене үлем тырнагыннан алып калдыгыз. Афәрин! Инде сезгә дә ял итеп алырга ярыйдыр. Иртәгә дә көн буена эшлисегез бар.

Бүлнис тынды. «Мес-мес», «пуф-пуф», «гыр-гыр»лар гына ишетелә.

Чү!

Үзәк өзгеч тавыш. Шул ук палатада. Теге абзый жан ачысы белән кычкыра. Шәфкать туташлары бүлмәләреннән торпедо кебек атылып чыктылар. Чыктылар да теге абзый янына чаптылар. Чапкан шәпкә бер очтан теге каталканы да эләктерделәр.

Тагын ыгы-зыгы.

Тагын мәхшәр...

Тагын теге егетләргә лафа. Тычканга үлем, мәчегә көлке кебегрәк инде.

Үле-мәле палатага килеп керсәләр... бая гына әжәл белән якалашкан абзыебыз гырлап йоклап ята.

Кычкыручы—бөтенләй икенче кеше! Яше утызлар тирәсендә булган бер ир. Торып утырган. Күзләре—маңгайда. Маңгае—шабыр тир.

—Ни булды?—дип сорыйлар аннан.

Дәшми.

—Ник кычкырдыгыз?

—Ай... Уф-ф-ф... Төш күрдем. Куркыныч төш.

И Аллам!.. Ходай сабырлык бирсен сезгә, табиблар, табибәләр, шәфкать туташлары!

• • •

Бүген бүлнискә кереп барганда бер егет эндәште:

—Сез травмотология бүлегенә түгелме?

—Әйе, нәкъ үзенә.

—Жиденче палатадан Миңлебаева Гажиләне чакыра алмассыз микән? Мине халатсыз кертмиләр.

—Тек, мин шул палатага керәм! Гажиләне? Әйтермен, әйтермен.

«Бәй, Гаделнең әтисе килгән түгелме соң?—дип уйлыйм баскычтан менгәндә,—Гажиләнең энесе түгелдер инде. Аны пеләш диде бит апасы. Тәгаен, Гаделнең әтисе бу. Кичә Гажилә: «Тагын бер шалтыратып кара инде»,—дигәч, өйгә кайтуга чыктым. Трупканы тагын кайнана алды. Бу юлы да сөйләшү ялан кул белән билчән йолыккан кебегрәк булды. Кайнананың үз туксаны туксан, һаман бер сүзне тукый: «Аның монда бер әйбере дә юк». Шулай да сөйләшү юкка булмаган. Менә малаен жибәргән бит. Алай ук имансыз түгел икән әле.

—Гажилә, синең ирең килгән, ахрысы. Аста көтә,—дидем палатага керәкерешкә.

Гажилә минем халатны эләктерде дә чыгып чапты. Ах бу Гаделне. Әрекмән колак. Минем сүзләрне ул да ишетеп алган. Аның «Ур-р-р-а! Әти килде. Әти!» дигән сүзләре палатаны гына түгел, бөтен бүлнисне яңгыраткандыр. Малай сөенечennән нишләргә дә белмәде. Ул шулкадәр шатланды ки, айлар буена хәрәкәтсез яткан, караватбашына тарттырып куелган аягы тышауларны ычкындырып-жимереп атты.

«Сөен әйдә, сөен, сабый. Мондый бәхет тансык сиңа»,—дип уйлыйм эчтән генә. Гаделнең сөенгәнен күргәч, үзебезнең дә күңелләр ереде. Баланы кызганудан гына түгел, аның шатланганын күрүдән дә күзгә яшьләр килә икән. Кеп-кечкенәдән михнәт-сынауларга дучар ителгән бер гөнаһсыз бала бит ул.

Ул арада Гажилә дә менеп житте.

Чү...

Аның сытылган чыраен, уйга баткан күзләрен күреп, аптырашта калдык. Халатның да кирәге чыкмаган.

—Ни булган, Гажилә?

—Миңа срочно китәргә кирәк. Авылга. Энекәш авыр хәлдә. Гаделгә күз-

колак булып торыгыз инде.

—Гадел өчен борчылма. Карарбыз!

Әнисе китүгә, моңарчы сабыр-тыныч яткан Гадел безне утлы табага бастырды. Анын: «Аягым, аягым. Авырта. Үләм»,—дип кычкырулары йөрәккә кадалды. Табибларны чакырдык. Алар нишләтеп кенә карамадылар ул аякны. Бушаттылар, тарттырдылар. Тагын бушатып, тагын тарттырдылар. Аптырагач, укол кадамакчы булдылар. Гадел кадаттырмады, теше-тырнагы белән каршы торды.

Ак халатлы абыйлар, апалар!

Юкка мәшәкатьләнәсез бит сез. Авыртмый анын аягы. Чәрдәкләнгән булса да, сынык булса да авыртмый. Күнеле сынык анын. Күнеле әрнегәнгә түзә алмыйча елый ул. Күнелен сындырганнарга нәфрәтен белдерә.

Мине дә гафу ит, Гадел. Әтиең килгән дип ышандым бит. Чын күнелемнән ышандым. Ышанасым килде.

Гажилә дүртенче көнне кичкә генә килеп житте. Арган, алжыган, тартылган. Күз кабаклары кызарган, шешенгән.

—Энекәшне жирләп килдем.

Күнелебез алдан сизенсә дә, таштай катып калдык.

* * *

Бүлнис һавасыннан, бүлнис мохитеннән тәмам туеп, эч пошып йөргән көннәребезнең берсендә Нияз палатага тычкан артыннан чапкан мәче кебек атылып килеп керде:

—Чыгыгыз әле, чыгыгыз тизрәк, бер нәрсә күрсәтәм,—малай һәмәй кошы тотканмыни, борын тишекләре киңәйгән, зур, якты күзләре акайган.

Бүлниснең дүрт яктагы дүрт салкын диварыннан гайре әйбер күрмәгән халкын Ниязның тәкъдиме ымсындырып, алгысытып куйды. Дәррәү кузгалдык. Бу бәхеттән мәхрүм булган Гадел белән Ардуан артыбыздан каерыла-каерыла, тилмереп карап калдылар.

Күнеле ярсулы ашкыну, жилкенү белән тулган Нияз күрше палатадагыларны да куптарды. Барыбыз да Жаншетка иярдек. Теге әзмәверләр дә иярде. Малай вәгъдә иткән кызыктан алар каламыни. Десантник абзый гына калды, чөнки таягын икенче каттан кемгәдер күрсәтергә алып торганнар.

Белмим инде, бүлнис бит бу, шулай шаккатырлык нинди хикмәт булырга мөмкин икән монда?

Нияз безне коридорнын теге башына ук алып китте. Син, шайтан малай, туп-туры операция залына алып барасың түгелме соң?! Шөкер, анда кермәдек. Малай барыбызны да баскычка алып чыкты. Монда урам як дивар тоташ пыяладан гына тора. Бөтен жирдә—кояш. Нияз безне әнә шул урамга караган пыяла дивар каршына тезеп куйды.

—Карагыз әле урамга. Урамга карагыз!

—Карыйбыз. Йә шуннан?..

—Күрмисезмени?!

Бик матур көн. Күк чат аяз... Өйләр, бакчалар, агачлар, коймалар, койма баганасы башындагы жирән мәче апрельнең юмарт кояшы жылысына талып, яз жырын, жир жырын тыңлыйлар.

Кемдер Нияздан сорап куйды:

—Багана башындагы теге мәчене күрсәтмәкче буласың мәллә? Эт-мәчене күргән бар ла.

—Әйбәтләп карагыз!

Бер әби мәтәлә-кадала каядыр чаба. Аны күрсәтергә алып чыкмады бит инде безне Нияз, чөнки ул кортка әле генә пәйда булды. Әнисе янәшәсендә бер сабый бара. Әле яна тәпи йөри башлаган, күрәсен, тырышып, хасиятләнеп

атлый. Өстендә—алагаем калын комбинезон. Нәкъ космонавт инде. Чү, күз тидердек бугай үзенә—егылды. Егылгач, кулларын як-якка шундый матур итеп җәеп ятты ки, гүя, Җир шарын кочаклап ятамыни. И сабый. Тик Ниязнын нәни «космонавтка» да исе китмәде.

—Нужәли күрмисез?

—Юк, күрмибез.

—Үлән чыккан бит. Үлән! Күрмисезмени?!

—Ниткән үлән күрәсең син анда. Койма буйларында әле кар эреп бетмәгән.

Кызык-тамаша карарга дип өметләнеп чыккан халык Ниязны әттән алып эткә салды. Теге хөрәсәннәр аеруча тузынды.

Зур күзләрен тутырып урамга баккан Нияз баскычта берүзе басып калды.

• • •

Бүген Гаделне чыгаралар. Кичә анын аягын «чылбырдан ычкындырдылар». Ычкындырдылар да «таш капчыкка ябып куйдылар». Гипсладылар. Ай—ай ярымнан гипсын алдырырга тагын киләчәк.

Их, менә ул—бәхет. Хәзер унга-сулга борылып ятарга була. Утырып торырга, бер аякта басып торырга була. Хәер, басып торырга иртәрәктер әле—башы әйләнә.

Бәхетнен ин зурысы исә—Гадел бүген өенә кайтачак. Пропискасы булмаса да, Киров урамындагы тугыз квадрат метрлы бүлмә анын өчен барыбер өй бит инде.

Табиб белешмәләре, кирәкле кәгазь-мәгазьләр әзер. Урын-җир тапшырылган. Нияз коридорның теге башында торган колясканы палатага ук алып кереп куйды. Гаделне шуна утыртып алып чыгачакбыз. Тик менә машина гына никтер килеп житә алмый. Шофер уникегә килеп житәргә вәгъдә биргән иде. Сәгать икенче китте бит инде. Төенчек өстендә көтеп утырабыз. Безнен көтеп утыру нәрсә ул? Гадел нишләргә белми. Ике айга якын сабыр гына яткан малайның бу минутларда тәкате тәмам төкәнде. Безгә минут саен урамга карарга куша. И Гадел, Гадел, язмыш бүлнистән чыкканда да сыный бит сине. Хәерлегә булсын!

Машинаны урамга чыгып тотудан башка чара юк.

—Утыз сумга алып кайтырлар бит инде, име,—диде Гажилә.

—Акчасы өчен борчылма. Җайларбыз.—Өстемә куртканы элдем дә урамга чаптым.

Машинаны бүлнис тирәсеннән эзләү—файдасыз. Монда барысынын да үз кайгысы. Соцгородтан шәһәр үзәгенә бара торган олы юлга чыктым. Көньяк кешесенә охшаган кара-чутыр бер адәм туктады.

—Рубь,—ди.

Безнеңчә 100 сум була инде. Күп сорый, билгеле. Гажилә кебекләр бу акчаны алыр өчен иртәдән кичкә кадәр базарда өч көн басып торырга мәҗбүр. Йөз сумына да риза булыр идең анын, бүлнистән аягы имгәнгән бер малайны алып чыгарга кирәклеген белгәч, шофер бәяне тагын да күтәрде.

—Сабыйнын бәлагә дучар булуыннан акча эшләмиләр. Хәерле юл!

Икенче машинаны туктатам. Шоферы гади генә егеткә охшаган. Авылдан-мазардан түгел микән. Хәлне анлатам.

—Күпме сорыйсын?

—Күпме, дип инде, абый... Бер тиен дә алмыйм. Барыбер шул якка барам иң инде мин. Күптән түгел генә үземнен малай кулын сындырып шул бүлнистә ятып чыкты. Урамда бер малай белән басып торалар икән, күрше йорттан мужик чыккан да, боларны сугышырга котырткан. Олы тиле. Ә теге малай минекеннән ике яшькә зуррак.

Бүлнискә килсәк, машинаны урамга ук чыгып көтеп торалар иде инде.

Гаделне озатырга бөтен палата чыккан (Ардуан гына чыгалмый). Әнә бер төркем булып килəлəр. Иң алда, Гадел утырган колясканы этеп, Нияз бара.

Машинага Гаҗилə сөенде. Иң сөенгəне, əлбəттə, Гадел иде. Алар машина чаттан борылып күздəн югалганчы безгə кул болгап бардылар.

Хуш, Гадел!

Хуш, Гаҗилə!

Язмыш!.. Гаҗилəне дə əнə гел сынап кына тора. Улының аягы белəн нилəр булып бетəсен дə Алла гына белəдер. Гарип кала күрмəсен иде инде, бичаракай.

Түз, Гаҗилə.

Сиңа тормышның карасын-пычрагын байтак күрергə туры килгəн. Пычрак дигəннəн, минем əти колхозда инженер-механик иде. Эштəн кайтканда кулы еш кына мазутка-майга баткан була. Ул нишли, кулын ишегалдындагы балчык белəн ышкый. Бүген безнең дə тормышның шул карасында, дөньяның шул пычрагында күңеллəребезне юасы, җаннарыбызны чайкыйсы бар!

* * *

Нишлəп əле бу Нияз коридор буйлап чатыр чабып йөрүлəрен туктатты, нишлəп əле əбилəр яткан уң яктагы палата ишеге төбендə генə чуала башлады, дисəм, əһə, хикмəте бар икəн. Без бүлнис—эш, бүлнис—өй арасында матавыкланып йөргəндə бер əбине чыгарганнар да аның урынына җидесигез яшьлəр тирəсендəге бер кызны салганнар. Гипсланган кулын муенына аскан, түп-түгəрəк йөзле, бөдрəлəнеп торган көрəнсу-саргылт чəчле бу кыз баштарак əллəни күзгə-башка чалынмады. Әллə инде палатадагы эчпошыргыч бертөрлелек туйдыра башлады, əллə инде Ниязның алар ишеге төбендə еш пəйда булуы ымсындырып куйды үзен, соңгы вакытта Бөдрəчəч коридорга чыккалый башлады. Үткəн-сүткəндə безнең палатага күз салып үтə. Нияз хəзер вермишель пешергəндə ишекне ябып тора. Шулай читтəн генə күзəтепөйрəнеп йөри торгач, көннəрдəн беркөнне бу Бөдрəчəч малайлар палатасына якынрак килеп карап торды. Иртəгесен йөрəксенеп ишек яңагына ук терəлеп баскан иде. Күзе күбрəк Ниязда. Күренеп тора, үзе ояла, ятсына-читенсенə. Нияз да сер бирми, кызга игътибар итмəгəн була. Йə китап укый шунда, йə нишли. Үзе, безгə бик сиздермəскə тырышып, ара-тирə ишек ягына күз салып ала. Карашлары очрашканда икесе дə кызарып чыгалар. Бер-ике көн кызарып йөри торгач, Нияз миннəн читенсенеп кенə сорап куйды: «Кудрявый татарча ничек була ул?» Минем җавапны ишеткəч, малай уйга калды. «Әһə, дип уйлап куям эчтəн генə, өр-яңа шигырь туарга тора түгелме соң?»

Малайлар үзлəре генə калгач, ниһаять, Бөдрəчəч кунакка кергəн. Мине күргəч, Нияз караваты янындагы урындыктан җəлт кенə сикереп торды ул. «Утыр, утыр,—минəйтəм,—хəзер чыгып китəм, врачлар бүлмəсенə барып килəсем бар»,—дигəн булам. Кыз кыяр-кыймас кына утырды. Икесенең дə кулында—китаплар. Нияз укыган əсəрлəреннəн алган тəэсирлəре белəн уртаклашкан күрəсең. Минем алда алар песилəр турында сөйлəшə башладылар. Пакеттагы əйберлəрне бушаткан арада колакка чалынып киткəн саран җөмлəлəреннəн шуны искəрдем, малай да, кыз да песилəрне үлеп яраталар. Тик икесенең дə өйлəрендə песи тотарга рөхсəт юк. Бөдрəчəч—аның исеме Элина икəн—əбисенең өендəге мəче турында сөйли. Бу песи шулкадəр матур, йомшак, акыллы икəн ки, аның турында сөйлəгəндə Элина, үзе дə сизмəстəн, кабынып, хислəнеп-дəртлəнеп китте.

Мин дə палатадан чыгып югалып торырга өлгерə алмадым, мəче турындагы əңгəмə дə кырт өзелде. Палатага атылып-бəрелеп Элинаның əнисе килеп керде:

—Кем кушты сиңа монда керергə?! Әллə ниткəн хулиган малайлар янына

кереп йөрисен. Марш бүлмәнә!—ачуыннан шартлардай булган хатын күзен чайпалдырып Ниязга карап куйды һәм Элинаны жилтерәтеп алып чыгып та китте.

Палатаны авыр тынлык басты.

Шигырь тумас борын үлде.

• • •

Палатада Ардуан белән Нияз икесе генә калдылар. Азат белән Алеша да сөякләрне урынына урнаштырып-тазартып өйләренә кайтып киттеләр.

Улым аягына баса башлады. Тик менә ара-тирә башы чатнап, күз аллары карангыланып китә аның. Хәзер үзен көне-төне саклап ятмыйбыз. Көнгә шул бер тапкыр хәлен белеп китәбез инде. Рәхмәт Ниязга, без югында Ардуанга тегене-моны алып килеп бирәсе булса, булышкалап тора. Мәшһүр артист Равил Шәрәфиев тә монда дәваланып ятучы апасы янына килгәндә, бу палатага сугылып, малайларның хәлләрен белешеп чыккалый. И, ул көннәрдә малайларның сөенешкәнен күрсәгез! Ике малай бер палатада матур гына яшәп яталар. Ардуан рәсем ясый. Нияз йотылып китап укый, әз-мәз кәгазь тырмаштыргалый, бөтен шартын китереп, хасиятләп вермишель пешерә. Мин килсәм, янымнан китми. Сөйләшеп утырырга ярата.

—Нияз,—минәйтәм,—«умыртка сөягеннән беренчесе, икенчесе, дүртенчесе хөрест», дисең, өченчесе ничек «хөрест» булмаган соң аның?

—Белмим,—Нияз жилкәләрен куырып, башын чайкап ала. Башын чайкаганда чырае сытылып китүен искәрдем. Чана шуганда ясаган «сальто» үзен һаман сиздерә әле, күрәсең. Шагыйрь әйтмешли, әрни әле, әрни ул яра.

—Бу муенчагыңны юарга кирәк инде.

—Юган идем мин аны. Кичә тагын пычранды. Елаганда күзне сөрттем мин аның белән.

—Елаганда?! Нигә еладың соң әле син?

—Юк, еламадым.

—Елагансың, яшермә. Кем дә булса кыерсытты мәллә үзеңне?

—Юк, үземнең елыйсы килде.

—Нияз, әйт дөресен!..

—Нәрсә, мина бер генә тапкыр еларга ярамый мәллә. Мин дә кеше бит. Тик торганда тоттым да еладым.

...Малайлар янында озак утырдым. Кичкырын гына киттем бүльнистән. Ардуан белән Ниязның мине һич кенә дә жибәрәселәре килмәде.

Кайтканда уйлап куйдым: нигә жибәрәселәре килмәде икән соң? Нигә алар бүген боек, кәефсез иде? Нияз нигә елады икән?

Нигә?

• • •

Самолет төзүчеләр шәһәрчеген узып, бүлнискә кереп барам. Күк тулы, кала тулы, жир тулы кояш. Кояш бер бинадан икенчесенә тыз-быз чабып йөрүче бүлнис персоналының ак халатларында, кулларында, эмаль чәйнек, чиләк, кәстрүлләрендә. Абау... Хәтта морг тәрәзәсендә, морг диварларында да кояш. Мондый көндә аягына басарлык хәле булган кеше тынчу палатада ятамы?! Күбесе—ишегалдында. Станокка кулын кыстырган теге хатын да чыккан. Ул кулын нишләтергә белми, селкеп карый, күкрәгенә куеп торып карый. Тукта әле, мина таба килә, миңа дәшә түгелме ул:

—Сез жиденче палатада яткан малайның әтисе бит.

—Әйе,—үзем хатынның яралы кулына карыйм, ул бинт белән чорный-

чорный утын пүләне хәтле булса да, кан барыбер тибеп чыккан,—әйе, Ардуан атлысының әтисе булам.

—Беләсезме, нәрсә? Аларны кичә кыйнадылар.

—Кыйнадылар?! Ничек инде кыйнадылар?..

—Әйе, кыйнадылар.

Мин берни анламыйм. Кайда диген—бүлнистә, кемне диген—бәлагә дучар булып имгәнгән ярты-йорты балаларны кыйнап буламы?

—Кемнәр кыйнады?

—Күрше палатада яшь егетләр ята. Шулар.

Әһә, аңладым. Теге шакаллар. Бөтен гәүдәм травмотология бүлегенә атылды. Аяклар баскычка әллә тия, әллә юк. Туп-туры тегеләр палатасына бәреп кердем. Керсәм, палатада өлкән яшьтәге ике абзый гына ята. Калган караватлар буш.

—Кайда бу кабахәтләр?

—Аларны бүген иртән «выписывать» иттеләр.

Гадәттә бүлнистән чыгасы кешене «обход»тан соң төш турыларында гына чыгаралар. Табиблар кара тавыш чыгасын сизгән, тегеләрне иртән иртүк олактырганнар.

Нияз белән Ардуан коридордагы һәм күрше палатадагы авыруларның сөйләгәннәреннән кичәге хәлләрне күзалларга була.

Ардуан белән Нияз икесе генә калгач, кичләрен теге бәдбәхетләр җиденче палатага иялэшеп китә. Ишекне ябып куялар да, малайларның канын катырып, кәрт сугалар. Өстәлнең түрендә—Утлыкүз.

Икенче көнне дә кереп кәрт сугалар һәм... Ниязга «үлән» күрсәтәләр. Син безгә күрсәттен, хәзер без сиңа күрсәтәбез ул үләнне, бәйрәм ашы—кара-каршы, имеш. Малайны, ике кул белән башыннан кысып, өскә күтәрәләр. Болай да муенын көч-хәл белән борган Нияз, авыртуга түзә алмыйча, елый. Шыпырт кына елый. Тегеләр дә шыпырт кына чыгып тая.

Кичә алар монда үзләрен хуҗа кебек тоталар. «Отбой»дан соң шәфкать туташы куып чыгаргач та, әле йокларга ятмыйлар. Утлар сүндерелгәч, коридор тәмам тынып калгач, ач күселәр кебек, шыпан-шыпан тагын кереп тулалар. Шалт та шолт. Өстәл өстенә тагын карталар куна башлый. Тамак кипсә, малайларның тумбочкасы өстендә—тәмле су. Аны эчәләр. «Мина да калдырыгыз»,—ди Ардуан. «Калдырабыз, калдырабыз, әле өстәп тә куябыз»,—ди сары ыштанлы Арышбаш һәм малайның төнгә диган суына лач итеп төкерә.

Баштарак коридорны һәм күрше палатадагы авыруларга комачауламый, зыян салмый гына утырсалар, тора-бара бу явызлар үзләрен бәйдән ычкынган этләр кебек хис итә башлыйлар. Ниязның: «Суга төкерергә ярамый»,—дигән сүзләренә үч итеп, тагын үлән күрсәтмәкче булалар «Тимәгез аңа!»—дип кычкыра Ардуан. «Ә сиңа хәзер йолдыз күрсәтәбез»,—ди бая суга төкергәне һәм бүлниснең киезләнеп беткән каты мендәре белән бар көченә Ардуанның башына суга. Кая сугасын беләләр—авырткан җиргә. Өстәл янында дәшминитми, тын гына утырган Утлыкүз ошбу «тамаша»дан татлы ләззәт кичерә. Тегеләр исә чибәркәйнең күнелен күрә алуларына шатланып туялмыйлар, нишләргә белмиләр.

Балаларның әче тавышына палатага беренче булып «станокчы» хатын атылып керә. Керә дә Ардуанга тагын сугарга дип мендәрен өскә күтәргән «йолдыз күрсәтүче»нең сыңар кул белән бугазына ябыша. Көтелмәгән һөҗүмнән теге каушап кала. Утлыкүз мыштым гына юкка чыга. Ул арада кизү торучы шәфкать туташлары йөгереп килеп җитә. Коридордагылар куба. Равил Шәрәфиевнең апасы күтәрелә. Тегеләр аңа, башыңа каплыйбыз, дип, өстәл өстендә торган кайнар чәйнек белән киләләр. Апабыз курыккандыр, дисезме?

Куркытырсың, бар. Бергәләп явызларның иманнарын кияләр. «Десант» та, таягын тотып, нәкъ вакытында, нәкъ урынында пәйда була. Таяк эшкә жигелә.

Өченче көн Ниязның нигә елавын да, кичә малайларның мине ни өчен жибәрәсе килмәүләрен дә аңладым хәзер. Их, элек без югында да Гажилә була торган иде бит бу палатада. Аның «Тихий час!, Барыгызга да йокларга!» дигән сүзләрен сагынып куйдым.

...Сәгатькә карыйм, бәй, эшкә кайтырга вакыт. Бирәсе әйберләрне биреп, аласын алып, малайларны тынычландырып кузгалдым. Коридордан үткәндә күрәм: яна йөзләр, яна авырулар. И Ходаем, бәла агач башыннан йөрми, кеше башыннан йөри шул. Диварга сөялеп торган егетнең үз кайгысы. Хатыны аягын сындырып ята икән. Шуның хәлен белергә килгән. Кеп-кечкенә ике баласын да иярткән. Үзе ләх исерек, аягында чүт басып тора, үзе сукрана. Табиблар балаларын алып калганнар. Десантнигыбыз да, таягы белән тук-тук килеп, тартырга чыгып бара.

—Дөрес әйткәнсез сез. Таягыгызның кирәге чыккан бит. Тик кундыргач-кундыргач, нишләп башларына кундырмадыгыз ул кансызларның.

—Зираттагы урын жалкы, энекәш.

Коридорны үтеп ишекне ачам дигәндә, колакка таныш сүзләр чалынып китте: «Операциядән курыкмагыз. Курыкмагыз сез операциядән!» Абзыебыз авыруларга кинәш бирүен дәвам иттерә.

Ул арада мине күреп алды:

—Карале, сина бер сирьюзный сүзем бар. Улыңның хәле ничек?

—Әйбәт.

—Их, тәки ясаттырмады шул операцияне. Курыкты. Әйт әле, курыкмасын әле.

Тышка чыгуга кояш нурларыннан күзләрем чагылды. Башны аска иеп барам. Үләм-бетәм, ни күрим—үлән! Юк, кичә-бүген генә борын төрткән үлән түгел бу. Урамда әле апрель генә булуга карамастан, хәйран калкып өлгергән. Ялтырап торган яшел, нәфис кыяклар, бер-берсенә чатябышып, жил искәндә жиргә елышып, язның тыгыз, жылы һавасын мес-мес сулап, үсәргә, шәһәр эчендә яшәргә тырышалар. Яшәүләре исә үләнгә дә жинел түгел. Апрель жылы, хәтта эссе килде. Әйтүләренә караганда, май салкын булмагае. Алда—сабан суыклары, шомырт салкыннары. Аларына түзәргә була. Тик менә юл кырыендагы бу үләннәрне дә машиналар таптап китмәсен иде инде.

Яшә, яшел ямь!

Ә син, Нияз, безне гафу ит. Без бит берни күрмибез. Сукырлар без. Дөресрәге, күзле бүкәннәр без.

Карашымны үләннәрдән алып, бүлнис бинасына төбим. Тәрәзәдән Нияз карап тора. Башы иелгән, йөзе сагышлы.

*2000 ел.*



Бикә
Рәхимова

## Ятимнәр

Бер Ходаем безне татар итеп,
Кавем-милләт итеп яралткан...
Кемнәр икән, кемме икән алар
Дан исемне бозып каралткан?

Ятимиләр алар, тома ятимиләр,
Милләтеннән китеп адашкан,
Җаһиллекнең чытырманлыгыннан
Аллаһ хөкеменә таш аткан.

Энекәшем минем, ятимкәем,
Кайтырсың дип өмет туганда,
Сул ишектән кереп, югаласың,
Уң ишектән көтеп торганда.

Сеңелкәшем, минем, ятимкәем,
Ялган сине алып киткәндә,
Тына алмас, сулкылдавым тынмас,
Ачы күз яшьләрем кипкәндә.

Шәфагатьсез шәфкать туташыдай
Бәгырեңә салгач ташларын,
Томаланды милли сулышларың,
Зыр әйләнде ятим башларың.

...Ачы дәһшәт—югалту килгәндә
Җаны булган җаннар уяна...
Кайда соң сез, мәгърур ил картлары?
Кайда соң Син—сизгер Ил-Ана?

Бикә РӘХИМОВА—*шагыйрә, публицист; "Сәрвиназ", "Иделләр Казанында", "Мәрхәмәт" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Әкият белән янәшә

Биекләргә ничек менгән идек!—
Дөнья манарасы күрерлек!
«Татар иле бар ул!»—диеп безләр
Сөенешеп җырлап йөредек.

Киңлекләргә ничек чыккан идек!
Байрагыбыз китте диңгезгә![1]
Мөстәкыйльлек алган халкыбызның
Гамәлләре иде иң изге.

Тирәнлеккә ничек төшкән идек!
Тарих катламнары ачылды...
...Шатлыгыбыз кабат йотыла бит...
Сим! Сим!
Тагын ишек ач инде!

## Кол

Туган илең читлектә чагында,
Үз ирегем, диеп сөйләшү:
Чыпчыкларның гамьсез чыркылдавы,
Булмастайны бүлеп өләшү.

Ирек кирәк!
Кем ирекле баштан
Ирексезлек гамәлен кыла,
Ireklegә кертмим андыйны.
Ул—Явызлыкның мескен колы.

## Биек тауны менгәч...

*Рәссам, сынчы Бакый Урманчега*

Урманче—
тылсымлы урман әче.
Кайтавазны кайтара—
юллары урау ничек...

Урманче—
чәчәкле болын исе.
Кыңгыраулар челтери,
җәйге иркә җил исә.

Урманче—Бакый мәңге
меңгәчә.
Көч-куәте ишәя,
биек тауны менгәч тә.

## Сердәш

Диңгез үксүләрен йөртә җаным,
Төпләрендә кайнау—вулкан бар.
...Үзәнлектә—бөркет оясында
Биеклеккә менәр дәвам бар.

Үзәнлеккә оя кора икән
Бөркетләр дә, туган ил, диеп.
... Яшәү серен сердәш итеп йөртәм,
Чәчәкләрдән үреп, гөл диеп.

---

[1] 1990 елның 30 августында Мөстәкыйльлек Декларациясен кабул иткәннән соң, бер төркем батыр егетләребез, Татарстанның яңа байрагын башка илләргә таныту өчен, җилкәнле көймәдә диңгезләргә, океаннарга чыгып китеп, йөреп кайттылар.

## Җитә

Әлки белән Кичү арасында
Бертуктаусыз йөрим әле дә.
Ничә еллар үткән, көндәгечә
Каршы ала әле әни дә.

Тәрәзәдә җуелмаган йөзе—
Мөлаем да шундый сөйкемле...
Уй агышы ирексездән түгел,
Ирекле баш ала иркемне.

Очып кына йөрим араларда,
Кай көндә мин—болан баласы...
Бүре кызы булып тәгәримен—
Кар көртенә чумып аласы.

Сары чыпчык булып тәрәз чиртәм
Иртәнге ак эңгер-меңгердә.
Әлки—Кичү: Галәм сыйган ара,
Бөтенлеге җитә гомергә.

## Якын итә

Безнең яклар карурманлы...
Карурманның өстеннән
Алтын табак—ай чыкканда
Күз чагыла төсеннән.

Йөгерә урман буеннан
Алтынлы күләгәләр,
Аннан көндез эссе җыйган
Күбәгә күмеләләр.

Әкияти бөтен дөнья...
Чирмешәннең ак суында
Сихерче су анасымы
Чупырдый төнге уенда?

...Ярый әле Табигать бар.
Үз итә безне, якын—
Үз-үзенә гашыйк булган
Бүгенге дөнья халкын.

## Дөнья—салкын күзле ... елан

Ни әйткәнен дә һич аңламассың,
Буталчыклык дөнья сүзендә...
Куркуымнан тирләп-пешеп чыктым:
Салкын акыл елан күзендә.

Әздән генә өстенә басмый калдым...

## Яман

Яманнан яман—
Надан яман.
Булдыксыз
Табип яман.
Тимерче дә ямый белә.
Яраны җәнлек ялый белә.
Хатасын затлы таный белә.
Игелек бир, Аллаһ, җаһиленә!

Коткаручым бул, Илаһ, кордашым.
Ни хәл итмәк кирәк? Бер башым...

## Көч—үзебез

Халык җанын таулар саклый,
Ләкин үзгә безнең табыбыз.
Таш таулары бездән киткән икән,
Рухи таулар табып таныйбыз.

**Биек таудай калка Кубрат патша,**
**Хан дигәннәр аны, билгеле.**
**Күзләребез күргәч, шатлык басты,**
**Полтавада калган билгене.[1]**

**Алмыш ханнар, хәтта Бәркәсе дә**
**Үзебезнең таулар, биеклек.**
**Мисыр хәтле, Мисыр була торып,**
**Безгә дога кылган иң элек.[2]**

**Сафа Гәрәй, Сөембикә дигәч,**
**Алар белән бергә үсәбез.**
**Фаҗигаләр күргән халык үлми!**
**Көлдән туа, әгәр белсәгез!**

## Тарлаш

*Урыс кызы урамда,*
*Чирмеш кызы—чирәмдә,*
*Татар кызы тарлауда,*
*Урак ура барнауга.*

Халык әйтеме

**Һәр көнемдә минем үзгә йөрәк,**
**Һәр көнемдә минем—икенче,**
**Урак-ургычлардан ерак киттем,**
**Күңелемдә яши игенче.**

**Басып торам Тарлаш урамында,**
**Төн эчендә, диңгез төбендә...**
**Болгар бабайларның сөйгән сыен—**
**Тарлау ашын ашыйм бүген дә.**

**Урамнары дидем ... урам булган...**
**Таралышкан язмыш усалга.**
**Тарлаш урамнары—диңгез төбе,**
**Алтын комы калган мисалга.**

**Борынгылык эзләп йөрим, юләр,**
**Сүнәме соң йөрәк ялкыны.**
**Кара яныш яннан узды берәү,**
**Күзләрендә тәмуг салкыны.**

**Ай тәрәше сузган нурларыннан—**
**Көмеш уйдан йомгак чорныйм да**
**Басып калыйм Тарлаш урамында,**
**Төн эчендә, Болгар чорында.**

---

[1] Борынгы дәүләтебезнең (5 -6 гасыр) бөек ханы Кубратның исемле йөзеге һәм гаҗәеп бай алтын-көмеш хәзинәсе 1912 елда Полтава янында табыла. Соңгы елларда Петербург Эрмитажыннан китерелгән бу мирасны Казанда да күрү бәхетенә ирештек.

[2] Бәркә хан заманында, төрки мәмлүкләр Мисырда хакимлек иткән чорда, андагы мәчетләрдә, болгар-татарларга уңышлыклар теләп, дога кылынган.

Барнау—акча бирмлеге.

Тарлаш—борынгы Болгар авылы, соңыннан урыс авылы, хәзер анысы да таралып беткән диярлек. «Кара» байлар зур өйләр сала башлаган.

Рәфкать
Кәрами

# ОЛЫ ЮЛ ДА СИКӘЛТӘЛЕ

РОМАН

## XXV

Артык зур булмаган авылның клубы да уртача иде. Бүген кино икән. Габделнур билетка акча сузды.

—Солдатны бушка да кертәбез,—диде клуб мөдире.—Уз әйдә, рәхим ит.

Клубта яшьләр шактый, ләкин берсе дә Габделнурга таныш түгел. Чөнки ул үскән чорда бу авыл балалары үзләрендә җидееллык мәктәптә укыдылар. Аннары күбесе күрше район үзәгендәге урта мәктәпкә йөреп унынчыны тәмамлады. Чөнки ул районга олы юл бар, арасы да якынрак. Хәер, үз район үзәгендә укысалар да егет аларны белмәс иде.

Яшьләр борыла-борыла кунакны күзәттеләр, ул да караштырып утырды.

Ут сүнде, кино башланды. Ләкин, ун минут чамасы вакыт узгач солдат бу фильмның эчтәлеген исенә төшерде. Армияда чакта караган икән. Ул шыпырт кына, кешеләрне борчымаска тырышып, клубтан чыгып китте.

Урамда чагыштырмача тыныч. Клуб тирәсендә җан иясе юк. Уң якта, бераз арырак, капка төбендә ике-өч ир-ат сөйләшеп тора. Сулда кемнендер кайтмый калган сарыгы кая барып сугылырга белмичә каңгырып йөри. Күк йөзе аяз, көнбатышта, алар авылы ягында шәфәкъ алсулыгы әле сүрелмәгән.

Агач клубның бүрәнә диварына ике велосипед сөяп куелган. Авыл яшьләренекедер инде.

Габделнур уйга калды: апаларына кайтса—җизнәсе өйдә түгел, кодаларына сугылса—алар әле капка белән мәшгульдер. Эшләгән кеше янында торганчы, тәмәке тарткан кеше янында тор, диләрме әле. «Аптыраган—йөдәгән, артын мичкә терәгән»,—дип куйды егет көлемсерәп.

Ул баскычтан төште дә стена буендагы велосипедлар янына килде. Өр-яңа булмасалар да, таза күренәләр. Тәгәрмәчләренә күз төшерде. Көпчәкләре дә яхшы кабартылган сыман.

«Ни булса, шул булыр»,—дип тәвәккәлләде дә, солдат җәлт кенә берсен эләктерде, менеп атланды һәм, урам аркылы чыгып, тау түбән төшеп тә китте. Елга аша салынган такта күпердән узып, каршы як тауга күтәрелә башлады. Яртысын менгәч, велосипедтан төшеп, аны житәкләп барды. Аннары, тау башындагы юл тигезләнгәч, кабат «бахбаена» утырды.

Өч ел берөзлексез спорт, хәрби күнегүләр белән шөгыльләнгән аяклары педальне житез әйләндерде: вак-төяк калкулыкны, яр-үрләрне менгәндә велосипедтан төшеп тә тормады, ә юл түбән таба булганда коштай очты гына.

Ярты сәгать узды микән, юк микән, ул инде үз авылының клубы янында иде. Баскычта ике егет тәмәке пыскытып тора.

—Исәнмесез, егетләр,—дип дәште Габделнур аларга һәм велосипедны стенага сөяп куйды.—Вечер барамы?

Икәве беравыздан исәнләшкәч:

---

*Ахыры. Башы алдагы саннарда.*

—Бүген кино,—диде егетләрнең берсе.

«Иртә унмаган—кич унмас, кич унмаган—һич унмас»,—дип әнисенең гел әйтә торган сүзләрен кабатлады егет. Шулай да эчкә узды. Егетләр дә аның артыннан керделәр.

Габделнур ишектә пәйда булуга, арткы рәтләрнең берсендә утырган дусты Касыйм аны күреп алды. Йөргән кызының колагына, мин хәзер керәм, дип, урыныннан торып, солдат янына килде. Исәнләшкәч, урамга чыктылар.

—Син кая югалдың?—диде дусты тәмәке кабызып.—Тартасыңмы? Беләм. Тәки өйрәнмәдең.

—Жизнәй алып киткән иде. Менә качып кайттым.

Һәм Габделнур кыскача гына сөйләп-аңлатып бирде, клуб диварына сөяп куелган велосипедка төртеп күрсәтте.

—Күрмәделәрме соң?

—Кем белгән аны?! Мин артка карарга да онытканмын.

—Ну башсыз!—диде Касыйм шелтәләгәндәй итеп көлеп.—Михаил Девятаев булгансың икән... Элек андый гадәтең юк иде сыман.

—Җәяү кайтып булмый бит инде,—диде солдат авыз ерып.—Тегеләр юкмы?

—Күренмәделәр.

—Значит, китkәннәр. Ә... кунак кызлары да юкмы?

—Берәү бар. Түлке ул авыл кызы, Алабугадан кайткан.

—Бушмы соң?

Дусты тиз-тиз генә бер-ике суырды да, тәмәке төпчеген җиргә ташлап, туфли табаны белән өстенә басып изде. Аннары клубка кереп китте.

Бераздан ул чыкты. Үзе генә түгел, бер кызны да ияртkән иде. Ул аны Габделнурга якынрак китерде.

—Бу абыеңны таныйсыңмы?

—Юк.

—Алайса, танышырсыз.

Шулчак клубтан ике егет чыкты.

Касыйм, артына борылып:

—Нәрсә чыктыгыз?—дип җикерде.—Барыгыз, керегез! Әйттем бит!

Болар инде унҗиде-унсигез яшьтә, гәүдәле, мыек чыгып килгән егетләр булсалар да, әле олылар сүзен тыңлаудан «җәяү качкан» түгелләр иде. Аннары, кунак солдатның беләкләр дә таза күренә. Туганнан бирле механизатор булып эшләүче Касыйм абыйларының бала башы хәтле йодрыгы нинди каты икәнен яшьләр ишетеп тә беләләр, үзләре дә «татып» караганнар иде инде. Шуңа күрә, тел озайтып, теш ыржайтып тормыйча, кире кереп киттеләр.

—Каты сөйләшәсең,—диде Габделнур дустына һәм янында басып торган кызга да елмаеп карап куйды.

—Һы, шулай итмәсәң, алар сыртыңа менеп атланырга да күп сорамас. Хәзерге яшьләр—без түгел, олы абый, дип сәвис саклап тормыйлар. Әле беркөн өчәү чүт тотып дөмбәсләмәделәр. Көчкә качып котылдым.

Ул шаркылдап көлде. Күрәсең, бер-икесен, үзе әйтмешли, тотып «ишкәндер». Юрамалый гына мескенгә сабышадыр. Тел төбеннән, сүзләренә шаян мәгънә салып әйтүеннән шул аңлашыла. Хәер, егетләрнең дәшми генә кереп китүе дә шул хакта сөйли иде.

Клубтан Касыймның үзеннән өч яшькә кечерәк энесе чыкты. Ул Габделнур белән кул биреп исәнләште. Анысының да маймылныкы кебек тез тиңентен төшеп торган озын куллары, кем әйтмешли, ташка үлчим—күрәктәй иде.

—Нәрсә анда теге малайлар тыз-быз килә?—дип сорады ул абыйсыннан.

—Берни дә юк. Бар, кер.

Егет таза гәүдәсен әле бер, әле икенче якка ташлап, клубка кереп китте.

Касыйм да, дустына күз кысып, баш какты да ишектә юк булды.

Егетләр сөйләшкәндә кыз читкәрәк китеп баскан иде. Солдат аңа күз ташлады. Ул уртача буйлы, уттай янып торган алсу яңаклы, тулы битле, эскәкмазар яки лезвие тимәгән кыйгач кара кашлы, чем кара чәчле. Чәчен бер толым итеп үргән. Габделнур анысын кыз баскычтан төшкәндә абайлаган иде. Әллә

тагы толымы тез астына ук төшкән.

—Ачуланма инде, кино каратмадык,—диде солдат анын янына килеп, тулышып торган алсу иреннәреннән күзен алалмыйча.

—Шәһәрдә карарбыз әле,—диде кыз батыр гына.—Сезне хәзер таныдым. Сез—Габделнур абый?!

—Әйе. Ә син?

—Мин—Зөнәйдә.

Сөйләшкәндә анын энҗедәй тезелгән ап-ак тешләре күренеп китә иде.

—Үпкәләмә инде, кем кызы икәненне белмим.

Зөнәйдәгә әти-әнисенең исемнәрен әйтеп бирергә туры килде.

—Апаң белән бергә укыган идек.

—Беләм. Ул кияүдә инде, күптән, ике баласы бар.

—Сәлам әйт.

—Ярар.

—Әгәр бик настаивать итсән, кино карарбыз. Мәҗбүри булмаса, киттек.

—Кая?

—Кая телисен. Желание дамы—закон для джентельмена, диләр бугай. Урам әйләнербез. Син дә авылны сагынгансыңдыр.

—Әйе. Мин Алабугада педта укыйм. Җәй көне, тик ятканчы дип, үзебезнең районда пионерлагерьда эшлим. Бер генә көнгә сорап кайттым. Әле клубка да чыгасы түгел идем. Аннан кире уйладым. Кино башланыр алдыннан гына килдем.

Габделнур, велосипедны бер кулы белән генә тотып, кызның уң ягыннан атлады. Кыз чая булып чыкты.

—Егетләр кызларның сул ягыннан барырга тиеш.

—Оһо, этикетны беләсен,—диде солдат кин елмаеп,—педагогическийда укуың күренеп тора. Ә мин уң яктан атларга тиеш. Әйт, ни өчен?

—Белмим,—диде кыз солдатка эчкерсез мөлаем карашын төбәп.

—Мин—солдат. Димәк, каршыга килгән хәрбиләргә честь биреп китәргә тиеш.

—Сул кул белән ярамыймыни?

—Юк. Һәрнәрсәнен үз тәртибе бар.

Шулай юк-бар сөйләшеп, бер-беренең хәтерен калдырмаска тырышып (бу күбрәк Габделнурга кагыла иде), киң урамнан җай гына атладылар.

Урам инде тынган, кайбер өйләрдә утлар да сүнгән, арган-талчыккан авыл халкынын берише ял итәргә йокыга талган. Ләкин күпчелек өйләрнен тәрәзәләрендә әле ут балкый. Ут яктысы урамга да төшә. Хәер, җәйге кич болай да караңгы булмый.

Яшьләрнең икесенә дә Алабуга таныш булгач, уртак сүзне тиз таптылар. Сөйләшә-сөйләшә Урта урамның югары очына килеп чыктылар.

Авыл артта калды.

Ике якта да иген басулары: кайсы инде урылган-сугылган, кайсына бүген-иртәгә комбайн керәсе. Ә алда, еракта, тау битенә үрмәләгән сыек урман. Тагын да арырак күз ташласан, күк йөзен һәм сирәк ак болытларны алсу төскә манган ут яктысын күрәсең. Бу—Әлмәт шәһәре өстендәге ялкыннар шәүләсе. Ул ялкыннар—газ факеллары. Алар монда да бар инде хәзер. Нефть вышкалары, аксыл-сары утлары белән балкып, караеп утыра.

Габделнур:

—Хәзер нефтьчеләрнен җир тишүе ишетелми дә,—диде.—Ә элек бер буровой бораулаcа да тавышы әллә кайларга тарала иде.

—Нигә алай?—дип сорады кыз.

—Элек аларда көчле дизельләр дөп-дөп эшләп утыралар иде. Хәзер—электр моторлары.

—Ә сез аны каян беләсез?

—Мин армияга киткәнче подстанциядә дежур тордым. Моторлары өстәлдән дә зуррак...

—Ә безнең авылга кайчан килделәр соң алар?—дип сорады Зөнәйдә.

—Син туганчы,—диде егет шаяртып.—Илле дүртенче елдамы, илле биштәме. Буровойда өйләнмәгән егетләр дә күп иде. Кайсылары, башлы-күзле булып киттеләр, ә берсен начальство бүтән бригадага күчерергә мәҗбүр булды.

—Нигә?

—Ул бер кызны көчләгән. Моны кызның ир туганнары кара канга батырып кыйнадылар. Алар сугышканда без урамда идек. «Вы за каждый мой волос ответите!» дип янаганы әле дә хәтердә. Үзең беләсең, безнең авыл кешеләре андый килмешәкләрдән генә өркә торганнардан түгел. Так что, башы исән чакта үзенә табан ялтыратырга туры килде... Мастерлары безнең әбиләрдә торды, гаиләсе белән. Мастер янына иптәшләре—бораулаучылар килә, киңәшәләр, бәхәсләшәләр. Миңа кызык, тыңлап утырам. Мин шунда беренче мәртәбә полиспат дигән сүзне ишеттем дә отып калдым, гомергә истә калды... Әнә, Ачыдан өстәрәк сыртта бер вышка да ауган иде әле. Без малайлар белән барып карадык. Ә беренче буровой килүе әле дә хәтердә: алты-җиде трактор җир тетрәтеп тегене сөйриләр...

Кыз көлеп җибәрде.

—Ә безнең казлар нефть базына төшкән иде, ул елны мәхрүм калдык.

—Бер елны әти белән машинада барабыз, бүген-иртәгә урасы иген өстеннән буровой вышкасы күчерәләр. Әти түзмәде, туктап, кабинадан чыкты да, берәүне сүгә башлады: «Ник әз генә сабыр итмисез? Ипи таптыйсыз?» Теге, флажок тотып тракторлардан читтәрәк баручы кеше, кулларын як-якка җәйде: «Абый, без бәләкәй кешеләр, кушканны үтәүче генә,—ди.—Мин үзем дә авыл малае, минем дә йөрәк сыза». Күрәсең, үзенә дә кызганыч булгандыр ипи әрәм итүе, ашлык таптавы. Ул нишләсен инде.

Буровойлар турында сүз чыккач, кыз:

—Әле шушы арада гына күрше авылның бер егете үлгән,—диде.

—Нишләп?

—Башына нәрсәдер төшкәнме, бәрелгәнме, төгәл әйтә алмыйм. Әлмәткә барып, ике генә ай эшләгән булган.

—Андый хәлләр була инде ул...

Габделнур да үзе белгән бер-ике хәвефле очракны сөйләде. Алар урамында туып үскән бер егетнең моннан ничәдер ел элек шахтада басылып үлүен дә әйтте.

Рудник дип йөртелгән урынга хәтле баргач, кыз әкрен генә әйтеп куйды.

—Габделнур абый, борылабызмы?

Егет каршы килмәде.

—Яхшы. Ардыңмы? Әйдә, велосипедка утыртып алып кайтам.

—Юк, кирәкми.

—Ихтыярың.

—Мин авыр бит,—диде Зөнәйдә оялып кына.

Егет аның гәүдәсенә карап сокланды.

—Синме?!

Алар борылдылар. Егет, бу такылдавык үзенең күп белүе белән мактана, дип уйлатмас өчен, күбрәк Зөнәйдәне тыңларга теләде. Ләкин тормыш тәҗрибәсе һәм дөньяны шактый күрүе, танып белүе аркасында барыбер аның үзенә күбрәк сөйләргә туры килә иде. Мәскәү, Ленинград, Ярославль, Казан турында әйткән дә юк, хәтта кыз үзе бер ел укыган Алабуга каласына кагылышлы вакыйгалар да Зөнәйдә өчен яналык иде.

—Музейда булдыңмы әле?—дип сорады егет.

—Юк,—диде кыз бераз кыенсынып.—Оят булса да... Лекциядән кайтабыз да тагын укырга тотынабыз. Бик күп биргәләр... Анда тәртип каты. Стипендиядән дә колак кагасы килми. Төрле кичәләр дә оештырабыз...

Габделнур аңа Алабуга, бөек рәссам Шишкин хакында, шәһәрдә күренекле шәхес булган атасының кабере хәзер дә исән икәнен, аның шәһәр бакчасында саклануы турында сөйләп бирде.

—Анда кавалерист кыз Надежда Дурова да күмелгән икән.

—Әйе. Ә Шишкинның «Утро в сосновом бору» исемле картинасы бар.

—Аны беләм.

—Шишкин—пейзажлар остасы: кырларны, иген басуларын, урманнарны бик тә оста ясый. Аның картиналарын карагач, гүя каршында жанлы урманны күрәсең, нарат урманында була торган тәмле ис сизәсең, агач шавын ишеткәндәй буласың. Икенче бер бөек художник Стасов әйткән: «Урман—Шишкинның патшалыгы һәм монда аның көндәше юк». Ләкин, беләсеңме, ул кешене һәм хайван сурәтен ясый белмәгән. Ясавын ясый, тик пейзажлары кебек әйбәт түгел.

—Ә теге картинадагы аюлар?

Габделнур көлеп җибәрде.

—Алар Шишкинныкы түгел. Хәтта томаны да...

—Ничек?

—Әйе, аныкы түгел. Аларны икенче бер художник ясый. Исеме хәтердән чыккан. Туктале, Константин Савицкий бугай ул. Башта, беренче тапкыр, картина күргәзмәгә ике имза белән куела. Аннары алар арасында низаг килеп чыга, судлашып та йөриләр. Ахырда теге художник үзенең имзасын сызып ташлый.

Сүз иярә сүз чыгып, алар сәнгатьтән әдәбиятка, аннары авыл хәлләренә күчеп, сөйләшеп янә авыл башына кайтып җиттеләр. Габделнур кызны Урта урамга алып кермичә, сулга таба борылды. Бераз вакыт болыннан, бәрәңге бакчалары буйлап бардылар.

Аннары сөйләшә-сөйләшә ике як ярны тоташтыручы борынгы таш күпер аша чыктылар. Аксакаллар сөйләвенә караганда, булачак Казан—Чаллы—Бөгелмә юлы өчен унтугызынчы гасыр ахырында ук бу тирәдә бетоннан коеп өч күпер салганнар: берсе—Иске авылда, икенчесе—шушы, өченчесе—Баллы дигән урында. Андый таза күперләр күрше авылларда да бар.

Габделнурлар урамына керделәр. Кыз Урта урамда, аның түбән очында яши иде. Шуңа күрә егет, велосипедка ымлап әйтте.

—Бу җәфаны өйдә калдырыйк та, сине озатып куярмын.

Зөнәйдә ризалашты. Ләкин Габделнур, өйләре турына житкәч, кызны да ишек алдына алып керде. Велосипедны агач келәт янына илтеп сөяде дә олы капка янында торган Зөнәйдәне кочагына алды. Кыз дәшмәде. Габделнур, кыюланып, аның кайнар иреннәреннән үбеп алды.

—Габделнур абый, алай итмә инде,—диде кыз көч-хәл белән башын читкә алып.

—Нигә?

—Оялам.

Кызның сүзләрендә бернинди дә ясалмалык булмыйча, моны ихлас күңелдән әйткәне сизелә иде. Егет, ничек кенә теләсә дә, аны яңадан үпмәде, ләкин шулай да куеныннан чыгармады. Унсигез яшьлек кызның ут кебек янган таза тәнен ул бик озак кочагында тотты. Үзе берөзлексез сөйләнде: армия хәлләре, андагы кызыклы вакыйгалар, спорт ярышлары исенә төште. Кыскасы, теле тегермән тартудан туктамады. Хәтта Зөнәйдәнең апасын да искә алды.

—Синең апаң бик матур җырлый иде.

—Ә ул хәзер дә җырлый,—диде кыз егетнең аны телгә алуына күңеле булып, апасы өчен горурлык хисләре дә кичереп.—Тавышы көчле түгел, әмма бик моңлы. Ә сез нәфис сүз сөйләргә бик оста булгансыз.

—Кем әйтте?

—Апам. «Томаулы гыйшык»ны.

—Әйе шул. Мин аның кайбер юлларын әле дә хәтерлим. «Утыра торгач, ахры, мин дәртләнеп, тотып кызның ике кулыннан, бер кызык сүз әйтеп көлгән идем, чыкты куйды куык борыннан...»

Икесе дә көлештеләр. Елмайганда Зөнәйдәнең бит очлары чокыраеп китте, алсу иреннәре ачылганда энҗедәй тезелгән ап-ак тешләре күренеп калды.

Аннары егет верандага таба башын борып:

—Мин әнә шунда гына йоклыйм,—диде.—Керәсеңме?

Кыз куркып калды. Биек маңгаенда бер сызык хасил булды, кара кашлары

жыерылды.

—Юк, Габделнур абый!—диде ул баш селкеп.—Син ни сөйлисең?!

—Нигә, без яшь чагында аулак өйдә гел кызлар белән куна идек.

—Ул бит аулак өйдә. Без дә малайлар белән кунгаладык. Анда берничә пар була, идәнгә тезелешеп, уен-көлке сөйләшеп ятасың төне буе. Аның гаебе дә юк.

—Ә минем белән гаепмени?

—Икәүдән-икәү генәме? Гаеп, билгеле.

—Куркасыңмыни?

—Юк та... Мин сезне әле юньләп белмим дә...

Әмма кызның тавышында курку гына бар, ә катгый рәвештә каршы килү яки баш тарту галәмәте чагылмаган шикелле тоелды Габделнурга. Әлбәттә, япь-яшь кыз, житмәсә студентка, шуның өстенә үз авылы кызы... Болар егет хыялының тормышка ашмасын раслый торган сәбәпләр, менә юл куелмаска тиешлегенә дәлилләр иде. Шулай да борын-борыннан килгән йола—егетләр һәм кызларның аулак өйләрдә куну гадәте, анда чишенмичә генә йоклау, кызларны мәсхәрә итүгә, алдауга юл куелмавы—әлеге дәлилләргә каршы үзенә күрә көчле аргументлар.

Зөнәйдә «башсыз» кыз түгел иде. Өендә әти-әнисеннән ярыйсы гына әхлак тәрбиясе алган, акны карадан аера, үзенен дә кадерен һәм бәһасен белүче зирәк кыз иде. Аның артыннан үсмерләр дә, егет-җилән дә йөрмәде түгел, хәзер дә кайткан саен озатучы табыла. Ул аларның берсен дә артык якын җибәрми торган иде. Ә бүген әллә нишләде, әдәп кагыйдәләреннән читкә тайпылды шикелле. Киноны ташлап, солдат абыйсына ияреп үк китте. Аның кочагында, әйткән бер сүзенә мөкиббән китеп, бер теләгенә дә каршы килергә базмыйча оеп тора. Нинди тылсымлы халәт, беренче күрүдә үк якынайта торган сихри көч бар монда?! Нилектән шулай бу? Аның күңеле ниндидер серле, әйтеп бетергесез шатлыклы яшерен хис кичерә түгелме? Нәрсә бу? Кыз моны бәлки тәгаен гына әйтеп тә бирә алмас иде. Габделнур аны белмәсә дә, Зөнәйдә, апасы сөйләве буенча, егетне бик яхшы белә икән. Кыз аның, тәртибе бигүк шәптән булмаса да (хәер, малайларның кайсының гына тәртибе үрнәк була икән?!), мәктәптә яхшы укуын, чаңгыда шәп шууын, әдәби кичәләр оештырып йөрүен белә. Әйе, белә. Хәзер әкренләп апасының сөйләгәннәре исенә төшә. Гармун уйнавы өстенә, ул әле күн итек белән дөп-дөп басып, сәхнәдә ярыйсы гына биегән дә икән, спектакльләр куюда да катнашкан. Ләкин, иң мөһиме, апасы аны бик яраткан. Балалык-үсмерлек самимилеге белән гыйшык тоткан,—тик ул җавапсыз мәхәббәт булган. Габделнур Зөнәйдәнең апасының дус кызын, күршесен, сары чәчле, зәңгәр күзле бер кызны әдәби кичәләрдән соң озаткалаган. Ләкин апасы үзенен ялкынлы, сагышлы мәхәббәте хакында Габделнурга да, дус кызына да сиздермәгән.

Җиденчедә укыганда, районнан фотограф килгәч, апалары класс белән карточкага төшкәннәр. Ләкин апасының альбомында үз классы түгел, ә параллель сыйныф (ул чорда бала-чага күп була бит) укучылары. Зөнәйдәнең соравына апасы, бер кыз белән алмаштык, диде. Чөнки ул яратып йөргән малай күрше сыйныфта укыган... Менә хәзер шул унөч-ундүрт яшьлек, апасы хыялындагы буй җитмәслек бер малай, техникум бетереп, Әлмәт якларында эшләп, өч ел армия сафларында хезмәт иткән солдат сыйфатында авылга кунакка кайткан. Бәлки әле вузга да керер... Зөнәйдәгә ул беренче күрүдән үк ошады: буй-сыны да, төс-кыяфәте дә, мескенләнмичә, ләкин шул ук вакытта артык һаваланмыйча үз-үзен иркен тотуы да. Аны озаткалаган үнҗиле-унсигез яшьлек авыл егетләреннән аермалы буларак, Габделнур яшькә дә олырак; дөньяны да күбрәк күргән; сөйләгән һәр сүзе кыз өчен яңалык; тиктомалга өзлексез кул озайтып борчып, сагызланып та тормый.

Зөнәйдә апасыннан бик еш ишеткән бер җырны хәтеренә төшерде. Апасы, әлеге фотога карап, уйланып утыра-утыра да, әйләнә-тирәсендә кешеләр барын да абайламыйча, йөрәк бәгырьләреннән савылып чыккан моңлы тавышы белән җыр суза иде.

Сандугачлар булалмадым,
Талларга куналмадым;
Булды дусларым бәхетле,
Бәхетле булалмадым.

Билгеле, хәзер, күпме сулар акканнан соң, үз гаиләсе барлыкка килгәч, балалары тугач, апасы ул малайны бәлки исенә дә алып карамыйдыр—күптән булып узган хәлләр бит инде. Яшәвен дә апасы чит авылда яши.

Ләкин, ни гаҗәп, апасы сөя алмаган, үкенечтә калган яшьлек хыялы булган өчен дә Зөнәйдәгә бу егет ничектер якын иде сыман.

Ахырда, егет баягы тәкъдимен янә бер кабатлап, бик кыстагач, һәм, бүген өйдә барыбер үзе генә кунасы булгач (әти-әнисе апаларына, бәби туена киттеләр), кыз кыенсынып кына:

—Тимисеңме соң?—дип, тәшвишләнеп, озын керфекле күзләрен зур ачып, егеткә текәлеп карады.

Аның кара кашлары өскә чөелде, тулы бит очлары кызарып чыкты, озынча муенына хәтле алсулык йөгерде шикелле.

Шулхәтле ышаныч, аны якын итү, олылау бар иде бу карашта. Ялваруга тартым бу аваздан Габделнур, бизгәк тоткандай, калтыранып куйгандай итте һәм ирексездән баягы уеннан кайтты.

—Алай ышанмагач, озатып куям.

Ләкин үзе кызны назлап кочып алды, аркасыннан сөйде, чәчләрен сыйпады, колагына ягымлы сүзләр пышылдады, кайнар иреннәренә үрелде. Күңеле купшыган кыз да тарсынып кына аны кочаклады: тере җан иясе, яшь, таза тәнле, сау-сәламәт... Нишләсен инде ул бу мизгелдә?! Алар бик озак берберенең назлы, кайнар, мәхәббәт тулы иреннәреннән аерыла алмыйча тордылар. Егет кызны суырып-суырып үпте.

Ниһаять, ул:

—Өйдә керик, курыкма, өйдә әтиләр бар бит,—диде һәм кызны кайнар, йомшак, беленер-беленмәс кенә дерелдәгән кулыннан тотып, болдырга таба алып китте.

Кыз карышмады, бер сүз дә әйтмәде.

Габделнур кесәсеннән пәке чыгарып, аның очын ишек белән борыс арасына тыкты, келәне өскә күтәрде. Пәкесен җыеп кесәсенә салды. Бавы эчке якта булган тышкы бикләвечне күтәреп, әкрен генә ишекне ачты. Шыпырт кына кызга дәште.

—Кил. Туфлиеңне сал.

Зөнәйдә баскычка менде. Аяк киемен салып кулына тотты. Егет ишекне эчтән бикләде, аяк очларына гына басып, веранда янына килделәр, ишеген ачып, эчкә керделәр. Габделнур итеген салды, кызны ишек катында калдырып, верандадагы караватны тиз генә җайлады—урын җәйде. Зөнәйдә янына килде дә, бармагын аның иреннәренә куйды.

—Күлмәгеңне сал.

Веранда тәрәзәсеннән тасраеп ай карап тора иде. Кыз тарсынды, ләкин салмыйча да булмый, бөгәрләнеп бетәчәк. Ул эчке күлмәктән генә калды. Әрсез ай эре челтәрле пәрдә эленгән зур тәрәзәләр аша аның зифа буй-сынына күзен чекрәйтеп карап торуында булды. Әллә инде кызның калын, озын чәч толымын тотып карыйсы, шәрә калган йомры инбашларыннан сыйпыйсы, ефәк эчке күлмәк аша беленеп торган нечкә биленнән кочасы килдеме? Тәгаен гына әйтүе кыен иде. Булгандыр, бу сылуга, алиһәгә тиң бер гүзәлгә ай да сокланмыйча калмагандыр!

Габделнур да чишенде—майка-трусиктан гына калды. Ул, куркудан бөрешкән кызны җитәкләп, карават янына алып килде, юрганны күтәрде һәм эчкә, стена ягына, ятарга кушты. Кыз артыннан үзе дә аның янына кереп чумды.

Аһ, ул яшьлекнең гамьсез, шул ук вакытта оялчан, бер үк вакытта куркуны

да куып җибәрергә сәләтле дәрт ташып торган чоры! Зөнәйдә гәүдәгә Габделнурдан кайтыш иде. Хәзер ул егет кочагында бөтенләй эреп юкка чыккандай булды. Ләкин—ул бар! Аның кайнар тәне, тартынып, кыяр-кыймас кына егетне кочкан куллары. Габделнур абыйсының таза муенына килеп бәрелгән кайнар сулышы бар! Аның сүз белән аңлатып-әйтеп бирә алмаган һәм бу минутта сүзләрнең кирәге дә булмаган сөю-сәгадәте бар! Ничек яратмасын ул кочагында эретә торган, бернидән дә курыкмас, теләсә нинди хәлләрдән дә җиңел чыга, югалып калмаучы бу асыл егетне!..

Габделнурның йөрәге дөп-дөп тибүен ишетә кыз. Ләкин бу тибү куркудан түгел, аны сөюдән бит! Ул—батыр йөрәк! Өч ел солдат хезмәте үтәгәндә нинди генә хәлләргә тарымагандыр дисең аны?! Солдат әле бер-ике генә вакыйга сөйләде. Анда да кызның йөрәге «жу!» итеп киткән иде. Каршына өй хәтле танк ажгырып килгәндә дә, кирәк чакта утка кергәндә дә курку белмәс йөрәкле бу солдатка ничек ышанмыйсың?! Һәрхәлдә, әлеге минутларда кызның зиһене ачык, фикерләве ачык иде.

Әлбәттә, Габделнур Зөнәйдәгә кагылмаска вәгъдә бирүен, йөгәнсез уйлар белән вәсвәсәләнмәскә тиешлеген, аның үз авыллары кызы, әле саф кыз, беренче кичтә үк буен куя торганнардан түгел икәнен акылы белән аңлый иде. Юрган астында ул аның иреннәреннән аерылмады, тын алыр өчен пауза ясаганда ана бик күп назлы сүзләр пышылдады, кайнар сулышы белән колак яфракларын көйдерде. Уң кулы кызның баш астында калган иде, ә сулы белән ул аның бәләкәй йон туптай (алар кечкенә чакта күрше кызлары шундый туплар белән уйный иде) тыгыз имиләрен тотты, иркәләде, назлады. Әллә авыртудан, әллә ләззәттән Зөнәйдә ыңгырашып-ыңгырашып куя иде. Ләкин егетнең яшьлек дәрте шулхәтле көчле, бөтен тәне ут яна, каны котырынып ага, ул, үзе дә сизмәстән, кулын кызның күкрәгеннән алып, эчке күлмәк өстеннән әкрен генә аска—кендек турына хәтле төшерде. Ул аны, аңлы рәвештә, менә шуны эшлим әле, шушы хәрәкәтне ясыйм әле, дип уйламады. Чөнки аның зиһене томаланган иде инде. Акылына буйсынмаган ул әрсез кул инде вәсвәсәгә бирелгән һәм аның туктыйсы килми иде. Чынында, аны туктатырлык көч тә юк иде бугай. Бәләкәй сәдәф зурлыгындагы уемтыкны узып, ул тагын да түбәнгәрәк төшә башлады.

Шул мәлдә Зөнәйдә айнып киткәндәй булды.

—Габделнур абый, нишлисең?! Тимим диден бит! Хәзер кычкырам!

Егетнең вәсвәсәгә бирелгән әрсез кулын туктатырлык көч бар икән, ул—яшь кызның әрнеп-өзгәләнеп әйткән, бәгыреннән чыккан сүзләре булды: башта ялварулы, аннан—тәвәккәл-катгый итеп әйтелгән сүзләр.

Һәм егет үзе дә кисәк кенә акылына килде. Беркавым хәрәкәтсез яткач, тыелып торудан башына саварга ургылган кан чыгарга юл эзли башлады һәм... шул минутта ук аның борыныннан кан китте. Ул борынын чак кына кулы белән тотып өлгерде. Торып, галифе кесәсеннән кульяулык алды, танавына каплады. Башын артка ташлап, бераз басып торгач, ул, кульяулыгын учында тоткан хәлдә, караватт янына килде. Утырды.

Кыз куркып калган иде.

—Габделнур абый, мин китим, озат мине,—диде ул мондый очракта ни кылырга кирәген белмичә гажизләнеп.

Тәҗрибәсезлеге аркасында ул аны юатырга да, сак кына кагылып берәр җылы сүз әйтергә дә кыймады.

—Үтте инде,—диде дә, Габделнур, кульяулыгын идәнгә ташлап, юрган астына кереп ятты һәм көлеп әйтте.—Синең янда йөз яшьлек бабай да тик ятмас иде. Тәнең бик назлы, үзең кайнар...

Кыз тынып калды, дәшмәде.

Бераздан, үзалдына уйланып чалкан яткан Зөнәйдәнең күзе өй стенасына, тәрәзә белән почмак арасына aслы-өсле эленгән ике картинага төште. Картиналар гадәттә өй эчендә була, болар нигәдер верандада һәм, яки ашык-пошык кына, яки кайдадыр аунап ятмасыннар өчен генә эленгән сыман иде. Чөнки өстәгесе түшәмгә үк терәлеп тора. Бер картинада башларына очлымнар, тимер челтәр күлмәк-коба кигән, кулларына кылыч, сөнге, җәя тоткан борынгы сугышчылар

сурәтләнгән. Уртадагысы сөнгесен, муенын борып кырын караучы атының сыртына аркылы салган, чөнки үзе чукмар аскан уң кулын каш өстенә куеп еракка караган. Атлары да өч төрле: сул яктагысы—башын күтәргәне—ак төстә, уртадагысы—кара, ә өченчесе, сакалсыз яшь сугышчы атланганы—жирән кашка. Өчесе дә озын яллы, дәү атлар, каеш йөгәннәре, тезгеннәре бизәкле...

Ә икенче картинада ясалма буа яки күл, як-ягында агачлык, бер агач суда ук үсә, артта—ике катлы озын йорт.

—Габделнур абый, болар нинди картиналар?—дип сорады кыз.

—Өстәгесе—«Өч баһадир»—Васнецов картинасы, ә астагысын хәтерләмим кемнеке икәнен.

Картиналар майлы буяу белән киндергә төшерелгән. Ләкин гадәттәгечә бизәкле, сары рамнар белән әйләндереп алынмаганнар иде.

—Аларны кем ясаган соң? Кибеттән алынган дисәң, рамнары юк.

—Вакыт булмады. Рамлый алмадым.

—Бу рәсемнәрне сез ясадыгызмыни?

—Әйе. Техникумда безгә махсус фән керде, клуб бизәргә, лозунглар язарга өйрәндек. Анда безне бик яхшы художник укытты. Ә репродукцияләрне Әлмәттә ясаган идем. Ахырынача җиткереп булмады. Армияга китәр алдыннан апкайтып калдырдым.

Кызның егеткә булган соклануы тагын да арта төште. Баягы гамәле онытылмаса да, ул аны гафу итте һәм хәзер аңардан курыкмый иде инде. Ул Габделнурга елышыбрак ятты. Егет аны кочагына алды.

...Габделнур ишек шыгырдаганга уянып китте. Ишектә әнисе басып тора иде.

—Улым, син кайттыңмыни?

—Әйе,—диде Габделнур юрган астыннан башын калкытып.

—Улым, әллә борының канадымы?

Һай бу ана кешене! Сизмиме соң, күрмиме соң?! Гөлзифа түти караватка таба килә башлады.

—Юк, юк, әни, канамады,—диде Габделнур тиз-тиз, чөнки кыз да уянган иде инде.—Бар, кер.

Егет юрганны өскәрәк тартты. Зөнәйдә шым булды—караватына сеңде. Гөлзифа түти верандадан чыгып китте. Габделнур үзен битәрләп алды. «Менә сиңа мә, веранда ишеген бикләмәгәнмен бит». Дөрес, ул эчтән бикләнми—келә куелмаган. Ә бит бик тырышса, Габделнур пәке очы белән өйалды ягыннан ишек тактасына аркылы беркетелгән шпингалетны да шудырып куя алган булыр иде. Аны кайтмаган дип уйларлар иде. Гел исенә килмәгән.

Таң беленгәндә, егет белән кыз, шыпырт кына киенеп, чыгып сыздылар.

Тыкрыкка борылгач, кыз:

—Габделнур абый, үзем генә кайтам,—диде һәм, җылы гына саубуллашып, китеп барды.

Солдат ишегалдына керде, велосипедны, әтисе күзенә чалынмасын өчен, бакчага кертеп, агач келәт белән кар базы арасындагы ышыкка яшереп куйды. Верандага кереп, әле Зөнәйдәнең кайнар тәне җылысын, хуш исен саклаган юрган астына чумды.

Иртән, җизнәсе килгәч (ә ул аның бабасына сиздермичә генә киләсен чамалаган иде), велосипедны машинасына салып җибәрде.

Үзенең дә яшь чагы булган Насиф кайнишен орышмады.

—Апаң бик борчылды, төне буе йокламады,—дип кенә әйтте.

## XXVI

Габделнур Әлмәт якларын урап кайтты. Абыйларында кунак булды. Рәйсәне дә күрү нияте бар иде. Ләкин аны, бәби үстерә, әле эшкә чыкмады, диделәр.

...Габделнур Казанга китеп барды. Урак өсте булса да Галләм абзый улын район үзәгенә илтеп куйды. Юл буе сөйләшеп бардылар.

Ата кеше җай белән генә уртанчы малаеның «колагына киртләп кую»ны

кирәк санады.

—Улым, юк-барга кызыкма. Эшләп алырга тырыш. Эшләмәсән, беркем дә китереп бирми. Аз булсын—үзеннеке булсын. Безнен нәсел гомер-гомергә үз көнен үзе күргән: иген иккән, мал-туар асраган. Бабаннар берсе дә кешедән ким-хур яшәмәгән...

Аннары әти кеше, әллә онытып, әллә тагын исенә төшерү өчен, улын армияга озатканда әйткән сүзләрне кабатлады.

—Монарчы йөзгә кызыллык китермәден, анысына рәхмәт. Моннан сон да шулай булсын. Син олы юлга чыктын. Мин юлларны күп күрдем. Кайчак тар гына грунтовой юл да тип-тигез була, кайсы төштә—кин шоссейка, асфальт та сикәлтәле. Тормыш та шулай. Алдын-артын карап йөр, сак йөр. Курыкма, әмма чит-ят жирдә икәненне онытма. Кемнәр белән бәйләнәсен—аны да кара. Кем чанасына утырсан, шунын жырын жырлыйсын. Әйбәт йөр. Кеше көлдерерлек булмасын...

Аэропортта Габделнур:

—Әти, рәхмәт!—диде.—Самолетны көтеп торма инде. Эшнен тыгыз вакыты.

—Ярар, улым, исән йөре. Үз жаенны үзен карарсын инде... Түлке, кая барсан да бер кояш—чыга да бата, улым, эшләргә кирәк. Әйбәт йөр. Мәһрүсә апаннарга сәлам әйт.

Анын күзләре дымланды. Машинасына кереп утыргач, солдат улына янә бер карап алды да, әкрен генә кузгалып китеп барды.

...Казанда Габделнурны күнелсез хәбәр көтә иде: югары уку йортынын биек, авыр имән ишеген каерып ачарга анын көче житмәгән, дөресрәге, солдатнын борын төбендә генә ишек шапылдап ябылган икән.

Күрше район егете Ирек белән коридорда, белдерүләр тактасы янында очраштылар. Ул Габделнурны колач жәеп, кин елмаеп каршылады. Алар имтихан биргәндә танышканнар иде.

— Сәлам, Старый,—диде ул.—Фамилиян юкмы?

Ирек ана үз итеп, старый (ягъни, «картлач», карт солдат дип эндәшә иде).

—Күренми.

—Мин дә таба алмадым. Әллә берәрсеннән күзлек сорап торырга микән. Бәлки бик кечкенә хәрефләр белән язылгандыр.

—Лупа белән карасан гына инде. Юк әйберне алай да табып булмас. Карангы бүлмәдә кара песине таба алмаган кебек.

Алар елмаерга һәм шаяртырга тырышып (үз-үзләрен алдап), сер бирмичә кыланып сөйләшсәләр дә, эчләрен корт кимерә—кемгәдер, нииндидер үпкә сизелә иде. Өмет баглап кайттылар бит, тырышып-тырмашып имтиханнар бирделәр һәм нәтижәсе... Ә бит кемнәрдер кергән! Кемнәр икән ул бәхетле студентлар? Кем балалары икән?

—Мат якасына, эткәй әйтмешли, керербез әле!—диде Ирек кул селтәп.—Авылда ничек? Әти-әниеннәр исән-саумы?

—Әйбәт.

—Минем әнкәй чирләп тора әле.

—Шулаймыни? Урын өстендә ятамы?

—Больницадан кайткан, йөри инде.

Бераздан кабат уку турында сүз куерттылар.

—Карале, Ирек, безнен егетләр арасыннан керүче бар микән?

—Бер сержант үткән, диделәр.

—Не густо.

Әйе, керү бәхетенә ирешкәннәр башка уку йортларында да бармак белән генә санарлык булып чыккан. Балл житмичә конкурстан узмаган икс йөзләп солдат-матросны кире үз частьларына озатмадылар (күп булса, ике-өч ай хезмәт итәселәре калган иде) Кремльдәге дивизиягә беркеттеләр. Бу дивизия кадрированный санала: офицерлар—күп, солдатлар—аз. Алай-болай мобилизация башланса, офицерлар ике дивизиягә житәрлек, ә солдатлар, сержантлар запастан чакырыласы икән. ...Өч ел эчендә берничә тапкыр урын күчеп йөргән Габделнур бу частьтагы тәртипләргә дә тиз ияләште.

...Язга чыккач, алар частенә вербовщиклар сукмак салды. Берсе Мәскәүдән булса, икенчесе Ленинградтан, калганнары Ярославль, Горький ише кечерәк шәһәрләрдән... Штабның бер бүлмәсенә быел хезмәтен бетерәсе солдат-матросларны жыялар да сөйли-кызыктыра башлыйлар.

—Безнең завод фәлән төрле әйбер чыгара... Безгә токарьлар, фрезерчылар һәм башка һөнәр ияләре кирәк. Әгәр һөнәрегез булмаса, без сезне ике-өч айда өйрәтәбез; уртача эш хакы түлибез... Укырга теләсәгез, безнең заводның үзендә үк институтның кичке филиалы эшли. Бик әйбәт тулай торагыбыз бар. Йөргән кызларыгызны да чакырта аласыз, аларга да эш табарбыз. Яңа өйләнешкәннәргә аерым бүлмә бирәбез, фатир чиратына куябыз. Балалар бакчасы, ял базасы, санаторий һәм ял йортлары, спорт комплексы...

Кыскасы, риза гына бул: беренче көннән үк ожмахта яшисең! Әле, подъемный дип аталган акча да биреләчәк икән. Кайберәүләр, бигрәк тә авылдан хезмәткә алынганнар, ризалашып, килешүгә кул куйсалар да, Габделнурның кайдадыр еракта яшисе килмәде.

...Икенче көнне Болак буендагы мунчага барып юындылар, эчке киемнәрен, ә казармага кайткач, урын-жир алыштырдылар. Төштән соң шәһәр стадионында футбол уены бара иде, монда хезмәт иткән бер солдат каяндыр юнәткән бинокльдән, тәрәзә аша чиратлашып футбол карадылар.

Стадионның яшел чирәмле кыры да, анда бер туп артыннан йөгерешкән егерме уенчы да, корбанына сикерергә әзер торган леопард кебек житез, кулларына күн перчатка кигән капкачылар да, эскәмияләрдә очынып-очынып утырган жанатарлар да—барысы да моннан аермачык күренә икән.

Бераз карап торгач, Габделнур бинокльне янәшәсендә түземсезлек белән чират көтүче солдатка бирде. Сул кул яктагы вокзал тирәләрен, уң яктагы Казансу аша салынган күперне һәм аның артындагы эреле-ваклы йортларны ул гади күз белән генә күзәтте. Шәһәрдә яшеллек күп булуына игътибар итте. Ә каршыда, еракта-еракта киң Идел жәйрап ята, аның уң яры Ослан тавына терәлеп ага. Янәшәдә, Кремль диварлары артында, йортлар тезелешкән, фабрика корпуслары монсуланып утыра.

Шимбә көн, «ирекә» чыккач Кремльне сәйрән кылып йөрделәр. Чөнки әле аны карарга вакыт тимәгән иде.

Ике ягында да тәбәнәк кенә яшел чыршылар үсеп утырган юлдан киттеләр. Сул якта казарманың өч катлы озын бинасы сузылып бара, ә каршыда—чиркәү калдыгы, аның артында Сөембикә манарасы күренә.

—Бәттәч, бу ава бит!—диде Ирек аңа таба якынлашкач.

—Дәүләте жимерелгәч, манарасы гына исән калмас инде,—дип көлемсерәде Габделнур.—Әле ничек тора диген. Озакламый бу Пиза башнясына әйләнәчәк.

—Менә, туристларга тагын бер экспонат.

...Габделнурга икенче төнне тынычлап йокларга ирек бирмәделәр. Кем диген? Өченче елын тутыручы солдат, мондагы каптерщик.

Кичке аштан соң Габделнур йомыш белән каптеркага керде. Чөнки чемоданнар шунда саклана. Ул конверт белән кәгазь алып, чыгып барганда, каптерщик дәште.

—Утыр әзрәк.

—Нәрсә?

Калын иренле, түм-түгәрәк симез битле, сары мыеклы, кыска муенлы Ильяшенков үзе дә соңгы елын хезмәт итә иде. Ул буйга Габделнурдан бераз кайтышрак, ләкин аңа караганда ярты гәүдәгә тазарак. Бигрәк тә аның ботлары һәм арты, егетләргә хас булмаганча, симез иде. Әле монарчы аралашкан солдат түгел. Шулай да, сангa сугып эндәшкәч, Габделнур туктап калды. Ул күрсәткән урынга утырды.

—Миндә шешә бар. Саласыңмы?

—Әйдә,—диде Габделнур бик исе китмичә генә.

Каптерщик ишекне бикләде, тумбочка өстенә ризык чыгарып куйды: сыр, колбаса, ипи. Алар янына ачылмаган ярты да кунаклады.

—Мин хәрби училищеда укыган идем, Ульяновскида,—диде ул өстәл

хәстәрләгәндә.

—Анда нинди училище?

—Элемтә. Ләкин китәргә туры килде. Германиядә хезмәт иттем, монда тәгаллим. Әйдә, якынрак утыр. Яратам укымышлы егетләрне.

Анын сонгы сүзләренә Габделнур игътибар итмәде.

Ильященков, шешәне ачып, ике кружкага аракы салды.

—Нәрсә өчен эчәбез?—дип сорады Габделнур.

—Синең исәнлеккә,—дип елмайды коптерщик һәм, калын иренле олы авызын зур ачып, кружкасын бушатып та куйды.

—Дембель өчен!—дип Габделнур да кыстатып тормады.

Гәп хезмәт, өй хәлләре, уку тирәсендәрәк барды.

—Син армияга хәтле кайда эшләден?—дип сорады коптерщик һәм, җавап алгач, дәвам итте.—Мин ресторанда официант булып эшләдем. Анда бөтенләй икенче тормыш...

Ул тагын кружкаларга аракы койды. Ләкин аларны бушатуга, коптерка ишеген шакыдылар. Ильященков, тумбочка өстенә гәзит каплап, барып ишекне ачты. Рота старшинасынын озын буе күренде. Ул керде, тумбочкага күз ташлады, тукмак борынын җыерып, иснәде.

—Сез нәрсә?

—Юк, иптәш старшина,—диде коптерщик үз урынына утырып.—Болай гына сөйләшеп утырабыз.

—Ә-ә,—диде старшина, ләкин үзенен чыгып китәргә исәбе юк иде.

Габделнур торып басты.

—Утырыгыз, иптәш старшина,—диде дә, бер киштәгә куелган конверт белән кәгазен алып, чыгып китте.

Кич белән, гадәттәгечә, отбой алдыннан кичке прогулкага чыктылар. Бөтен Кремльне көр тавышлы солдатларнын җырлары янгыратты.

Не плачь, девчонка,
Пройдут дожди;
Солдат вернется,
Ты только жди.

Анысы бетүгә, мәнге популяр булып калачак «Катюша» авазы ишетелде.

Аннары бәләкәй генә юантык гәүдәле бер әзәрбайҗан егете, җир буе сузып, үз телендә ниндидер җыр башкарды. Габделнур, үзалдына елмаеп, теге солдатны җәлләп тә куйды. Частька берүзе килеп эләккән бу егетне ул әле яклап та маташты.

Беркөнне казармада моны солдатлар төркеме уратып алган да үртәпме үртиләр

—Ашур, синең апаң бармы?

—Бар.

—Мин синең апанны ниттем.

—Кирәкми! Алай әйтмә!

—Ә синең йорт кенәгән бармы?

—Бар.

—Мин шуны фәлән иттем.

—Нигә алай әйтәсен? Әйтмә андый яман сүз!

—Ә синең хатынын бармы?

Калын кашлары кушылып үскән тулы битле көньяк баласы—беркатлы бәндә һаман боларга ышана, мәрхәмәт яки теләктәшлек көтеп, сорауларына дөрес җавап биреп тора.

—Бар.

Шунда кемдер такмаклый: «Спасибо Сулейману, помогал мне беда, пока я в армии служил, целовал моя жена».

Шул чакта каратут йөзе кызарып-бүртенеп чыккан, еларга җитешкән мескен егетне яклап бер-ике сүз әйткән иде Габделнур.

Ә кичке прогулкада аны һәрчак җырлаталар, кызык өчен. Чөнки ул озын

жырның сүзләрен анламыйлар, аяк атлаган көйгә ритмы да туры килми. Егет исә карышмый, иренмичә жырлый. Бүген дә анын үз илендә тау-таш арасында еш янгыраган монлы, янгыравык авазы калын диварларга сыеша алмыйча ерак-еракларга—Казансу буйларына тарала, Кремль астындагы туку фабрикасы цехлары түбәсенә инә иде.

Бу карусыз тырыш егет бүген урысча да жырлап жибәрде. Анын жыры, әлбәттә, үзенен газиз туган ягы, күнеленә хуш шәһәр—Баку турында иде.

...Я полюбил тебя, родина огней,
Гордятся все друзья доблестью твоей,
Над вышками горит счастье твоих дней.
Ты—город красоты,
Ты—славы и мечты,
Мое богатство—ты,
Баку родной.

Казармага керделәр. Кичке барлау үттеләр. Солдат халкы өчен иң кадерле, ягымлы команда бирелде.

—Отбой!

Хәер, тагын берничә колакка ятышлы сүз бар икән әле: иртәнге аш, көндезге аш, кичке аш.

Старшина чыгып киткәч, кемдер кычкырды:

—Теш!

Икенче тавыш аны куәтләде:

—Тарт!

Һәм, мылтыктан аткан кебек үк булмаса да, йөзтүбән яткан берничә солдатның салют биргәне ишетелде. Фейерверк кына күккә чөелмәде.

Кемдер сөенеч белән әйтеп куйды.

—Көн үтте!

Икенчесе шатланып җавап кайтарды:

—Хрен с ним!

Берәү стенадагы, ә калганнар тумбочка өстендәге бәләкәй календарьлардан бүгенге көнне аеруча зур тырышлык белән матур итеп сызып ташладылар.

Юка одеал ябынып яткан таза тәнле, сәламәт егетләр күршеләре белән тегене-моны сөйләшкәләделәр дә бераздан тонык ут яктысында тирән йокыга талдылар.

...Габделнур кисәк уянып китте. Өстенә нидер килеп төшкән кебек булды. Ул күзләрен ачты. Бернәрсә дә аумаган, ә янына кемдер килеп яткан икән. Юньләбрәк караса—коптерщик.

—Тебе чего?—диде Габделнур ачу белән.

—Не шуми. Хочу молока.

—Чего?

Ильященков итләч кулы белән анын бот арасына үрелде. Берни анламаган Габделнур, ике аягын да берьюлы тездән бөгеп, арткарак авышты да, аркасын стенага терәп, тегенә тибеп жибәрде.

—Иди на...!

Симез гәүдә лапылдап идәнгә барып төште.

—Ладно, ладно, не шуми!—диде моны көтмәгән коптерщик һәм көчкә санын жыеп идәннән торды да, ары китеп барды.

Габделнур бик авырлык белән йокыга китте. Иртән ул, юынгыч янында төнге хәл турында Ирекkә әйтте. Дустының бер дә исе китмәде, тешен чистарта торган жиреннән пырхылдап көлеп жибәрде: авызыннан сыек ак порошок белән бергә щеткасы да атылып чыкты.

—Син белми иденмени?

—Нәрсәне?

—Ильященковнын нинди икәнен.

—Каян белим.

—Алайса мин сина әйтергә онытканмын. Аны мина беренче көнне үк житкезделәр. Аны училищедан да шунын өчен куганнар бит.

—Ни өчен?

—Да, син күрәм, бөтенләй профан. Ул егетләр ярата, артын бирә.

—Менә...—дип сүгенеп алды Габделнур.—Ә мин анын белән коптеркада аракы эчеп утырам тагы.

—Ахыры ни белән бетте соң?—дип сорады Ирек кара төкле битен кырыну өчен сабынлап.

—Старшина керде дә, чыгып киттем.

—Синен—бәхетен, анын—бәхетсезлеге,—дип авыз ерды Ирек.

Салкын суга манчылган юеш сөлге белән тәнен ышкып торучы Габделнур жирәнеп идәнгә төкерде.

—Кичә үлгән булсам, белмичә үләсе икәнмен. Зараза... Өч елга беренче күрәм андый шакшыны.

## XXVII

Тагын ике атнадан аларны өсте ябык машиналарга утыртып, Казан тирәсендәге бер хәрби лагерьнын берсенә илттеләр.

Каен урманы эченә урнашкан бу лагерьда тактадан гына әмәлләнгән, элек офицер дачалары булган жыйнак өйләр, зур-зур казармалар, озын барак рәвешендәге ашханә, чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган складлар һәм тыл хезмәте өчен кирәкле бүтән биналар бар иде.

Монда сасы, тынчу шәһәр түгел инде, күкрәк тутырып саф һава сулыйсын, табигатьнен гүзәл бер почмагына карап хозурланасын. Каеннар әле яшеллеген жуймаган, шулай да арада сары яфраклары да бар. Алар, башкалардан аерылып, виноград тәлгәшләре кебек ботагы-ботагы белән асылынып тора.

Лагерьда хезмәт бүтәнчәрәк икән. Иртәгесен, монда карантин узып, чит илгә озатыласы, яна гына хезмәткә алынган «такыр башларны» китереп тутырдылар.

Габделнурлар аларны, корал сүтеп, майлап, янадан жыеп, озак саклау өчен консервациягә салырга өйрәттеләр. Яшь сугышчы курсын алар шушы лагерьда үтәләр, ант кабул итәргә әзерләнәләр иде булса кирәк.

Әмма бу «салага»ларны «карт»ларга беркетү—сонгылары өчен мач килде. Чөнки яшьләрнен әле өйдән ата-аналары биреп жибәргән «сәмән»нәре бар, ә үзләренен каядыр чыгып йөрү мөмкинлеге юк диярлек. Үзләре өстеннән командалык итүче Машкин фамилияле капитан белән дә бик тиз уртак тел таптылар «картлар», чөнки ул тамак чылатырга ярата икән.

—Иптәш капитан, увольнительный кирәк иде,—дип үтенде өч елын да Казанда хезмәт итеп үткәргән солдат Гена.

—Нинди сүз булуы мөмкин?!—диде офицер гамьсез генә.—Кемгә?

—Ковалевка.

Ни өчен икәне анлашыла иде. Капитан артыгын төпченеп тормады, өстәл янына килеп, артсыз урындыкка утырды да, аркылы-торкылы каешлар белән чолганган куе яшел гимнастеркасынын түш кесәсеннән кәгазь-каләм алып, язарга да керешге.

Колгадай озын буйлы, ябык йөзле, кылыч борынлы Ковалев, анын янәшәсенә утырды. Капитан ана ярты бит зурлыктагы кәгазь тоттырды.

—Патрульгә очрамаска тырыш, киемен тәртиптә булсын.

—Есть, иптәш капитан!—дип Ковалев урынынннан кузгалды, егетләргә күз кысты, сөйләшкәндә анын тамак алкасы уйнаклый иде: әле югары күтәрелә, әле аска төшә.

Бөтен йөзен кара төк баскан Гена тагын Машкинга сүз катты.

—Иптәш капитан, кичке аштан сон безгә керерсез.

—Яхшы,—диде тәбәнәк юантык гәүдәле, кып-кызыл йөзле офицер.—Яшьләр дә буламы?

—Әйе, акча аларныкы бит,—дип сүзгә кысылды тәбәнәк гәүдәле, йөргәндә, җир үлчәгән кебек, олы атлап йөрүче Вася исемле солдат.

—Булса соң,—диде капитан илтифатсыз гына.—Әйдә без болай итик...

Һәм ул үзенең планын сөйләп бирде. Карт солдатлар берсүзсез ризалаштылар.

...Кич белән, билгеләнгән вакытка, яшьләрне чакырдылар. Алар бишәү булып чыкты. Кайсы өстәл тирәли урындыкларга, кайсы тимер челтәрле койкаларга утырышты. Монда хуҗа кеше—Гена—калай кружкаларга көндез Ковалев Казаннан биштәр капчыгы белән алып кайткан аракының ике шешәсен бушатты.

Ул, як-ягына каранып:

—Ковалев кайда соң?—дип сорады.

Ирек аңа:

—Ул монда гына,—диде елмаеп.—Әллә Казанда ярамаган нәрсә ашаган, понос ахры, эчен тотып чыгып китте. Хәзер керер.

Гена, бил каешын ычкындырып, үзенең караватына ташлады, гимнастерка изүен чишеп җибәрде, йонлы күкрәгән юан бармаклары белән кашып алгач, кружкасын кулына тотты.

—Ну, күтәрдек!—диде ул көр тавыш белән һәм берәм-берәм калганнар белән чәкеште.—Безгә—исән-имин өйләргә кайтып җитәргә язсын, сезгә—хезмәт итәргә...

Генаның кружканы авызына китерүе булды, шулчак кинәт ишек ачылды һәм анда капитан Машкинның кызгылт йөзе күренде. Ул алга таба кискен хәрәкәт ясап килеп тә керде, кычкырып та җибәрде.

—Нәрсә бу? Эчү мәҗлесе оештырдыгызмы?

«Картлар» урыннарыннан сикереп тордылар, төзәтенә башладылар: кем каеш буа, икенче берәве пилотка кия, өченчесе гимнастерка төймәләрен эләктерә. Аларга охшарга тырышып бераз тугарылып утырган яшь солдатлар да, офицерны күрү белән, аракысын чөмерергә өлгерми калган кружкаларын өстәлгә куеп, сикереп тордылар, гимнастеркаларының болай да озын итәкләрен тарткаларга тотындылар, муен турысындагы сәдәфләренә үрелделәр.

Машкин җикеренүендә булды:

—Кем сезгә рөхсәт итте? Безобразие...

—Гаеплебез, иптәш капитан,—диде хуҗа «картлач» аклана-аклана.

—Яшьләр дә монда?—дип акырды яшелле-зәңгәрле тавыш белән офицер.—Бер атна хезмәт итәсез, инде тәртип бозарга керештегезме? А-ну-ка марш!

Ул шулай дип, броневикка басып нотык сөйләгән Ленин бабай кебек кулы белә ишеккә күрсәтүгә, дер калтырап торган яшь солдатлар, бер-беренә һәм ишек борысына бәрелә-сугыла, калын табанлы өр-яңа олы кирза итекләре белән лап-лоп басып, чыгып йөгерделәр.

Алар юк булгач, баядан бирле көчкә чыдап, тыелып торган карт солдатлар, эчләрен тотып, сыгылып төштеләр, бүлмә яңгыратып көлә башладылар. Машкинның да авызы ерылды.

—Ну, ничек соң, әйбәт уйнадыммы?

—Шәп!—диде Ирек.

—Чын артист икәнсез, иптәш капитан,—дип мактады аны Вася.

—Талант әрәм булып ята,—дип капитанның салпы ягына салам кыстырды Габделнур.

—Монда ул «маңка»ларга әрәм итә торган аракы юк,—диде офицер күнеле булып һәм бер кружканы кулына алды.—Тутырып сал.

Хуҗа ул кушканны үтәде. Шулчак ишектән, башын ия төшеп, Ковалев керде. Ул да чыдый алмыйча көлә иде.

—Мин чак кына бәдрәф чокырына егылып төшмәдем,—диде ул.—Чыдап кына булмый тегеләрнең элдерүенә. Анда берсе, мәтәлеп, аягын сындырды бугай.

—Нәрсә?—диде кружкасын әле генә авызына каплаган капитан.

Аракы ялгыш юлга китте булса кирәк, ул чәчәде.

—Юк, юк, иптәш капитан, шаярып кына әйттем,—диде тиз генә Ковалев,

арттырыбрак җибәрүен сизеп, һәм үзе дә кружкага үрелде.—Ул «салага» нәрсәгәдер абынып егылды да тагын торып йөгерде. Мин ярыктан карап тордым.

—Ну и у тебя шутки... пол-хрена в желудке...

Гена капитанга су бирде, олы тәлинкә тулы итне ана табарак этәрде. Өстәлдә алма, тозлы кыяр, колбаса белән ипи дә бар иде. Тагын берәрне тоттылар. Ковалев үзенең калын тавышы белән җыр сузып җибәрде.

Що ты меня пидманула,
Що ты меня пидвила.
Що ты меня молодого
С ума, разума свела.

Ул Киевта, украин егетләре белән хезмәт иткән һәм кирәксә-кирәкмәсә дә алардан отып алган сүзләрне кушып җибәрергә ярата иде. Өйрәнгән бер җыры да бар икән.

Җырны белгәне дә, белмәгәне дә күтәреп алды. Бәләкәй генә дача йорты киңәеп, зураеп киткән сыман булды. Җырлау дәвам итте. Бу юлы Гена башлады. Аның тавышы, Ковалевныкы шикелле үк калын булмаса да, ярыйсы гына яңгырады.

Поишь меня, поишь меня
Горячим чаем.
За что тебя, за что тебя
Я уважаю.
Эх подружка, моя большая кружка,
Полулитровая моя!

Аңа да бердәм кушылдылар. Чөнки хәрбиләр арасында кин таралган, өч ел буена солдаттан аерылмаган кружкага мәдхия укыган җыр иде бу.

Әлбәттә, гармун булса, Габделнур аны тартып җибәрер иде. Ләкин мондагы хезмәт урыны вакытлыча, җәйлеккә генә көйләнгәнлектән, андый нәрсә юк. Шуңа күрә ул да җырга кушылды, анысы беткәч, үзе үк икенчене башлап җибәрде.

В нашем батальоне все равны:
Русские, татары и хохлы.
Есть бойцы любого сорта,
Есть бойцы смелее черта,
Есть бойцы упрямы, как ослы.

Габделнурдан соң Ирек татарчага күчте.

Оныт мәшәкатьләренне.
Оныт, оныт беразга;
Сыйпап-сыйпап чәчләремне
Бер иркәлә, бер назла.

Кушымтасын Габделнур белән икәү урысча җырладылар.

Садись рядом, ко мне, милый,
Сердцу будет веселей.

Икенче тапкыр кабатлаганда барысы да күтәреп алды.

Әлеге җыр беткәч, Гена:

—Мин дә татарча бер җыр белә идем,—диде.—Хәзер искә төшерәм.

Ирек:

—Ә син каян беләсең аны?—дип сорады.

—Бездә татарлар күп бит, тоташ татар авыллары бар. Мин техникумда укыганда тулай торакта ике татар егете белән бер бүлмәдә яшәдем. Җырны шулардан отып алган идем.

—Нинди җыр соң ул?—дип төпченде Ирек.

Гена серле генә:

—Җырлагач белерсең инде.—диде.—Хәзер... искә төште.

Агыйдел каты ага,
Рәхмәт яусын Гатага;
Иртән торсам, сиеп куйган
Минем киез катага.

Габделнур, капитанга карап, җырын сүзгә-сүз тәрҗемә итеп биргәч, барысы да көлештеләр.

—Молодец, Гата!—дип кычкырды капитан Машкин стаканга үрелеп.

Габделнур:

—Ә мин мордвача җырлый беләм,—диде.—Тыңлагыз.

Мәтик, мәкри, мәтик, мәкри,
Мәтик, мәкри, нысалак.
Ним мәтик, мәкри нысалак,
Пынгас әгмек нысрарак.

Гена, җилкәләрен җыерып, башын кыңгыр салып, ни дияргә белмичә аптырашта калды.

—Юк, мин андый җырны белмим,—диде ул ахырда.—Бер сүзен дә аңламадым. Хәер, мордва ике халыктан тора: эрзя һәм мукшы. Мин—эрзя. Бәлки бу мукшылар җырыдыр? Без бер-беребезне аңламыйбыз.

Габделнурга эшнең нәрсәдә икәнен сөйләп бирергә, серен ачарга туры килде.

—Без мәктәптә укыганда еш кына концерт куя идек. Анда таләп шундый: төрле милләт җырлары булырга тиеш. Гап-гади татар авылы. Урысчадан башка бер халыкның да җырын белмибез. Анысын да белмәс идек, урыс теле укытучыбыз маржа иде. Менә шул: бүтән милләт җыры дип, без, татар җырын, сүзләрен киредән укып җырлый идек. Мин җырлаган татарча болай:

Китәм, иркәм, китәм, иркәм.
Китәм, иркәм, каласың.
Мин китәм, иркәм, каласың,
Сагынып кемгә карарсың?

—Ну хәйләкәр дә бу татарлар!—диде капитан Машкин көлеп.—Ә шулай да батыр халык! Юкка гына, один татарин в две шеренги становись, димиләр. Гена, ә син беләсеңме, армияда мордва егетләренә ничек әйтәләр?

—Беләм,—диде Гена теләр-теләмәс кенә.—Эй, мордва, стой по-два, я—чуваш, командир ваш.

—Дөрес.

Гена, булган—булсын инде, диде бугай, такмаклап та күрсәтте:

—У мордовки—поперек, у татарки—бритая.

—Ә безгә барыбер: аркылы булса ни, буйлай булса ни,—диде Ковалев.

Монысы бөтенесенә ошады, көлештеләр.

Офицер Габделнурга карап:

—Бүлдердек,—диде.—Дәвам ит.

—Бетте инде. Шулай итеп без бик күп милләт вәкилләре булып җырлый идек. Шәп ятлатканнар. Күрәсез, әле һаман онытмаганмын.

Бераздан офицер, сәгатенә карап, торып басты.

—Ну, егетләр, яраттым мин сезне!—диде ул күтәренке пафос белән.—

Гомумән, хезмәтне яратам! Күнелле сезнен белән!

Капитан, хезмәтне яратам, дип дөрес әйткәндер. Чөнки ул кечкенәдән Суворов училищесында тәрбияләнгән, хәрби училище тәмамлаган, кыскасы, гомеренен күп өлешен биленә каеш буып үткәргән чын гаскәри иде.

—Да, кстати, сез похмельдән нишлисез?—дип сорады капитан һәм җавап көтеп тормастан түш кесәсеннән бер кәгазь кисәге тартып чыгарды.—Безнен йортта бер спортчы егет тора. Кичә мина СССР һәм Чехословакия футболчылары белән хоккейчыларынын ничек баш төзәткәнен язып бирде. Тынлагыз. «Проснулсы Рагулин в Понедельник с Хмельницкого: в животе Колотов, в глазах Черни, во рту Сухи. Взял Копейкина и Поспешил в гастроном, а там братья Холики и Третьяк. Взяли Сухи. Хорошевски, но Мальцев. Тогда взяли Краснецкого и пошли к Бабичевой. Он ее за Кохту, она—Недомански. Тогда он ей на Пузач и Горбатько Мотовилова промеж Белоножкина и появился Малофеев. Она: «Плати Альметьев». А он: «Хусаинов». Тогда она звонит в милицию и приезжают братья Майоровы со Старшиновым, а на поводке—Репс».

Солдатлар бүлмә янгыраттылар. Вася гына тыныч утырды.

—Ә син нигә бик житди?

—Иптәш капитан, мин кайчан көләргә иканен белмәдем.

—Жирафка да шулай сон барып житә,—диде колгасар Ковалев кәтәнә Васянын жилкәсеннән кагып.—Башын яшь, бераз үскәч анларсын.

Офицер төзәтенде: портупея каешларын тарткалады, гимнастерка төймәләрен каптырды, фуражкасын киеп алды.

—Рәхмәт, иптәш капитан,—диде Габделнур ихлас белән, чөнки хезмәт дәверендә ана офицерларнын төрлесен күрергә туры килгән иде.

—Гена,—диде капитан Машкин хужага мөрәҗәгать итеп һәм ун кулынын имән бармагын өскә күтәрде.—Тәртип булсын! Комендант ротасыннан патруль килгәнче жыештырыгыз.

—Есть, иптәш капитан!—диде Гена честь бирмичә генә.

Офицер, берни булмагандай төп-төз басып, туп-туры атлап, чыгып та китте. Аны аягүрә озатып калдылар.

Беркавым хезмәттәге мәзәк хәлләрне, кызык вакыйгаларны искә төшереп, сөйләшеп утырдылар да өстәлне жыештыра башладылар.

Шулчак урамда, тәрәзә каршында, кемнендер йомшак кына сызгырып, тавыш биргәне ишетелде.

Гена елмаеп әйтте.

—Әһә, кызлар килде.

Габделнур:

—Нинди кызлар?—дип сорады.

—Алар монда килгәли,—диде Гена Васяга карап, расла, дигәндәй.—Кем чыга? Дәртегез булса, барыгыз.

Ирек белән Ковалев бер-беренә караштылар. Габделнур дәшмәде.

—Үзем,—диде Ковалев.—Алар ничәү сон? Бәлки бөтенебезгә дә житәрлектер?

Гена көлде, тавыш килгән якка ымлады.

—Каян белим. Бар, санап кер.

Ковалев каешын буып, пилоткасын киеп, иелә төшеп чыгып та китте. Бераздан ул әйләнеп керде. Авызы ерылган иде.

—Дүртәү. Беребезгә житми.

Гена баш тартты. Башкалар, киенеп, «бәхет эзләргә» чыгып киттеләр.

...Габделнурга эләккәне—өлешенә тигәне—бик дәртле нәрсә булып чыкты. Ул солдатны, авыл хатыннары әйтмешли, алтынчы бүрәнәгә хәтле чөя иде. Егет астында ятканда ул, буш даманы янгыратып, аһылдый-уһылдый башлады.

—Ай! Ой! Уh!.. Войди в меня!.. Ah!.. Войди!.. Ah!.. Войди в меня!.. Ah, нинди рәхәт!.. Рәхәт!..

Эшен бетереп, үзләре йортыннан алып килгән матраска чалкан яткач, солдат бераз хәл жыйды. Анын чәчләрен сыйпап, янәшәсендә яткан кызга Габделнур:

—Нигә син ай буена ир күрмәгән хатын кебек кыланасың?—диде.

—Чыны да шулай. Мин монда сирәк киләм бит!

—Нишләп?

—Эшлим. Баламны карыйсым бар.

—Синең балаң да бармыни инде?

—Әйе. Ә син мине саф кыз дип уйлаган идеңме әллә?

—Юк. Карт күренмисең.

—Рәхмәт. Иртә бала таптым мин.

—Иреңнән аерылдыңмыни?

—Аның булганы да юк.

—Ә бала кемнән?

—Әллә тагы... Әллә солдаттан, әллә сержанттан—белми дә калдым,—диде хатын авыз чите белән генә ачы елмаеп.—Яшь чак, җүләр чак... Менә хәзер йөрим тилмереп... теләсә кем астына ятып...

—Нишләп, сиңа кем булса да барыбермени?

—Билгеле,—диде хатын ничектер ямьсез итеп авыз ерып.—Мине бер солдат биш тапкыр канәгатьләндерсә ни дә, биш солдат берәр тапкыр басса ни...

Хәтта Габделнур да, егет кеше булса да, хатынның бу сүзләрен килештермәде һәм уйлап куйды: «Авылда ветврач абзый, ата каз бер генә баса, дип әйтергә ярата иде. Дөрес әйткән икән. Күп ир-ат белән чуалса, хатын-кыз баласының кемнән икәнен дә белми кала шул".

Хатын сөйләвен дәвам итте.

—Ишеткәнең бар микән бу җырны: «Эх раз, еще раз, еще много, много раз, лучше сорок раз по разу, чем по разу сорок раз!» Их син, ефрейтор! Берегез дә безнең хәлне аңламый...

Габделнур шаярткан булды.

—Син солдатлар яратасың ахры.

—Әйе. Мин үзем дә солдат кызы,—диде хатын җитди төстә.

Габделнур аптырап калды. Кызыксынуы артты. «Кыек атып, туры тидергәнмен икән»,—дип уйлады.

—Ничек?

—Без моннан ерак түгел бер авылда торабыз, өч кенә чакрым. Сугыш вакытында әни шушы лагерьда кухняда эшләгән, посудомойкада. Аны бер повар солдат үзенеке иткән дә мин туганмын.

—Әтиең исәнме соң?

—Юктыр. Сугышка алып китәләр аны. Шунда хәбәрсез югала. Мин солдатларны яратам, ә сугышны—күралмыйм.

—Сез әниең белән икегез генәме?

—Әйе. Хәзер. Элек әбием бар иде. Үлде инде.

—Әйе-е, язмыш... Гафу ит.

—Бер кешегә дә әйтмәсәң, мин сиңа бер әйбер сөйлим.

—Бик яшерен сермени?

—Түгел дә... Сөйләргә дә ярамый. Аны үләр алдыннан әбием әнигә сөйләгән, ә ул—миңа.

—Тыңлыйм.

—Вәгъдә бирәсеңме?

—Эчемдә саклармын. Тешем сирәк булса да мин сер саклый беләм.

—Мин сиңа, сугышны күралмыйм, дидем. Әтисез калган өчен генә түгел... Минем әби... кеше ашаган...

—Нәрсә?

—Әйе. Ул сугышка хәтле Ленинградта яшәгән... бабай белән. Бабай инвалид булган, шуңа күрә сугышта катнаша алмаган, шәһәрдән дә китмәгән. Әби үзе киткән дә булыр иде, бабайны ташлап калдырмаган. Ә әнине сугыш чыккач та авылга озаткан, менә шушы хәзер без яши торган авылга. Әбинең туган авылы бу. Ә Ленинградта блокада башланган. Халык кырыла, ачлык... Бабай кырык өченең кышында үлә. Үләр алдыннан әбигә үзе әйткән.

—Нәрсәне?

—Мине ашарсың дип.

Габделнур—дары иснәгән, күпмедер дәрәҗәдә утны-суны кичкән солдат, шулай да бу сүзләрне ишеткәч, аның чәчләре кымыржып куйды; салкын суга кереп чирканчык алгандай булды—тәне чымырдап китте.

Хатын дәвам итте.

—Әби ул чорны сораштырганны һич яратмый иде. «Куй, куй, сөйләмим»,—ди дә утырып елый торган иде. Аның сәбәбе булган икән. Әби үләр алдыннан (ә ул, блокада беткәч, кырык дүртнең җәендә монда кайта) гына серен әнигә тишкән. Гомер буе үз-үзен гафу итә алмаган.

Бераз тын торгач, Габделнур:

—Нигә син моны миңа сөйләдең?—дип сорады.

—Үзем дә белмим. Син бүтәннәргә охшамаган: иркәлисең, матур сүзләр әйтәсең. Әллә ничек рәхәт булып китте. Абыем шикелле итеп тойдым сине. Мин абыйлы кызларга кызыга идем. Әтием дә булмагач...

Хатын, солдатның күкрәгенә капланып, беравык аны кочаклап ятты. Күз яшьләре гимнастеркасына тамды. Егет аның йомшак чәчләрен сыйпады, тирләгән аркасына кулын куйды.

Хатын кисәк кенә торып утырды.

—Әйдә, эчеп бетерик.

Тәрәзәдән төшкән тоныкъ яктыда ул үзе алып килгән очсызлы кызыл аракыны стаканнарга салды, чәкештерде. Эчеп куйдылар. Габделнур ризык капты. Хатын буш стаканнарны һәм гәзит өстендә калган ипи телемнәрен сумкасына салды. Сәгатенә карады.

—Мине кызлар көтәдер. Йә, хуш, мин киттем. Рәхмәт. Күңелемне күрдең.

Ул чыгып киткәч, матрасны каккалап, бөтереп култык астына кыстырды да Габделнур да үз йортларына юл алды.

Урман эче караңгы, ачулы җил агач башларын чайкалдыра, карасу болытлар түгәрәк айны каплаганнар һәм әкрен генә, гамьле кешеләрнең уйлары сыман, каядыр еракка-еракка агылалар иде.

## XXVIII

Икенче көнне, бүтән яшьләрдән акча җыеп, тагын шул ук рәвешле бәйрәм иттеләр. Әмма бүген кич тәрәзә каршында сызгырып йөрүче «сандугачлар» булмады.

Габделнур, урынга яткач, тиз генә йокыга китә алмады, нигәдер мондагы тормыш (моны хәрби хезмәт дип әйтергә тел әйләнми иде) турында уйланды.

Әйе, дөресен әйтергә кирәк, солдат өчен бу мохит—бик кулай, унай күренеш. Ләкин... «Армия нинди булырга тиеш?—дип фикер йөртте солдат караватында әле болай, әле тегеләй боргаланып ятып.—Менә шушындыймы: тәртипсезлек, эчү, хатын-кызлар белән типтерү... Әллә мин элекке частьларда хезмәт иткәнчәме?.."

Габделнур одеалын башына бөркәнде дә, ник чукынып китми дөньясы, дип саный башлады: «Бер, ике, өч... дисциплина... Менә сиңа авыртмаган башка тимер тарак,—дип, ул, тагын уйлана башлавына аптырап, одеалын ачып ташлады.—Миңа дисә... Әнә, егетләр инде гырлап йокыга киткәннәр... Нәрсәгә миңа юк белән баш катырырга? Оборона министры мәллә мин?!» Ләкин, юк икән шул, өч ел буена политзанятиеләрдә аның башына өзлексез тукылган уй-фикерләр эзсез генә югалмаган икән. Пионерда, комсомолда тәрбияләнеп, армиядә партиягә кергән егерме ике яшьлек егетнең башы уйламыйча гына тора алмый иде инде. Партиягә керүе дә фәкать үз теләге белән һәм изге дип саналган эшкә хәер-хаһ булудан, шул бөек идеалларга чын күңелдән хезмәт итәргә омтылудан иде бит. Армиядә (яки флотта, анысы барыбер) ана бернинди дә ташлама яисә өстенлек кирәкми, карьерага үрмәләү дә максат түгел. Бу гамәле тормыш-көнкүреш мәсьәләләрен хәл итүгә дә корылмаган.

Шуңа күрә, үз каланчасы югарылыгыннан торып, ул хәзер фикер йөртте:

көч-куәтен арттырып, дары иснәп, дөнья күреп, кайберәүләре гражданкада кирәге чыгардай һөнәр үзләштереп, һәм, иң мөһиме, ир-егет булып кайтучы солдат-матрос аңа якынрак. Солдат хезмәтенең дә төрлесе бар: берәүләр хуҗалык взводында дуңгыз карап вакыт үткәрергә дә риза, икенчеләр пешекче булуны хуп күрә, кемнәрнеңдер күңеленә стройбат якын, кайберәүләр кочегарка миченә көрәк белән ташкүмер ыргытып җылыда ятуны бәхеткә саныйлар, штабта писарь булып утыру—монысы инде оҗмахның җиләкләре күгенә ашу белән бер. Ләкин Габделнур андый урыннарда хезмәт итәргә атлыгып торучыларны өнәмәде, үзе—омтылмады. Алар турында ул: «ничек бөкре килгән, шул бөкре килеш кайтып китә», дип кенә җибәрә иде.

Чөнки Габделнурларга беренче көннән үк, хезмәт авыр булган саен мактаулырак, дип тәкрарладылар, миләренә сеңдерделәр. Хәер, ул моны алдан ук белеп килде. Хәрби хезмәт шулай булырга тиеш икәнен кечкенәдән үк укып-ишетеп үсте алар буыны.

Габделнур өчен армия—олы максат куеп, кулына корал тотып, мактаулы хезмәт итү. Моңа бәлки ул караган киноларның да тәэсире көчле булгандыр. Чөнки кинода һөҗүмгә баручы, юлында очраган дошманны куркусыз тар-мар итүче батыр солдат, берүзе өч-дүрт истребительгә каршы торучы яисә яна башлаган самолетын дошман колоннасы өстенә ташлаучы очучы, чокыр-чакырларны бар дип белмәүче һәм окопларны сытып-изеп алга ыргылучы танкист, соңгы патронына хәтле немецләргә ут яудыручы ялгыз пулеметчы, дошман позициясенә бәреп кереп үзеннән ике тапкыр авыррак симез офицерны—«тел»не аркасына салып алып кайтучы разведчик, буй-буй тельняшка киеп, тасмалы бескозыркасын кыңгыр салган киң күкрәкле, гайрәтле һәм кыю матрос гәүдәләнә иде. Сугыш чорында туган малайлар өчен алар үрнәк булды, ә кайдадыр артта сөйрәлүче обозларны, солдат-офицерларны ризык һәм башка кирәк-ярак белән тәэмин итүче интендантлык хезмәтен башкаручы солдатларны алар күрмәделәр һәм хәтта андый хезмәт барын башларына да китермәделәр.

Габделнурга төз буй-сын белән, чыныгып, тиешле срокны тутырып әти-әнисе янына, туган авылына, карчыклар әйтмешли, чын ясау булып кайтучылар якынрак иде. Әлбәттә, вакытында кайтучылар.

Кисәк кенә исенә төште: Кронштадтта, Флот экипажында, күчмә рота дип аталган подразделение бар иде. Анда Хәрби-Диңгез флотының төрле частьларыннан җыелган, кайсы кая озатылуны көтеп ятучы солдат-матрослар вакытлыча хезмәт итә, дөресрәге, җыелып ята иде. Шундагы бер матросны хәтерли. Ул яшьләр белән ярышып гер дә күтәргән иде әле... Ана ике ел дисбат бирәләр. Шуннан күчмә ротага кайтып төшкән чагы иде. Димәк, барысы алты ел хезмәт иткән ул... Дөрес, сугыштан соң җидешәр ел солдат шулпасы эчкәннәр дә булды. Анда барысы да тигез. Ләкин моның яшьтәшләре инде ике ел гражданкада бит. Кемгә кирәк булды икән аңа—дүрт ел авыр хезмәтне намуслы башкарган егеткә—шушы хәтле каты җәза бирү? Үзен тәртипкә чакыру өченме? Ә ул бит хезмәттән баш тартмаган. Башкаларга сабак булсын өченме? Ә бит аны өендә газиз ата-анасы зарыгып көткәндер, бәлки вәгъдәләшкән сөйгән кызы да, аңа тугры калып, дүрт елдан кайтырына өмет баглап, кияүгә сорап килүчеләрне кире боргандыр... Ә җәза бирүче теге мичман берәр төрле вөҗдан газабы кичерде микән? Үзен шушы матрос хәленә куеп карадымы икән? Әллә озак еллар тимер корабта яшәп, бәгыре дә тимергә әйләнде, бүтәннәр хәленә керә алмаслык, кешеләрне гафу итмәслек хәлгә килде микән аның? Бу вакыйганы күреп торган матрослар ничек хезмәт итте икән: курка-өркәме, әллә намус эше, гражданлык бурычы дип санапмы? Габделнурның ишеткәне бар: солдат-матросларны каты җәберләгән, берөзлексез чокчып торган сержант-старшиналарны, дембельгә бергә әләксәләр, поездан тотып ыргытулар да булгалаган. Шуңа күрә андый кансызларның күбесе үз кул астында хезмәт иткәннәрдән аерым рәвештә йә алданрак, йә иң ахырдан частьтан китәләр икән.

Ә икенче төрле фикер йөрткәндә, армияда каты дисциплина урнаштыру—

мәҗбурият. Шунсыз көчле армия була алмый, ул—анархиягә әйләнә. Армия яшьләрне тәртипкә, төгәллеккә, өлкәннәргә буйсынуга өйрәтергә, аларга жебегәнлек, йөгәнсезлек, курку, икеләнү, таркаулык кебек тискәре сыйфатлардан арынырга булышырга тиеш. Ир балалар мәктәп елларыннан ук ил терәге—аны саклаучы булырга үзләрен әзерләргә тиеш. Кыз баланы бизәгән сыйфатлар сафлык-инсафлык, гүзәллек-нәфислек булса, егет асылы—ул батыр, кыю, көчле, ватанпәрвәр... Ә командирлары нинди булырга тиеш? Әлбәттә, тәртип—алардан башлана. Үзе буйсына белмәгән кеше башкалардан буйсынуны таләп итә алмый.

«Мин болай артык күп уйласам, иртәнгә тикле йокыга китә алмам»,—диде Габделнур үз-үзенә һәм иплән кенә урамга чыгып кергәч, егетләрнең гамьсез тигез сулышына кушылып, тирән йокыга талды.

## XXIX

Лагерьга тагын яшьләр килде. Аларны, мунча кертеп, өр-яңа солдат киеменә киендерделәр: гимнастерка белән галифе, пилотка, кирза итек бирделәр, киң каеш буылдылар.

Гена, дусларын ияртеп, мунча тирәсендә кайнашты һәм арурак чалбар, күлмәк, костюм ише нәрсәләрне яшьләрне киендерүче старшинадан сорап алды. Старшина үзе дә күзе төшкән киемле егетләрне алдан ук чамалап-күзләп тора. Монда кием-салымның иге-чиге юк—барысына да житәрлек. Аларны соңыннан—сүсәргәнме, кияргә ярарлыкмы—аралап тормыйча барыбер өеп яндыралар.

Гена белән килгәннәрнең барысы да, култык астына шактый «товар» кыстырып, дача йортына кайтты.

—Минем белән кайсыгыз бара?—дип сорады Гена алып кайткан чүпрәк-чапракны идәнгә ташлап.

—Кая?

—«Сорочка»га, базарга, боларын сатарга,—диде Гена һәм идәндә яткан иске-москыны аралый башлады.—Үзегезгә ошаганнарын сайлап алыгыз, гражданкада беренче мәлдә ярап куяр.

Ул шулай дигәч, һәрберсе гомуми өемнән кулга тотардай ни дә булса алып, читкә куя башлады.

—Ишәкләрегезне алыгыз, үземнекен атам,—дип шаяртты Ирек һәм әлеге мәгълүм мәзәкне сөйләп бирде.

Генаның тәкъдиме жавапсыз калган иде.

—Мин барам,—диде Габделнур ярыйсы гына күренгән бер кара костюм һәм шакмаклы күлмәк алып.

—Мә, кепка да сиңа булсын,—диде Гена һәм ана ак фуражка сузды.

Габделнур, дөресен генә әйткәндә, Казанны әле юньләп белми, ә «Сорочка» дигән базар хакында беренче ишетүе иде. «Сорочинская ярмарка» дип кайдадыр укыганы бар иде. Шул микәнни? Ләкин сорарга кыенсынды. Ә менә янага омтылыш, беләсе килү теләге көчле булганлыктан, ул Гена белән барырга ризалашты. Апаларына да сугылып чыгу иде нияте.

Якшәмбе көнне, капитан Машкиннан увольнительный кәгазе алып, Габделнур белән Гена базарга юл тоттылар. Сатасы әйбер-караны кичтән үтүкләп, «адәм рәтенә керткәннәр» иде.

Сары яфраклар коелган сукмактан турылай гына олы юлга чыктылар. Моңсу каеннар, аларга хәерле юл теләп, тымызык жилдә тирбәлгән озын чукларын чайкалдырып, озатып калдылар.

Көн матур. Кәефе күтәренке. Габделнур жырлап жибәрде.

Әйдә, жаныем, базарларга,
Одеколон алабыз;
Тор, жаныем, таңнар ата,

Үбешә алмый калабыз.

—Анламадым,—диде Гена бик бирелеп, дикъкать белән тынласа да.

Дусты тәрҗемә итте. Көлештеләр. Ходайның рәхмәте—озак көтмәделәр. Бер миһербанлы шофер, машинасын туктатып, аларны кабинага утыртты.

Сентябрь ахыры житкән. Кояш саранлана башласа да әле ана зарланырлык түгел: лагерь белән шәһәр арасындагы басу-кырлар яп-якты, урылган игеннең камыллары сап-сары булып ялтырап ята, сөрелгән жирләр Габделнурлар авылындагы кебек чем-кара түгел түгелен, шулай да киләсе елга муллык вәгъдә итеп, күпергәннәр. Урман читендәге вак куаклар да, күккә ашып, биек-биек булып үскән һәм эчкәрәк утырган агачлар да инде саргайган. Миләш яфраклары, тәлгәш-тәлгәш булып салынып төшкән жимешләре төсенә—кызгылтка маныла башлаган.

...Шәһәр эчендә әллә ни үзгәреш юк: шул ук трамвай-троллейбуслар, автобуслар, биек таш йортлар, каядыр ашыгучы яки ялкау гына гомер сөрүче кешеләр... Хәер, агачлар монда да саргайган.

Компрессор заводы яныннан үттеләр.

—Бервакыт, мин үзебезнең частьта бирелә эшләнгән компрессор күрдем,—диде Габделнур.—Иллә рәхәт тә булып китте инде. Якташымны очраткандай сөендем. Корпусына кулымны куеп, сыйпап тордым. Күзләр яшьләнде. Егетләр көлделәр дә әле үземнән.

—Син бераз сентиментальрәк,—диде Гена гәптәшенә сокланып.—Хәер, мин үзем дә, бая басу-кырлар күргәч, әллә нишләп киттем, телдән яздым. Тизрәк кайтасы да эшкә керешәсе иде. Өч ел буе мондый тормыш туйдырды. Бигрәк тә минеке шикелле һөнәр иясенә бу тормыш—мәгънәсез.

—Илне сакларга кирәк бит кемгә булса да.

—Анысын мин аңлыйм,—диде Гена авыр сулап.—Барыбер... гаделсезлек күрәм. Миңа иген игәргә булсын... Ә синең уйлаганың бармы: безнең белән кемнәр хезмәт итә?

—Таза, сәламәт егетләр.

—Ә кем балалары? Берәр завод директорының, обком дип әйтмим дә, райком секретареның кадерле баласын күрдеңме?

—Анысы дөрес—юк. Ә бит аталары чат саен вәгазь укый: яшьләрнең ватанпәрвәр булуын тели, патриотизм хакында лаф ора, идеалларга тугрылык таләп итә... Бәлки алар бракоделдыр, малай ясый алмый торганнардыр.

—Ясамас. Әле ничек кенә... Монда берәү ялгыш килеп эләккән иде, КДН эчә башлады да, комиссовать иттеләр. Үзем күрдем дару эчкәнен,—диде Гена ачу белән.

—Бездә дә берәү астына жибәрә башлады, ә икенчесе постта торганда үзенә атты.

—Үлдеме?

—Үләр сина... Колагына әз генә эләккән. Юри эләктергән, билгеле. Кабат күрмәдек без аны. Кем баласы икәнен дә белә алмадык...

Габделнур, автобуста кысылып барса да, Гена әйткәннәрне уйламыйча булдыра алмады. Дөрес, аның белән хезмәт иткәннәрнең бөтенесе дә авыл малайлары түгел, Мәскәү, Ленинград кебек мәшһүр кала егетләре дә бар иде. Ул аларның фамилияләрен, күбесенең исемнәрен дә хәтерендә саклый. Ләкин нигәдер олы түрә баласы дип әйтерлекләре истә калмаган, күрәсең, булмагандыр. Мәскәүдән алынган Лавров Володя шофер иде, әти-әнисе—төзүчеләр. Постнов Вячеславның әнисе... ул да заводта мастер гына иде шул. Тресков—Горький шәһәреннән, үзе—шофер, жиңел машина чыгаручы завод эшчеләре династиясеннән. Литвадан килгән егетләрнең байтагы хуторлардан, икесе Каунастан, берсе Шауляйдан—гади халык балалары. Егетләр хәзер кайда, нишли икән бу минутларда?.. Юк, әле берсе дә китмәгәндер, дембель—сонрак...

...Габделнур, кабыргасына Гена төртүгә, уйларыннан аерылды. Төшәргә кирәк икән.

Уң якта авыл тибындагы поселок, аның артында, еракта, тау хәтле балчык

өемнәре. Алар әле соңгы елларда гына актарылып өелгән булса кирәк. Габделнурга алар Чупай тавында эшләгән елларны, андагы тау-таш өемнәрен хәтерләтте. Анда да карьер иде: таш катламы инде уникe метр тирәнлектә җир астында ята һәм өсте менә шушы рәвешле көчле экскаваторлар, бульдозерлар белән актарылып, кыш көне шартлатылып, читкә этәрелә иде.

Базар эчтәрәк, сул кул якта икән. Ана әле шактый барасы. Юл аркылы чыктылар һәм авыл йортлары кебек өйләр арасыннан, кечкенә сай елга аша салынган тар басмадан үтеп, тигезле-тигезсез бер урынга килеп җиттеләр. Биредә халык мыжгып тора: өзлексез алга таба агыла, тулгана, кайберәүләр каршыга килә, койма янында өелешеп тора, читтәрәк бер-ике машина, мотоцикл күренә. Капкадан базар эченә керделәр, монда да мәхшәр: койма тирәли әйбер сатучылар тора, ни-нәрсәләрен койма башына да элгәннәр, кулларында тоталар, катыргы кәгазьләр өстенә тезеп җиргә салганнар. Сүзләре аңлашылмаган сөйләшү тавышлары кәстрүлдә быгыр-быгыр аш кайнавын хәтерләтә, һәр тарафтан колакка кычкыру, сатулашу авазлары чалына, кайдадыр бер читтә гармун тарталар.

Габделнур түзмәде:

—Әллә гармун да саталармы?—дип сорады.

—Монда атаң белән анаң гына юк.

Әйбер дә күп, кеше дә. Халык чуар: картлар-карчыклар, абый-апалар, яшьләр... Сирәк-мирәк милиция фуражкалары да базар эчендә бутала, капка янында гына түгел. Кыскасы, бөтен Казан халкы монда җыелган диярсең.

Гена Габделнурның, телдән әйтмәсә дә, кая барасы килүен чамалады. Әйберләрен чыгарырга ашыкмады, ары китте. Гармун тавышлары отыры якынайды. Алар монда берничә икән: ике-өч тальян, хромка, баян, кыңгыраулы саратски да бар. Кемнең нинди көй уйнаганын аерырлык түгел, бөтенесе берьюлы тарта, товарын күрсәтә.

Габделнур иң кырыйдагы тальян янында туктады. Олы яшьтәге абзый, кыска юантык бармакларын җитез генә йөгертеп, бер озын көй уйный иде. Күренеп тора: кайчандыр оста гына гармунчы булган яки үзе гармун ясаучы-төзәтүче.

Ул, каршында ике солдат торуын абайлап, көен тәмамлады, күрекләрен кысып, гармунын ике куллап тотып тора башлады.

—Солдатларга гармун кирәкме әллә?

—Юк, абый. Әйбәт уйныйсың, тыңларга гына килдек.

—Шаяртма, солдат!—диде абзый һәм, сул кулы белән тар мыегын сыпырып, хәйләкәр елмайды.—Синең кебек егетләр гармун янында болай гына тормыйлар. Уйныйсың киләме? Мә.

Абзый, сул кулы белән уң як иңбашыннан каешын алып, гармунны Габделнурга сузды.

Бик матур иде тальян: буялган-бизәлгән, пөхтә эшләнгән, җизләре ялтырап тора, телләре перламутр яшел төстә, бакалары калай, биш планкалы...

Габделнур кыстатып-ялындырып тормады, каешын җайлап киде дә, уйнап та җибәрде. Татар халкының дәртле, һәркемгә таныш, бөтен кеше дә ярата торган «Баламишкин» көен сузды. Бу арада бик тупас физик эшләр башкармаганга бармаклары җитез йөгерә, өлгер һәм көйне дә дөрес тота иде. Тирә-яктагы гармун сатучылар да солдатка ихтирам йөзеннән уйнаудан туктадылар. Көй агылды да агылды, аны биек такта койма да тотып кала алмый, стенадай тыгын кеше ташкыны да туктатырлык хәлдә түгел. Ә өскә таба—сирәк болытлар йөзгән зәңгәрсу күк йөзенә ул язгы сабан вакытында яңгыраган тургай моңы кебек берништи киртәгә тап булмыйча өзлексез күтәрелә. Габделнурның үзенә дә рәхәт иде. Ләкин артык мавыкмады, кеше әйберсе белән озак файдалана алмыйсың. Тагын бер көй уйнагач, ул туктады. Гармунны хуҗасына бирде.

—Рәхмәт, абый.

—Үзенә рәхмәт,—диештеләр аны сырып алган яше-карты, чөнки кеше шактый күп җыелган иде инде.

Габделнур белән Гена кузгалып киткәндә абзыйның гармунын сатулаша да

башладылар.

Күрәсен, Генаның монда беренче тапкыр гына килүе түгел. Ул капкадан ун-унбиш адым гына читтәрәк торган бер юан апа янына килеп исәнләште, колагына нидер пышылдады, алып килгән әйберләрен берәм-берәм аның беләгенә салды һәм, тиешле әҗерен алып, китеп тә барды.

—Булды,—диде ул Габделнурга.

Алар капкадан чыктылар, кайту ягына борылдылар. Басмага житәрәк, бер читтә озын итәкле күлмәк, калын йон кофта, ачык изүле куртка кигән ике чегән хатыны бер кызны кысрыклап, ай-ваена карамыйча тарткалап-йолыккалап азапланалар иде. Моны ике солдат берьюлы күреп алды. Габделнур дустына дәште.

—Анда теге кызны кыерсыталар ахры.

—Әйдә барыйк әле,—диде Гена аның тел төбен анлап.

—Киттек.

Гена, тавышын юри калынайтып:

—Нәрсә бар монда?—дип сорады.

Авызына папирос капкан, чуар яулыгын чөеп бәйләгән чегән хатыны кул селтәде.

—Узып кит, чибәр егет, берни дә юк.

—Барыгыз, бар, служивые,—диде икенчесе дә.

Габделнур карашын кызга төбәде, яшьле күзләреннән, төс-битеннән чамалап, татарча дәшәргә булды.

—Нигә елыйсың?

—Ун сум акчамны алдылар,—диде кыз яклаучы булуга сөенеп, әмма елавыннан туктый алмыйча.—Хәзер алкамны сорыйлар. Бирмәсәм, бозым белән куркыталар.

Зәһәр хатыннарның тиз генә бирешергә, кулга керергә торган табышны ычкындырырга исәпләре юк иде, билгеле, алар кызга ябырылдылар: берсеннән-берсе уздырып такылдарга, көчек кебек чәңгелдәргә тотындылар.

—Мы тебе гадали... Баккан өчен алкамны да бирәм диден... Акчаңны үзең чыгарып бирдең... Мәрхәмәтле кешеләр, нәрсә инде бу? Без—намуслы чегәннәр!.. Ә сезгә ни кирәк? Үзебез анлашырбыз...

Алар бичара кызга алтын йөзек кигән карасу нәзек бармаклары белән чытырдатып ябышканнар. Ләкин солдатларның каты торуларын һәм киту исәпләре югын күргәч, кулларын бушаттылар. Шуны гына көткән кыз, кисәк тартылып алардан ычкынды һәм солдатларга таба омтылды. Аннары, икесенең уртасына ук кереп, беләкләренә чат ябышты.

—Зинһар коткарыгыз!—дип ялварды ул әле һаман сулкылдап.—Булышыгыз, абыйлар, ташлап китмәгез!

—Курыкма!—диде Габделнур кызга һәм Генага баш какты.—Киттекме?

Солдатларның берсенең калын кара кашлары җыерылган, йөзе усал, рәхим-шәфкать көтә торган түгел, икенчесе аннан бер башка калку, киң җилкәле—анысының да чыраенда иман нуры юк шикелле тоелды чегәннәргә. Күпне күргән, байтак мәтәвекләрдән исән-имин чыга торган булсалар да, солдатларга каршы кабат сүз әйтергә базмадылар. Аянычка (алар өчен), халык агымына ияреп, нәкъ шул минутта тагын бер хәрби узып бара иде. Бер хатын-кыз белән янәшә атлаучы бу офицер, солдатларны күреп, туктады, кеше ташкыныннан аерылып, алар янына килде.

—Солдатлар, нәрсә бар?

Тавышка борылып караган Габделнур белән Гена (алар халык йөргән сукмакка арт белән торалар иде, офицерның килгәнен күрмәделәр) башта бер мизгелгә югалып калдылар, аннан, тураеп, үрә катып, честь бирделәр.

—Иптәш майор, менә бу кызны талыйлар,—диде Гена йомшак тавыш белән.—Ярдәм итәргә булдык.

—Ул сезнең танышыгызмы?

—Юк,—диде Гена.

Габделнур да сүз кыстыруны кирәк тапты.

—Иптәш майор, барыбер кызганыч.

Офицерга хәлне сөйләп бирделәр. Ул, чегән хатыннарына карап алды да, солдатларга:

—Яхшы иткәнсез,—диде.—Барыгыз. Мин хәзер милиция җибәрермен.

Майор, хатынын култыклап, китеп барды. Аның артыннан ике солдат белән кыз да кузгалдылар.

Чегән хатыннары, «мал»ның кулдан ычкынуына җен ачулары чыгып, атыюлы белән сүгенеп, каргап калдылар.

Кыз су аркылы салынган тар басмадан чыкканда да Габделнурның кулын ычкындырмады. Юл кинәйгәч, тагын икесен дә култыклап алды. Автобус тукталышына барып җиткәч кенә алардан аерылды.

—Рәхмәт инде сезгә.

—Ачык авыз булма,—диде Гена төксе генә.—Алар янында бөтенләй туктыйсы юк. Туктадыңмы—беттең, алар сөлек кебек ябыша.

—Хәзер аңладым инде, сабак булыр.

Кыз, кат-кат рәхмәтләр укып, килеп туктаган автобусның алгы ишегеннән керде, солдатлар—арткы ишектән.

...»Вузовец» кинотеатры каршында автобустан төшкәч, Габделнур Генага:

—Минем монда апалар бар,—диде.—Берәр нәрсә алып, кереп чыгасы иде.

—Була ул,—диде Гена һәм, дустына күз кысып, тамак астына чиертте.—Безгә барыбер кибеткә керергә кирәк.

Алар, «Кольцо»дагы кибетләрнең берсенә сугылып, Габделнурның апаларына күчтәнәч, ә үзләренә берничә шешә алдылар. Соңгыларын яхшылап төреп, сумка эченә яшерделәр. Шушы арада Гена янына баласы белән хатыны киләсе икән, аларга тәм-том дә булды.

—Минем себерке җыеп саткан акча да бар әле,—диде ул сере белән уртаклашып.—Иренмәсәң, «котелогыңны» эшләтсәң, ничек тә җай чыгарырга була.

Габделнурга дустына карап соклanudан башка чара калмады, ана булган хөрмәте бермә-бер артты.

Кызганычка, Габделнур апаларын өйдә туры китерә алмады, күчтәнәчләрен күршеләренә биреп калдырды.

Юл читеннән терек-терек җәяү атлаганда Гена бераз дәшми барды да әйтеп куйды.

—Август аенда Җәлил турында күп сөйләделәр. Сезнең халыкның горурлыгы.

—Әйе.

—Ә син беләсеңме, безнең дә дөньяга билгеле атаклы бер кешебез бар. Дөрес, ул каһарман да, шагыйрь дә түгел, ә сынчы.

—Кем ул?

—Эрьзя. Үз фамилиясе Нефедов, ә бу—псевдоним. Мордва халкының бер тармагын эрьзя дип йөртәләр бит, шуны алган. Әле революциягә хәтле үк Италиядә һәм Франциядә үз әсәрләрен күргәзмәгә куйган. Аны «Мордва Родены» дип атаганнар. 1926 елны Латин Америкасына китә. Аргентинада таштан да каты, әмма бик матур альгарро дигән агачны файдалана. «Лев Толстой», «Бетховен», «Әнием портреты» һәм башка әсәрләре белән дан казана. Гаҗәеп шәп итеп тегендәге чибәр кызларның сыннарын ясый.

—Шәп дигәнең нәрсәне аңлата?—дип елмайды Габделнур.

—Аңлыйсың инде, шәрә килеш,—диде Гена күз кысып.—Эш анда түгел. «Моисей» скульптурасына бер бай ун миллион доллар бирә. Ләкин Степан Дмитриевич сатмый, 1956 елны, байтак сыннары белән бергә, пароходка төяп, иленә алып кайта.

—Димәк, ул да патриот.

—Саранскида булырга туры килсә, музеена кереп чык. Атаклы совет скульпторы Коненков аны үзеннән өстен санаган...

Һәм Гена бик озак үзенең мәшһүр якташы турында сөйләп кайтты.

Лагерьга җитәрәк Габделнур:

—Гена, син нишләп кызлар янына чыкмыйсың?—дип сорады.

—Ә нигә кирәк алар миңа? Хатын ике айга бер килеп китә,—диде Гена һәм үзе дә сорау бирде.—Бүген бәлки алар тагын килер. Чыгасыңмы?

—Нигә алай төпченәсең?—диде Габделнур эчкерсез елмаеп.

—Саграк бул, бозыгы эләкмәсен.

—Нинди мәгънәдә?

—Чирлесе.

—Андыйлар да бар микәнни?

—Дөнья бу... Узган ел бер сержант эләктергән иде.

...Чыннан да, кичен йорт тирәсендә «сандугач» тавышлары ишетелде. Габделнур Ковалевны кисәтеп куйды.

—Әгәр мине сораучы булса, авырый, диярсең.

Генаның көндез әйткән сүзләрен Габделнур Ирекkә дә җиткергән иде.

Ул да Ковалевка:

—Мин дә авырыйм,—диде.

—Мин чыгам,—диде озын торык Ковалев батыраеп.—Не ссите кипятком, держите хвост пистолетиком.

Ә өч-дүрт көннән аның сөмсере коелды, чыраен сытып йөри башлады. Аны нәрсәдер борчый иде. Үзе әйтмәсә дә, фәһемле Генаның үткер күзеннән берни дә яшерә алмыйсың икән.

—Эләктеңме? Мин бит сине кисәттем. Тыңламадың. Хәзер үзеңә үпкәлә.

—Нәрсә булды?—дип сорады Габделнур төшенеп җитмичә.

Ирек көлде дә аңа татарча такмак әйтте.

—“Тамчы, там, там, тамуыңны яратам”. Меңә нәрсә булган.

Эшнең нидә икәнен белгәч, Ковалевка кинәшләр бирә башладылар. Ләкин Гена аларны тиз туктатты.

—Башка чарасы юк, капитан Машкинга әйтергә кирәк. Булышса, ул гына булышыр. Җаен табар.

Һәм шулай иттеләр дә. Ковалев көн саен Казанга, дәваланырга йөри башлады.

## XXX

...Габделнурлар кабат Кремльгә кайттылар. Тагын элеккеге солдат тормышы башланды: вакытында йокыдан тору, физзарядка, юыну-чистарыну, иртәнге аш, дәресләр, кухняга яки каядыр башка урынга нарядка бару, часть байрагы янында сакта тору... кичке барлау...

Ротага яңа командир билгеләгәннәр икән. Белокуров фамилияле, кечкенә гәүдәле, караңгы чырайлы ябык капитан бик зәһәр бәндә булып чыкты.

Беренче көнне үк казармада «картлар»ны сафка тезеп бастырды.

—Үрә кат! Отставить! Тигезлән! Үр-рә кат! Шәлперәй!

Һәрберсен күздән кичереп, киемнәрен тикшереп чыкты.

—Якаларыгызны ычкындырыгыз!

Монарчы эленке-салынкы йөргән «карт» солдатлар теләр-теләмәс кенә гимнастерка төймәләренә үрелделәр. Капитан шеренганың башында беренче булып басып торган Ковалевка ябырылды. Ул аның гимнастерка изүеннән күренеп торган җылы йон пуловерын нәзек бармаклары белән чеметеп кенә эләктерде.

—Бу нәрсә?

—Пуловер, иптәш капитан.

—Салып ташла!

—Иптәш капитан, салкын...

—Сөйләшүләрне туктатырга! Рядовой Ковалев, чираттан тыш нәрәт аласың киләме?

—Һич юк, иптәш капитан!

—Шул-шул... Лагерьда бөтенләй тугарылгансыз...

Һәм ротный шеренга буйлап китте. Һәр солдат каршында туктап, гимнастерка эченнән кигән җинсез жилет, җылы күлмәк, якасыз свитерише нәрсәләрне салырга кушты. Хәтта гимнастерка якасына тегелгән ак ситсы каралган булса, кырынмаган яки итеген юньләп чистартмаган өчен дә кайберәүләргә кисәтү ясады.

—Рядовой Крылов, сез бүген кырындыгызмы?

—Так точно, иптәш капитан!

—Икенче юлы бритвага якынрак торыгыз.

Ул кабат «картлач»ларны үзенчә мыскыл итеп, команда бирде.

—Тигезлән! Үр-рә кат! Шәлперәй. Барыгызга да үз-үзегезне тәртипкә китерергә! Унбиш минут вакыт бирәм. Тарал!

Капитан очлы күзләрен караваг һәм тумбочка тирәләренә дә йөртеп чыкты.

—Иптәш матрос, бу нинди язу?—дип сорады ул бер койка башына эленгән кәгазь кисәген кулына алып һәм кычкырып укыды.—"Адмиралдан түбән якын килмәскә!" Мина ярамый инде алайса?

—Иптәш капитан, бу—шаяру. Бирегез, ертып атам.

—Истәлеккә миндә калсын.

Белокуров ары китте. Берәүнен тумбочка өстендәге язуны алып укыды.

—"Янгын вакытында ин беренче чыгарырга!" Рядовой, башта жинелрәкләрне чыгарырбыз. Сез ин ахырга калырсыз!—диде ул таза гәүдәле солдатны кызартып.

Ротный тикшерүен дәвам итте.

—Ә монысы нәрсә? "Тревога булса—уятмаска!" Бәлки сезне иртәнге ашка дәшмәскәдер?..

Солдатлар, нишләсеннәр, сукрана-сукрана җылы киемнәрен салып аттылар, төзәтенә-«бизәнә» башладылар.

—Менә бу солдафон!—диде Ковалев рота командиры чыгып киткәч.

Кемдер әйтте.

—Әле күрәселәр алда икән.

Аны башкалар күтәреп алды.

—Түзәргә туры килә.

—Бу мәрхәмәтсез белән бәйләнеп, кайсыбызның артыгын хезмәт итәсе килсен.

—Бу эт җан утыз беренче декабрьгә хәтле дә тоткарларга мөмкин.

—Сак булыйк, егетләр, сүзгә килмик.

Шулай бер-беренә үгет-нәсыйхәт бирделәр. Караватларны кабат рәтләп, җыештырып куйдылар, тумбочка эчләренә күз салдылар. Чөнки демобилизация көткән солдат өчен иң хәтәре—утыз беренче декабрьдә китү иде. Тәртипсезрәк солдатларны командирлары шуның белән генә куркыта. Солдатны беренче айларда, мин сине Макар бозау көтмәгән җиргә җибәрермен, дип куркытсалар, соңгы көннәрне исә, утыз беренче декабрьдә өенә китәрсен, дигәне иң үтемле сүз була. Ә ул—иң авыр җәза. Чөнки яшьтәшләрен-хезмәттәшләрен инде берәм-берәм китеп беткән, син—судагы йомычка кебек кая барып сугылырга белмичә тулганасын, өендә әти-әниен, кияүгә чыкмаган булса сөйгән кызын зарыгып көтә. Күнелсез, ямансу көннәрнен берсе дә айга торырлык була...

...Соңгы көннәр ничектер бик җанлы үтә башлады. Бер көнне егетләрне клубка җыйдылар. Эшкә чакыручы—вербовщик килгән икән.

Озын буйлы, күзлекле, яхшы костюм-чалбар кигән, култык астына папка кыстырып кергән бу ир-ат, үзенә сүз бирелгәч, кәгазьгә карамыйча гына сөйләп китте.

—Татарстан—нефть төбәге. Үзегезгә мәгълүм, нефтьтән бик күп нәрсә эшләнә. Менә шуна күрә дә Казанда органик синтез заводы төзелә башлады. Бу эшкә 1958 елда ук тотынган идек. Хәзер исә беренче комплекслар сафка басты. Узган ел фенол, ацетон цехлары продукция бирә башлады...

Ул кеше заводта нинди продукцияләр эшләп чыгарылуы, аларның күләме, сыйфаты, ил өчен әһәмияте һәм башка якларын тәфсилләп сөйләде.

—Ләкин,—дип дәвам итте эшкә яллаучы,—бу әле башы гына—төзелеш яңа җәелеп килә. Шуна күрә безгә эшче көчләр бик кирәк, менә сезнең кебек батыр, таза беләкле, өч-дүрт ел буена ил сагында торган кыю солдат-матрослар, иртәгәсе көннән яңа тормыш башлап җибәрәчәк егетләр кирәк...

—Салпы якка салам кыстыра белә бу,—диде Ирек Габделнурның колагына.—Ә үзе нинди эш икәнен әйтми. Кара эштер инде.

Теге әле һаман сөйли иде.

—Заводта тагын берничә комплекс булачак—завод эчендә завод...

Ләкин шулчак аны бер матрос бүлдерде.

—Эшчеләр заводка кирәкме, әллә төзелешкәме?

—Төзелешкә,—диде сөйләүче, сүзен бүлдерүләренә бераз хәтере калса да, йөзенә чыгармады, кызыксыну уятуына сөенде генә.—Мин—трест вәкиле. Ә безнең трест—генподрядчы.

Аны тагын бүлдерделәр.

—Сезгә нинди һөнәр ияләре кирәк?

—Балта осталары, бетончылар, арматурачылар...

—Тапкан юләрләрне!—диде Ирекнең сул ягында утыручы, Казанда туып-үскән бер солдат күршеләре ишетерлек итеп кенә.—Саз ерырга үзең бар.

—Ә электриклар?—дип кычкырды Габделнур, чөнки залдагылар нык кына шаулаша башлаганнар иде.

—Рәхим итегез!

Шул сүз җитте: Габделнур Казанда калырга ризалык белдерде. Ирекнең, авылдан киткән егетнең, төзелештә ярардай һөнәре юк иде. Ул балта остасы булып язылды.

—Бәлки моннан иртәрәк җибәрерләр,—диде ул Габделнурга.

Гадәттә солдат, «дембель» дигән татлы сүзне соңгы елының гыйнвар аеннан ук теленә кертә. Ләкин дембель үзе кемгә ничек елмая бит: укырга кергәннәр августта ук андый бәхеткә ирешә, ә калганнарга ул сентябрьдән башлап, утыз беренче декабрьгә хәтле сузыла. Тәртибең «бишле» булса, алмаш килсә—иртәрәк китәсең, ә инде «гөнаһлар»ың күп икән, бәхетең юк икән—соңгы көнне китәсең.

Клубтан чыккач Ирек көлеп җибәрде. Ләкин аның елмаюында шатлык сизелми, ачы сагыш күбрәк иде.

—Безнең бәхет шуннандыр инде: әтиләр шахтага барып акча эшләгән, абыйларны мәҗбүри фызыуга алганнар, апалар вербоваться ителеп читкә киткән... Их дөнья—буялган җонга, буялса иде мамыкка—рәхәт булыр иде халыкка!

Казармада Габделнурны Мораттан килгән хат көтә иде. Дусты үзенең өйләнүен һәм киләсе елда хезмәтен бетергәч тә Кронштадта калачагын язган иде. «Тәки каптырганнар икән егетне»,—дип уйлады Габделнур...

# ЯКТЫ ТАЛАНТ

XX гасырда гомер кичеп, үзен татар санап, әдәбият-сәнгать дөньясы белән кызыксынган һәр кешегә Кутуй дигән исем таныштыр. Кутуйлар тармаклы һәм затлы нәсел булып, бу токымнан байтак атаклы кешеләр чыкса да, алар арасыннан ин әүвәл бер шәхесне—Гадел Кутуйны беләләр иде. Белмәскә сон—атаклы «Тапшырылмаган хатлар» авторы бит ул! Үз вакытында миллионнарнын күнеленә береккән, байтак телләргә тәрҗемә ителгән, радиотапшыруларда еш янгыраган, күп укылган популяр әсәр. Ни кызганыч, фронт юлларын исән-аман кичеп, сугыш беткән көннәрдә, 1945 елнын маенда һәлак була әдип. Яраткан язучысынын шундый вакытсыз үлеме дә бик күпләрнен күнелендә Кутуйга карата инде булган мәхәббәт өстенә әрнү, яна сагыну, табыну хисләре уятты шикелле. Өстәвенә, замандашлары анын турында әледән-әле якты истәлекләр сөйләп, чибәр кеше, зыялы, кин карашлы кеше иде, чын интеллигент иде, дип әйтә киләләр... Болар һәммәсе халык күнелендә язучынын матур, мәһабәт образын тудырды. Кыскасы, үткән гасыр урталарындагы әдәби мөхиттә яхшы мәгънәдә Кутуй культы булып алды.



60 нчы елларда данлы Кутуй исеменә яна бер баскыч шөһрәт өстәлде: әдәбиятта Рөстәм Кутуй исеме пәйда булды. Яшь, чибәр, талантлы. Казан интеллигенциясе, бигрәк тә яшьләр арасында аерым бер абруй белән әйтелә иде анын исеме. Бәхетле йолдыз астында туган диярргә генә кала! Арттан—әтисенен якты исеме унай җил булып барса, алда—талант иясе алдында ачылырга тиешле биек үрләр. Үсәсе дә үсәсе!..

Хәер, Рөстәм Кутуй, әтисенен исеме һәм мирасыннан башка да, әдәбиятка юл ерып, үз биеклеген яулаган булыр иде. Чөнки, таланты югары кимәлдә. Бу җәһәттән табигать ана бик күпне биргән. Р. Кутуй зур әдәбиятка үткән гасырнын 60 нчы еллар башында килгән әдип. Заманында күп шау-шу тудырган Е. Евтушенко, Б. Әхмәдуллина, А. Вознесенскийлар чордашы. Минемчә, Ходай биргән таланты буенча Рөстәм Кутуй әле саналган шагыйрьләрдән һич тә ким түгел. Дөньяны образлы күрә белү ягыннан өстенрәктер дә әле. Төрле республика-төбәкләрдә булган чакларда, төрле халык әдипләре авызыннан Р. Кутуй иҗатына, анын язучылык талантына, иҗатына карата ихтирам һәм соклану сүзләрен шәхсән үземә дә байтак ишетергә туры килде.

Рөстәм Кутуй рус телендә иҗат итте. 60 нчы елларда, милләтләр үзара «эреп», рус телле уртак совет халкы булып йөрү шаукымында, бу телдә язу перспективалырак һәм нәтиҗәлерәк санала иде. Шул заманда кыргыз Ч. Айтматов, белорус В. Быков, казакъ О. Сөләйманов кебекләр чыннан да дөньякүләм дан алдылар да. Асылда Р. Кутуй да шулар токымыннан. Әмма ул алар төркеменә кермәде. Монда тагын—«керә алмадымы?», «кертмәделәрме?» кебек сораулы фигыльләр дә тезәргә мөмкин. Уйланырлык нәрсәләр бар: хикмәт нидә? Шәхеснен үз холык-принцибыннанмы, әсәрләрдә күтәрелгән проблемаларнын иҗтимагый әһәмияте дәрәҗәсеме, татар менталитетымы, автономияле республика вәкиле статусымы, сәясәткә уралмыйча, чиста сәнгать тарафдары булумы. Ни генә булмасын, ни генә димәсеннәр, шунсы

хак: Рөстәм Кутуй иҗатта үз инануларына тугры, вөҗданлы язучы булып кала алды. Хакимият әллә бар, әллә юк иде кебек аның өчен. Табигать бар, кешеләр бар, талант бар, мәңгелек сәнгать бар... Ул чын шагыйрь дә, шул ук вакытта зур прозаик та. Кайбер китапларының исемнәрен генә булса да искә төшереп узыйк: «Мин җирдән барам» («Я иду по земле»), «Җир яфрагы» («Лист земли»), «Тамырлар («Корни»), «Җәяүле буран» («Поземка»)... Болары шигырь китаплары. Проза китапларыннан—«Яңгыр килә» («Дождь будет»), «Шундый-шундый тормыш» («Такая жизнь»), «Усаклыкта яктылык» («Свет в осиннике»), «Көләм, буылам, елыйм» («Смеюсь, задыхаюсь и плачу») һәм башкалар. Алар төрле елларда, абруйлы нәшриятларда басылып чыктылар. Татар укучысына да кайберләре генә булса да таныштыр.

Рөстәм Кутуй—экспрессив пульста иҗат итүче әдип. Образлар системасы да, фикерләү рәвеше дә беркемнекенә дә охшамаган. Ул тудырган Дөнья фәкать аныкы, Рөстәм Кутуйныкы. Тагын... әлбәттә, аны яраткан укучыларныкы. Мина калса, аның кайбер әсәрләрендәге сүзләр мозаикасы В. Врубель яки татар рәссамы Ф. Әминов (Тукай «Шүрәле»сенә ясаган иллюстрацияләрен исегезгә төшерегез) иҗат иткән сурәтләрне искә төшерә. Әкияти һәм реаль күренешләрнең серле үрелешенең тәэсире зур.

Рөстәм Кутуй, русча язса да, әтисе—классик татар язучысы Гадел Кутуйның традицияләрен күпмедер дәрәҗәдә дәвам итте дип уйлыйм мин. Аның әсәрләре, нигездә, безнең җирлек нигезендә язылганнар, герой-персонажларның байтагы—татар кешеләре. Хәтердә, әле кырым татарлары турында яхшы яктан сүз әйтергә дә ярамаган елларда, ул «Идти за облоками» исемле повестенда «халык хыянәтче була алмый!» дип сөрән салып чыкты. Шуның өчен дә язучы кырымлылар өчен намуслы, фидакарь җан булып саналды. Дөресен әйтергә кирәк, үзебезнең кайбер өлкән язучыларыбыз аны кайчак өнәп үк бетермәгән чаклар да булды: янәсе туган халкыннан читләшкән... Ә ул исә әкертен генә даими рәвештә татар язучыларын, шагыйрьләрен рус теленә тәрҗемә итеп торды. Кемнәрне генә тәрҗемә итмәде ул! Әтисе Г. Кутуй, Ә. Еники, С. Хәким, Ә. Давыдов, Р. Фәйзуллин, М. Әгъләмов, Ә. Рәшит, Зөлфәт, Акъегет... Аның тәрҗемәсендә чыккан китаплар дистәләргә җыйнала.

Рөстәм Кутуйга бу айда 70 яшь тула. Әтисе гомеренең икесе кадәрле үк яшәмәсә дә, шактый озын юл үтелгән. Энциклопедик-белешмә китапларда элек Гадел Кутуйга күбрәк урын бирелсә, хәзер Рөстәм Кутуй «графа»сы зуррак. Табигый хәл: андый басмаларда һәр мыскал урын эшләнгән хезмәтнең зурлыгына карап бирелә. Шунысы моңсу: хәзер әдәбиятка, язучы хезмәтенә караш Рөстәм Кутуй әдәбиятка килгән 60 нчы елларга караганда шактый үзгә. Җәмгыятьнең әдәбиятка мәхәббәт белән тулышкан чорлары безнең олыгаю көннәренә калган булса икән!

Рөстәм Кутуй—сирәк очрый торган талант. Шәһәрдә туып-үссә дә, авылдан чыккан күпләребезгә караганда Табигатькә якынрак кеше ул. Әсәрләрен җентекләбрәк укысаң, язучының Табигать-Ананың чын улы булуын тоясың. Җир сулышы, ел фасылларының кабатланмас халәте, Күкнең серле балкышлары, гомумән, яшәешнең, кеше психологиясенең күпләр күрә алмаган нечкәлекләре бик тә үзенчәлекле итеп тасвирлана аның әсәрләрендә. Үлән үскәнен ишетә, таш эчендәге төсне күрә ала торган язучы.

Миңа калса, Рөстәм Кутуй иҗаты тиешенчә өйрәнелмәгән, бәһаләнмәгән әле. Сәяси-иҗтимагый яктан да, әдәби-эстетик яктан да. Әгәр, киләчәктә әдәбиятны үткән гасырдагы кебек җентекләп өйрәнү булса, Рөстәм Кутуй иҗаты тикшеренүчеләр өчен стиль һәм образлылык җәһәтеннән күтәрелмәгән чирәм булачак.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

*Сентябрь, 2006 ел.*

Рөстәм
Кутуй

# ВАТАНЫМ ДИП ЕЛЫЙЛАРМЫ?..

## Булат Тимер турында баллада

Ул биеде кисәүләрдә,
янган ташта.
Болгар иле ыңгырашты...
Иске урда, тешләк чирү!—
Күзегездә нинди сагыш?
Хатын-кызмы сагындыра?
Җирдә әнә үлән чери.
Уу-уу, азгын кавем!
Менә тагын көтү сезгә—
кысык күзләр, зур күзлеләр.
Бабайлардан калган эшне
онытмагыз.
Сезнең кулда
тайлар кебек алар кешни.
Йөгәнләгез!
Сызгыр, камчы!
Учка кызыл кан тамганчы.
Шундый була азамат ир—
килсен сарымсак, тир исе.
Бар да—сезгә.
Арканлагыз,
калын толымнарын кисеп.
Әллә соң кан кузгатмыймы?
Тутыкканмы ятаганнар?
Әллә бабагыз орлыгы
башка аналарга тамган?
Әнә тагын атлар кешни,
яугирме сез, черек тешме?

Аллаһ әкбәр! Аллаһ әкбәр!—
болытларны кылыч кисә,
аягыгыз асларына
берәм-берәм башлар төшә,
башкалалар тыпырчына,
чажлап тора көйгән төннәр.
Бездән соң да килер кемдер,
безгә кадәр дә килгәннәр.
Үгез башын кисеп алып
күзен суырып чыгарырмын.
Аллаһ әкбәр!
Аллаһ әкбәр!—
Өзәңгеләр чыдармы соң?

Әйттем—дала бүредәй улый.
Әйттем—таштан су саркыла.
Әйттем—кяфер калтырана.
Көек исле җил аркылы
уктан җитез безнең хәбәр—
ыргылабыз!—йә, каршы кем?
Башны кистерергә бирәм,
яу һавасы татлы!—
әйттем.

Аллаһ әкбәр!
Аллаһ әкбәр!
Мәрәенә җитсен угым.
...Йөрәк янына яшергән
туган җир туфрагын...
Изге ватан—бармы соң ул?
Бугазланган тимгел болан—
пыяла күз.
Кызыл канны
сөртте биттән бөек огълан.
Кузлар сүнә бара инде.
Җирдә тамырлар селкенә.
Чыгаргамы соң телиләр?—
Куркып ул почмакка түнә.

Биеде ул кисәүләрдә,
янган ташта,
Болгар җире ыңгырашты.
Эңгердә—
тере агачлар—
әсирләр кебек йөренде.
Еладылар.
Нигә, ни дип?
Сагышларына төренеп,
ватаннарын сагыналар.
Ха!
Ватан—хатын-кыз төсле,
эшкәрт,
еласын акырып,
аңга кертә ирләр исе.
Ә минем ватаным монда!
Әйттем—актарыла агач.

Әйттем—суда череп ята,
беркемгә дә ярамагач.
Юкса төнлә тамырлары
чыга, гүя кара елан,
бугазыма ябыша да,
мин ташлар кебек буылам.
Йолкыгыз тамыры белән!
Шатырдатып.
Җәлләмичә...
Кулда теле—канлы яфрак,
чиный-чиный җилләр исә.

Ватаным, дип елыйлармы?
Кайда барсам—шунда ватан.
Әйттем!
Ә бу йолкышларны
давыл читкә селтәп ата,
эзләрен яңгырлар ашый.
Сибелгән көл—алар иле,
сүнгән күмер—алар гүре.
Әйттем!

Бер урысы күзгә карап:
«Үзеңдә үзең янарсың...»—
диде миңа.
Ә аннан соң...

Әйттем—кулларын бәйләгез.
Түгәрәк буйлап куыгыз.
Сумалага чумырыгыз.

Янады. Ха!
Сасы дуңгыз!
Яна!
У, сары шакаллар,
илне сагына, янәсе.
Болармы соң белүчеләр
ил бәясен?

...Таң белән аны таптылар,
аһ-уһлар торды яңгырап.
Буып үтергән, диделәр,
чит җирдә кара тамырлар.

## Сөембикә манарасы

1

Сары тузан, төтендә,
Кызыл кирмән өстендә
Ханбикә.

Ай агарган,
Уч төбедәй генә калган.

Аста калтырый шәүлә.
Казанда тагын хәйлә!
Авачак, диләр, кара—
аумаячак манара.

Монда аккош язмышы.
Касыймда—кабер ташы.
Эремәс боз шикелле
буш төрбәдә карашы.

Тән—вакытлы, тик сүзнең
озын-озак тарихы.
Саф мәрҗәндәй сулкылдый
Хатын-кыз аһы.

Һәм тагын манарадан
күңелебезгә табан
Ташлана Сөембикә,
төшүе озак микән?

Тарих кабергә сыймый.
Чәчрәп китә биек,
төпсез гөмбәзгә тиеп,
Ирек,
озын сулыштай.

Егылган нур да түгел,
онтылган җыр да түгел.
Яши һаман—мәңгелек
сергә әверелеп.

Көлгән чакта елаган,
елаган чакта көлгән.
Башы күкләргә тигән
ташланганда түбән.

2

Ул җәсәд туфрак булып
Касыймнан кайтса әгәр,

чәчәк таҗлары төсле
тузмасмы хәрабәләр?..

3

Тарих булсын бер тында,
карлыгач канатында
безгә җиткән ул язмыш—
кагылмаска тиешле
каннарда аккан сагыш.

Авазы, һава ерта-ерта-ерта,
авырта.

*Ркаил Зәйдулла тәрҗемәләре.*

## Казан ятиме турында баллада

**(Өзек)**

*Казанда бит булды шундый хәлләр,—*
*Явыз патша—исерек, кемне җәлләр?!*

1.

Арба күчәреннән биегрәкме? –
Һәммәсен дә Алла хозурына!
Аһ итмәсен!

Бүрәнәгә ягылып кала җылы—
Янәшәдә сакал белән сакал,
Колак белән колак—
Нинди гөнаһ!

Эшли эшен балта—
Өелә тау.

Алтын Урдагамы бу җиһанда
Фәкать хуҗа булу!
Сүнгән көлгә
Очкын булып куну!
Явыз мөселманның
Тынсын тыны.

Аһ итмәсен!
Йөз елларга җитсен
Курку хисе.
Төшендә дә татар
Вәхшәт күрсен!

(Нишләп әле
Кыска минем муен?!
Нишләп әле...
Нишләп миңа кыен!)

Әй, күчән баш!
Нык итеп бас!
—Грозный, әйт, нәрсә булды сиңа—
Зыян килдеме әллә акылыңа?!
Алу мәллә синең бөтен аңың
Мөселманнар җанын?

Үзең әле шактый
Яшь булсаң да,
Теш араңнан саркый—
Сусагансың канга.

—Кем хөкемдар монда—
Мин түгелме?!
Мәңгелек Русь били
Бу күңелне.

—Җитәр, патша, җитәр,
Ачу сакламыйк без—
Җепләр өзелмәсен,
Аралар ул кадәр
Хәтәр бозылмасын.
Югыйсә бит алар
Кылыч алса кулга,
Безне дә бит мөмкин
Әйләндерү колга.

—Аларга аз әле
Мондый гына җәза;
Күп күрде Русь иле
Татарлардан каза.
Җирләре гел канга—
Кара канга тулсын...
Ат бирегез миңа—
Кара кучкыл булсын.

—Карачы, Грозный,
Таланган мал азмы?!
Йөзек-муенсалар—
Синеке ич алар.

—Бар, югал күземнән...
Бар, әйттер мәзиннән—
Христиан диненә өндәсен,
Исламга чакырып йөрмәсен.

2.

Кремль капкасын
Чит кавем какмасын!..
Агылды бар халык,
Вәхшәткә таң калып.

—Чуалыш башланса,
Нишләрбез, и патша?!
Түмәрләр, чүпрәкләр
Бездә соң, йә, азмы?—

Тыгыгыз авызына—
Тыгылсын бугазы.
Яшен дә, картын да
Кызганма, тартынма.

Күкләрнең чит-чите
Каргалар көтүе—
Патшаның вәхшәтнең
Дәвамын көтүе.

Бер яктан бер якка
Ишетелә колакка
Бер курай тавышы—
Киселер бит башы.
Һәй!

Ник җырлый, хәзер үк
Үләсен белмиме?!
Бәланең хәзер үк
Киләсен белмиме?!

Кош елый күкләрдә—
Сагышы, һәй, таныш;
Үләннәр арасын
Тибрәтә саф тавыш.

3.

Җырчыны өстерәп
Килделәр каршына;
Патшадан рәхмәтләр
Алмакчы барысы да.

—Язмышы һәркемнең
Тик минем хөкемдә,
Чәркәгә шәрабне
Салыгыз тиз көндә.
Нигәдер сагыштан
Зиһенем чуалган...
Тураклап ташлагыз—
Аһ итсен бар мәйдан.

Шаулады киң мәйдан
Рәнҗүле ай-һайдан.

—Үтермә, күктә бит
Кояшның яктысы...
Бар җирне балкытып
Яктырта ак төсе.
Яшереп кенә дә
Үтереп була ич.
Шөһрәтле падишаһ,
Гөнаһка кермә һич.
Эзендә кан гына,
Тик татар башы сау;
Нишләрбез, бу хәлдән
Үчләре ташыса?!

—Кит, югал!...
Бик шәпләп
Майлагыз кимендә,
Аунасын иң башта
Ул пычкы чүбендә.
Аннан ут төртегез—
Тоймасын салкынны.
Бар дөнья аһ итсен—
Күкләргә күренсен ялкыны.

*Әхмәт Рәшит тәрҗемәсе.*

---

*Алхәбәр*

## «КАЗАН УТЛАРЫ»—2007

### *Шигърият*

Һәр елдагыча, 2007 нче елда да шигърияткә журналыбызда урын мулдан биреләчәк.

Киләсе елда күренекле шагыйрьләр **Рөстәм Мингалим**, **Зөлфәт** һәм **Разил Вәлиевләрнең** 70, 60 еллык юбилейлары уңаеннан иҗатларына багышланган мәкаләләр белән шигъри бәйләмнәре дөнья күрәчәк.

Татарстанның халык шагыйре **Әхсән Баянга** 80 яшь тула. Әдип бу олуг бәйрәмен яңа шигырьләре белән билгеләячәк. Киләсе елда шулай ук Татарстанның халык шагыйрьләре **Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин**, күренекле шагыйрьләребездән **Роберт Әхмәтҗан, Лена Шагыйрьҗан, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла** һ. б. шигырьләре дөнья күрәчәк. Һәрвакыттагыча яңа исемнәргә, яшьләр иҗатына зур урын биреләчәк.

Рауль
Мирхәйдәров

# ҮЗЕМ ХӨКЕМ ИТӘМ

РОМАН

## VII

«Матросская тишина» төрмәсендә Сенатор элекке дәрәҗәләре белән түгел, ә үзен тотышы белән аерылып тора башлады. Нәкъ шунда анын ике төрле сыйфатка ия табигате ярап куйды: ул бит күптән инде зыялы, демократларча фикер йөртүче юрист битлеген кигән иде.

Төрмәдә буш вакыт күп, барлык сүзләр сәясәт, хакимият, Горбачев тирәсендә бөтерелә. Кем ул: коммунистмы, әллә демократмы? Империя яклымы, әллә ана кабер казучымы? Сенатор да шул турыда уйлана иде. Ул «Тамгалы» кеше илне кая алып бара: көнбатышка хас демократиягәме, яки яңартылган социализмгамы? Әгәр дә социализмга икән—анын сайлап алган ысуллары: үзгәртеп кору, хәбәрдарлык, янача фикерләү дигәннәре шундый «могҗиза» булып чыкты ки, алар социализмны яңарту урынына, анын һәлакәтенә китерделәр.

Сенатор өчен бу көн кебек ачык иде, шуна күрә ул «үзгәртеп кору прорабы, яңа фикерләү атасы» дигән бәхәсләргә катнашып та тормады. Шунысы сәер, бүген күп кенә кешеләр,—гади журналистлар, сәясәтчеләрне әйтеп тә тормыйбыз инде, Горбачевтан ераграк күрә, генсекретарь ике куллап ябышкан коммунистлар партиясенең тиздән җимерелеп төшәчәген сизә иделәр. Ул бит партиянең үз реформаларына каршы төп көч икәнен дә абайламады. Россия составына ике-өч йөз еллар көчләп кертелгән милләтләрне империядән чыгып таярга этәрүе Горбачев заманында җинел эш булачак тарихи мизгел икәнен күпләр аңладылар, ә ул аңламады. Социалистик илләр үзләренә көчләп тагылган режимнарны бер сәгать эчендә бәреп төшергән хәлләр Балтыйк дингезеннән Тын океанга, Ак дингездән Кара дингезгә кадәр сузылган империядә дә мена-мена кабатланырга тора иде. Ни сәер тоелмасын, әмма Әкрәмхуҗаев Аллаһыдан Горбачев хакимият башында озаграк утырсын иде дип, ялынып сорый иде.

Әмма: «Алма пеш, авызга төш!»—дип, үзе хәл итә алмаган вакыйгаларны гына көтеп, агым унаена агып ятса, Сенатор Сенатор да булмас иде. Ул һәрвакыт үзен бәхетен үзе коючы итеп санап килде, социализмга кабер казучы Горбачевның совет империясен таркатуын, республиканың бәйсезлек-суверенитет алуын гына көтеп ятарга һич ярамый иде. Беренче мөмкинлек булуга ук ул иреккә фәрман тапшырды—республика прокуроры Камалов белән Бармаксызны, ягъни Арсен Парсегянны юк итәргә! Нинди генә акча һәм корбаннар сораса да, Парсегянны теләсә ничек юк итәргә кирәк, Миршаб та бу фәрманны дөрес анлар. Прокурорнын «Москвич»ына ике һөҗүм

*Дәвамы. Башы алдагы санда.*

ясалганын ишетте, димәк, Миршаб аның күрсәтмәләрен төгәл үтәгән. Дөрес, каһәр суккан прокурорны Ходай саклаган—исән калган икән. «Матросская тишина» төрмәсе ничек кенә каты сакланмасын, Сухроб Әхмәтовичка кирәкле хәбәрләр даими килеп тора бирде. Әлбәттә, бу очракта эшне зур акчалар хәл итә килде. Вакыт үтә, Сенатор да нык тора, һәр гаепләүләрне кире кага, ләкин төп гаепләү шаһиты әле һаман да исән, хастаханәдә ятса да, прокурор үз вәкаләтләреннән баш тартмаган иде. Сенатор Ташкентта Шубаринның булмавы турында һаман да ешрак уйлана башлады: банкирны беркайчан да сәяси яки җинаятьчел эшләргә катнаштырмаска, дип үзара килешкән булсалар да, бу очракта Шубарин аңа ярдәм итми калмас—кирәкле кинәшләрен биргән булыр иде. Әйе шул... хәзер бит Сенаторның гомере турында сүз бара!

Сухроб Әхмәтович үзенә бер вакыт та билгеләп куйды—әгәр дә бер ай дигәндә Ташкенттан үзе көткән хәбәрне алмаса, Миршаб Мюнхенда Артур Александрович белән очрашырга тиеш, артык кичектерергә ярамый иде. Соңгы вакытларда ул илдәге хәлләр белән шулкадәр хәбәрдар иде, «Матросская тишина»да озаклап яткан тоткыннарның, бигрәк тә якташларының исләре китә иде. Аның шулай хәбәрдар булуы рәшәткә артындагы тоткыннар алдында өстенлеген дә күрсәтә шикелле, ләкин ул моның өчен бары тик Миршабка гына рәхмәтле вә бурычлы иде.

## VIII

Полковник Жураевны әле таң атканчы ук йокысыннан уяттылар. МВДның кизү бүлегеннән җитди хәл буенча шалтырата иделәр—прокурор Камаловка чираттагы һөҗүм оештырылган. Кичә иртәнге якта, Парсегянның КГБ изоляторында көтелмәгән үлеме турында ишеткәч, аның тикшеренү сизгерлеге үзе кулга алган Бармаксызның турыдан-туры прокурорга һөҗүм оештыруда катнашы булганлыгын, аны атып үтерүне дә шул ук кешеләр гамәлгә ашырырга тырышканлыгын ачык әйтә иде. Ул Камалов янына хастаханәгә кереп чыкмакчы да булган иде, ләкин шул көнге берничә шәфкатьсез үтерү һәм дистәләрчә кыргый талаулар хәтта көндез капкалап алырга да мөмкинлек бирмәде. Шулай да, ул, эштән китәр алдыннан шәһәрнең кизү хезмәте кешеләренә бу төндә травматология институтын махсус күзәтеп торырга кирәк, дигән күрсәтмә биреп өлгерде. Ул нindидер бәла булачагын сизенә иде. Аның күрсәтмәсен хәтта кизү кенәгәсенә язып та куйган иделәр. Әмма ләкин...

Кизү хезмәте, имеш! Төнлә пистолеттан аткан ике тавышны милиция кизү бүлекләренең дә берсе-бер ишетмәгән, юкса МВД үзе вакыйга булган урыннан ерак та түгел, бер квартал аша гына. Полковник Жураев милициянең көннән-көн начаррак эшләгәненә янә бер тапкыр ышанды...

Вакыйга булган урынны тикшергәннән соң, Жураев, травматология институты түбәсендә канлы эзләрен калдырган кеше, мөгаен, альпинист булгандыр, дигән фикергә килде—альпинистлар гына куллана торган махсус әйберләр шул хакта сөйли иде. Кыя тауларга менеп йөрү һөнәре—сирәк спорт төре, бу җепне кичекмәстән сүтәргә кирәк!

Камалов белән сөйләшеп киңәшкәннән соң, полковник аны дәвалаучы профессор белән дә күзгә-күз очрашты, алар бергәләп ишегә яхшы күзәтелә торган бер хәвефсез палатаны башка каттан сайлап алдылар. Янәшәгә генә телефонлы медицина кизүе куелды. Бирегә «медбратларны» Жураев үзе беркетте, чөнки хәзер прокурор Камаловны саксыз калдырырга ярамаганлыгы ачык иде инде, аңа чираттагы һөҗүм көндез дә булырга мөмкин иде бит.

Үзе йөртә торган эш машинасын шәһәр милиция идарәсенә таба куганда, Жураев: «Кешене һәрьяклап уратып алдык»,—дип уйлап куйды. Аның хәтеренә

башка прокурор—Азлараханов килеп керде, ул да шулай, кемнен кемлегенә, абруй-дәрәҗәсенә карамыйча, үлсәм-үләм, калсам-калам, дигән ышаныч белән көрәшкән иде бит. Юкка булмаган икән... Полковник сонлап кына җинаятьчел дөньянын бер тапкыр Азлархановны да тезләндергәнен, моны нәкъ Жураев гомере өчен, дөресрәге, ике гомер өчен—төбәктә абруй-дәрәҗәле Бикхуҗаевлар нәселеннән кемнедер үтергәне өчен утыртылган Азат Ходайкулов гомере өчен дә иканлеген белде. Бу мескенне, Бикхуҗаевларнын бер юньсезе анын хатынын да мәсхәрәләп көчләгәч, үз хатынын үзе үтергән, дигән җинаять эше кузгатмау вәгъдәсе белән алдаганнар икән.

Жураев һәр ике прокурорнын берсен дә саклап кала алмаганыннан күнелендә ниндидер гаеп барлыгын тоя, чөнки тегеләр, анын үзе кебек үк, гадел законнарга хезмәт итүчеләр иде.

Милициянен шәһәр идарәсе каршындагы машиналар куя торган урынга килеп җиткәч, ул чия төсендәге «Вольво» янындагы бердәнбер буш җиргә үзенекен дә китереп төртте. Бу зиннәтле лимузин турында шәһәрдә күп сөйлиләр, полковник анын кемнеке икәнен дә яхшы белә иде. Ул машина янында ук көмешсыман «Порше», «Мерседес» һәм «Ниссан»нын патруль джипын күргәч,—ә андыйлар милициягә бик кирәк, һич тә җитми иде,—ул күнеленнән генә шартлап куйды: «Шакаллар! Инде эшкә дә миллионнарча торган машиналарда гына киләләр бит, оялмыйлар да! Юкса, хезмәт хаклары өч йөз сумнан артмый». Шундый ук күренеш район прокуратурасы, теләсә кайсы исполком, банк тирәсендә—кемнендер ниндидер йомышын үтәргә кирәк булган һәр бина янында иде...

Мәһабәт бинанын газган мәрмәре белән тышланган беренче катын ОБХСС алып тора иде. Әле уйларыннан суынып җитмәгән Жураев, бер ишектәге «Кудратов В.Я.» дигән язуны укуга, аны йолкып ачты: бәлки, дөньянын кендеге булучылар янында йөргән бу майор нәрсәнедер ачыкларга ярдәм итәр, тикшеренү эшендә һәртөрле «кинәтләр» әһәмияткә ия бит.

Бүлмә хуҗасы, полковникны күрүгә, урыныннан сикереп торды, анын йөзе ялагайларча балкып китте. Шәрекъгә кече булганны хөрмәт итәләр, ә Жураев шундый көч кешесе—анын исеме хакимият башында утырган бик күпләрнен теш кортына әверелгән иде бит. Анын батырлыгы, сатып алынмаслыгы турында бик күп риваятьләр йөри, андый кешенен бер үк вакытта җинаятьчеләр арасында да, үз милиционерлары арасында да шундый хөрмәт казанганы бик сирәк буладыр. Аны күрүгә, Кодрәтов ана андый сәбәпләрдән генә ташланмады, әгәр дә Жураев үз егетләре белән килеп җитмәгән булса, үз йортына рэкитерлар һөҗүм иткәч, исән калган булыр идеме икән әле ул?

—Син күлмәктән тугансындыр,—дип кerә-керешкә сүз башлады полковник.—Сине котларга сугылдым, сина һөҗүм итүчеләрнен икесе дә теге дөньяда инде...

Кодрәтовнын гаҗәпләнүен күргәч, анлатып бирде:

—Варламын син үзен атып үтергән идең инде, ә Парсегян кичә КГБ изоляторында үлде...

—Ничек үлде?—дип аптырап сорады Кодрәтов, бу сораудан полковник анын, чынлап та, Бармаксызнын үлеме турында бернәрсә дә белмәгәнен анлап алды.

—Күрәм, син шат түгел?—дип кызганусыз-нисез өстәде Жураев.

—Парсегяннын үлеме хакында белми идем, сезгә ант итеп әйтәм!—дип ялварды майор.

—Ярый, ышандым. Әгәр нәрсәдер белешсән, мина—шылтырат.—Анын үлеме сина да файдалы булган икән дип уйламас өчен, Жураев шундук тагын бер сорау ташлады:—Әйт әле, машина алырга ике йөз егерме биш мен

акчаны син каян таптың? Сорау алганда, Парсегян шулай дип сөйләгән иде...

—Кайнатадан,—дип, күзен дә йоммыйча җавап бирде Кодрәтов.—Сез, мөгаен, аны белгәнсездер дә әле?

Әмма кайчандыр югары урындагы түрә булган кайнатасына ымлавы белән ул полковникның ачуын гына кабартты, көчсезлектән гаҗизлек Жураевның тынын кыса иде.

—Әйе, кайнатаңны белә идем,—диде ул.—Прокуратурада аның өстеннән кузгатылган эшләрне дә күрдем, зур жулик булган...—Аннары, чыгып киткәндә, ишек төбеннән генә әйтте:—Ә мин сугыш ветераны булган кайнатама, кызына өйләнгәндә, инвалид коляскасы алу өчен дә бер ел буе акча туплаган идем,—диде.

Идарәдән ул килгәндәгесеннән дә үртәлебрәк чыкты. Машинадагы рация көн дәвамында булган вакыйгаларны гади генә тавыш белән хәбәр итеп тора. Әле бер өч еллар гына элек андый хәбәрләр гадәттән тыш карала һәм аларга карата чаралар да иң югары даирәләрдә хәл ителә иде. Ә хәзер...

Эчендә кайнаган ачуы, кемнәрнедер көл итеп ташларга теләве бәреп чыгарга юл эзли иде. Ул сизенә: бүген төнлә прокурор Камаловка уңышсыз һөҗүмнән соң, кайдадыр, мөгаен, тагын бер һөҗүм турында сөйләшәләрдер һәм өстенә ак халат кигән берәр яңа ялланган үтерүче «мәскәүле»нең палатасын эзләп кереп барадыр. Ул шунда кинәт, барлык юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозып, машинасын урам уртасында әйләндерде дә, кире якка элдерде. Абруйлы районнарның берсендәге шәхси йортта законлы карак Талиб яшәгәнен хәтерләде. Полковник аны әле үсмер чагыннан, кесә карагы, кәрт уенында уңышсыз булып һәрвакыт бурычка теләнеп йөргән вакытыннан ук белә иде. Ләкин бу хәлләр бик күптәнге, Ташкентның үзендә дә түгел, ә Жураев капитан погоннары тагып йөргән чактагы, әмма ул заманда да аның исеме җинаятьчеләр арасында үзе белән хисаплашырга кирәклеген аңлаткан иде.

Хәзер исә Талиб ак «Мерседес»та йөри, бик тәрбияләп тотыла торган егерме биш сутый бакчалы ике катлы зиннәтле йортта яши. Бу йортны ул танылган рәссамның тол хатыныннан сатып алды, мәрхүм рәссам кунакчыл, юмарт, дөньяга танылган кеше иде—аңа үзбәк зыялылары һәрчак килеп йөрде. Хәзер Талибка башкалар килә...

Милициядә иң куркыныч эшләр—җинаятьчеләрне тоту белән шөгыльләнгән Жураев, әлбәттә, алар дөньясын яхшы белә, көчләрен-хакимлекләрен дә, акча мөмкинлекләрен дә чамалый иде. Ул бик ышанычлы кешеләр аша мәгълүматлар ала, җинаятьчел дөнья хакимиятнең һәр йомшаклыгында бик тиз җавап таба, аның һәр «указы» вә «законнары» шундук үз көченә керә, үлеп бара торган хакимият аларны тыя да алмый иде.

Әлбәттә, Талибның хәзер нинди көчкә, абруй-дәрәҗәгә ия булганын белгән хәлдә, ана тиктомалдан гына барып кереп булмый, ниндидер бер җитди сәбәп табарга кирәк. Талибны һәм аңа тиң башкаларны да, аларның шәһәрдәге һәр җинаятькә катнашы барлыгын белсәң дә, чынлыкта берничек тә кулга алырга мөмкин түгел. Алар үзләре бер хилаф гамәл дә кылмый, алар өстеннән беркем дә, беркайчан да шаһитлык бирмәячәк. Ләкин бүген Жураевны берниндидәлил дә тыеп тора алмас—аның җаны хәрәкәт сорый иде. Прокурор Камаловны кем һәм ни өчен бертуктаусыз эзәрлекләп йөри?

Жураев биек имән капкалы, аскы өлеше калай белән тышланган авыр тоташ дувал—коймa янына килеп туктады да машинасын юеш асфальт түшендәге яңа «девятка» янына китереп төртте. Ташкентның кәттә егетләре хәзер шундый машинаны хөрмәт итә. Капка бикле иде, әмма Жураев шакып тормады, аның көтмәгәндә генә килеп керәсе килә иде, «девятка» хуҗасы күрше бүлмәгә шылмасын тагын!

Ул капканы ачкыч ярдәмендә генә ачты да, ишегалдына үтте, телевизор карап утырган каравылчының ишеккә ташланганын күрде. Жураев анардан өлгеррәк булып чыкты, бусагага беренче булып аяк басты:

—Бас почмакка, аякларыңны аерып куй, кулларыңны—артка!—дип, кул богауларын алды ул. Тегесе карават өстендәге матраска омтылмакчы булган иде, тимер богаулар белән китереп суккач, өстәлдәге савыт-сабаларны да кырып төшереп, почмакка тәгәрәде. Жураев матрас астыннан пычак тартып чыгарды да, аны үзенә алып, тыныч кына әйтте:

—Монысы турында сонрак сөйләшербез. Тавыш кубармаска киңәш итәм,—дип, тегенең кулын богаулап куйгач, ишекне тышкы яктан такта белән терәтте.

Ишегалдын күздән йөгертеп, тынланып торганнан соң, ул тиз генә өйгә табан китте. Икенче каттагы шаулашып көлешкән тавышлардан Талибның «девятка» хуҗасын кайсы бүлмәдә кабул иткәнен аңлап алды да өскә күтәрелде. Талиб белән аның кунаклары, дөньяларын онытып, нардлы уйныйлар—өстәлдә хәтсез акча җыелган иде. Шуңлыктан, алар Жураевның килеп кергәнен дә тиз генә абайлап ала алмадылар. Әлбәттә, полковник, күңеленнән генә булса да, Талибта кемнәр булырга тиешлеген чамалаган шикелле иде. Әмма хәзер, йөзләгән кешене әйтеп чыкса да, ялгышасын төшенде: йорт хуҗасы белән шәһәрнең иң атаклы адвокатларыннан берсе уйнап утыра иде. Аның Ташкент мафиясендә күптән инде төп киңәшче булып торуы турындагы хәбәрләр Жураевка да килеп ишетелгән иде, әмма ничектер моңа ышанасы килмәде: фәннәр кандидаты, коммунист, хөрмәткә лаек кеше...

Жураевның эчендәге ярсуы кинәт бәреп чыкты: ул, башкаларны кулга алгандагы кебек итеп, адвокатны чәчennән умырып тотты да башын кискен генә үзенә таба борды:

—Менә кем белән дуслыкта икән сез, адвокатлар коллегиясенең хөрмәтле рәисе! Кичә безнең егетләр «Вернисаж»да Ваганны каптырдылар, без аны күптән аулый идек инде. Кесәсеннән пистолеты да чыкты, ә тагын үз кулы белән тырмачлаган, бу коралны әле бер сәгать элек кенә табуы һәм милициягә илтергә җыенуы турындагы кәгазе дә бар иде. Хәзер менә акылы бик акырын Ваганның шулай тиз акыллылануы аңлашыла да инде. Сез бит аның белән күптәнге танышлар... Бар, исән чакта чыгып шыл моннан, кабәхәт!

Шунысы сәер, судларда прокурорларны, судьяларны, утырышчыларны һәм зыян күрүчеләрне үзенең әрсезлеге белән авыруга сабыштырырлык бу адәм әтрәге янәшәсендә торган «дипломатын» алды да баскычтан тәгәрәп тешкәндәй юкка чыкты. Күрәсең, куркуыннан ул Ваган аны саткандыр дип уйлагандыр, чөнки тикшеренүчеләрне аптырашта калдыра торган фикерләр һәм башкалар, дөрестән дә, анык иделәр.

«Ярсуның һәм үз-үзеңне тыеп тора алуның да үз өстенлекләре бар икән»,—дип уйлап өлгерде Жураев. Инде аңына килгән Талиб, кәттә мыегын сыпыргалап, усал гына төрттереп куйды:

—Кеше йортына бәреп керү, шәһәрнең хөрмәтле кешеләрен мәсхәрәләү яхшы түгел. Сезнең башбаштаклык бетте—хәзер үзгәртеп кору заманы, илдә демократия...

—Әйе, Талиб, син хаклы, сез алдырасыз, караклар заманы килде, халык әле аның ни-нәрсә икәнен аңлап бетерми. Әйе, хәзер синең аяк астында депутатлар да, министрлар да аунап ята, чөнки алар синең депутатларың, синең министрларың. Ләкин сиңа да, дусларыңа да минем белән санлашырга туры килер, законнарны үзегезгә яраклаштырырга маташсагыз да, алар әле үз көчендә...

—Сезгә миннән нәрсә кирәк соң? Мина бит хәзер сезнең тешегез үтми,—дип бүлдерде аны Талиб, ул полковникның каны кайнаганын сизә иде.

—Әйт әле, прокурор Камаловның үлеме кемгә хаҗәт? Кем аны тозакка каптырмакчы була?

—Мин каян белим?—дип хәйләкәр елмайды Талиб, аның йөгергәләп торган күзләре кинәт катып калды.

—Син беләсең бит, мин сезнең халыкка ярдәм сорап сирәк мөрәҗәгать итәм, ике мәртәбә дә сирәк сорыйм. Соңыннан үкенерлек булмасын, яхшылап уйла әле.

Жураев хуҗага аркасы белән борылды да ишеккә юнәлде.

—Син, мөгаен, кемгә килгәнеңне онытkансыңдыр. Әгәр дә бу йортның капкасыннан исән-сау чыгып китә алмасаң...—диде Талиб юмакайланып.

Полковник аның кулындагы пычакның йомшак кына ачылган тавышын ишетте, гәүдәсе авыр булса да, шундук җәһәт кенә борылды—кулындагы пистолеты ялтырап китте:

—Ташла пычагыңны!—диде ул.—Заман синең башыңны әйләндергән булса кирәк. Хәзер синең гомерең бер тиенлек тә тормый!—Ул, аяк астындагы финканы иелеп алып, баскычка таба атлады.

—Син нәрсә эшли аласың соң, кабәхәт мент? Шәһәрнең иң яхшы адвокатлары минем дусларым. Өстәрәк тә түрәләрем бар!—дип ярсып кычкырып җибәрде Талиб.—Бу көн синең өчен эзсез генә үтмәс, белеп тор... Жураев текә баскычтан сүзсез генә төшеп китте. Ә Талиб аның артыннан илереп кычкырынуын дәвам итә иде:

—Пычагымны да кыра алмассың! Сезнең көч бетте инде, куркытмакчы буласың тагын... Әле миннән гафу сорарсың, аяк астымда аунарсың әле...

Полковник, кинәт кискен генә борылды да, ике генә атлап Талибны якасыннан эләктереп алды:

—Тукта дим, кабәхәт, бүгеннән сиңа хөкем карары чыкты. Моннан сигез ел элек Фарухны тоттырганыңны оныттыңмы? Аңа күпме ел чәпәгәннәрен дә онытма. Фарух хәзер шәһәрдә тине юк кешеләрнең берсе, син дә төшеп калганнардан түгел-түгелен. Бел, сатлыкҗаннарга гафу юк—караклар канунының иң мөһиме шул.—Ул борылып, янә ишеккә атлады.

Бусагага җиткәч, Талибның тавышы ишетелде:

—Туктагыз әле! Икебез дә кызып киттек. Мин ул прокурорның сезнең дустыгыз икәнен белмәгән идем. Әмма безнең аның белән бер бәйләнешебез дә юк. Эш сәясәттә булса кирәк, хакимият өчен көрәштә...

—Ә кем көрәшә?—дип кырыс кына сорады Жураев.

—Миршаб...—Йорт хуҗасының тавышы бик әкрен чыкты.

## IX

Яңа палатада прокурорның караватын башкачарак урнаштырдылар—Камалов ишекне күреп ята башлады, полковник Жураевның сак куйдырганын да чамалады ул. Төнге һөҗүмнән соң өч атна үткән иде инде. Прокурор көн саен диярлек үзен чыгаруларын таләп итте, вакыйгаларга күз-колак булырга кирәк иде, вакыт һаман үтә тора бит... Һәм менә өмет чаткысы күренде шикелле: шәфкать туташы аны бер атнадан инвалидлыкка тәгаенләп чыгарып җибәрәчәкләрен әйтте.

Шулай да ул хастаханәдә вакытын бушка уздырмады: озын-озак йоклый алмый яткан сәгатьләрендә башына күп кенә яңа фикерләр килде, теге яки бу гамәлләрне башкарырдай көтелмәгән мөмкинлекләр ачылды. Эшсез яту мәҗбүрияте аңа үз игътибарына эләккән һәр кешенең адымнарын, һәр хәрәкәтен төрлечә җентекләп тикшереп-анализлап карарга булышты. Ул Парсегянның үлеме турында төрмәдән хәбәр алган Әкрәмхуҗаевның ни-

нәрсәләр эшләргә җыенганын белмәсә дә, хан Акмалның гамәлләрен белә—ана ханның Мәскәүдә судта ясаган нотыгының стенограммасын җибәргән иделәр. Димәк, Акмал Ариповка Бармаксызның үлеме билгеле һәм ул бик оста юл уйлап тапкан. Хәзер Сенаторның котылып чыгуын озак көтәсе булмас, мондый мөмкинлекне ычкындырмас ул. Адвокатлары, мөгаен, Мәскәү белән Ташкент арасында көн-төн чабышып йөриләрдер әле. Мәскәүдә Сенатор белән хан Акмалның даими элемтәләре бармы икән—монысы табышмак. Прокурор аларның төрмәдә аерым утырганнарын белсә дә, Парсегянның үлеме һәм Ариповның судта ясаган көтелмәгән чыгышыннан соң хәтта ни көчле КГБ да бер нәрсә дә эшли алмас иде. Бармаксызның шаһитлык кылулары хәзер суд өчен әһәмиятсез. Сенаторның эше дә судка барып җитәрме-юкмы бит әле—һәммәсе дә бик сак кылана, кайсы як җиңәр, дигәндәй, нәрсәдер көтәләр. Юкса, республикаларда хакимияткә кемнәр килгәне билгеле дә инде.

«Хан Акмал мине республиканың җаваплы кешеләреннән ничек оста читләштерде!—дип уйлады Камалов.—Мәскәү килмешәге, манкорт, республиканың иң яхшы улларының башын ашарга кайтканмын икән мин. Оста! Шулай итеп ул башкаларга әйтә шикелле: сезне гафу итәрләр, ә моны корбанга бирерсез. Көчле хан Акмал, төрмәдән дә иртәгәге сәясәтне күрсәтеп ятa!» Ариповтан башканы көтеп тә булмый иде шул. Ә Камаловны янаулар белән генә куркытып булмый, ул аларга күнеккән инде—эше шундый, үзе сайлаган хәвефле юл. Боларны хан Акмалның һич аңлыйсы юк, ул һәрнәрсә сатыла һәм сатып алына дип уйлый, шуңа инанган, аның фаҗигасе дә шунда. Чөнки ул һәрчак барысын да сатып алырга өйрәнгән, бер дә ялгышмаган. Хәзер вәзгыять тә аның файдасына: теләсә нинди җинаятьне милли ясссылыкка күчереп акларга була, сәясәт буявына гына манасың. Ләкин барысы да сатылмый һәм сатып алынмый икән бит, моны хан Акмал үзе татыды—төрмәгә эләкте, юкса аның кебекләр үзләрен хөкемнәрдән өстен дип ышанып йөргәннәрдер. Камалов хан Акмалның Сенаторга юл ачуы иң әүвәл ханның үзе өчен файдалы икәнен аңлый. Менә шуңа күрә дә прокурор травматология институтыннан тизрәк чыгып китәргә ашкына иде.

Аны тагын бер сәбәп ашыктыра—Шубаринның Германиядән кайтыр көннәре якынлаша, аның белән очрашу җаен Камалов озак эзләде, тапты да бугай. Үтерелгән прокурор Азлархановның соңгы еллардагы хезмәтләрен Сенаторның докторлык диссертациясе белән өстән генә чагыштырып карасаң да, аларның бер төсле икәнлегенә шик калмый иде. Азлархановтагы тулы абзацлар, бүлекләр Сенатор диссертациясендә сүзгә-сүз кабатлана. Камалов Азлархановның матбугатта бастыру өчен әзерләгән бер каралама кулъязмасын да тапты. Анысы, соңрак, үзгәртеп кору елларында Сухроб Әхмәтович имзасы белән басылып чыккан һәм республикада зур шау-шу тудырган. Шулай итеп, Сенаторны кулыннан ук тотты Камалов—моны инкяр итү мөмкин түгел иде. Мәрхүм прокурорның фәнни хезмәтләре ничек итеп Сенаторга килеп кергән—табышмак иде бу. Шубарин аларны Сухроб Әхмәтовичка үзе бирмәгәндер ич инде.

Әйе, Камалов хастаханәдә вакытын бушка уздырмады. Сенаторның шулай тиз югары үрләвен ачу үзе генә дә ни тора! Әлбәттә, ул Шубарин белән очрашудан могҗиза да, барлык сорауларына җавап та көтми, бары тик күп нәрсәләрнең Японец тирәсендә әйләнүен генә сизенә иде. Яңа заман Шубаринга лаеклы тормыш, үз мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру җаен биргән. Ул бит 1986 елда ук финанс оешмаларына үзенең шәхси миллион сумы барлыгын белдергән. Аңа беркем дә бәйләнеп тормаган. Ә коммерция банкы ачу фикерен хөкүмәт дәрәҗәсендә хуплаганнар, шәһәр башкарма комитеты аңа шәһәр үзәгендәге бер кәттә йортны туксан тугыз елга арендага биргән,

анда хәзер ремонт-төзәтү эшләре бара. Ә бит үткән заманнар янадан әйләнеп кайтса, рәсми шәхси миллионың турында да, шәхси банк турында да сүз йөртергә мөмкинлек булмас иде. Шубарин, мөгаен, монысын да чамалагандыр. Шуңа күрә аның белән фикердәш булу юлын эзләргә кирәк. Һәрхәлдә аны Миршаб белән дә, Сенатор белән дә очраштырмаска иде. Сенатор бит Ташкентка Японецтан алда кайтып төшәргә мөмкин. Алар берләшеп алса, бу коточкыч кара көч булачак...

Шубарин турындагы уйлары Камаловка тынгы бирми иде. Шуңа күрә ул Интерполдагы элекке элемтәләре аша Японецның Мюнхендагы тормышы турында кайбер мәгълүматлар алырга карар кылды: кайда һәм ничек буш вакытларын үткәрә, кемнәр белән аралаша, кем, каян ана килеп киткән икән? Камалов гади кеше генә булмаган Шубаринның тәртип саклаучы жирле оешмалар күзеннән дә югалмавын төшенә, немецлар—төгәл халык. Ул, әлбәттә, артык зур уңышка ирешү турында уйламый, гадәтенчә һәр эшне җентекләп, төпле уйлап эшләргә күнеккәнлектән, шулай итә, ә хәзер буш вакыты да күп. Шубарин турында никадәр күбрәк белсә, шул кадәр яхшы булачак.

Мюнхеннан җавап Камаловны хастаханәдән чыгарган көнне килеп төште, прокурорны алырга оешкан җинаятьчелек белән көрәшү бүлеге начальнигы килгән иде. Ул Камаловка машинада ук, прокуратурага кайтып җиткәнче үк, юка гына папка тоттырды. Камалов мәгълүматларның бик әһәмиятле булуын аңлады. Интерпол мәгълүматларындагы прокурорга бирергә ашыккан ике фамилия аларны белмәгән кешеләргә бер нәрсә дә сөйләми иде, әмма Камалов өчен...

Фамилияләр исемлекнең иң ахырында: Әнвәр Абидович Тилләхуҗаев белән Талиб Солтанов иде. Фоторәсемнәре дә теркәлгән.

Камалов кәттә генә капчыксыман костюм кигән пөхтә мыеклы ир кешенең рәсеменә озак карап торды. Фамилиясе дә таныш. Үз кабинетына кергәч, прокурор бер альбомны кулына алды—андагы рәсемнәргә күпләр күз төшерергә теләр иде. Менә ул мыекбай: Талиб Солтанов, 1953 елгы, ике мәртәбә хөкемгә тартылган законлы карак.

—Җинаятьче Талибка банкир нигә кирәк икән? Уралда төрмәдә утыручы Әнвәр Абидович Тилләхуҗаев ничек Мюнхенга барып чыкты икән?—дип сорады прокурор чекисттан, тегесе җавап урынына җилкәләрен генә җыерып куйды.

## X

Татьяна Георгиевна—Танечка Шилова Ташкент университетының юридик факультетына өч ел рәттән керергә тырышып карады, ә мәктәпне тәмамлаган елны Мәскәүдәге МГИМОга да талпынган иде. Ул абруйлы уку йортына гына омтыла торган иркә һәм сәләтсез бала түгел иде. Танечканы җирле авиация заводында җыештыручы булып эшләүче әнисе бер ялгызы тәрбияләп үстерде, дөрес, ул берьюлы ике урында эшли, чөнки кызына югары белем бирүне максат итеп куйган иде. Мәктәпне Таня алтын медальсез генә тәмамлады, юкса медаль алган сыйныфташлары аның үзләреннән өстен булуын да аңлый иделәр. Ләкин тормыш тормыш шул инде: ата-аналар, аларның абруй-дәрәҗәсе, укытучылар, ата-аналар комитеты—һәммәсе дә үз эшен эшләде. Житмәсә, Танечканың әнисе дә үҗәт, көчле холык-табигатьле булды, ә бездә берәр урында түрә-фәлән булмаган андый кешеләрне кем ярата? Әле бу бит җыештыручы гына! Ләкин Таня артык борчылмады, ул үз көченә ышана иде.

МГИМОга беренче имтиханында ук Таня биредә гади кешеләр укымаганын төшенде. Аның тулай торагы Мәскәү тирәсендәге Монинода иде, сонга калмас

өчен ул сәгать җидедәге электричкага чыгып йөри башлады. Абитуриентлар җыела башлагач, ана алар һәммәсе дә хөкүмәт машиналары булган «Чайка»ларга яки зиннәтле иномаркаларга гына утырып киләләр кебек тоелды. Аларны әбиләре-бабалары, абзыйлары-апалары, күркә кебек кабарынган ата-аналары, ниндидер бик елгыр егетләр көтүе озатып йөри. Институт бинасына тыелган булса да, болар тыз-быз кереп-чыгып йөри иделәр. Озата килүчеләр арасыннан Таня фоторәсемнәре газеталарда басыла, йөзләре телевизор экраннарында еш күренә торган кешеләрне дә абайлап алды. Кулына кәгазь папка тотып бер читтә басып торган Таняны абитуриенткадыр дип уйлаучы да булмагандыр, швейцар анардан гына документ сорады, кулындагы имтихан кәгазен күргәч, бик гаҗәпләнде.

Ул көнне инша яздылар. Татьяна үзеннән унда да, сулда да утыручы, киләчәктә дипломат булырга хыялланучыларның, артык яшереп тә тормыйча, шпаргалкадан күчергәннәрен күреп торды. Тегеләрнең барысының да диярлек теманы алдан белгәнлекләре күренә һәм әзерләп килгән шпаргалкалары кул астында гына иде. Таня тирәсендә бик купшы киенгән укытучы ханым йөреп торды, әмма кыз, эш белән мавыгып, аны сизмәде дә. Беренче имтиханың ул «бишле»гә бирде. Икенче, өченчеләрен дә шулай ук... Ана игътибар итә башладылар—каян килеп чыкты соң әле бу кызый, маскарадфәләң түгелме, уең уйнамыйммы, зәңгәр күлмәктән, тыйнак кына босоножкадан үзе...

Һәр имтиханнан соң Татьяна Ташкентка бер генә сүз белән телеграмма сугып торды: «бишле». Әнисенең өйдә бик борчылып көткәнен белә иде ул. Соңгы имтихан тарихтан, кыз инде үзен җиңүче итеп тоя, тарихны ул яхшы белә генә түгел, ярата да иде, аны даталар да куркытмый, чөнки хәтере—искиткеч яхшы.

Керүчеләрнең исемлеген чыгарып элгәч, ул, әлбәттә, кемнең кем икәнлеген төшенеп алды. Гаделлеккә ианып яшәгәнлектән, мине «бишле»ләрем өчен генә түгел, социаль чыгышым өчен дә алырга тиешләр—деканаттагылар «шушындый вузда җыештыручы кызы укый» дип мактаныр лар: кыз шулай уйлады.

Бәлки, шулай килеп тә чыккан булыр иде. Әмма соңгы имтиханга килүчеләр тиешеннән артык күп иде. Имтиханда Татьяна беренче булып җавап тотты, артык әзерләнеп тә утырмады, билеты җиңел иде. Ул сөйләп бетергәндә генә аудиториягә ышанычлы атлап урта яшьләрдәге бер ир-ат килеп керде, кабул итү комиссиясе әгъзасы икән, имтихан алучыдан рөхсәт сорап, кызны игътибар белән тыңлый башлады. Татьяна сөйләп бетергәч, ул ана өстәмә бер генә сорау бирде. Таня билетындагы сорауларга ышанычлы җавап биргән шикелле үк сөйли алмады. Ана «өч»ле генә куеп чыгардылар. Шунда гына кыз үзен «кармакка каптырганлыкларын», шома агайларның ана аяк чалганын аңлады.

Якындагы кечкенә бакчага кереп, Таня күз яшьләренә ирек бирде, башына һәртөрле ямьсез уйлар килде—Ташкентка кайтып китәргә оят иде ана. Әнисе, күршеләре, дус кызлары күзенә ничек күренмәк кирәк, ана бит бик ышанып калган иделәр. Шунда аның янына ниндидер егет килеп утырды, ул, күрәсең, эшнең нәрсәдә икәнен шундук аңлап алды, кызга конфет сузды да, хәленә кереп сорады:

—Нәрсә, «икеле» алдыңмы?

Ни-нәрсә булганын белгәч, кинәт күңелле генә итеп әйтте:

—Имтихан турында бер мәзәк сөйлиммe? Сиңа бик тә туры килә бугай.—Җавап та көтеп тормастан, тезеп сөйләп китте ул:—Имтихан алучы сорый икән: «Әйтегез әле, Бөек Ватан сугышында ничә совет кешесе һәлак булган?» Абитуриент ышаныч белән әйтә: «Егерме миллион...»—ди. Шуннан профессор, күзлеген ялтыратып, тагын сорый: «Һәммәсен дә исемнәре белән санап чыгыгыз әле...»—ди.

Көтелмәгән бу мәзәктән Татьяна көлеп җибәрде, күңелендәге күңелсез уйлары эреп югалды, әйтерсең лә, дөньяга күзләре ачылып китте..

Менә шул чагында ул юрист булырга ныклы карар кылды, һәркем үз көченә һәм мөмкинлекләренә генә ышанмаска, ә законга да таянырга тиеш. Ул, район җирлегендә туып үскән бала, кичәге мәктәп укучысы, Мәскәүгә беренче килеп керү белән үк, тормышка аяк басучы мәскәүлеләрнең үзеннән бер башка өстен булуларын тойды. Мәскәүдә ул дистәдән артык зур институтларның, шул исәптән МГИМОның да тулай тораклары юклыгын белде—димәк, алар мәскәүлеләр өчен генә булып чыга. Калган институтлар да нигездә шуларга гына йөз тота икән. Әгәр дә алга табарак карасак? Илнең Балтыйктан алып Тын океанга кадәр булган тормышын, Памирдагы таҗикның, яки Төньяктагы чукчаның язмышын союз күләмендә хәл итеп утыручы меңнәрчә зур-зур оешма һәм министрлыкларда кемнәр эшли ала? Шул ук мәскәүлеләр, чөнки тумышыннан ук ул Мәскәүдә теркәлгән, һич тә акылы түгел, ә мәскәүле булуы шул оешмаларның ишекләрен ача, алар грузинның да, үзбәкнең дә, татарның да язмышын хәл итә...

Һәр халыкта үз-үзен саклау хисе яши, кан яңарту кирәк булса да, кан катнаштырудан куркалар, ә Мәскәүдә исә моны аңлы рәвештә эшләп, законлаштырып хуплап торалар. Бу очракта нәрсәгә исәп тотарга мөмкин соң? Бары тик көчсезләнүгә, юкка чыга баруга гына. Шул ук МГИМОда Татьяна кайбер студентларның горурлык белән, мирас итеп алган хокуклары шикелле:

—Бу безнең гаилә институты, биредә әти, абзый, әни, абый, апамнар укыган...—дип сөйләгәннәрен ишетте.

Яшьлеккә зур хыял-максатлар хас, Татьяна да үзенең юрист булачагына ышана, ә инде юрист булып алгачмы?.. Ләкин ана чаклы әле университет тәмамларга кирәк. Ташкентына кайткач, Таня шул ук авиазаводка, әнисе эшләгән цехка инструментальщица булып урнашты. Акыллы кешеләр эш стажы җыярга киңәш иттеләр.

Үзләрендәге университетның юридик факультетына да ул беренче талпынышында үтә алмады. Урта Азия һәм Кавказ республикаларында бу факультетта, мәскәүлеләр өчен МГИМО нинди булса, шундыйрак абруйдәрәҗәле икән. Юк, биредә ул—кызларын «Чайка», «Мерседес» машиналарында алып килмиләр, барысы да шау-шусыз, тыныч кына, арадашчылар аша биек дуваллар һәм ябык ишекләр артында хәл ителә. Беренчесендә Татьяна мандат комиссиясеннән үтмәде: эш стажың җитеп бетми, диделәр... Икенче юлы: быел алтын медальлеләр, интернационал сугышчылар, гомумән, армиядә хезмәт итеп кайтучылар артык күп, дип аңлаттылар. МГИМОда шикелле үк, аны биредә дә таный башладылар, хәттаниндидер резерв исемлеккә дә язып куйдылар, шылтыратырга вәгъдә бирделәр. Әмма шылтыратучы булмады...

Үзенең белеме һәм үҗәтлеге белән ул, мөгаен, кабул итү комиссиясеннән дә, ниһаять, үткән булыр иде. Бу юлы болай да аның бәхете басты.

Беренче имтихан көнендә ул ишек төбендә комсомол Үзәк Комитеты секретарьларының берсен очратты. Секретарь аны элек мәктәптә укыган чагыннан ук белә, МГИМОга рекомендациягә дә теге вакытта ул кул куйган иде. Кызның күңелсез тарихын ишеткәч, куен дәфтәренә нәрсәдер язып куйды да, хушлашканда: «Быел эшең уңышлы булыр»,—диде. Шулай булды да. Татьяна бу юлы, имтиханнарын гел «бишле»гә генә биреп, отличница булды, беренче курстан башлап университет тәмамлап чыкканчы махсус исемле стипендия алып укыды.

Кызның студентлык еллары үзгәртеп кору чорына туры килде. Мөгаен, Ташкенттагы бер генә югары уку йортында да үзгәртеп кору дигәннәрен

биредәге шикелле йодрык төйнәп, янап каршы алмаганнардыр. Күп кенә студентларның ата-аналары ришвәтчелек, ялган исәп-хисаплар, хезмәт урыныннан явызларча файдалану, казна милкен урлау кебек яман эшләре өчен җинаять җаваплылыгына тартыла башлады. Берәүләр бу хәлләрне яшереп калдырырга тырышты, кемнәрдер моны булдырды да, әмма шау-шулы низаглы эшләр матбугатта фаш ителә һәм бөтен халыкка, барып ирешә иде.

Әлбәттә, бу факультетта республика Эчке эшләр министрлыгында, Югары судта, Юстиция министрлыгында һәм бигрәк тә Прокуратурада барган үзгәрешләрне белеп-ишетеп тордылар. Ә прокурор булу хыялы юрфакка керүчеләрнең күбесенең күңелендә иде. Яшьлектә кемнең генә гаделлек яклы буласы килми!

Таня белән аның иптәшләрен хокукый дәүләткә бару юллары кызыксындырды, алар шул темага багышланып атна саен басылып килгән мәкаләләрне йотлыгып укып бардылар. Әлбәттә, Сухроб Әхмәтович Әкрәмхуҗаевның да җирле матбугатта басылган атаклы мәкаләләре турында да фикер алыштылар, ул мәкаләләр бит республиканың хәл итәргә тиешле мәсьәләләре турында, гадел юристлар әзерләү турында иде.

Сиксәненче еллар азагында әле кайчан гына җәмәгатьчелек тә хуплап каршы алган, шау-шулар белән хөкем ителгән казна каraклары бер-бер артлы әйләнеп кайта да башлады. Татьяна да аңлады: реформалар, үзгәрешләр, өметләнеп көтүләр бетте дигән сүз бу. Кичә генә газет мәкаләләрендә, телевизион тапшыруларда камчыланган, урлаган-талаган байлыклары күрсәтелеп килгән «геройлар» кайтып кына калмады, алар низаглаша-талаша, үзләренең элекке җылы урыннарын даулый, таләп итә башладылар.

Бу хәлләр барысы да кичә генә үзгәртеп кору—матур тормышка аяк басуның бердән-бер юлы дип ышанган, ә бүген инде янадан сүзсез-телсез калган, башын игән күпчелекнең күз алдында эшләнеп килде. Матур тормыш янадан да шул ук элеккегеләр кулына кайта икән ул. Студентларның да фикерләре үзгәрә башлады. Хәзер инде партия сәясәтеннән ата-аналары кыерсытылган студентлар ачыктан-ачык мактана, кемнәргәдер янарга тотындылар. Янәсе, ул башбаштаклыкларны республикага Мәскәү керткән, милләтебезнең чәчәге булган, илебезгә иминлек-бәхет теләгән, мөстәкыйльлек-суверенлык яуларга омтылган асыл шәхесләребезне җәберләгән.

Үзбәкстанның хокук саклау органнарында янадан бик зур үзгәрешләр булды: кемнәрнедер бәреп төшерделәр, кемнәрнедер күтәрделәр. Кәнәфиләрдә утырган түрәләрнең шулай алышынып торуы университет диварларында да шау-шулы бәхәскә сәбәп кенә булды.

Шундый кискен вакытта Татьяна Шилова беренче тапкыр прокурор Камалов фамилиясен ишетте. Рәшидовның дусты Аксай ханы Акмалны кулга алганнан соң, прокурорга студентларның да, укытучыларның да карашлары төрле иде. Берәүләр аның нинди абруй-дәрәҗәле кешегә дә каршы торуына сокланып, хөрмәт белән сөйләсәләр, икенчеләре аны Мәскәү куштаны, үз халкын сатучы, дип яманладылар.

Әлбәттә, студентлык еллары—өлгереп җитү еллары ул. Ә Татьяна укыган еллар исә, үзгәртеп кору елларына, туры килеп, бу чорны күп мәртәбәләр тизләтте. Иң мөһиме, шунда, ул башка сыйфатлы булды: принципиальлек, үз фикерләренә инану кирәк иде, чөнки шунсыз юрист, чын юрист булу мөмкин түгел. Әгәр дә элек кешенең гражданлык карашлары сонрак, эш барышында тулысынча ачылып житсә, хәзер ана университетта укыганда ук нигез салына. Кеше фикер-карашлары белән яшәргә, борганалып кыенлыклардан качарга тырышу авыр—барыбер кайчан да булса бер көн килә: син ачылырга тиешсен, гомерлек битарафлар яр читендә кала, аларны уннар да, суллар да яратмый, читкә кага.

Хәзерге вәзгыятьтә, теге яки бу кешеләргә булган мөнәсәбәтләрне күреп, булачак юрист Таня үзенә кемнәр якын, белгеч буларак ул кемнәр белән эшли алыр иде икәнен сизенә-тоя иде. Әле шәхсән танышуга кадәр күп алдан ул үзенең герое итеп күңеленнән генә прокурор Камаловны санады. Диплом эше язар алдыннан ана, курсның иң яхшы студенты буларак, практика үтәр урынны үзенә сайлап алырга тәкъдим иттеләр. Таня, әлбәттә, республика прокуратурасын сайлап алды. Аның үз фикер-карашлары белән уртаклашырдай, эш-гамәлләрен хуплардай кеше белән бергә эшлисе килә иде. Соңрак Таня моны «үзем сайлаган язмыш» дип атады...

Практикасын ул прокуратураның беренче катындагы тикшерү бүлегендә үткәрде, ә Камаловның бүлмәсе дүртенче катта иде. Кыз аны көн дә күрә алмавына борчылды. Ана эшне беренче сәгатеннән үк өеп бирделәр—тикшерү бүлегендә эш һәрвакыт муеннан була. Таня эшкә бер сәгать алданрак, Камалов килергә бер ун минут кала килә, шундук тәрәзәгә йөгерә, прокурорның килеп керүен күрми калырмын дип курка иде. Беренче тапкыр Камалов аңа үз яшенә караганда шактый яшь күренде—чәчләренә иртәрәк чал кергән булса да, җыйнак-пөхтә, хәрәкәтчән; һәр хәрәкәтендә, һәр адымында тәвәккәллек, бәйсезлек чагыла. Күркәм киенә, үзен тотышында, кыяфәтендә «биредәге кеше түгеллеге» сизелә. Соңрак, аның гомереңең күп өлешен Мәскәү белән Вашингтонда, хәтта бер елдан артыграгын Парижда үткәргәнен белгәч, Таня үзенең сизгерлегенә куанып та куйды.

Кызның практикасы беткәнче, алар тәки бер тапкыр да күзгә-күз очраша алмадылар. Прокурор, әлбәттә, үзенең фикердәше, ана һәрвакыт уңышлар теләүче Танянын барлыгын да белми иде.

Көтмәгәндә генә «Лидо» ресторанына чакыру алгач, Татьяна Шилова анда прокуратураның бер яшь егете белән китте. Шундагы бер сөйләшүнең ирексез шаһиты булу һич тә очраклы түгел иде. Әңгәмәчеләр Танянын үзбәкчә белгәнен, мөгаен, абайламаганнардыр, шактый ишетелерлек итеп үзбәкчә сөйләшеп утырдылар.

Еш кына «мәскәүле» дип, кемнедер телгә алып, сүзләрен йә ым белән, йә әйтеп үк бетермичә сөйләшеп утыручыларны тыңлагач, Татьяна прокуратурадан эшкә мөнәсәбәтле ниндидер яшерен мәгълүматларның читкә таралганын йөрәге белән аңлады, чөнки ул үзенең кайда эшләгәнен белә иде инде. Бу сөйләшүне ишетүен дә, ресторанга баруын да кыз югарыдан ингән ишарә дип санады. Үзе хөрмәт иткән кешене хәвеф-хәтәрләрдән ничектер саклап калырга кирәклеккә ишарә иде бу.

Ул кичне ресторандагы яшерен сөйләшүнең ирексез шаһиты булган Таня аңа артык игътибар итмәсә дә, үзе артыннан йөрергә тырышкан кешедән саклана башлады. Ә инде мәсхәт төрекләре белән бәйләнешле Фирганә вакыйгалары вакытында Коканд-Ленинабад юлында Камаловка һөҗүм ясалганын газетлардан укып белгәч, күңеленнән һич китмәгән әлеге сәер сөйләшү кызда ниндидер шик-шөбһә тудырды. Берничә көннән соң, бу юлы Ташкентның үзендә яна һөҗүм оештырылып, прокурорның хатыны белән улы һәлак булгач, Татьяна, ниһаять, аңлап алды: яшерен сөйләшүдә сүз Камалов турында барган икән....

Үзенең шикләнүләре турында сөйләргә теләп, Камалов янына хастаханәгә барырга кыймыйча, бер өч атналап йөрде Таня, әйтерсең, бу адымнан соң үз тормышы кискен үзгәрәчәген тойды ул. Барып сөйләп биргәч, үз хәбәренең бик кыйммәтле булуын аңлады: сатлыкҗан прокуратурада эшли, күп гомерен шундый сатлыкҗаннарны фаш итүгә багышлаган Камаловның тикшерү эшендә нәкъ шушыны ачыклау җитми икән. Прокурор, Татьянаның сүзләрен тыңлап бетергәч, караватъ янындагы тумбочкадан бер папка тартып алды, аны ачып кызга бер фоторәсем күрсәтте дә:

—Синең янга шушы кеше килеп утырган идеме?—дип сорады.

—Әйе...—кызның җавабы барлык шикләнүләргә ачыклык кертте.

Бу сөйләшүдән соң шактый вакыт үтте. Татьяна Шилова республика прокуратурасында бер айдан артык эшли иде инде. Аны үзе элек практика үткән беренче каттагы бүлмәгә утырткан иделәр.

Хәзер Таня яңадан тәрәзә буенда басып тора, чөнки үзенең шефы, оешкан җинаятьчелек белән көрәшү бүлеге начальнигы Камаловны алып кайтырга дип хастаханәгә киткән иде. Инде ярты ел үтте дигәндә, кемнәрдер Камалов кайтмас дип йөргәндә, ул үз бүлмәсенә эшкә кайтырга тиеш.

Урамда прокуратура тирәсендә машиналар тезелеп тора, анда таныш түгел ниндидер кешеләр йөрenә. Кичә шефы, ничектер тәрәзәдән карап торды да: «Боларның теләсә кайсысы прокурорны ауларга йөрүче булырга мөмкин бит»,—диде.

Татьяна прокурор машинасының килеп туктаганын абайламый калды. Машинадан беренче булып Нортухта сикереп төште—Әфганнарны үткән егет, Камалов шуның белән бит инде үзен үтерергә ялланган бандитларны Коканд-Ленинабад юлы өстендә кырып салган иде. Егет, тиз генә борылып, тезелеп торган машиналарга күз йөгертеп алды. Игътибарлы кеше аның юка замш курткасы астында корал барын чамалар иде.

Камалов ишеккә күтәрелә торган мәрмәр баскычлардан әкрен генә менә башлады, һәр адым аңа авырлык белән бирелә иде. Татьяна аның ябыгып-сулып калган йөзен, киң маңгаен урталай ярып төшкән яңа яра эзен күрде, чәче дә үскән, Голливуд киногеройларына охшап калган икән, ләкин кыз үз чагыштыруыннан үзе үк оялып куйды. Баскычтан асыл ир-ат менеп килә, башлаган эшен ахырына кадәр җиткерү өчен менеп килә иде. Кызның иреннәре үзеннән-үзе пышылдады: «Ходаем үзе сакласын сезне!»

## XI

Төзәтү учреждениеләре, ягъни зоналар-төрмәләр өстеннән күзәтчелек алып бару бүлеге прокуроры Канзафар Рөстәмовның кәефе начар иде. Өченче атна рәттән кәрт уенында гел оттырып килә, машина алырга дип тәвәккәлләп җыйган акчалары очып бетте инде. Барлык зоналар, һәм төрмәләрнең әле тегесендә, әле монысында бер-бер хәл булып тора, йә бунт күтәрәләр, йә төрмәчеләрне тоткыннар каптыра, качып китүчеләре дә күбәйде. Рөстәмовка республиканың бер төбәгеннән икенчесенә чабып йөрергә туры килә—хезмәт белән төзәтү колонияләре ял итеп ята торган матур җирләрдә түгел. Исеме генә кунакханә саналган пычрак йортларда кунасың, ярлы гына казна ашханәләрендә ашыйсың, һаман да транспортның җитәрлек булмавы—болар, чыннан да, җенеңне чыгара, үртәләсең, башка бүлекләрдә эшләүче хезмәттәшләреңә көнләшеп карыйсың. «Ни өчен соң әле мин тоткыннар тотылган ул зоналар-төрмәләрдәге гаделсезлек, шәфкатьсезлек, хәерчелек өчен җавап бирергә тиеш?»—дип үзеннән сорый Канзафар, Сенаторны ашыкмаганы, акрын кыймылдаганы өчен эт итеп сүгә. Партия Үзәк Комитетының административ органнар бүлеге мөдире булып эшләгәндә, ул бит Канзафарга, Ташкентның берәр районына прокурор итеп урнаштырам дип бер генә тапкыр вәгъдә бирмәде. Ныклы вәгъдә бирде, ә нәрсә килеп чыкты? Үзен утыртып куйдылар, шул булды. Рөстәмов аны һич кенә дә кызганмый—Сенатор рәхәтләнеп яшәп калган ичмасам!—Рөстәмов үзен кызгана.

Канзафар Табаксайга барып кайтырга тиеш иде. Андагы төрмәдән, сакчыларның кайсысындыр куркытыпмы-сатып алыпмы, бер төркем тоткыннар качкан икән. «Кем инде шул юк кына акчага тоткыннар белән

эшләргә барыр иде?»—дип уйланды ул, төрмә хәлләрен башка барлык кешеләрдән күбрәк белгәнлектән.

Тоткыннардан ничә төрле юллар белән акча каеруны хәтта Канзафар да белеп бетерми—чөнки ул ысуллар көн саен гел янарып тора.

Бервакыт шундый вакыйга булды. Бер шәһәрчектәге дүрт катлы «хрущевка»ның балконнары төрмәнең чәнечкеле тимерчыбыклы коймалары өстенә үк асылынып тора икән. Бер яшь кенә кызның лоджиясе нәкъ ирләр барагы каршысында булып, кыз көннәрдән бер көнне шунда купальниктан гына чыгып баскан. Шулчак барактагы тоткыннар сокланудан дәррәү үкерергә тотынганнар, хатын-кыз хатын-кыз инде, үзенә игътибар булганда ул һәрвакыт шат, бу кыз да бaрактан өерелеп чыккан ир-атларның үтенече буенча, төрлечә кыланып-кызыктырып, бер биш минут йөренеп тора. Кереп китәргә җыенгач, кемдер аңа: «Монысы сиңа безгә рәхәтлек биргәнең өчен, гүзәлкәй!»—дип, балконга брезент бияләй ыргыта—бияләй эчендә таш белән бергә йөзлек акча да була. Шуннан соң кыз эшеннән китә һәм көн саен өч мәртәбә шул үкереп торучы тоткыннарга күренү өчен балконга чыга икән—аның ярымшәрә стриптизы-кыланышлары оятсыз фильмнардагылардан бер дә ким түгел, диләр. Бу бәхетле балкон хуҗасына шәһәр халкы көнләшеп карый, ди. Канзафар Рөстәмов, бу вакыйганы ачыклау өчен әлеге шәһәргә килеп, кыз белән дә очраша. Кыз бик күпне белә икән: «Мин,—ди,—демократик дәүләттә яшим, үз балконымда физзарядканы кайчан теләсәм, шунда ясарга хакым бар!»—ди. Менә син аны берәр җаваплылыкка тартып кара инде—хакың юк.

Рөстәмов үзе дә тоткыннар хисабына яши, кайвакытларда кесәсенә ОБХСС хезмәткәрләре каерганнан ким акча керми иде. Төрмәгә бик кирәкле хат-хәбәр илткән өчен, бигрәк тә эше судта булган берәрсенең туганнарыннан унар мең каера иделәр. Бервакыт Рөстәмов берьюлы йөз мең сум алды—бу бит акча әле көчендә булган елларда! Дөрес, аңа төрмә начальнигы белән бүлешергә туры килде. Бик зур урлашулары өчен кулга алынган бер гаепләнүче янына биш кенә минутка кереп чыгарга аның бер куштаны үтенгән һәм шуның бәрабәренә йөз мең вәгъдә иткән иде. Күрешү күзгә-күз, шаһитларсыз гына булырга тиеш, хат-хәбәр тапшырырга аның ризалыгы юк—түләү дә шуның өчен иде. Аларның күрешүе, әлбәттә, тикшерүчеләрне бутау, судта үзенне ничек тоту хәлләрен сөйләшү-килешү өчен булды. Күрешү төн уртасында, нәкъ биш минут кына дәвам итте.

Канзафар каты тәртипле төрмәләрдә утыручы «абруйлыларга», законлы каракларга хат-хәбәрләр дә ташый, алардан иректәге кулдашларына һәртөрле кинәш-тәкъдимнәр алып чыга—җинаятьчелар арасында аның кушаматы да бар иде: «Почтальон». Бу һөнәренә дә яхшы түләп килделәр, ләкин хәзер, үзгәртеп кору дигәннәре башлангач, әлеге эш белән шөгыльләнү хәвефлегә әйләнде. Элек эре караклар аңа таяна, килештереп булганы өчен аны хөрмәт итә иделәр, ә хәзер, әйтерсең, үзләрен шайтан котырта, даими өркетеп-куркытып, хәбәрдарлык заманына ишарә итеп кенә торалар. Законлы бер карак аны төрмәдә француз коньягы белән сыйлады, менә шул үзгәртеп коруны болай аңлатты: һәр нәрсә сатыла һәм сатып алына торган заман бу, әйбәт заман, озаккарак кына сузылсын иде—менә шуның хөрмәтенә чәкәшеп эчтеләр дә.

Үз гомерендә Канзафар кулы аша аз акча үтмәде, әмма алар аңа бәхет китермәде, бәла һаман да шул кәрт уйнавында иде. Ул, күпчелек—башкалар шикелле үк, студент чагыннан тулай торакта ук уйный башлады, әле ул чагында аның бу комсыз-комарлы уеннан котыла алмаячагын берәү дә чамаламаган-белмәгәндер. Университетны тәмамлап чыкканнан соңгы беренче ун ел торгынлык елларының гөрләп чәчәк аткан чагына туры килде. Нәкъ

шул чорда рәсми кешеләр арасында кәрт уйнау чире таралды. Кайсы гына шәһәргә командировкага барып төшмәсен, Канзафарны һәркайда кичләрен кәрт уйнарга чакыралар, гадәттә өлкәләр-төбәкләрдә уен кунакханәләрдә бара, бу инде нәкъ Мәскәүдән йоккан гамәл, чөнки анда һәр кунакханәдә диярлек катран—кәрт уйный торган урын була.

Ул заманнарда әле гореф-гадәт, йолалар хәзерге шикелле каты түгел: бик зурдан оттырсаң да, аны җинел генә гафу итәләр, чит-ятлар анын исәбен дә алып бармый, оттырышынны башка кешегә күчерү дә юк, түлисе бурычынны вакытында түләмәгән өчен сине кыерсыта да башламый иделәр. Әмма кинәт кенә һәркайда,—әйтерсең лә, моны ниндидер мәкерле һәм бик акыллы кемсә оештырган шикелле,—уенга һаман күбрәк кешеләр тартыла башлады. Төрле кагыйдәләр уйлап чыгардылар, кәрт уйнаучылар капкынга капты. Җинаятьчел дөньяның галәмәт зурлыгын, анын кануннарын булдырып, тормышка ашырып торган «даһиларын» белгәнлектән, Канзафар еш кына үз-үзенә шундый сорау бирә: бу хәлләр очраклы гына килеп чыктымы, әллә юкмы?

Ул үзе дә шул уеннын әсире булып китте. Беренче елларда ул даими отып килде. Отып алган акчаларына халык телендә «дворяннар оясы» дип йөртелгән абруйлы районнан биш бүлмәле кооператив фатир сатып алды. Прокуратура хезмәткәренә авыр эш түгел иде бу, калын кесәле дә булгач, тиешле акчаны ул берьюлы түләде дә бетерде. Ул чорда һәртөрле түрәләр йорт-җирне казна хисабыннан алырга тырыша һәм шулай эшли дә иде. Әмма Канзафарнын бер көн дә чират көтеп торасы килмәде. Кооператив гаражы да, беренче машинасы да отышлар һәм ришвәт акчаларына булдырылды, гади прокурорнын хезмәт хакына бик сикеренә алмас иден юкса.

Анын «катала» дигән абруе да үсә барды—кәрт уйнаучылар үзара оста хәрәмләшүчеләрне шулай атыйлар. Уенда төп кагыйдә—әгәр оттырсан, бурычынны үз вакытында түлә, бурычы булмаган «катала»лар бер тиенсез килеш тә янадан уйнарга хаклы, анын абруй-дәрәҗәсе шундый. Канзафар бик озак кәрт уенын теләсә кайчан ташлый алуына ышанып яшәде, уенда да бик «сикереп төшми», комарлыкка бирелми, үзенен көчлелеген шунда күрә иде. Уенда ул, тормыштагыча, алдын-артын уйлап эшли, салкын канлы, тыштан хисчән кеше булып күренсә дә, үз хисләрен тыя белә иде. Анын кәрт уенындагы уңышларын аналитик, ягъни тикшерә белүчән акылы белән дә аңлатырга булыр иде, ул бит Ташкенттагы атаклы йөз унынчы математик мәктәпне тәмамлады, хәтере дә искиткеч яхшы иде. Андый уенчы уенда ташлап барылган кәртләрнен һәрберсен исендә калдыра, шунын белән ота да. Әгәр дә кәрт уенына бирелеп китмәгән булса, Рөстәмов танылган гына шахматчы була алыр иде. Ул үз көченә шулкадәр ышана иде ки, әгәр дә бәхете басып, бер миллионны отса, уеннан әкренләп кенә таярга хыялланып яшәде. Ә ул заманнарда, бик сирәк булса да, андый отышлар чыккалый иде. Барып чыкса бу хыял, ул тыныч кына, акчалы гына берәр хезмәткә урнашыр (сатып алыр!), анда-монда тыкшынмый гына тормыш итәр иде—бар халык ярлы-хәерче заманда безнен илдә миллион сум акча зур акча иде инде ул.

Ләкин, кеше хыяллана, ә Ходай Тәгалә үзенчә хәл кыла... Канзафар, җирле халык уенча, сонга калып өйләнде, егерме сигез яшендә генә. Әмма анда да бәхет елмайды, яхшы һәм танылган ырудан матур гына кызны эләктерде—мәктәп бетереп чыгуына ук!

И бу язмыш уены! Өйләнеп ярты ел да үтмәде—беренче кисәтү янгырады: сина гел генә отып барырга димәгән, оттырып, һәммәсен дә югалтуын да бар икән...

Ул, туйлар үткәргәннән сон озак та үтми, бик нык оттырды, откан кеше бик көчле иде, анардан кул селтәп кенә котылып булу мөмкин түгел иде. Рөстәмов өметсезлеккә бирелгән мизгелләрендә аны үтерергә дә ниятләп

карады, әмма моны эшләргә көче булмады. Алай гынамы соң, теге адәм, әйтерсең, аның уй-ниятләрен укыган: прокуратура янында очратты да төксе генә әйтеп куйды:

—Башка берәү булса, бәлки, бурычын гафу да итәр идем, ләкин ментларга—бервакытта да. Мине аңламаячаклар...—Аннары ул, Канзафарның күзләренә туп-туры карап өстәде:—Әгәр әшәкелек эшләргә уйлаган булсаң, кисәтеп куям—сезнең халыкка миндә рәхим-шәфкать хисе юк.

Бурычы өчен Канзафар, бөтен җиһазлары-ние белән, биш бүлмәле фатирын, машинасы-ние белән гаражын биреп, үзе Чиланзарның егерме алтынчы кварталында машиналар юлы өстендәге өч бүлмәле панель йортка күчәр, дип килештеләр. Хатынын күченүгә әзерләргә кирәк иде, чөнки вакыт кыса. Хатыны, табигый инде, елап, әти-әниләренә йөгерде. Шунда Канзафарга тагын бик каты китереп суктылар: хатынының әтисе, күрәсең, кәрт уйнаучыларның кем икәнлекләрен белә иде, тиз һәм тыныч кына итеп кызын иреннән аерылыштырды да өенә кайтарып утыртты. Бу әле язмышның беренче чаң сугуы гына булган икән. Хатыны киткән көнне үк Канзафар оттырганыннан да күбрәк итеп акча отты. Әлбәттә, бар булган бурычларын түләп бетерде, үз йортында калды, әмма хатынсыз гына... Шуннан соң ул тагын бер тапкыр өйләнде, ләкин бер ел да яши алмыйча, үзе теләп аерылышты. Бу хатыны ялкау, ашарга-эчәргә әзерли белми, кер юа алмый, теләге дә, сәләте дә юк икән. Уенда бары тик шул бизәнү салоннары да, тегүчеләр генә, өйгә шылтырата алмыйсың—ул һәрвакыт телефонда кем беләндер ләчтит сата, ә инде бала табу турында ишетергә дә теләмәде.

Озакламый Канзафар зур шәһәрдә һәрвакыт кияү егет булуның үз рәхәте барлыгын абайлап алды. Гадәттә, ул өч-дүрт кызның башын әйләндерә, теге мескеннәр аның керләрен дә юа, фатирын да әйбәтләп җыештырып чыга—көндәшлек үз эшен эшли. Кем мондый хәлләргә түзә алмый—китеп бара, әмма шунысы сәер, киткән кыз урынына шундук икенчеләре, әле җитмәсә, аның дус кызлары ук йөгереп килә. Егет артык тәкәббер-горур булганнарына гел әйтә торды: изге урын буш тормас. Ә кияү егете буларак, ул кызыгырлык та иде шул: үзе яшь, эчү-тарту дигәннәрне белми, абруйлы урында эшли, машинасы, менә дигән биш бүлмәле фатиры бар—кыскасы, Рөстәмовка кызлар балга сарылган чебен кебек сарыла иделәр, дөресрәге, ул аларның бәясен белә иде... Ләкин аның йөрәген яулап алырлык кыз, ай-һай, табылыр идеме икән—ул бит баш-аягы белән шайтан шаукымына, кәрт уенына бирелгән кеше иде инде.

Фатирын саклап калгач, ул үзенең уңышларына инанып, акча өчен кемнедер үтерергә дә әзер торганын бик тиз онытты. Дөрес, оттырышлары да булгалый иде. Бервакыт, аның Нәвои шәһәренә тикшереп кайту өчен барасын белгәч (ә анда хезмәт белән төзәтү колонияләре шактый), анардан бер тоткынга хат тапшыруын үтенделәр, әҗере итеп, оттырган бурычларын гафу иттеләр. Ул исә, күзен дә йоммыйча оятсызланып, тагын бер биш мең сум акча сорады, янәсе, төрмә башлыкларын майларга кирәк булачак. Гаҗәпләнүенә каршы, аңа сораган кадәре акчаны китереп тә салдылар. Шулай итеп, табыш табуның тагын бер ысулы ачылды, менә шуннан инде аңа «Почтальон» кушаматы ябышып калды да.

Бер саткан-сатылган кеше алга табан туктый алмаячак, диләр. Канзафар да, зонадагы «хуҗага» күрсәтмә хат кертеп биргәч, моның хыянәткә беренче адым гына икәне турында уйлап карамагандыр. Ташкентта ул елларда яшеренеп кәрт уйный торган егермеләп катран бар иде. Аларда, зур-зур суммалар салып, зур-зур түрәләр уйный, Рөстәмов «катала» буларак өскәрәк күтәрелгән саен аның Сенатор һәм Миршаб белән очрашу ихтималы арта барды. Ниһаять, алар очраштылар.

Ул кичтә халык күп иде. Сенатор белән Миршаб озак тормадылар, алай да прокуратурада эшләүче егетне шәйләп алдылар, аларны яхшы белгән Канзафар, үзләрен күрсә дә, уен өстәле яныннан кузгалмады, уенның бик кызган чагы иде. Икенче тапкыр алар бер айдан соң шунда ук тагын очраштылар, бу юлы уенда ук инде. Төнлә соңлап кына кайтып барганда Миршаб Сенаторга әйтеп куйды:

—Бу егетне ничектер төп башына утыртасы иде, тормышының чигенә китереп җиткерсәк, безгә кирәкле кабинетларда актарынырга мәҗбүр итәр идек үзен.

—Шәп фикер!—диде йокымсырап барган Сенатор.—Мин прокуратурада күптән инде үз кешебезне булдыру турында уйлап йөри идем. Ә бу Канзафар шома егеткә охшаган, төшеп калганнардан түгел. Ләкин ничек каптырырга соң аны? Әйбәт уйный, артык мавыгып та китми, мин аның куйган акчаларын, кәртләрен күзәтеп утырдым.

—Мин дә ул хакта уйландым. Икәүләп кенә без аны җинә алмабыз, бик сак егет, шундук сизеп алыр. Ике оста профессионал уенчыны ялларга кирәк, андыйлар катранда гел булып тора. Аларга әйбәт кенә түләргә, без бу егетне бер хатын-кыз өчен акылга утыртырга телибез, дияргә була. Ярдәм итегез әле, диярбез. Әлбәттә, жай чыкканын озак, бер өч айлап көтми булмас, янәсе, очраклы гына килеп чыккан эш бу, диярбез.

—Бик шәп! Мин Бармаксызга ике оста уенчы табарга кушармын, Канзафарны шулай аулый башларбыз, кирәге чыгар аның...

Оста уенчылар үзара «мокыт» дип йөртә торган корбаннарын кайвакытларда еллар буе әзерлиләр. Аны ияләштерәләр, ана оттыралар, кайчакларда зур-зур оттырышлар да ясыйлар. «Мокыт»ка бурычларын сөйләшенгән вакытта шаһитлар алдында гына түлиләр. Болар барысы да алдагы көннәр өчен эшләнә: гадәттә, «мокыт» дигәннәре—калын кесәле хуҗалык хезмәткәрләре, ришвәт алып миллионнар туплаган рәсми түрәләр. Ләкин көннәрдән бер көнне бик зур акчалар салынган уенда «мокыт», әтәчләнеп китеп, үзеннән дә шул кадәр үк акча ыргыта, шунда аны берәр миллион-миллион ярым сумга каптыралар да. Ана чаклы аны үсендерү өчен тегеләр исә күп булса йөз-йөз илле мең генә оттырган була.

Оттыручылар бурычларын төрлечә түли: берәүләр шунда ук булганын чыгарып сала, икенчеләре, Канзафар кебек үк откан кешесен үтерергә хыяллана, төрлечә боргалана башлый. Бурычларын бигрәк тә зур партия түрәләре, хокук саклау оешмаларындагы хезмәткәрләр түләргә яратмый. Әмма моны оста «каталалар» яхшы белә, алар һәрнәрсәгә әзер, бөтенесе дә энәсеннән җебенә кадәр исәптә була. Әгәр дә «мокыт» яхшылык белән түләмәсә, эшкә кәттә егетләр тотына. Алар, һәр шәһәрдә бар, күбесе элекке спортчылар һәм элекке милиция хезмәткәрләре. Бу кәттә егетләр кәрт уенчылары белән эшмәкәрләргә генә түгел, акча белән бәйле теләсә кемгә хезмәт итәләр—түләгез генә! Бирелә дә бәя ныклы—һәр йөз сумның кырыгы аларга. Алар, кирәк булса, кемнедер үтерүне дә әллә нәрсәгә санамыйлар.

Кирәкле егетләр белән бергә Канзафарга каршы уйнау мөмкинлеге җиде айдан соң гына килеп чыкты. Ана кадәр Миршаб йортында озаклап-җентекләп уйнарга өйрәнү, осталыкларын арттыру әйбәт нәтиҗә бирде: Рөстәмовны тетеп кенә салдылар, аның әле үз гомерендә бер генә дә ул кадәр оттырганы юк иде. Бу уенчыларга түләргә тиешлесен Канзафар шул көнне үк түләде, ә үз иптәшләре булган прокурорларның берәр ай көтеп торуларын үтенде. Нәкъ Сенатор уйлаганча булды бу. Канзафар килешенгән бер ай бик тиз үтеп тә китте, ул хыялланган зур отыш чыкмады. Тиешле вакытка бары тик түләнәсе акчаның өчтән бере генә җыелды. Рөстәмов, очрашып, шушы акчаларын биргәч, тагын бер айга вакыт сораган иде дә, бик каты кире

кактылар. Бу инде сине «сәгатькә» утырттылар—яки-яки дигән сүз, иртәгә үк бу турыда һәр теләгән кеше белә ала, сиңа уен өстәле янына юл ябык.

Аның шулай «өлгереп җиткәнен» көтеп торган Сенатор Рөстәмовка үзе күптән уйлап килгән тәкъдимен әйтте: син безгә кайбер хезмәтләр күрсәтәсең, ә без бурычларынны каплыйбыз, диде. «Хезмәтләр» дигәне шул: Канзафар аларны кызыксындырган документларның күчермәләрен алырга, хезмәттәшләренең эчке телефоннарын тыңлап, аларны хәбәр итәргә, кайбер бик кирәкле эш кәгазьләрен урлап алырга—кыскасы, шпионлык белән шөгыльләнергә тиеш иде. Сенаторның гаҗәпләнүенә каршы, Канзафар кырт кисеп, бу эшләрдән баш тартты. Менә шуннан соң Сенатор белән Миршаб, үзләренә эшләрдәй кешенең прокуратурада булуы кирәклеген тагын бер кат уйлагач, тегене кәттә егетләр белән куркытмакчы булган иделәр, әмма мәсьәлә көтелмәгәнчә үзеннән-үзе хәл ителде дә куйды. Костаны чакырып, бик артык тырышмаска, өркетергә генә дигәч, тегесе көлеп җибәрде дә, Канзафарның җинаятьчеләр өчен күптән таныш кеше булганлыгын, кушаматы «Почтальон» икәнлеген дә сөйләп бирде. Сенатор белән Миршаб шаккаттылар—алар болай булырын һич көтмәгән иделәр бит. Костаның сөйләгәне эшне бик тә җиңеләйтә иде, ләкин Миршаб тагын бер мәкерле нәрсә уйлап тапты: ул Рөстәмовка шылтыратты да житди сөйләшү өчен аны тиз генә үзенә килергә чакырды. Бу хәйлә гади һәм нәтиҗәле булып чыкты: прокурорлар белән тәмләп сөйләшеп торган Костаны күргәч, Канзафар эшнең нәрсәдә икәнен шундук аңлап алды һәм аларга тулысынча бирелде. Шулай итеп, ул үз хезмәтендә алар агенты булып калды.

Әйе, нәкь менә агент, чөнки үзенә кушылган эшләрне үтәр өчен, һичшиксез, шпионлык сәләте кирәк тә иде. Сенатор белән Миршаб аны ныклап әзерли башладылар.

Рөстәмовка кечкенә генә автоматик «Кодак» фотоаппараты, Миршабтагы шикелле япон диктофоны бирделәр. Бу диктофон сөйләшүчеләрне стена аша да җиңел тыңлый ала иде. Прокурорга фатир басучы каракларлан да дәрес алырга туры килде—аны төрле ишекләрне ача торган ачкычлар белән ничек эшләргә кирәклегенә өйрәттеләр. Ул сәләтле «укучы» булып чыкты, кулына тоттырган ун йозакның унысын да вакытыннан элек шартлатып ачып бирде. Әмма Сенатор аңар һәр мөмкинлек булган саен теләсә нинди ачкычның күчермәләрен алу бурычын куйды. Чөнки ул андый ачкычларның да эзе төшеп калганлыгын белә иде. Бу эш Канзафарга бик ошап китте. Беренче ун ачкыч күчермәсен ул тиз генә эшләде—ачкычлар еш кына бүлмә ишекләренә тыгылган килеш тора иде. Аларның күчермәсен алгач, хуҗаларына кире кайтарып бирә дә, җитмәсә әле ваемсызлыклары өчен кисәтү дә ясап китә башлады. Әмма ул ешрак башка алым белән эш итә иде: үзен кызыксындырган кабинетка кереп, тегесен-монысын сөйләштереп утыра да, бүлмә хуҗасын телефоннан өскә чакырып алган чагында, ачкычлар аның ихтыярында була. Бер генә кеше дә, ачкычлары, хәтта сейф ачкычлары өстәлендә яткан чакта да, ана чыгып торырга кушмый иде—прокуратура кешесе бит! Сонрак шул кадәр остарып китте ки, хуҗалары чыгып йөргән арада кирәкле кәгазьләрнең күчермәләрен дә төшереп ала башлады. Бик кирәк очракларда алар Әкрәмхуҗаев белән бергә эшли башладылар: тегесе, прокурорның берәр урынбасарына килә дә, шуннан үзләренә кирәкле кәгазьләрдә актарынырга тиешле бүлек башлыгын чакыртып алдыра—шул арада Канзафар тегенең бүлмәсендә утыра инде.

Бервакыт, Канзафар бик тә кирәкле әһәмиятле документлар урлап чыккач, аны Сенатор шатлыгыннан «Штирлиц» дип атады. Шуннан соң аны Миршаб белән бергәләп үзара гел шулай атап йөртә башладылар. Ләкин бу болай да куркыныч эш, Мәскәүдән яңа прокурор Камалов килеп төшкәч, тагын да

куркынычракка әйләнде. Ничектер бервакыт Канзафар Сенаторга: «Аның күзләре рентген кебек»,—дип, куркынып әйтте. Рөстәмов ике тапкыр чак кына янмый калды. Беренчесендә, ул Миршабка прокурор Камаловның мафиягә каршы яңадан оештырылган бүлеге белән үткәргән яшерен киңәшмәсе турында хәбәр иткәч булган иде. Ул көнне, инде киңәшмә башлангач, Канзафар үзеннән бурыч төшкәнгә санап, чыгып китәм генә дигәндә, прокурор янына көтмәгәндә республиканың җинаятьчеләргә каршы эшләү бүлеге начальнигы полковник Жураев килде. Сенаторның күзәтүенчә, Камалов белән Жураев соңгы вакытларда артык еш очраша башлаган иделәр. Менә шул вакытта Канзафарның йөрәге кага башлады—Жураев, хәйләкәр төлке, нәрсәнедер иснәнеп тапкандыр, ахрысы. Ул, күрше йорт түбәсендә утырып, каршы яктагы бүлмәдә яшерен киңәшмәдә сөйләтүчеләрнең сүзләрен иреннәреннән укып утырырга сәләтле. Айдын шул ук Жураев кулына эләксә, үзенең харап буласын да сизенгән иде. Ләкин ул вакытта снайпер-төз атучы Ариф, Жураев кешеләре Айдынны алып китеп барганда ук атып үтереп, бу эшне йомдырырга ярдәм итте. Рөстәмов ул вакыйгадан соң бер атна аңына килә алмый йөрде...

Икенче тапкыр ул тагын бер айдан соң аз гына үлми калды: баскычтан төшеп барганда богау салынган Фәхретдиновны алып төшеп килә иде. Ә Фәхретдинов ана таныш ин оста кәрт уенчысы, үзәк телефон станциясендә элемтә инженеры булып эшли икән. Аллаһы Тәгалә бу юлы да Рөстәмовны ярлыкап калды—Фәхретдинов прокурор Камаловның сөйләшүләрен тыңлап барган икән дә, шуның белән эләккән икән. Әлбәттә, Канзафар Фәхретдиновны кем сатып алганын белә иде. Теге мескен Махачкаладан килгән бер оста уенчыга бик зур акча оттырган, ә откан Ташкентта беркем дә күрмәгән икән, ул юкка чыккан. Менә шуннан соң коты ботына төшкән Рөстәмов үз хезмәтләре өчен Сенатордан аны башкаладагы берәр район прокуроры итеп урнаштыруын сораган, ә тегесе, Камалов Гоголь урамындагы кабинетыннан киткәч, эшләрмен, дип ризалык биргән. Әмма башкача килеп чыкты шул: Сенатор үзе республика партия Үзәк Комитетының «Ак йорты»ннан «Матросская тишина» төрмәсендәге как тактага күчәргә мәҗбүр булды.

Төнлә бик соң гына Рәстәмовка Хашимов шылтыратты. Шушы көннәрдә прокурор Камалов хастаханәдән чыга икән, аны гел күзәтеп торырга кирәк булачак, диде. Нигездә КГБның элекке хезмәткәрләреннән тупланган яңа бүлеккә—оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәшү бүлегенә күчү җаен карарга боерды. Ул бүлектә яңа хезмәткәр, прокуратурада практика үткән Татьяна Шилова эшли башлаган иде. Канзафар шуны бит инде Сенатор белән очрашыр алдыннан «Лидо» ресторанына чакырган иде. Егет, аның белән танышкач, Миршабны кызыксындырган бүлеккә ешрак кереп йөреп булыр дип өметләнә иде. «Почтальон» эш бик куерып китәсен чамалый, әмма чигенер җире юк—ул үзен күптән шул хәлгә куйган иде инде.

### XII

Аксайның мәһабәт Ленин һәйкәле каршындагы Кызыл мәйданда мәчет төзү эшләре таңнан-таңга кадәр диярлек туктаусыз дәвам итә иде. Хәтта ял-бәйрәм көннәрендә дә туктап тормыйлар. Мәчетне өлгертеп бирергә ялланган эшчеләр житәрлек булса да, Аксай һәм якын кышлаклардагы ир-атларның олысы-кечесе буш вакытларында булышырга килә, юкса, беркем дә өмә-фәлән игълан итеп тормый иде.

Мөгаен, үзгәртеп кору чоры башланган, бу, ниһаять, күзгә күренерлек бер эш булгандыр, һәркем үз өлешен кертергә тырышты. Башка сәбәпләр дә

юк түгел иде: хан Акмалның кайтуын күп көтәсе калмады, «кайчандыр көчле булган ил күз алдында таркала бит»,—дип сөйләнүләр ешайды. Ә үзгәртеп кору дигәненнән башлары әйләнгән кайберәүләр хәзер үзләрен озын телләре өчен каргыйлар. Сабир-бобоның үткен күз карашын тоеп, төзелештә тырышып эшлиләр—гөнаһларын юалар. Янәсе, кайчандыр Горбачевның тәмле теленә алданып, хан Акмалның хакимлеге бетәр, ул гадел түгел иде, дип йөрүчеләр хәзер шып булдылар.

Яшелчә-мазар килеп кенә тора. Көнгә ике-өч йөз кешене ашатып торуы җинел түгел.

Мәчетнең гөмбәзе белән манарасындагы очлы башлы, алтын айлы төп манарасын күккә кадәр күтәрә башлагач—ә ул мәһабәт Ленин һәйкәленнән дә шактый биек иде!—намаз уку йортын бизәргә дә бүләкләр килә башлады. Бусында инде элекке һәм хәзерге түрәләр юмартлыгы белән гади халык ярыша алмый иде. Өлкә сәүдә оешмасынын элекке директоры, яшеренеп кенә, Сабир-бобога шәхсән үзе Югославиядә эшләнгән зур-зур ун люстра китерде, ул аларны конфискациядән ничек саклап калгандыр—белмәссең. Күрәсең, бүләк иясе, үзгәртеп кору чорында казна каракларын, исем-дәрәҗәләренә карамастан, төрмәгә яба башлагач, үзенең исән калуы өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтергә теләгәндер. Мәчеткә берьюлы өчәр-бишәр келәмнәр бүләк итә башладылар, алар Хива келәм комбинаты эшләгән юкбар гына түгел, ә чын келәмнәр—кулдан эшләнгән әфган, фарсы келәмнәре иде, ә кайдандыр ерактан килгән бер сәүдә хезмәткәре «Рус чибәре» дип аталган уникә данә келәм калдырып китте. Күрәсең, гөнаһлары күп булгандыр инде, шуларны ярлыкауны сорагандыр.

Кайвакыт, телефоннан шылтыратып, ярдәм-фәлән кирәкмиме, дип сорыйлар. Кирәге чыкса, шундук цемент, менә дигән эрбет бүрәнәсе, яки хәзер беркайдан да табып булмый торган йөзләгән банка шәп буяу төягән машиналар килеп тә җитә. Ә Нәмангандагы бер хуҗалыкчан түрә Сабир-бобога бигрәк тә зур яхшылык эшләде. Мәчетнең тышын тышлыйсы плиткалары белән сантехника җиһазларының үзебезнең илнеке икәнен белгәч, ул аларны тиз генә гаҗәеп матур перуан кафельләренә һәм фин сантехникасына алыштырып китерде. Болар өлкә концерт залына дип кайтарылган булган икән дә, түрә, мәчет халык өчен сәнгатьтән дә артыграк кирәк, дигән. Аның бу сүзләре Сабир-бобо өчен бүләкләреннән дә кадерлерәк булды.

Аксай мәчетен төзүгә зур бүләкләр биргән түрәләрнең күпчелеге Сабир-бобо яна мәчетне хан Акмал кайтуга төзеп бетерергә тырыша дип уйлый иде. Әмма Сабир-бобо, бөтен көчен-җегәрен, күнелен, булган байлыгын мәчет төзүгә салганда, бөтенләй башка хыялларда булды: өлкәдәге берләнбер мәчетне ул төзетте бит, бу исем-данны аның берәү белән дә бүлешәсе килмәде. Хәтта хан Акмал белән дә. Ул көн-төн Аллаһы Тәгаләдән мәчетне үз исеме белән атасыннар иде, дип сорады, төзелеш вакытында исемен телгә алсалар да чиксез куана иде. Очрашканда үзеннән: «Мәчетегез ничек төзелеп килә?»—дип сораучыларга да ул елмаеп кына торды. Көн саен ул мөселман халкына бу мәхәллә аның мәчетенә йөриячәк, дигән фикерне сендерә килде. Янәсе, мәчет аның үз якташларына бүләге, аның дөньядагы төп бурычы да шушы мәчетне салдыру иде.

Ләкин бу эш-гамәл алай бик гади генә булып чыкмады. Хәйләкәр Сабир-бобо мәчетнең хан Акмал кайтып җиткәнче үк исем алырга тиешлеген аңлый иде. Теге кайтса, мондагы һәр нәрсәнең—кешеләрнең дә, башкасының да үзенә Тәңре тарафыннан бирелгәненә инанганлыктан, мәчетне дә үз исеме белән атарга мөмкин иде бит.

Хәзер инде Акмал Ариповның кайту-кайтмавы аның гаепләме-түгелме

икәнлегенә, анардан зыян күрүчеләрнең һәм алты томлык эштә шаһитлык бирүчеләрнең сүзләренә карап түгел, ә сәяси яктан хәл ителәчәк иде. Ә бу очракта төрле мөмкинлекләр булып, хан Акмал ирекккә чыгарга да бик мөмкин иде.

Әгәр дә Горбачев дәүләтнең бөтенлеген саклап кала алмаса, Акмал Ариповка беренче мөмкинлек ачылачак иде. Моны бит Сабир-бобо юктан гына уйлап чыгармады: хан Акмалсыз да Аксай таулардагы бер кышлактай төшеп калганнардан булмас, моны алга таба күрә белмәгәннәр генә шулай уйлар иде.

Соңгы вакытларда Аксайга хан Акмалның күптәнге дусты, Үзәк Комитет хезмәткәре Тулкен Назарович еш килеп йөри башлады, ул инде, тәҗрибәле сәясәтче буларак, җилнең кай яктан искәнен чамалый, мөгаен, Аксай ханының җиңүче булып кайтып керүен сизенә иде.

Бәйсезлек, суверенитет... Әле кичә генә тормышка ашмас хыял булып тоелган бу төшенчәләр көннән-көн ачыклана барды. Халкын ана әзерме? Чынлыкта нәрсә булып чыгар бу? Бу хакта Сабир-бобо да еш уйлана, кайбер дәүләт хезмәткәрләреннән аермалы буларак, ул Советлар Союзы дигән илдәге халыкларның бер-берсенә берегеп үскәнлекләрен, дисталәрчә елларга сузылган ул бәйләнешләрне җинел генә өзеп булмаячагын аңлый иде. Ә Үзбәкстанның дәүләтчелеге—ул нинди рәвештә, нинди чикләрдә булыр икән? Яхшымы-яманмы, бары тик коммунистик хакимият, социализм чорында гына республика дәүләтчелек һәм үз чикләрен яулап алган иде бит. Алга таба, элекке шикелле, Хива, Бохара, Коканд ханлыкларына бүлгәләнеп бетмәсме Үзбәкстан? Аны бит Ленин үзе шулай бүлгәләп биргән иде.

Үз төбәгенең патшасы булырга теләүчеләрнең исәбе-хисабы юк, әмма монардан милләт отармы, дөньяда үз урынын табармы соң? Сабир-бобо һаман да ешрак шул хакта уйлана иде—ул бүгенге көндә Рәшидовтан да көчле, еракка караучы абруйлы башка кешене белми. Менә Рәшидов бу тарихи мөмкинлектән файдалана алыр, төшенә дә кермәгән хыялларын тормышка ашырып, үзбәк халкына дөнья җәмәгатьчелеге алдында үз урынын табып бирергә белер иде. Үз вакытында Үзбәкстан Урта Азиянең көзгесе булды, анын җитәкчесе дә илдә соңгы кеше түгел иде. Шуңа күрәдер, анын йогынтысы, абруй-дәрәҗәсе бик үсеп китмәсен өчен, ничәмә-ничә ел Политбюрога кертмичә тоттылар үзен. Менә хәзер Рәшидов кебек бер көчле кеше булсын иде әле!

Әмма Сабир-бобо белгән бик күп эшлекләләрдән берсе дә юлбашчылыкка тартмый, алай гынамы соң, үзгәртеп коруның беренче елларында ук, тикшерү оешмалары казына башлагач, республиканың күп кенә җитәкчеләре үз урыннарын саклап калырга теләделәр. Күбесе бу сынауны үтә алмады, хәзер исә кеше күзенә туры карарга да оялып йөриләр. Бу җәһәттән Акмал Ариповка тиннәр юк, аңа бик зур кыенлыклар килсә дә, ул сыгылмады-сынмады. Аны КГБның иң тәҗрибәле кешеләре тикшерде, Үзәк Комитет һәм Обкомнарның секретарьлары үз гөнаһларын аңа сыларга тырышты—әмма барып чыкмады. Ә үзен тикшерү җиде елга якын сузылган Акмал хан барлык гаепләрен кире кага килде, беркемне дә сатмады, үзенең күп миллионлы байлыгын дәүләт белән бүлешмәде.

Шуңа күрәдер, алып ашкан сәясәтче Тулкен Назарович Аксайга еш килеп йөри башлады, элек тә башкаларга бик өстән генә карый торган хан Акмал хәзер инде, утырып кайтканнан соң, үзен бер каһарман итеп сизәргә тиеш иде. Әмма Аллага ышан, үзенә таян, диләрме әле. Сабир-бобо да кул кушырып кына утырмады—Аксай хуҗасының котылып кайту сәгатенә әзерләнде. Анын үтенүе буенча адвокатларны да өч мәртәбә алыштырдылар, алар, башка эшләргә тартылмыйча, бары тик Акмал Арипов эше белән генә шөгыльләнергә, айга

бер мәртәбә Аксайга килеп, Сабир-бобога хисап бирергә тиеш булдылар.

Илнең таркалып барганын чамаласа да, прокуратура Ариповка судны тизләтергә карар кылды, аның эшен тиз генә аерып әзерли дә башлады. Бу исә гаепләнүчегә каты хөкем, хәтта иң югары хөкемгә кадәр илтеп җиткерергә мөмкин иде. Шуны чамалагач, Аксай адвокатлары, яңа хәйлә табып, судны ничек булса да өзү ягын карадылар. Ә моның өчен иң әшәке ызгыш-талаш чыгарырга, судның үзен дә, дәүләтне дә мыскыл итәргә кирәк иде.

Сабир-бобо мөмкинлектән файдаланмаса, Акмал Ариповның рухи укытучысы да булмас иде. Ул Сухроб Әкрәмхуҗаевны судта каты тәнкыйтьләп чыгу кирәклеген әйтте, адвокатлар бу фикергә ике куллап ябыштылар. Шулай итеп, суд дигәннәре билгесез вакытка кадәр туктатылды. Сабир-бобоның хәйләкәрлеге дә тормышка ашып килә: Сенаторны «Матросская тишина» төрмәсеннән азат итәргә өч-дүрт атна гына калган иде. Һәрхәлдә башкала адвокатлары шулай дип ышандырдылар.

Сабир-бобоның күз алдында абруе бик нык үсеп киткән Сухроб Әхмәтович аңа бик кирәкле кеше иде. Аның үзгәртеп кору ничек бетәчәген, республиканың бәйсезлеген алдан ук әйтеп бирүе белән ул бу ак чалмалы картка бик тә кирәк кеше иде шул. Карт алдында Сенатор хәзер хан Акмалдан да өстен тора, алар икәү генә көчле иде хәзер. Сабир-бобога Акмал Ариповның уй-ниятләре генә түгел, хыяллары да мәгълүм иде. Акмал Үзбәкстанның бәйсезлеге, суверенлыгы турында, чын-чынлап уйламый да иде. Ә республика, ничек кенә карасаң да, бәйсез дәүләт булып килә—сәяси вәзгыять шуңа бара иде. Ләкин бу үзгәрешләргә хан Акмал әзер түгел, тормыштан җиде елга төшеп калган иде бит—ә ул елларның һәр көне бер елга торырлык иде шул. Картка бүгенге сәяси хәлләрне генә белүче түгел, алга таба күрә белүче яшь сәясәтче егет кирәк иде. Сабир-бобо шундый кеше итеп Сухроб Әкрәмхуҗаевны күз алдында тотты. Сенатор хан Акмалга, үзгәртеп кору уңышлы барып чыкса, без үзебезгә үзебез хуҗа булачакбыз, хәзерге шикелле, Мәскәү Кремленең һәр кычкырганына калтырап тормаячакбыз, дип тукып килде. Бу хәлләрнең киләчәгенә илнең Югары Советында депутат, Мәскәүдә бик көчле дуслары булган хан Акмал да ышанып бетми иде. Шул дусларыннан тыш, шушы Аксайда да хакимиятне үз кулында тота алмыйсың бит.

Сабир-бобо испаннарның «Реал» Мадридындагы һөҗүмче Альбертоде Стефаноны исенә төшерде. Ул егет, картая башлап, тизлеген киметкәч, әле һаман да көчле уенчы икәнен исәпкә алып, тренерлары аны уенда сакларга тырыштылар. Таянучылар дип аталган ярым сакчылар аңа гел ярдәм итеп торды, ул йөгереп, барып җитә алмаган урыннарны каплый, аңа һәрвакыт тибәр өчен тупны бирә килделәр, ә «Реал» шул картаеп барган Альберто де Стефано белән дә ике ел рәттән Европа чемпионнары кубогын яулап алды.

Сухроб Әхмәтович та, Сабир-бобоның уйлавы буенча, хан Акмалга менә шундый ышанычлы кеше булырга тиеш иде.

## XIII

Бавария банклары директорларының киңәшмәсенә аны махсус чакырган иделәр, чөнки фикер алышуларның бер өлеше Россиядә яшәүче немецларга финанс ярдәме күрсәтү мәсьәләләренә багышланасы иде. Артур Александрович Шубарин иң беренче эше итеп факстагы сүзләрне укыды. Ташкенттан килгән хәбәр бик кыска иде: «Мюнхенның «Бавария» клубына теләктәшлек күрсәтүче күренмәде»,—һәм вәссәлам!

Тагын җиде сәгатьтән соң тәфсиллерәк килгән хәбәр аның күңелен күтәреп җибәрде, бу хәбәрне ул бер атна көтә иде инде: банк җиһазлары, сейфлар, компьютер системалары төялгән дүрт зур машина бүген Ташкентка килеп

житкән икән. Шоферлары гаиләләренә исән-сау икәнлекләрен әйтергә сораганнар, үзләрен Мәскәүтә кертмиләр икән. «Ни өчен икәнен очрашкач әйтербез, диләр. Өч механик машиналарын алып кайтырга һич риза түгелләр, үзләрен самолет белән генә кайтаруны сорыйлар, имеш. «Люфтганза» самолетына пәнҗешәмбе көнгә билетлар Франктфуртка кадәр алынган. Алар белән бергә сезнең шәхси машинагызны алып кайтучы ике кеше дә бар. «Рус-Азия» банкын рәтләп бетерү тәгәлләнеп килә, бүген җиһазларны урнаштыру бетәргә тиеш. Банк үз хуҗасын көтә». Джиоевның соңгы хәбәре шундый иде.

Артур Александрович «Магирус» машиналарының шоферлары аларны кире куып алып китәргә теләмәячәкләрен белә иде, чөнки безнең юллардагы хәвеф-хәтәрләрне немецлар куркыныч төшләрендә дә күрә алмый—ул авылламы-шәһәрдәме сине талау, дисенме, урмандамы-кырдамы туктатып үтерүләр, дисенме—Ташкентка ашыгыч йөк илтүче немецлар бу хакта алдан белгән булсалар, ун бәягә дә барырга риза булмас иделәр.

Шоферларга нинди авыр юл үтәргә туры киләсен белсә дә, Артур Александрович кирәкле йөкне башкача ни поезд, ни самолет белән җибәрә алмый иде. Теләсә нинди очракта да, беркем дә ана гарантия бирә алмый—йөк дигәнең бөтенләй эзсез югалырга да бик мөмкин, ә ул миллионнарча долларлык иде. Нәрсә ул долларлар! Ул бит эшне кин колач белән алып бармакчы була, ана банк ачу өчен әнә шул йөк дигәне кирәк, ә банкның һәр көне дистәләрчә, йөзләрчә мен доллар китерәчәк. Шуна күрә чик буендагы Чоп станциясе янында ук «Магирус» машиналары кәрванын һәр машинага икешәр кешедән сигез кеше каршы алды. Безнең юлларга чыккач, немецлар рульгә утырмадылар да диярлек.

Кыйммәтле йөк озатып йөрүче немецларның коралларын исәпләмәгәндә, безнекеләрнең биш автоматы бар иде. Конвойга кешеләрне бик сайлап кына алалар, алар, авыр машиналарны йөртү, «Калашников» автоматы белән оста эш итүдән тыш, төрле каршылыкларны алдан күрергә, низаг-тавышлануалардан качарга, еш очрап тора торган ГАИ хезмәткәрләре белән сөйләшә-килешә дә белергә тиешләр.

Чопка кәрван эңгер-меңгер төшкәндә килеп житте, әмма Закарпатьеда төн кунарга калмадылар. Ашап-эчеп алгач, машиналарына бензин салып, янадан кузгалдылар.

Олы юлга чыккан машиналар элдерделәр генә. «Магирус»лар яхшы маневрлы гына түгел, яхшы тизлекләре белән дә алдыралар. Сәгать өчләр тирәсендә, юридик фәннәр докторы Сенатор әйтүенчә, жинаять эшләү өчен иң кулай вакытта бер пөхтә-жыйнак шәһәрчек читендәге гадәти ГАИ постын үтеп бара иделәр. Постта торучы гаишник, машинаның артындагы номерын бик жентекләп караганнан соң, шундук дежуркага йөгерде. Кәрван башлыгы Карен бер ярты сәгатьтән үзләрен сагалап торучыларның килеп чыгачагын аңлап алды, рациядән иптәшләренә дә шул хакта хәбәр итте. Алар тарая барган юлдан карагайлар үскән инкүлеккә төшеп житкәч, конвой Кареннын кисәтүеннән башка да үзләрен шушында туктатачакларын чамалаган иде. Шулай булып чыкты да. «Магирус»ның көчле фаралары ерактан ук бүрәнә төялгән лесовоз машинасын яктыртты, машина юлга аркылы тора иде. Ә юлның ике ягындагы тәбәнәк чит ил машиналары—иномаркалар тирәсендә күн курткалы таза-таза егетләр шәйләнә.

—Мине алга үткәрегез!—дип боерык бирде Карен үзенекеләргә. Бу алымны куркыныч туган очракта эшләнергә тиеш дип алдан сөйләшеп куйган иделәр. Кареннын машинасы зур тизлектә алга ыргылды. Ул үзбәкчәләтеп яна боерык бирде:—Ин соңгы чиктә генә атарга! Беренче булып үзем атам,—диде.

Ул, тизлеген киметеп, ерактан ук әкрен генә лесовозга якынлаша башлады,

күзләре төнге кәрванны каршы алучыларны абайларга тырышты. «Магирус»лар туктый башлауга, һәр машинага ике-өч кеше ташланды, ә алдагы машинага берьюлы бишәү ябырылды. Алар, төнлә дә күрсәтә торган җайланмадан карап, кәрван хуҗасының шул машинада икәнлеген аңлап алган иде. «Магирус»лар, туктауга, дәррәү фара утларын сүндерделәр, һөҗүм итүчеләр бер мәлгә буталып калды, ләкин юл читендәге иномаркалар үз фараларын кабыздылар. Бандитлар, күрәсең, тәҗрибәләре буенча беләләр: тозакка капкан машиналардан алар белән сөйләшер өчен кешеләр төшәр дип көтә иделәр, әмма моторлары әкрен генә эшләп утырган «Магирус»лардан беркем дә төшәргә җыенмады. Шуннан соң ак «Мерседес» янында басып торган күн кепкалы кеше әмер бирде:

—Беренче машинадагы кәрван хуҗасын йолкып алыгыз әле! Ул яхшылык белән сөйләшергә теләми булса кирәк.

Ике егет «Магирус» тупсасына басып, ишекне йолкып ачты. Аларның йөзенә «Калашников» автоматының салкын көпшәсе килеп төртелде. Егетләрнең берсе куркуыннан асфальтка егылып төште, иптәше исә, яман сүгенеп кычкырды:

—Бурый, анарда автомат...

—Икенче-өченче машиналарны талагыз, ә бу юньсезне, кабинасыннан чыгармыйча, мушкада тотыгыз...

Һөҗүм итүчеләр, бер-берләрен дәртләндерә-дәртләндерә, шаулашып машиналарга ташланды, ләкин һәр ачылган ишектән аларны автомат көпшәсе каршы алды. Тагын аптырашта калдылар. Кайчандыр Шубаринга хан Акмал бүләк иткән, пуля тишә алмый торган жилетны кигән Карен җиргә сикереп төште дә автоматын Бурыйга төзәде, һәр сүзен өздереп аерым-аерым әйтте:

—Әгәр сез, хәзер үк юлны ачып, безне тыныч кына чыгарып җибәрмәсәгез, башта сезнең кәттә машиналарыгызны чәрдәкләп бетерәчәкбез. Безгә атасы булсагыз, үзегезгә үпкәләрсез—без пуляларны кызганып тормабыз...

Кинәт туган төнге тынлыкта Бурыйның артында кемдер обрез затворын тартып куйды. Карен, аның атуын кисәтеп, баш өсләреннән бер очередь бирде. Куркынып читкә ташланган Бурый лесовоз шоферына кычкырды:

—Кит тизрәк юлдан! Әллә нинди психлар болар...

Бу Кареннарга каршы оештырылган беренче һөҗүм иде. Ә тагын әле ничәмә-ничә мәртәбә аларны шулай, Карен әйткәндәй, «шап-шарапка», ягьни көтмәгәндә туктатып таламакчы булдылар. Кәрванны берәр ашханә яки бензин салу станциясе янында шәйләп алгач, җирле рэкетирлар бандасы, биш-алты машинага төялеп, арттан куа чыгалар. Ләкин Карен егетләренең аларны күрми калган бер генә очрагы да булмады. Андый чакларда колоннаның соңгы машинасы прицеп таккан «Магирус» була, анда автоматлы ике сакчы утыра. Куа килүчеләр, коралларын болгап, боларның туктавын таләп иткәндә генә ике автомат һөҗүмчеләр машинасы өстеннән очередь бирә, ул да ярдәм итмәсә, атып йә көпчәкләрен, йә радиаторларын тишкәләп бетерәләр.

Юлбасарлар, һәркайда—Чоптан алып Ташкентның көньяк капкасына кадәр хөкем сөрә, Украинада, Россиянең һәр өлкәсендә, Татарстанда, Башкортстанда, галәмәт зур Казакъстанның һәр төбәгендә кычкыртып талыйлар.

Кареннар колоннасын соңгы мәртәбә, кайтып җитәргә егерме биш чакрымнар калгач, Келестә туктаттылар. Инде үз җирләрендә Карен белән аның командасының җилкәсеннән авыр йөк төшкәндәй булган иде. Ә элекке СССР төбәкләрендә бу мал-мөлкәтнең дәүләтнеке яки чит илнеке булуы мөмкин дигән уй беркемнең дә башына кереп чыкмады. Конвойның күпне күргән егетләренә биредә хәзер бер закон-фәлән дә юктыр шикелле тоелды. Күп кенә ГАИ хезмәткәрләренең дә юлбасарлык белән шөгыльләнүче

бандитларга теләктәш булулары, алар белән бергәләп эш итүләре күзгә ташлана иде.

Чопта колоннаны күтәп торган Карен таможня хезмәткәрләреннән кырык әрҗә аракы сатып алды—бередә аракыны көнгә менәр шешә жыеп ала торалар. Конвойның үзендә коры закон—эчәргә ярамый, хәмер гаишникларны сыйлау өчен генә кирәк иде, ләкин ул ярты юлга гына житте. Алып кайтып килгән йөккә тутырылган кәгазьләр тәртиптә, таможняларның пичәт һәм штамплары ачык сугылган булуга да карамастан, аларны юлдагы постларда сәгатьләр буе тоткарлап торалар, бигрәк тә өлкә-республика чикләрендәгеләр котырына иде. Казакъстанда исә һәр районда туктата башладылар. Бередә, әлбәттә, корал куллана алмыйсың. Карен, тешләрен шыкырдатып, бер читкә китә, эшкә колонна башындагы машина шоферлары Сумбат белән Хашим керешә. Алар озак еллар шулай ерак юлларга йөргәннәр. Россиягә кавын-карбыздыр ташыганнар, юл хәлләрен яхшы беләләр, пост хужалары белән дә уртак телне тиз табалар икән.

Бары тик бер мәртәбә генә, Оренбургка кереп житәрәк, Сумбат белән Хашим егерме мең сум сораган гаишниклар белән килешә алмаганнарын күргәч, Карен түзеп тора алмады. Ул пистолетын тоткан килеш пост бүлмәсенә атылып килеп керде дә, Сумбат кулындагы ике көлтә егерме биш сумлыкларны йолкып алып идәнгә сибеп жибәрде:

—Йә сез шушы акчаларга ризалашасыз, йә мин сезне эт урынына атып үтерәчәкмен!—дип кычкырып жибәрде ул, үз-үзен белештермичә.

Кирпеч битле офицер куркынып шундук автоматик шлагбаумны ача торган кнопкага басты. Шулай итеп колонна янадан кузгалды...

Әмма иң зур талау аларны алда, Актүбәдән узгач, Иргиз далаларында көтә, моны юлаучылар яхшы белә иде. Иртән иртүк алар даладагы бер каберлек янында биш сәгатькә тукталып калырга мәжбүр булдылар—шунда Сумбатның жилкәсен яраладылар. Юлны хәрбиләрчә оста итеп бүлеп куйганнар: юл читләрендә ике яклап аягүрә басып йөрерлек тирәнлектә окоплар казылган, юлбасарларның ике автоматы да бар икән. Үзара ызгышып-янашып күпмедер тартышканнан соң, ниһаять, патрон тутырылган өч «мөгезе» белән бер автомат һәм илле мең сум акчага килешеп, юлны ачарга булдылар. Дөрес, Шәрекътәге мәкерлелекне яхшы белгән Карен юлбасарлар башлыгының үзләрен Челкарга кадәр озата баруын шарт итеп куйды. Немец шоферлары күпне күргән, Африкасында да, Европа, Америкада да юлбасарлар белән очрашып торган кыю егетләр иде, бередәге хәлләргә исләре китте. Дөнья телендәге итальян мафиясе дә, американныкы да, советларныкы белән чагыштырганда, балалар бакчасы гына, дип гел кабатлап йөрделәр. Төрле бәрелешләр, атышулар, куышулар, япан даладагы берәр бау белән генә тарттырып куелган шлагбаум янында озаклап сөйләшү-килешүләрдән соң, немецлар инде ашау начар, дип тә, элемтә юк, дип тә, безнең кунакханәләрдән дә зарланмый башлады.

Шуңа күрә дә күпчелек немец шоферлары машиналарын кире алып китүдән катгый рәвештә баш тарттылар. Аларның хәлен аңлаган Карен шикләнгәләп торган Костага боларга самолетка билетлар алып бирергә кушты:

—Хәзер алар, атып үтерәбез, дип куркытсаң да, машина белән кайтып китмәячәкләр,—дип тә өстәде.

«Магирус»ларның шоферлары, машиналарын ташлап калдырып, самолет белән генә кайтып киттеләр, дип хәбәр иткән иде Коста. Бу хәбәр Шубаринга үзе Германиядә йөргән ярты ел эчендә илдә жинаятьчелек бик нык үскәнлеккә дәлил иде. Меңнәрчә яңа кешеләр жинаятьчелеккә тартылып, алар өчен юлбасарлык яшәү рәвешенә әйләнгән икән.

Менә шуңа күрә дә Костаның: «иртәнге якта «Мюнхен» футбол командасын яратучы күренмәде»,—дигән яңа хәбәре Шубаринны борчуга салды. Аның әле ачылмаган банкы белән кызыксынган кешене эзләү озакка сузыла

башлады. Кем ул? Аның артында тагын кем тора икән? Илдәге эре җинаятьчеләр күптән инде яна коммерция һәм финанс системаларына кереп оялаган иделәр. Ә алар артында күп очракларда шул ук хакимлеккә ия кичәге кешеләр тора иде. Шубарин аларның байтагын яхшы белә, нигә соң алар ана турыдан-туры, арадашчы-ниләрсез генә мөрәҗәгать итмәделәр икән, ни өчен бу эшкә җинаятьчеләрне тартканнар? Нәрсәне аңлата бу? Әгәр дә җинаятьче төркем, үзен шул кадәр ышанычлы тоеп, хакимият башындагыларның булышлыгыннан башка гына республикадагы финанс эшләренең бер өлешен үз кулына алырга теләсә? Әллә соң соңгы елларда хакимияткә килүчеләр алар белән бәйләнешкә керергә теләмиләрме? Ә Шубарин, ни әйтсән дә, үзенә үзе баш булып күренсә дә, Рәшидов төркеменә буйсына, бу яңалар өчен ул, әлбәттә, чит-ят кеше, үзенең финанс мөмкинлекләре белән исә ачыктан-ачык куркыныч та тудыра. Ләкин Рәшидов төркемендәгеләрнен курку-өркүләре тиз юкка чыкты, күп кенә элекке җитәкчеләр төрмәләрдән кайтты һәм үч алырга хыяллана. Нәкъ шул чакта Шубаринның акчалары бик кирәк булырга мөмкин. Ул үзе андый максат һәм бурычларны куймыйкуюын, әмма вакыйгалар аның ихтыярыннан башка гына куерып килә иде. Халыкара мафия җибәргән адәм ана турыдан-туры әйтте: «Ташкентта бик зур үзгәрешләр, сезнең анда хәзер таяныр кешегез калмады. Без, бары тик без генә сезнең талантыгызны бәяли алабыз, сезгә банкир булырга булышырбыз да. Сезнен дусларыгыз һәм яклаучыларыгыз хакимият башында кала алмадылар, төбәктә хәзер яңа хуҗалар...»—диде.

Әлбәттә, бу вәкил Шубаринны бераз өркетергә дә теләгәндер, очрашуның көтелмәгәндә булуы да шуны сөйли, ләкин ул әле яшь, финанс эшләрендә генә түгел, сәясәттә дә тәҗрибәсез, шулай булгач, Үзбәкстандагы көчләрнен асылын каян белеп бетерсен, ди. Әйе, элекке клан-төркемнәр каты җиңелүгә дучар булды, алар өстенә СССР Прокуратурасының барлык җәза көчләре ябырылды. Читтән килгән меңнәрчә тикшерүчеләр республика тормышын һәрьяклап тикшерәләр. Мондый хәлгә кайсы гына республика тарса да, матуррак күренә алмас, хәле мөшкел булыр иде. Бу очракта тикшерү эшенә күптән инде хакимиятне үз кулларына алырга теләгән эчкерле адәмнәр ярдәм итте. Ләкин шунда да, әгәр Рәшидов исән булса, Үзбәкстан бу кадәр авыр югалтулар кичермәгән булыр иде. Республика үзенең юлбашчысын югалткач, барысы да коелды да төште. Әмма хәзер, Рәшидов тарафдарлары бер-бер артлы кайта башлагач, вәзгыять, әлбәттә, үзгәрәчәк.

Үз банкын оештырырга йөргәндә Шубарин көткән кыенлыклар турында чамалый иде, әмма үзенең кинәт кенә капма-каршы көчләргә кирәк булачагын башына да китермәде. Ул гомере буе хыялланган үз банкын һич тә сәясәткә кертергә теләми иде.

Парсегянның үлеме турында ишеткәч, Шубарин Сенаторның, бу мөмкинлектән файдаланып, төрмәдән чыгасына шикләнмәде. Дәүләт таркалганда аның көндәше, республика прокуроры Камаловның да йогынтысыкөче көннән-көн кими иде бит. Республиканың суверенитеты хан Акмалга да ирек китерер, аның эшен, мөгаен, Ташкентка бирерләр, ә инде үзләрендә Аксай ханын гаепләрлек хөкемдар табылмас.

Җинаятьчел дөнья хезмәттәшлек тәкъдим итә, яклау вәгъдә итә. Алар Шубарин банкында үзләренең наркобизнес һәм башка кара эшләрдән тупланган «пычрак» акчаларын файдалы гына итеп «юып» алырга хыяллана.

Илгә кайту көне якынлашып килә, Шубаринны Костаның әлегә кадәр стадионда үзе янына килгән кешене эзләп таба алмавы борчый. Әгәр аны тапсалар, аның артында торучы җитди кешеләрне дә ачыклап булыр иде. «Пычрак» акчалары белән эшләячәк банкны саклап-яклап, аның куркынычсызлыгын тәэмин итеп тормакчылар бит.

Шулай итеп, элекке «Рус-Азия банкы» бинасының биек мәрмәр баскычларыннан беренче клиент әле күтәрелмәгән, ә банк хуҗасын бөтен яктан да чорнап алганнар.

## XIV

Иртән Нортухта прокурор Камаловны көтелмәгән яңалык белән каршы алды:

—Мин кичә «Мазерати» машинасын күрдем,—диде. Ул монда ярты ел элек «Лидо» ресторанын янында булган сөйләшүне онытмаган, ахрысы.

—Кайда? Нинди төстә иде? Аның хуҗасы кем?—Хөршид Азизович кызыксынып сораштыра башлады.

—Кичен мин Тузельдәге туганнарыма барган идем. Анда хәрби округның аэродромы бар, шунда Мәскәүдән хәрби һава көчләренен самолеты килеп кунаклады. Ә аның эченнән сирень төсендәге бик матур перламутр автомобиль килеп чыкты. Аны шундук йөгерешеп килеп чолгап алдылар: «Мазерати», «Мазерати»,—дип сокланырга тотындылар. Чынлап та, шундый бик кыйммәтле машина бар икән. Аны Мюнхеннан Мәскәүгә хәтле үз йөреше белән куганнар, ә ары таба курыкканнар, һавадан алып кайтырга булганнар.

—Йә, ул матуркайның хуҗасы кем соң инде?—дип соравын кабатлады прокурор, юкса үзе әлеге каттә автомобильнең кемнеке икәнлеген чамалап алган иде инде.

—Машина хуҗасы күренмәде, аны алып кайтучы ике егет кенә, ниндидер банкир сатып алган, дип сөйләделәр.

«Димәк, шушы көннәрдә Артур Александрович Шубарин үзе дә кайтып житәчәк»,—дигән нәтиҗәгә килде Камалов.

Аның бу фаразлавы бик гади аңлатыла: газетларда, радио-телевидениедә, аерым сөйләшүләрдә—кыскасы, соңгы вакытта һәркайда бик зур коммерция банкы—«Шәрекъ» ачылачагы турында гына сүзләр йөри иде. Газетларда һәм телевизион яңалыкларда еш кына элекке «Рус-Азия банкы»ның матур зиннәтләп эшләнгән касса һәм эш йөртү залларының рәсемнәре күренгәләп торды. Банкның тыгыз итеп түшәмгә кадәр өелгән броня сейфлары тутырылган—атаклы немец фирмасы «Крупп»ныкы!—өч катлы җир асты складлары да бар икән, дип сөйләделәр. Банк революциядән соң беренче мәртәбә сакларга халыктан кыйммәтле кәгазьләр, ювелир әйберләре дә алачак икән.

Хәзер Ташкентта хосусый коммерция банклары ачылу белән беркемне дә шаккатыра алмыйсың: инде «Ипак юлы», «Семург» кебек банк хуҗалары бер еллыкларын үткәрделәр, ә Уфаның атаклы банкиры Рәфис Кадыйров, «Восток» банкының хуҗасы, Ташкентта гөрләтеп эшләп яткан филиалының ике еллыгын зурдан кубып үткәрергә әзерләнә иде. Әмма Шубаринның «Шәрекъ» банкы, шәһәрнең үзәгеннән, дәрәҗәле районнан тарихи бер бина алды, анда хәзер зиннәтләү-җиһазлау эшләре алып барыла. Менә ни өчен матбугатта даими рәвештә яңа банкның ачылуы унаеннан аны тәкъдир итү-презентация булачагы турында язылып киленде.

Бу презентациядә чит илләрдән дә күп кунаклар булачагын Камалов белә иде. Ул хәтта МИД аша килергә виза сораучыларның исемлеген дә алды, аны Интерпол исемлеге белән чагыштырып чыкты. Шубаринга Мюнхенда килеп йөргән кешеләрнең барысы да Ташкентка җыелачак икән, алар, мөгаен, Артур Александровичның күптәнге хыялын беләләр һәм шатлыгын уртаклашырга телиләр иде булса кирәк. Кунакларның өчесе-дүртесе Көнбатыштагы финанс даирәләрендә исемнәре танылган кешеләр иде. Аларны Ташкент иске дуслык җепләре белән генә үзенә тартмый, алар яңа дәүләттә яңа мөмкинлекләр ачылу белән дә кызыксыналардыр.

Әлбәттә, Камаловның әлеге презентациядә буласы, ул бай тантанада катнашкан кызыклы кешеләрне видеотасмага да төшереп аласы килә. Әмма ярамагач, ярамый инде. Ул «Лидо» ресторанына килүчеләрне дә төшермәячәк. Аның белүенчә, менә бер атна инде ресторанның икенче катын бизәүче дизайнерлар эшли—төрле чаралар һәм банкет шунда үтәчәк икән. Иллә дә кызык кино булыр иде, төшерсәң! Анда бит Шубаринның дуслары белән яклаучылары гына түгел, дошманнары, көндәшләре дә җыелачак. Әмма, бик төшерергә теләсәң дә, җинел эш булмас иде бу. Японец бик сак кеше, үз эшен саклаучы оста профессионалларын да ул үзгәртеп коруга кадәр күп алдан булдырган, әле шәхси сакчыларның исе дә юк заман, хәтта республика җитәкчеләренең дә күбесенең шәхси тән сакчылары булмаган. Хәер, Камалов хастаханәдә ятканда ук Шубаринга карата ачыктан-ачык, намус белән эш йөртергә сүз биргән иде—үз миллионерыбызга ул ничектер сокланыбрак карый иде. Камалов аңа ачкыч табачагына ышана, ул кан дошманнары Сенатор белән Миршабның Шубаринга дус булып йөрүләрен күз алдына да китерә алмый.

Интерпол исемлеген МИД исемлеге белән чагыштырып утырганда, Хөршид Азизович янә элекке өлкә секретаре Тилләхуҗаев белән законлы карак Талиб исемнәренә килеп төртелде. Алар презентациягә килерләрме икән? Мамык Наполеонының күренүе икеле—прокурор аның Пермь лагеренда утырамы-юкмы, зонадан Интерпол күрсәткән вакыттан алда чыгып китмәгәнме икәнлеге хакында белешмәләр алган иде инде. Төрмә начальнигының рәсми җавабы яңа сораулар гына тудырды, Камалов үзебезнекеләргә караганда, Интерполга күбрәк ышана иде. Германиядә тегенең төрмәдә утырганын каян белсеннәр, ди. Белешмәсенә фоторәсеме дә теркәлгән булгач, буталчыклык килеп чыгу мөмкинлеге юк. Димәк, ниндидер бик дәрәҗәле берәүгә төрмәдә утыруы элекке өлкә секретаренең зур банк ачарга йөрүче Шубарин белән чит илдә яшерен генә очрашуы бик тә файдалы. Өлкә секретаре презентациядә булмас, үзенең ирекә чыгып йөрүләрен башкаларга фаш итү аңаниемә кигәк, ди, күпләр аңа теш тота, тикшерү вакытында артыгын сөйләнгәненә гафу итә алмыйлар. Мамык Нополеонының тикшерүдә алдашмый-нитми барысын да сөйләп бирүе күпләргә зур мәшәкать китерде, күп акчалар сарыф иттерде, ә кемнәрдер ирекләреннән дә мәхрүм булдылар. Юк, ул, әлбәттә, «Лидо»да күренмәс.

Ә Талиб, мөгаен, булырдыр да—хәзер ни Мәскәүдә, ни Ташкентта, ни Санкт-Петербургта презентацияләр җинаятьчел дөнья вәкилләре, аның башлыклары, законлы каракладан тыш үтми—аларны хәзер эшлекле дөнья вәкилләре дип зурлап йөртәләр.

Корабтан туп-туры тантанага килеп кергән кеше, җитәрлек дәлилләр табылмаганлыктан, атаклы Мәскәү төрмәсе «Матросская тишина»дан чыгарылган Сенатор иде. Миршабның аны аэропортта куанып каршы алуы, самолет янында ук диярлек тәкә суюлары турында прокурорга шундук хәбәр дә иттеләр.

Презентация буласы көнне оешкан җинаятьчелек белән көрәшү бүлеге начальнигы, аның уйларын укыгандай итеп, прокурор Камаловка әйтте:

—Бүген банк ачылу тантанасына һәр җирдән, хәтта чит илләрдән дә кунаклар килә. Йөрәгем сизенә, ул банк күпләр өчен ызгыш-тарткалаш алмасы булыр. Зәнгәр читле тәлинкәдә әзер килеш бигрәк тәмле ризык ята бит. Өлкәдәге иң яхшы банк чит кавем кешесе кулында дип акырынучы кайнар башлар да табылыр, Шубаринның управляющий кәнәфие какшарга да мөмкин, хәзер мондый хәйләләр, ни кызганыч, һәркайда туры бәрә, төз тигезә. Турыдан-туры таяк тыгарга кыюлык итмәсәләр дә, ачыктан-ачык аңа ярдәм итүдән дә тыелырлар.

—Син аның банкына Сенатор яки Миршаб күз салыр дип уйлыйсыңмы?

—Ә нигә булмасын икән? Алардан һәм тагын без белмәгән башкалардан тыш, әле хан Акмал да бар бит. Ул тәкәбберғә банк кирәк тә кирәк булачак инде.

—Ә Шубарин нишләр? Ул алар белән дус шикелле,—диде Хөршид Азизович, нинди җавап ишетәсен чамалап кына.

—Хәзер заманнар башка бит. Дуслык дуслык белән, ә тәмәкеләр аерым. Мавр үз эшен эшләгәч китәргә тиеш. Ләкин Шубарин үз эшен алай җиңел генә бирә торган кеше түгел, миңа калса, банк—аның тормыш хыялы. Шуңа күрә дә мин «Шәрекъ» ачылган көннән башлап прокуратурага да эш артачагын сизенәм.

Хөршид Азизович кичке һәм төнге телевизион яңалыкларда презентациягә багышланган кадрларны җентекләп карады, хәтта видеотасмага язып та алды. Эченнән генә телевидение хезмәткәрләренең банк ачылуга артык күп вакыт багышлауларын искәртте, югыйсә шундый бай материал аның үзен, Камаловны шатландырды бит. Ул түземсезлек белән иртәнге газетлар килүен дә көтте. Газетчылар да, мөгаен, телевизиончылардан калышмас, газет битләрен муллан бирерләр, барчасын да «Лидо» ресторанында шартлаганчы сыйлаганнар, шампан да елга булып аккан икән. Алар өчен, башка барлык дәрәҗәле кунакларга әзерләгән шикелле, махсус табыннар әзерләнгән, аларга да истәлекле бүләкләр тапшырылган. Шубарин матбугат белән дус булуның иң кулай эш икәнен күптән аңлаган. Шуңа күрә дә ул, саранланмыйча, башкаланың зур газетларына үзенең «Шәрекъ» банкын ай буе мактап язып килгәннәре өчен шактый муллан түләде. Прокурор Камалов каһкаһә белән әйтте: «Хәзерге матбугат җилбәзәк хатын-кыз шикелле ул—әлек бары тик дәүләткә генә бирелеп, ана гына дан җырласа, хәзер исә, озак уйлап тормастан, эшмәкәрләр алдына менеп утырды. Кем күбрәк түли, шуңа дан җырлый»,—диде. Һәр ике як та никах-нисез генә шулай килешеп яши башлады, ә укучы һаман да шул ахмак булып кала бирде.

«Лидо»дагы тантана төшерелгән кадрларны әкрен генә карый-карый, прокурор Камалов кунакларны җентекләп күзәтте. Җыелган кунакларның барысына да, шул исәптән Камаловка да АКШтан килгән ниндидер Гвидо Лежава дигән кунак нык тәэсир итте—ул, күрәсең, Японецның күптәнге дусты, русча да шәп итеп сиптерә генә икән үзе. Ул шундук 375 мең долларлык чекка кул куячагын игълан итте—океан арты кунагы «Шәрекъ» банкы акцияләрен шул суммага сатып ала икән. Миллионлаган тамашачылар күз алдында Шубаринга шул чекны тапшыргач, ресторан көчле кул чабулардан шартлап китәрдәй булды. Прокурор, әгәр дә үзбәк банкирларының эше болай барса, республиканың барлык проблемалары да якын елларда хәл ителеп бетәчәк, дип уйлап куйды.

«Лидо»дагы тантаналы кабул итүдә элекке һәм хәзерге хакимиятнең прокурорга таныш бик күп кешеләре күзгә чалына иде, «үзгәртеп кору» дигәннәре тәмамланганнан соң, тамашачылар телевизор экраннарында элекке җитәкчеләрне яңадан күрде. Ак йортның иң өске катындагы шәхесләр, министрлар йөри, әмма иң күп күзгә ташланганы Миршаб булды, ул йә үзе генә, йә Сенатор белән үтеп китә. Төрмәдән соң ул тагын да төзрәк, тагын да җегәрлерәк күренә. Бик тә кәттә ефәк костюмлы Әкрәмхуҗаев аны белмәгән кешеләргә берәр артист булып күренгәндер—ул шул кадәр зәвыклы иде. Сенатор, банкетта телевидениенең булуыннан файдаланып, нәкъ прокурор уйлаганча, кыска гына интервью бирде. Аның чыгышы Камаловны бераз гаҗәпкә калдырды: Үзәк Комитетның административ органнар бүлегенең элекке мөдире йомшак-ягымлы гына итеп, сүзләрен бик озаклап сайлап кына сөйли, ә республиканың бүгенге прокуратурасы турындагы провокацион

сорауга да ул тыйнак кына җавап бирде. Үзенең беркемгә дә үпкәсе юклыгын, хәзер авыр заман, дөньялар алмашынган чак икәнлеген әйтте, шуннан файдаланып, дошманнар мина яла яктылар, диде. Әлбәттә, Камалов аның бу сүзләре тыңлап торучылар өчен генә икәнлеген аңлый, болай сөйләү Сенаторга яңадан үз урынына кайту мөмкинлеген калдыра: хата килеп чыккан икән, димәк, кешенең барлык хокукларын кайтарырга, биләгән вазифасын да кире бирергә кирәк. Ә аның биләгән урыны бик югары—ул республика прокурорының эшен карап-күзәтеп, тикшереп тора иде. Сухроб Әхмәтович еракка төби, күңеленнән ул, әлбәттә, прокурор Камаловның аны җинаятьче, кеше үтерүче итеп санаганын, үзен яңадан рәшәткә артына утырту өчен яңа дәлилләр җыячагын да сизенә иде .

Камалов иртәнге якта газетлардан үзе өчен кызыклы-кирәкле язмаларны әзерләп утырганда, телефон шылтырады.

Республиканың җинаятьчеләрне эзләү бүлеге начальнигы полковник Җураев икән. Исәнләшкәч, ул:

—Ни өчендер мин сезне кичә «Лидо»дагы дәрәҗәле кунаклар арасында күрмәдем,—дип шаяртып алды.

—Башкалар тормыш бәйрәмендә шампан эчеп, Карденда тегелгән костюмнардан гына көязләнеп йөргәндә, безгә шул чүп җыючылар язмышы гына кала. Алар боткаы пешерәләр, ә безгә «ашарга» туры килә,—дип, шаяртыбрак җавап бирде Камалов.

Әмма полковник кинәт кенә тавышын үзгәртте:

—Әйе, әле кемнәрдер шау-шулы банкеттан соң уянып та җитмәгәндер, ә бездә яңа борчулар туды да инде.

—Нинди?—дип кызыксынып талпынып куйды прокурор Камалов, ул ни өчендер, очрактан файдаланып, тантанада Сенатор берәр хикмәт эшләп ташлагандыр дип уйлаган иде.

—Телефоннан сөйләшә торган сүз түгел, хәзер килеп җитәрмен,—дип җавап бирде полковник, трубкада кыска звонок кына яңгырап калды.

Җураев телефон трубкасын бик вакытлы куйды, прокурор Камалов кабинетыннан бер катка түбәнрәк, нәкъ аның турысында Канзафар Рөстәмов утыра, аның телефоны яшерен генә прокурорныкы белән тоташтырылган иде. Полковникның: «Телефоннан сөйләшә торган сүз түгел, хәзер килеп җитәрмен»,—дигән сүзләрен ишеткәч, Рөстәмовның, тизрәк чыгып, Камаловка кем килгәнен күрәсе килгән иде дә, барып чыкмады. Аның үзен өскә—прокурор урынбасарларының берсенә чакыртып алдылар, ул шунда киңәшмәдә сәгать ярым чамасы утырырга мәҗбүр булды. Киңәшмәдән беренче булып атылып чыкса да, Камалов китеп барган иде шул инде. Аның ярдәмчесеннән: «Кем килгән иде?»—дип сораштыру файдасыз, әйтмәячәк—сак прокурор беренче көненнән үк бик каты тәртип урнаштырган иде. Кәефе киткән Канзафар нindидер бик мөһим мәгълүматны кулыннан ычкындырганын абайлады. Ә кызганыч! Кичә ул телевизордан Сенаторның интервью биргәнен күреп утырды. Димәк, ул инде иректә, Канзафардан иртәгә-берсекөнгә үк исәп-хисап сораячаклар. Сенатор Камаловны үзен төрмәгә утыртканы өчен дә, хезмәт урынын, дәрәҗәсен югалтканы өчен дә эзәрлекләячәк, һич гафу итмәячәк. Бу көрәштә, әлбәттә, тигезлек булмас...

Трубканы куйгач, Җураев үткән төндә булып үткән вакыйгалар турындагы белешмәне күздән йөгертеп чыкты да, үзен дулкынландырган вакыйганың анда теркәлмәгәнен күреп, республика прокуратурасына ашыкты. Үзенең Камаловка җиткерәсе хәбәрен ул гадәттән тыш вакыйга дип саный, кичекмәстән ниндидер чаралар күрергә кирәк. Җинаять Шубарин һәм аның банкына кагылышлы булып, әле республикага кичә генә билгеле булган иде. Бу җинаятьнең ни өчен эшләнгәнлеге аңлашылып җитми, акча аркасындадыр

дип уйласаң да, Жураев сизенә: бу юлы эш башкачарактыр. Прокурор Камалов Японецның тормышы белән күптәннән кызыксына, банкир белгән мәгълүматлар әлеге вакыйгага ачыклык кертергә мөмкин, ул исә «Шәрекъ» банкы ачылудан да сенсацияле һәм шау-шулы булырга мөмкин.

Трубканы элеп куйганнан соң, Камалов янә газетларны күз йөртеп чыкты,—бәлки, ул игътибарсыз калдырган берәр материал, дәлил бардыр,—әмма сискәндерерлек бер нәрсә дә юк иде. Газетларга мәкаләләрне ярты төннән соң гына куялар, теге бай-мул мәҗлесне бер генә журналист та ташлап китмәгән, игътибарга лаек булырлык нәрсәләрнең барысы да газет битләрендә иде инде. Полковник Жураевны нәрсә сагайтты икән соң? Бергә эшләү дәверендә аның әле бер дә, бүгенге шикелле итеп: «Телефоннан сөйләшердәй сүз түгел...»—дигәне юк иде.

Полковник бүлмәгә һәрвакыттагыча тавышсыз-тынсыз гына һәм бик житез килеп керде. Ишекне катырак япкач, читтәрәк торган радиоалгычны кабызып җибәрде, аркасы белән тәрәзәгә таба борылып, өстәл янына килеп басты, кыска гына исәнләшкәннән соң, шәрекъчә хәл-әхвәлләр дә сорашып тормады:

—Бүген төнлә «Лидо»да мәҗлес гөрләгән чагында Шубаринның кунагы, АКШ гражданы Гвидо Лежава югалган...—диде.

Жураевның килүе Сенаторга, һич югында Миршабка кагылышлы булыр дип көткән прокурор бераз югалып калды—бу яналык аның өчен бөтенләй көтелмәгән булып чыкты, әмма ул үзен бик тиз кулга алды һәм:

—Ялгышмыйсызмы?—дип сорады.—Минә минем өстәлемдә үткән төндәге вакыйгалар турында МВДның да, КГБның да белешмәләре ята, «Шәрекъ» банкы ачылу унаеннан үткәрелгән презентация һәр икесендә телгә алынса да, сез әйткән хәбәр хакында бер сүз дә юк.

—Мин МВД сводкасын күрдем инде,—диде полковник.

—Димәк, сезгә Шубарин үзе шылтыраттымы?—дип кызыксынып сорады прокурор. Болай булса, Японец белән бернинди хәйләләрсез очрашу мөмкинлеге туачак бит.

—Юк,—диде кунак, аны вакыйга белән тизрәк таныштырырга ашыкты:—Мин үз каналларым аша белдем. Төн уртасында көтелмәгән телефон шылтыравы йокымнан уятты. Җинаятьчеләр арасыннан үземнен бер шымчым шылтырата икән, ул бик ашыгыч күрешергә сорады. Мин аның тавышыннан ук нindидер гадәттән тыш хәл булганлыгын аңлап алдым. Ул шымчы хисчән кеше түгел, угрозыскны собес белән бутамый. Почмактагы автоматтан шылтырата икән, мин аска пижамадан гына төштем. Шымчым: «Кичә кич «Лидо» ресторанынннан телевизордан күрсәтелгән тапшыруны карадыгызмы?»—дип сорады. «Әйе»,—дигәч, грузинга бик тә охшаган американның миңа ошау-ошамавы белән кызыксынды. Мин: «Бер имзасы белән безнең икътисадка ярты миллион чамасы доллар салучы шундый кунаклар күбрәк булса иде»,—дидем. Шуннан ул минем башыма күсәк белән тондыргандай итеп әйтте: «Интервью биргәннән соң, бер сәгать үткәч, мәҗлес ин кызган чагында, ул кешене урлап алып киткәннәр»,—диде. Янадан йоклап булмаячагын аңлаган идем инде: «Бу сиңа ничек билгеле?»—дип сорадым. Ул кичен бер катранда кәрт уйнап утырган булган, теге вакыйгадан соң бер сәгатьтән шунда Шубарин кешеләре Коста белән Карен килеп кергән, ә урамда тагын егетләр төялгән ике «Тойота» калган. Алар бу ямьсез хәлне ачыклардай кешеләрне озак тинтерәткәннәр. Берәр төрле сизелерлек хәбәр өчен дә ике йөз мецне шундук чыгарып салырга вәгъдә иткәннәр. Төнге кунагымның сүзләреннән мин Шубарин егетләренен шәһәрне бик нык кармалап чыкканнарын аңладым. Мин һавадагы торна булган ике йөз мен сумга кызыкмаска, ул-бу ачыкланса, шундук Шубариннан алда миңа хәбәр

итәргә кинәш бирдем. Үзем өйгә кереп, телефонга ташландым. Әмма кайда гына—шәһәрнең кизү бүлегенә, республиканың МВДсына, сезнең прокуратураның кизүенә, КГБга шылтыратсам да, Шубарин кунагын урлап алып китүчеләр турында бер нәрсә дә белми иделәр. Әлбәттә, мин алай мангайга бәреп, турыдан-туры сораштырмадым да... Иртән миңа шундый хәбәр җиткерделәр: дустының кайда икәнлеген әйтүчегә Шубарин хәзер үк биш йөз мең сумны чыгарып салырга вәгъдә иткән.

—Нигә соң ул милициягә яки КГБга мөрәҗәгать итмәде икән? Чит ил гражданы югалган бит. Сез ничек уйлыйсыз? Нигә бу хәлне яшереп калдырырга тели? Нигә үзлегеннән генә эзләп тапмакчы була?—Камалов гадәтенчә диктофонын кабызып җибәрде.

—Презентациягә чит илләрдән дә күп кунаклар килгән, аларның кайберләре яңа банкка үз акчаларын салырга әзер торалар. Шул банкның акцияләрен халык күз алдында ярты миллион чамасы долларга сатып алган кешене урлап китү, әлбәттә, башкаларны да куркуга салачак—яхшы фал түгел бу. Әгәр дә Шубарин ярдәм сорап органнарга мөрәҗәгать итсә, ул шундук матбугатка фаш булачак, журналистларга чәйнәргә менә дигән азык. Мафиянең Шубарин банкына күз салуы да күренәчәк. Йә, кем инде шуннан соң ул банкка акчасын салсын да, кем аның белән хезмәттәшлек итсен? Банкның ышанычлы булуы, абруе кирәк бит!

—Нигезле сүзләр, бик нигезле,—диде уйга калган прокурор.—Ә ни өчен Шубаринга нәкъ менә презентация көнендә шундый этлек эшләгәннәр икән? Әллә очраклы гына шулай килеп чыкканмы?

—Моны төгәл генә белсәк, күп нәрсәләр ачыкланыр да иде. Башта ук Шубарин белән борчаклары пешмәгән көчләр бар. Кемгәдер аның киң колач белән эш башлап җибәрүе, Германиягә дә барып керүе ошамыйдыр,—дип әллә җавап бирде, әллә кычкырып уйланды гына Җураев. Аннары үзе прокурордан сорап куйды:—Ә бәлки, Шубаринның органнарга хәбәр итмәвенең берәр сәбәбе бардыр, ә? Уйлагыз әле, Хөршид Абидович, хастаханәдә ятканда миңа күрсәткән папкагызга караганда, сез аның турында миннән күбрәк беләсез бит...

—Әйе, Японец турында күп мәгълүмат җыйдым. Бик каршылыклы шәхес, аны әле ачасы бар. Мәрхүм прокурор Азлархановбелән булган дуслыгы гына да ни тора. Сездән яшермим, мин аның Мюнхеннан кайтуын көтеп алдым, очрашырга әзерләндем. Аның Сенатор, Миршаблар белән аралашып йөрүе ошамый миңа, араларына чөй кагарга телим. Саллы гына дәлил дә таптым шикелле. Әкрәмхуҗаевның докторлык диссертациясе белән танышканнан соң шуны әйтә алам: ул сезнең дустыгыз прокурор Азлархановның матбугатта чыккан һәм чыкмаган хезмәтләреннән тора. Теләсә нинди рәсми тикшерү бу фикерләремне раслаячак.

Үз дустының үлеме серен ничә еллар чишә алмый аптыраган угрозыск начальнигы сискәнеп куйды:

—Ә бәлки, прокурор Азлархановны үтерү дә Сенаторлар эшедер?

—Моны ачыклауны без башта банкирга калдырып торыйк. Мин хәзер ни Сенатор, ни Миршаб урынында булырга теләмәс идем,—дип сүзен тыныч кына дәвам итте Камалов.—Бүген исә без хезмәтебез буенча да, кеше буларак та Шубаринга ярдәм итәргә тиешбез. АКШ гражданинының югалуы дәүләти мәсьәләгә әверелергә мөмкин. Мин хәзер эзләүне каян башларга икәнен беләм кебек...—Камалов шкафыннан полковникка таныш альбомны тартып чыгарды. Бу альбом аңа элекке прокурордан калган иде, анда республикадагы аерата куркыныч җинаятьчеләрнең фоторәсемнәре тупланган. Талиб Солтанов рәсеме һәм аның турында мәгълүматлар теркәлгән битне табып ачкач, прокурор альбомны Җураевка сузды:

—Бу егет сезгә таныш түгелме соң?

Полковник, карап торырга да өлгермәстән, шаяртып әйтте:

—Мондагылар миңа үз туганнарым шикелле таныш,—диде.—Бу зәңгәр тышлы альбомны сезнең элгәрегезгә мин бүләк иткән идем. Сизгерлеген югалтмасын, безнең якларда да караклар, төрле җинаятьчеләр Россиядәгедән ким түгел икәнен белеп торсын өчен,—дип тә өстәде ул.

Талибның фоторәсемен күргәч, полковник дертләп китте. Аның белән очрашуын исенә төшерде. Шунда ул Камаловны каптырырга йөрүчеләрнең башында Югары суд кешесе Миршаб торганлыгын белгән иде. Прокурор Камаловның сүзләре аны уйларыннан айнытып җибәрде:

—Бу кеше Мюнхенда Шубарин белән очрашкан. Шул вакыйга сездә, бәлки, берәр фикер уятыр?—диде Камалов.

—Талиб? Мюнхендамы? Аңа Шубариннан нәрсә кирәк булды икән?—дип гаҗәпләнде полковник.—Бу мәгълүматларны сез каян алдыгыз? Шуны әйтә алам: Талиб Солтанов Германиягә чыгып кайтырга виза юлламаган.

—Мөһим яңалык, мин ул кадәресен белешергә уйламаган идем. Әйе, Талиб Мюнхенда булган. Интерполдан алынган ышанычлы мәгълүмат бу. Бәлки, аңа визаны Мәскәүдә эшләп биргәннәрдер.—Хәзер хосусый фирмалар теләсә кемне теләсә кая җибәрергә әзерләр, тик акчанны гына түлә. Җинаятьчеләр өчен оҗмах инде. Сез хаклыдыр, немец коллегаларның күзәтүеннән аңлашылганча, аның Шубарин белән электән таныш булуы икеле. Алай да, очрашу яхшы оештырылган.

—Шубарин бүгенгә кадәр үзенә кем килеп киткәнлеген белми булып чыга. Без дә Талибка аның нигә кирәк булганлыгын белмибез. Җитмәсә, чит илдә әле. Нигә ашкындылар икән? Шубаринның тиздән Ташкентка кайтачагы билгеле иде бит...—дип фикер йөртте полковник.

—Бер нәрсә ачык: Шубаринга якын булган, анардан зур суммага акцияләр сатып алган кешене урлап китү бары тик банк белән, әле бер көн дә эшләргә өлгермәгән банк белән генә бәйләнгән. Бу нәрсә хакында сөйли?

—Билгеле инде, аңа этлек эшләү, финанс ягыннан да сизелерлек зыян ясау өчен мәтәштергәннәр. Бәлки, кемдер аның белән өлешкә керергә теләгәндер. Мистер Лежава кебек бай кешене болай гына урласалар, Шубаринга шылтыратып, хак сораган булыр иделәр. Ул, тавыш кубарырга теләмичә, әлбәттә, акчасын кызганмас, бирер иде. Кунаклары киткәч, яхшылап тикшерер иде аннары.

—Сез хаклы,—диде прокурор. Өстәлдә яткан газетларга үрелеп өстәде:—Әйдәгез, кичә Шубарин банк җитәкчеләре, аны оештыручылар дип тәкъдим иткән кешеләрне тагын бер кат барлап чыгыйк әле. Алар арасында Японецка ачу тоткан кеше юкмы икән?

Ул исемлекне укып та бетермәде, Жураев кычкырып җибәрде:

—Анда шәһәр адвокатлар коллегиясе рәисе Горский, яки Фәйзуллаев фамилиясе булырга тиеш. Аның да өлкә прокуратурасындагы бер әрсез бәндә иде, хәзер нindидер шикле бер хосусый фирманың юрист-консульты гына.

—Биредә андый фамилияләр юк,—диде Камалов.—Шикле исемнәр дә күренми.

Жураев бераз уйланып утырды да, кинәт көлеп җибәрде, сикереп торып биергә тотынды. Прокурор, берни аңламыйча, елмаеп кына тора иде. Полковник аңа күз кысып, бию көенә җырлагандай итеп әйтте:

—Ул кешеләр чакырылу булмаганга күрә дә Лежаваны урлаганнар. Талиб кешеләрен дәрәҗәле банкка якын җибәрмәүләренә үч итеп. Мин американны кемнәр һәм ни өчен урлап киткәннәрен беләм хәзер, кайда яшереп тотканлыкларын да беләм хәтта...

—Анлатыбрак сөйләгез әле,—дип дулкынлана башлады прокурор. Ул Жураевның нindидер бик кирәкле эзгә төшкәнен аңлады.

Жураев прокурорга хастаханәдә һөҗүм ясалганнын икенче көнендә, Камаловны кемнәр аулаганын белергә теләп, үзенең Талиб йортына барып чыкканын, анда кемне очратканын һәм ул очрашуның ничек беткәнен тәфсилләп сөйләп бирде. Ул анда, Талиб белән Горский нардлы уйнап утырган икенче катка әкрен генә күтәрелеп килгәндә, аларның сөйләшүеннән өзек-төтек кенә сүзләр ишетеп калган иде. Хәзер ул йорт хуҗасының кунагына әйткән кайбер сүзләрен генә исенә төшерде, ә кунакның җавабы һаман колагында тора: «Марк Семенович, кабатлап әйтәм, банкка безнең вәкил булып сез барырга тиеш, безнекеләр шулай хәл итте. Анда акыллы, житез кеше кирәк. Яки Фәйзуллаев барырга тиеш... ул бирeдәге кеше...»—дигән иде кунак.

—Алай икән...—диде прокурор, икесе дә сәгатьләренә күз төшереп алдылар.

Ашыгырга кирәк иде. Гвидо Лежаваның эзенә Шубарин үзе төшәргә мөмкин, ул вакытта Японецка ярдәм күрсәтү кирәк тә булмаячак. Ә прокурорның Сенатор белән Миршабка каршы көрәшендә Японецның булышлыгы начар булмас иде. Банкирның үз кешеләре дә, тәртәне артык бөгеп, сындырып куюлары бар. Ни әйтсән дә, Лежава Америка гражданы...

—Без аны азат итеп, Шубаринга илтеп тапшырырбыз. Яки Талиб белән, аның артында торган кешеләр белән аңлашуны үзенә калдырыйкмы икән?—Жураев тоткарлау төркемен чакырту өчен сөйләшү аппаратына тотынган иде инде.

—Шулай да, дустын азат итүне Шубаринның үзенә калдырыйк әле. Ә безнең хезмәткә килгәндә... Ул без ничек булышканны белгәч, тиешенчә бәяләр үзе. Әгәр дә инде Сенатор белән Миршаб та, безнең Шубаринга ярдәм итүебезне ничектер абайлап алсалар, араларында салкынлык, берберләренә ышанмау туар. Мин дә Японец белән сөйләшергә җыенып йөрим, бу хәлләрдән соң ул очрашудан баш тартмастыр. Бу эшне Артур Александровичка калдыруның тагын бер ягы бар. Әгәр без Талибны алсак, ул Шубаринны урлап китү банк эше белән бәйләнгәнлеген һич әйтмәячәк, аның кешеләре, үзенә әйтми-нитми генә, урлап киткәннәр, зур акча каерасы килгән, диячәк. Башымны кисәргә бирәм, аның инде бар гаепне үз өстенә алырга тәгаенләгән кешесе дә бардыр. Сез бит Горскийны менә дигән юрист, дидегез. Шулай булгач, Талибның ни өчен банкка үз кешеләрен төртергә тырышуын без беркайчан да белә алмаячакбыз. Ә инде Шубарин дустын үзе коткарса, аңа барыбер кайчан да булса, ни өчен, әйтик, Сенаторны түгел, ә Гвидо Лежаваны урлап китүләрен аңлатып бирергә туры килер. Шулай да, без банкирны күзәтеп-саклап торырга тиешбез. Чакыр үз егетләреңне, мин дә сезнең белән барам,—дип сүзен тәмам итте прокурор.

Прокуратура янына яна көпчәкле, көчле моторлы, әмма тыштан караганда башка машиналардан һич тә аерылып тормый торган ике «Волга» килеп туктады. Прокурор телефоннан Шубарин номерын җыйды, ул бүген өендәме, машинасындамы—барыбер телефонны алырга тиеш иде. Телефон шылтыравы гадәти түгел иде, күрәсең, «Мазератти» эченнән булды. Кичә Камалов телевизордан ишеткән тигез-тыныч тавыш ишетелде:

—Тыңлыйм сезне.

—Хәерле иртә, Артур Александрович. Сезне республика прокуроры Камалов борчый...—Ул аз гына тынып торды, банкирның тавышында югалып калу, гаҗәпләнү сизелмәсме икән, дип көтте. Әмма шул ук тыныч тавыш:

—Исәнмесез, Хөршид Азизович. Болай иртә шылтыратуыгыз ни-нәрсә өчен икән?—диде.

—Яңа банкыгыз ачылу белән котлыйм сезне. Кичә телевизордан күрдем.

Ташкентта шул кадәр күп чит ил кунаклары бер генә презентациядә дә булмагандыр әле, мөгаен.

—Рәхмәт. Банк нигездә чит илдән килгән байлар өчен бит. Бу турыда матбугатта да хәбәр ителде. Шуна күрә алар күп булды. Асылда барысы да үземнең иске дусларым, күптән түгел генә биредән киткән кешеләр. Бүген аларга ватаннарына ярдәм итү мөмкинлеге ачылды, ешрак кайтып та йөрерләр. Ышаныгыз, ностальгия, ягъни жирсү—әдипләр, шагыйрьләр уйдырмасы гына түгел. Анын белән ешрак бай, рәхәт яшәүчеләр авырый.

—Мистер Лежава да шулай авырыймы?

—Башкалардан көчлерәк тә авырыйдыр әле. Шуна күрә дә ул шундый зур суммага чек язды, күпләр хәтта аптырап та калды шикелле,—бу юлы, тавышы тыныч булса да, Шубаринның гажәпләнгәне дә сизелә иде.

—Алай булса, Артур Александрович, мин үземне сезгә һәм кунагыгызга ярдәм итәргә бурычлы дип саныйм. Аны табып алу өчен адрес бирәм, языл алыгыз: эшчеләр шәһәрчеге, Радиальная урамы, 12. Биек коймалы, ике катлы йорт булыр. Анда кайчандыр танылган үзбәк рәссамы яшәгән иде. Бутамассыздыр бит?

—Рәхмәт. Бу явыз шаяртуга сез үзегез гаепле түгелдер дип ышанам, —Шубаринның тавышы кырыс янгырады.

—Юк, Артур Александрович, мин Мюнхенга сезнең янга килеп киткән кешенең адресын гына бирдем.

—Кем ул?—дип кистереп сорады банкир.

—Германиядә яныгызга килеп киткән кешене белә алмагансыздыр дип уйлаган идем. Тәгаен шулай икән. Ул бит сез Ташкентка кайткач та шылтыраткан, без белеп торабыз. Ул банкыгыз идарәсенә үз кешеләрен кертүне таләп иткән, ә сез кире каккансыз. Америкaн кунагыгызны урлап китүнең сәбәбе дә шунда. Ул карак—Талиб Солтанов. Кызганыч, без анын артында кем торганын белмибез. Мөгаен, кемнән булса да шундый фәрман алгандыр ул.

—Янә бер кат рәхмәт. Ашыгыйм әле. Гвидо—кайнар, түземсез кеше, берәр мөгез чыгарып куймагае анда. Сонгы соравым: сез «без» дә «без»—дип сөйләштегез, димәк, мин тагын кемнәргәдер бурычлымын. Сер булмаса, әйтегез—кем ул «без»?

—Полковник Жураев, республиканын угрозыск начальнигы.

—Житди кеше. Мин аны яхшы беләм, кайчандыр уртак дустыбыз да бар иде. Рәхмәт әйтегез ана...

Сөйләшү кырт өзелде. Күрәсең, Японец тиз генә үз егетләрен жыеп алырга теләгәндер.

—Без анда Шубариннан алда барып житәргә һәм сиздерми генә унайлы урыннарга урнашырга тиешбез. Кирәк булса, вакыйгага катнашып, Америка гражданын азат та итәрбез,—диде прокурор.

Полковник белән прокурор тиз-тиз генә машиналары янына ашыктылар, анда аларны тоткарлау, тотып алу төркеме егетләре көтеп тора иде инде.

Гадәти киемле угрозыск егетләре, яшеллеккә күмелсә дә, күзгә ташланып торган ике катлы ялгыз йорт тирәли сиздермичә генә урнашып, полковникнын сонгы күрсәтмәләрен алырга да өлгермәде, Радиальная урамынын уникенче йорты янына карангы-зәнгәр төстәге «Тойота» автофургоны килеп туктады. Мондый машиналар Ташкентта хәзер шактый күп, бигрәк тә шәһәрнен мул тормышлы кешеләре яши торган бу өлешендә алар артык күзгә дә ташланмый иде. Уралып-бөтерелеп беткән, әллә ничә тыкрыклы-тупиклы Радиальная урамы аны камап алучылар өчен дә, Японец кешеләре өчен дә бик унай иде. Утарга керә торган юл урамнан юньләп күренми дә, чөнки капка бик эчтә, үтеп-сүтеп йөри торган юлдан пөхтәләп кыркылган, өстенә куе булып йөзем

һәм чәй розасы үрмәләре сыланган яшеллек каплап тора. Элекке хуҗасы—рәссам яшәгәндә бу йорттан кунаклар өзелми, мондый биек капка-коймалар да юк иде.

Радиальнаяга якындагы тыкрыктан тын гына килеп чыккан «Тойота» зәңгәр капка буендагы йөзем куаклары арасына кереп посты. Машинаның ишекләре ачылгач, аннан сигез егет килеп чыкты, койманың теге ягына сикереп тә төште. Шундук шыгырдап авыр тимер ишек ачылды. Машинадан соңгы кеше булып Шубарин чыкты. Өстендә шул ук кичәге кичке костюмы иде, әмма күзәтүчән кеше аның бугазы төбендә бераз ачылып торган башка жилеттан икәнен шәйләр, ефәк галстугын булавка белән биек якалы күлмәгенә эләктереп куйганын күрер, әйтерсең, күлмәк нәкъ шушы жилет белән кияр өчен тегелгән, диярсең. Шубарин текә баскычтан икенче катка күтәрелгәндә, андагы өч ир-ат, кулларын баш артына кушырып, бүлмә почмагында стенага карап басып торалар иде инде. Таза-таза егетләр аларның һәр хәрәкәтен күзәтәләр иде.

Залга килеп кергәч, Шубарин егетләрнең башта берсен, аннары икенчесен борып йөзләренә карады, әмма тыныч-салкын карашы боларның үзен кызыксындырмаганын аңлата иде. Шунда банкирның түземлеге сынды шикелле, ул гадәттәгедән ашыгыбрак өченче кеше янына атлады, спорт костюмы кигән ул кеше шушы йорт хуҗасы иде. Шубарин аны кискен генә итеп үзенә таба борды, күз карашлары йөгереп торган, бик тә пөхтә мыеклы бу кешене ул шундук танып алды. Тегесе ирексездән чәчләрен төзәтеп куйганда, Японец аның бармагындагы бриллиант йөзекне дә, беләзегендәге чыгарып бетерелмәгән татуировкасын да күреп алды—бу кеше, һич шиксез, аның янына Мюнхенга килеп киткән вәкил иде. Алар бер мизгелгә генә бер-берсенә карашып алдылар. Шубарин янында торган Костаның кулындагы пистолетны тартып алды да, Талибның чигәсенә терәде:

—Өчкә хәтле генә саныйм. Кайда минем кунагым?—диде ул әкрен генә .

Мондый хәлләргә бер генә мәртәбә калмаган Талиб үзенең аңлатып булмаслык ниндидер җинаятьчел эчке тойгысы белән сизенде: ана атмаячаклар, әмма, киреләнеп торуның файдасыз булачагын аңлап, әйтергә мәҗбүр булды:

—Ул мәҗлес булган йортның почмак бүлмәсендә генә. Сакчылар белән нардлы уйнап утыра. Аның безгә үпкәсе юктыр дип уйлыйм, без аны зур кунак буларак кабул иттек...—диде.

Аларның сөйләшүен тәрәзә аша ишетеп торучы астагы кешеләр үзбәк биналарына хас бер катлы йортка атылдылар, бераздан кемдер кычкырды:

—Шеф, тәртип—биш! Ул исән-сау, хәтта кәефле дә...

Шубарин, Талибны онытып, тәрәзәгә ташланды, Лежаваны күргәч, сәламләп йодрыгын сүзсез генә күтәрде. Әле кайчан гына адвокат Горскийны тәгәрәтеп төшергән текә баскычка таба атлагач, ул бер мизгелгә туктап, Талибка борылып әйтте:

—Бүген миндә бәйрәм, кунаклар, мәшәкатьләнеп торыр вакытым юк. Синең белән сөйләшү алда булыр әле...

Жураев белән Камалов прокурор машинасында иделәр. Яшеренеп утырган җирләреннән алар бинокль аша Радиальная урамына зәңгәр «Тойота» килеп чыкканын, аның күкшел капка артына кереп югалганын гына күреп калдылар. Нәкъ җиде минуттан «Тойота» шулай ук тавышсыз-тынсыз, тиз генә йорт яныннан чыгып та ычкынды. Бер тавыш-тын, бер кычкырып сөйләшү, бер йөгерешеп йөрүчеләр дә юк иде...

—Оста майтаралар!—диде ирексездән сокланган полковник.

—Атыш-нисез генә узуы әйбәт булды әле. Юкса газетчиклар хәзер күтәреп алыр иде. Анысы Шубаринга да, безгә дә кирәкми. Талибка кирәкми дә кирәкми инде. Хәзер аның дөнья җимердәй булып йөргәнен күз алдыма китерәм...—Камалов, Нортухтаның җилкәсенә сугып алды да:—Бездән башка

да булдырдылар, әйдә прокуратурага жиллерт, эш муеннан. Сенатор кайтты,— диде.

Алар эшчеләр шәһәрчегенең буталчык урамнарыннан чыгып та житмәделәр, «Тойота»дан «Мазерати»га күчеп утыручы Шубарин белән мистер Лежаваны күреп алдылар. Кереп яшеренер урын юк иде, шуна күрә «Волга», тизлеген арттырып, шәһәр үзәгенә таба элдертте. Әмма урыныннан зур тизлек белән кузгалып киткән «Мазерати» аны жинел генә куып житте дә туктарга сигнал бирде. Күрмәмешкә-ишетмәмешкә салышу юләрлек булыр иде. Камалов шоферга юл читенә туктарга кушты да, тротуарга чыгып басты. «Мазерати» бераз арткарак калып тукталды, аннан шундук Шубарин чыгып прокурорга таба атлады. Камаловның Артур Александровичны беренче күрүе иде: бик көчле тәэсир калдырды—төз буйлы гәүдә, ачык йөз, тирән батып утырган ачык зәңгәр күзләре аның тыныч-тотрыклы табигатьле, ихтыярлы кеше икәнлеген сөйли иделәр. Ул шәрекъчә кыланып, баш иеп-нитеп тормыйча гына килде дә, әдәпле генә итеп күрешергә кулын сузды:

—Үзем өчен әһәмиятле бу көндә сезнең белән танышуыма бик шатмын, Хөршид Азизович,—диде ул.—Полковник белән мине ышыклап-яклап калуыгыз өчен дә рәхмәтлемен. Кунагымны үзем коткарырга мөмкинлек биргәнегезгә дә рәхмәт. Мин хәзергә Жураев белән сезнең мина ни өчен булышуыгыз турында уйланып тормыйм, мина анысы мөһим дә түгел, иң мөһиме—мина, минем эшемә ышанган дустымның иректә булуы. Бүген мина бәйрәм. Хәтта ул кабәхәт жанның мине Мюнхенда эзләп табуын каян белдегез дип тә кызыксынмыйм. Шуны гына беләм: сез булмасагыз, Гвидо турындагы мәгълүматлар өчен минем ярты миллион сум вәгъдә иткәнлегемне полковник Жураев та иртүк ишеткәндер. Әмма ярдәмне сез—прокурор белән угрозыск начальнигыннан—минем өчен көтелмәгән хәл булды, биредә акча түләп кенә котыла алмас идем. Ләкин мин тормышта һәр нәрсәгә түләргә күнеккәнмен. Теләсәгез әйтим, бу минем тормыш девизым. Үзегезгә кыенлык килгән көннәрдә икегез дә минем ярдәмемә таяна аласыз...

—Рәхмәт, Артур Александрович, әлбәттә, безнең ярдәмебез сезгә бераз сәер тоелгандыр, ләкин бәлага тарганнарга ярдәм итү—безнең бурычыбыз. Дустыгызны коткарырга булышканыбыз өчен без дә сездән ким шатланмыйбыз. Ул сезнең хәзер кем белән сөйләшкәнегезне абайлагандыр инде, ана безнең иң яхшы теләкләребезне житкерегез...

—Әйтермен, прокурор, әлбәттә, әйтермен, ул тиз төшенеп ала торган кеше...—Шубарин үзенең зиннәтле машинасы янына ашыкты. Аларның «Мазерати»е «Волга»ны узып китте дә еракка кереп югалды.

## XV

Сенатор, «Матросская тишина» төрмәсеннән «Шәрекъ» банкы ачылуны тәкъдир итү алдыннан кайтып төште, үзенең журналистлар һәм теле репортерлар күзенә шундук эләгүенә ул бик шат иде. Юкка-барга ышанучан һәм үзенең бәхетле йолдызына инанган кеше буларак, ул моны уңышлы фал, язмышның аерым бер билгесе дип кабул итте. Камалов кулыннан ычкын да, «иң югары хөкемнән» котылып кал да, ничек инде үзеңне бәхетле санамаска мөмкин?! Шулай да... Уңыш—уңыш белән, бәхет—бәхет белән, әмма югарыга үрләүне янабаштан—нульдән үк башларга кирәк иде.

Сенаторны коммунистик идеяләр дә, «демократик» үзгәртеп корулар да, хәтта Үзбәкстан өчен исламча яна юл ачу да дулкынландырмый. Нинди генә хакимият, нинди генә идеология, нинди генә режим булса да,—яшелме, буй-буйлымы, хәтта борчак-чуар байракмы,—барыбер: аның һәрвакыт хакимият түрәләре арасында, дөресрәге, алардан да өстә—иң югарыда буласы килә иде.

Үзләрендә һәм башка республикаларда бара торган вакыйгаларны күзәтеп, ул бер нәрсәне ачык абайлады: һәркайда бер үк уен, хакимияткә омтылучылар өчен теләсә нинди байрак, теләсә кайсы идея дә ярый, бары тик аларны тулы «тагарак» янында гына калдырсыннар. Ә бу хакимиятне кулга төшерү өчен озакка сузылырдай кырыс көрәш булачагын вәгъдә итә. Аксай ханы Акмал янына беренче баруында ук ул: «Безнең якларда коммунистик идеология көрәшсез-нисез, авыртынуларсыз гына алмашыначак. Кесәләрендә кызыл билет йөрткән бер партия кешеләре хәзер инде хакимияткә килгән икенче партиягә—яшел яки сары билетларына дәррәү күчәчәкләр. Чөнки шәрекъта КПСС әгъзасымы син, ислам яки демократик фирка әгъзасымы—барыбер, ул җылы урыннарга, түрәлеккә үрләү юлы булыр. Ә фиркаләрнең программасы, уставы, максатлары кемгә дә кирәкми, моны һәрберсе яхшы аңлый»,—дигән иде. Хаклы булып чыкты бит тәки!

Бүген сәяси көчләр нинди генә булмасын, Сухроб Әхмәтович аңлый—ничек кенә булса да элекке вазифаны кайтарып алырга тырышу кирәк. Партбилетларын башка төскә алыштырсалар да, шул ук кешеләр, хакимият нигезләре үзгәрешсез калды. Әмма ул югарыда хөкем сөргән тәртипләрне дә яхшы белә—беркем дә, бигрәк тә хокук органнарында эшләүчеләр, үз урыннарыннан китмәячәкләр. Ә бу органнар реаль көч, анда кораллы кешеләр эшли. Югарыга үрләргә теләгән сәясәтче өчен бу урын һөҗүмгә күчәргә бик тә җайлы. Шуңа күрә Сухроб Әхмәтович, әле тирәягын күзәтеп, ниндидер бер карарга килмәс борын, телевидениегә бик сак кына интервью бирде: янәсе, хата килеп чыккан, аңа яла якканнар, әмма ул беркемне дә гаепләми, мондый кискен үзгәрешләр вакытында андый хаталар китә инде ул. Гадәттә җәмгыятьтәге үзгәрешләр өчен көрәшнең алгы сызыгындагылар, республиканың бәйсезлеге өчен көрәшүчеләр шундый бәлагә таралар, бәйсезлекнең бәясе һәрвакыт һәм һәркайда шундый була. Кыскасы, ул үз дәрәҗәсен белеп, әдәп вә тыйнаклык белән сөйләде. Мәскәүнең изүеҗәберләве аркасында республиканың хокук саклау органнары да юньләп эшли алмый, дип зарлану урынына болай сөйләү бик матур килеп чыккан иде. Корбаннарга һәрвакыт кызганып кына да карамыйлар, аларны аңлыйлар, алдан күрә белүче Сенатор шунысын күз алдында тоткан да иде.

Тәкъдир итү—презентация кичендә Сухроб Әхмәтович шунысына игътибар итте: җәмәгатьчелек тормышында үз-үзләрен бөтенләй башкача, бәйсез тотучы, кыйммәтле һәм зәвыкъле киенгән таныш булмаган яңа кешеләр бик күп иде. Болар күбесенчә яңа эшмәкәрләр, сәүдәгәрләр, бизнесменнар... Алар элек хакимияткә керергә, җәмгыятьтә үзләрен күрсәтергә бик ашкынып тормаган, күләгәдәрәк яшәүче шәхесләр иде. Әмма аз гына яктылык күренүгә алар, шундук өскә калыктылар да, икътисадта, финанс эшләрендә, бик тиз генә иң дәрәҗәле урыннарны биләп алдылар, бүгеннән республикада хакимиятнең кем кулында булачагы һәркемгә дә аңлашыла иде инде.

Сенатор үзенең күптәнге карарының, чын-чынлап күрәзәчелек кылган карарының дөреслегенә дә шат булды. Ул бит ике кеше гомере хисабын каравылчы белән Кощей кушаматлы җинаятьче гомере хисабына—республика прокуратурасыннан Азлархановның үтә яшерен документлары сакланган дипломатны урлатып алды. Ул документларда Үзбәкстандагы гына түгел, Мәскәүдәге бик югары түрәләргә кагылышлылары да бар иде. Димәк, Миршаб белән алар оттырышсыз уен уйнаганнар: партия элитасына катнашы булмаса да, алар белән дуслыкта яшәгән, аларга матди ярдәм күрсәтеп килгән Шубарин, банкир булып алгач, үзенең абруй-дәрәҗәсен бик нык күтәрде һәм яңа катлам кешеләр арасында да көчле шәхес булып танылды. Ә инде банк презентациясенә дөньяның төрле якларыннан җыелган кунакларына караганда, ул хәзер халыкара мәйданга ук чыккан иде. Димәк, әгәр дә элеккеге урынына

менеп утыра алса, Сенаторга да үзен яңа эшмәкәрлек яки сәүдәгәрлек өлкәсендә сынап карарга мөмкинлек бар дигән сүз. Артур Александрович аңа һич каршы килмәстер инде, гомере белән бурычлы бит. Аксайда хан Акмалдан алган миллионнар да бу эштә ярап куядыр. Аларны банк аша ике-өч мәртәбә әйләндереп чыгарсаң, табышы да ике-өч мәртәбә артачак иң. Тәвәккәлләп кирәкле кешеләргә кирәк вакытта ярдәм итү менә шундый матур җимешләр дә бирә икән.

Әйе, Сенаторның иректәге тормышы яхшы гына булыр шикелле иде дә... Әмма... Әмма һаман да прокурор Камалов исән-сау, һаман да үз урынында эшләп утыра. Әлбәттә, «мәскәүле»нең бер генә мизгелгә дә җиңеләсе килмәс, Сенатор бит прокурор өчен җинаятьче һәм шулай булып калачак, ул киребеткән чигенә белмәс—токымы шундый каты-кырыс, бер дә шәрекькә хас түгел. Шуңа күрә алга таба планнар корганчы, башта Камалов белән исәп-хисапны бер һәм берәгәйле итеп өзәргә кирәк, юкса янә кулына богау салуларын көт тә тор! Миршаб эшли алмаганны Сенаторның үзенә хәл итәргә кала, прокурор бернинди килешүләргә дә бармаячак.

Әлбәттә, Әкрәмхуҗаев хәзер инде Камаловның элеккеге көче-абруе да юклыгын чамалый, хәзер һәр мөстәкыйль республика халкы Мәскәүдән куелган түрәләргә чумага караган кебек карый, Камаловның КГБның ябык уку йортларында укытып йөрүе дә аның «демократлар» арасындагы дәрәҗәсен күтәрә алмады. Сенатор илнең генераль прокуроры (ә бәйсезлек алганнан соң Камаловның вазыйфасы да, мөгаен, шулай аталыр) дәүләттә иң әһәмиятле-дәрәҗәле урын биләп торачагын да аңлый. Мөгаен, бик күп көчле ырулар бу урында үзләренең бугазларына басардай килмешәк «мәскәүле» утыруына үртәлерләр, аны төртеп төшерергә дә теләрләр. Шулай килеп чыкса, иллә дә шәп булыр иде! Кайда кайчан бензин сибеп, шырпы гына сызасы калыр, ә анысын Миршаб белән ул ничек эшләргә икәнен белә инде. Камалов утырган урындыгыннан тәгәрәп төшсә, куркыныч кеше булмас, яшәсен әйдә. Ә инде ничектер утырып калса,—чөнки аны Югары Совет депутатларының күбесе ярата, диләр,—ул чагында бер генә юл бар...

Ләкин хәзер, өч мәртәбә үтерергә теләп тә үтереп булмагач, «мәскәүле»не эләктерү барып чыкмас, очраклы хәлгә дә ышанырга ярамый, ул чукынмыш үзен эзәрлекләүләрен беләдер инде. Прокурор хәтта кемнәр эзәрлекләгәннәрен дә беләдер, әмма сизенүләренне теркәп куеп булмый, дәлил кирәк, шаһитлар кирәк, суд эше кузгату кирәк. Ә безнең заманда суд эшләре кузгату җиңел түгел. Сенатор монысын КГБ подвалларында Артем Парсегянның кинәттән үлеп китүеннән соң бик яхшы аңлый. Әйе, Камаловны капкынга каптыру хәзер җиңел булмас, ул хәзер бик сак, хәтта хастаханәдә ятканда да үзе беренче булып атты бит. Миршаб ул чакта Камаловны көпә-көндез дөмектерергә теләгән иде дә, барып чыкмады. Сизгер полковник Жураев прокурорны тәрәзәсез-нисез аерым палатага салдырып, медицина хезмәткәрләре исеме астында сак та куйды. Бу ике кешенең бер-берсен аңлап эшләүләре бик куркыныч була башлады. Күптәннән эчке органнарда эшләп килгән Жураев республикадагы көчләрне, аларның яшерен тормышын, кемнең кем һәм нәрсәгә сәләтле икәнен яхшы белә иде. Мөгаен, ул күп гомерен Мәскәүдә һәм чит илләрдә үткәргән прокурорга кирәкле кешеләрне еш кына биреп торгандыр. Аның прокуратурага килеп-китеп йөргәнен, кәрт уенында күп итеп оттырганнан соң, Сенатор белән Миршабка килеп капкан Канзафар һәрвакыт хәбәр итә иде.

Тәкъдир итү кичәсеннән кайткач, йокысыз төн үткәргәндә, Сенатор янәдән-янә прокурор Камалов турында уйланып ятты. Инде таң атып килгәндә йокымсырый башлагач, соңгы уе шул булды: иртәгә үк Канзафарны күрергә кирәк, бәлки, ул «мәскәүле»нең йомшак якларын беләдер, прокуратурада эшли бит.

Әмма иртән Иске шәһәрдәге үз өе капкасыннан чыгып килгәндә Сухроб Әхмәтович каршындагы йөзьяшәр чикләвек куаклары күләгәсе астында йөренеп торган кешене күреп алды. Ул адәм Ташкент өчен сәеррәк киенгән—ялык-йолык килгән күнитекләрдән, эссе булса да, үзенә зуррак булган кыйммәтле, инде күптән модасы чыккан яңа костюмнан иде. Кинәт кенә Сенаторның башына барып житте—бу бит Аксай егете Исмат, ул аны хан Акмалның таулардагы йортыннан нәкъ шушы капка төбенә китереп, Шубаринга телефоннан хәбәр иткән иде: сезнең дустыгыз өендә, исән-сау, диеп.

Әйе, бу Исмат иде. Сенатор аның шәп күнитеге шыгырдаганын ишетте шикелле. Әллә кайдан ераклардан килгән кеше аны көтеп тормас иде, шуңа күрә Сухроб Әхмәтович, туктап бармагы белән генә аны машинага утырырга чакырды. Кузгалып киткәч кенә исәнләштеләр дә, Сенатор ни өчен телефон аша гына очрашу билгеләмәгәннәрен сорады.

—Сабир бобо кушмады,—диде Исмат.—Сезнең телефонны тыңлап торулары бар.

Кайдадыр туктап, машинада гына бик әйбәтләп сөйләшергә кирәк иде. Тәрәзәләре ачык булса да, котычкыч эссе иде, ул шуңа күрә чәйханәгә кереп утырырга тәкъдим итте. Сенаторның үзендә дә кинәт кенә бер иске мәхәллә чәйханәсендә утырып чыгу теләге кузгалды. Бер шундый чәйханә Чыгатайда бар, каусы-буалы, суга иелеп торган талларына читлекле бытбылдыклар да элеп куелган. Төрмәдә утырганда да шул таллар төшләренә керә иде. Иртәнге якта чәйханә буш диярлек, бары берничә аксакал карт утыра,—өсләрендә бертөрле яшел чалма-чапан, димәк, Мәккәгә хажга барып кайтканнар, картлар келәмнәр җәелгән кызыл залда иделәр. Әкрен генә әңгәмә корып утырган аксакалларны күздән кичергәч, Сенатор кинәт кенә: «Менә болар үзгәртеп коруга да, Горбачевка да рәхмәтледер,—дип уйлап куйды. Элек мөселманнарның изге урыннарына—хажга барып кайту боларга әкияти төшләрендә дә кермәс иде. Ә хәзер бер мәхәлләдән генә дә өчәү барганнар». Үзгәртеп коруның яхшылыгы турындагы уйны айван ишек төбендә ике егетнең тәмләп сумса ашап утырулары бүлде. Кунагына карап алгач, Исматның Наманганнан беренче самолет белән очып килгәнен, әле авызына ризык кермәгәнен абайлап алды, үзенең дә кинәт сарык кабыргаларыннан курдюк мае салып пешерелгән сумсаны ашыйсы килеп китте. Ул чәйханә каршындагы тыкрыкта яңа суелган сарык ите, ат итеннән пешерелгән казылык, кыздырылган бавыр гына сатып калмыйлар, ә уйгур ишегалларында сумса да пешергәннәрен белә иде. Чәйханәче аның күз карашын абайлап алды да, чәйнек куелган подносын сузды, подностагы тәлинкәдә өем-өем сумса да бар иде.

—Ә бәлки катлы-катлы сумса бирергәдер чәй янына, тандыр мичennән кайнар килеш кенә алып.

Сенатор ризалык белдереп баш какты. Чәйханәче аяк астында чуалып йөргән малайны тиз генә күрше йортка йөгертте.

Чәйханәдә бер сәгатьтән дә артык юандылар. Ашап бетергәч, Исмат пинжәгенең эчке кесәсеннән поезд билетлары чыгарды.

—Болар иртәгәге Ташкент-Наманган поездына, йомшак вагонга ике билет. Сезнең купеда ялгыз гына йөрергә яратканыгызны беләбез,—диде. Сенаторның нәрсәдер әйтергә җыенганын күргәч, ашыгып өстәде:

—Сабир-бобо бик тиз килеп житүегезне сорады. Сезнең өегездә дә эшләрегез бардыр, аңлыйм, әмма билетларны алыгыз. Бу—фәрман, миңа үпкәләмәгез, мин үз иркемдә генә түгел...

Исматны аэропортка илтеп куйгач,—тегенең көндезге самолетка билеты бар иде инде,—Сухроб Әхмәтович Миршаб янына юл тотты. Аксайга теге

заманнардагы шикелле яшерен генә баруның мәгънәсе юк иде: вәзгыять үзгәрде хәзер, Сухроб Әхмәтович үзе генә барачак, партбилетның да дәрәҗәсе төште. Югары суд бинасы янына килеп туктаганда, Аксайга барачагы турында да сөйләнеп йөрү ярамас, дип уйлап алды ул. Үзен бер гаепсез итеп күрсәтеп, Ак Йорттагы кабинетына янадан кереп утырганчы, Акмал Арипов белән бәйләнеше барлыгын да әйтми тору мәслихәт булыр.

Сәлим Хәсәновичта кинәшмә беткәнне кабул итү бүлмәсендә көтеп утырганда, ул Канзафарга да шылтыратып карамакчы булды, әмма тегесе урынында юк иде. Сенатор язмыш шуклыгы турында уйлап, елмаеп куйды. Ул Канзафарны чакырып, «пешерергә» җыенган иде, барысы да киресенчә килеп чыкты, аның үзен катгый боерык белән Сабир-бобо чакырткан, күрәсең, сөйләшү дә каты булыр шикелле. Хан Акмалның рухи мөгаллиме Аксай ханың кулга алганнан соң булган куркуын җиңгән, Горбачевның үзгәртеп кору сәясәте чәлпәрәмә килгәнен дә аңлагандыр, ул хәзер Мәскәүнең республика өстеннән контроле дә югалганын белә, димәк, үзенең хакимлеген янадан тойган, акча көченең тәмен янадан сизенгән.

Миршаб белән Сенатор әбәт җиткәнче диярлек сөйләшеп утырдылар, Сабир-бобо янына барырга кирәклеген тәфсилләп тикшерделәр, ә бармыйча булмый, акча кирәк, акча!

Сенаторның күңелен бер нәрсә генә җылытып тора, үзенә куркыныч янау мөмкинлегенә дә карамастан, ул мөшкел хәлдә калган хан Акмалга ярдәм кулын сузды. Бу бит әле үзгәртеп коруның иң кызган чагында, күпләр, аның көннәре санаулы инде, дип, Ариповтан йөз чөергән чагында эшләнде! Ә Сухроб Әхмәтович ераккарак карый иде, алдан күрүчәнлек сәләте дә бар икән. Хәзер инде хан Акмалның, әлегә төрмәдә утырса да, хәлләре иректәге хакимнәрнең күбесеннән яхшырак, тегеләре Мәскәү тикшерүчеләренә бик тырышып тәлинкә тоттылар, шуның белән үзләренә дә күләгә төшерделәр ич. Димәк, Сенаторга беркемгә дә кирәк булмаганча хан Акмалның иректә булуы кирәк иде. Үзе төрмә тормышын татып караган кеше буларак, ул белә—хан Акмал котылып кайткач, Сенаторга гына ачык йөз күрсәтәчәк. Дуслар бәладә танылалар—бу сүзләр буштан әйтелми. Төрмәнең как такталарында йоклап, баландасын чөмергән кешеләр генә аны яхшы белә. Хан Акмал судта ялкынлы чыгыш ясаганнан сон, үз кешеләрен дә истә тоткан иде. Шул чыгышыннан соң аны азат та иттеләр. Хәзер чират таянырдай үз кешеләрендә иде.

...Тиз йөрешле Ташкент-Нәманган поезды, моннан дүрт ел элек йөргән шикелле үк, иске расписание белән кузгалып китә икән.

Проводник хәйләкәррәк кенә исерек кеше иде, өстендә—чапан, аякларында—галош, алай да башында—тимерюлчылар фуражкасы үзенең. Башта Сухроб Әхмәтовичка аның салмыш булуы ошамады, кешеләр аңында тимер юл гадәт буенча әле һаман да көчле һәм катгый тәртипле булып яши бит. Дөреслек өчен шунысын да әйтергә кирәк, үзгәртеп кору чорында тимерюлчылар үз дәрәҗәләрен башкалардан озаграк сакладылар. Кая карама—өзек-төтек кенә эшлиләр яки бөтенләй тукталып калганнар, ә поездлар әле һаман да йөреп тора, күрәсең, соңгы көчләренә тырышалардыр инде.

Ташкентның шәһәр тирәләрен узып китүгә, галошлы проводник Сенатор купесына ике зур төргәк әйбер күтәргән яшь кенә елгыр бер егетне кертеп утыртмакчы булды. Әмма ярым исерек проводник Сенаторның салкын-кырыс карашына килеп төртелгәч, гафу үтенеп тиз генә чыгып шылды һәм янадан борчып йөрмәде.

Дүрт ел элекке шикелле үк, поезд бер яктан икенче якка бәргәләнә иде. Әкрәмхуҗаев аны үзе бервакыт утырып үткән Австрия тимер юллары белән чагыштырып та тормады. Аның уйлары башкада иде. Шулай да Аксайга

кайчандыр барып кайтуы башсызлык булганлыгын исенә төшергәләде: ул сәяхәт көтелмәгән нәтиҗәләр биргән иде. Бүген Сенатор сәясәтчегә алдан күрүчәнлек, вакыйгаларны алдан сизенеп, карар кабул итү кирәклеген аңлый. Теге вакытта ул бит хан Акмалга ярдәм итәргә тырышучы бердәнбер кеше булды. Вакыт аның зирәклеген раслады, ул шуна шатлана иде. Сәгатенең яктырып торган телләренә карап, уйлап куйды: үткән килүендәге шикелле таң белән йокыдан торып китәсе юк. Ул чагында, бер сукыр-саңгырау станциядә төшеп калгач, аны Аксайга иске генә вертолетка утыртып җибәрүчеләр көтеп тора иде. Хәзер исә ул Нәманганның соңгы тукталышына кадәр барачак, анда аны вокзал мәйданында ак «Волга»да алтын тешле Исмат көтеп торачак, ул хан Акмал биләмәсенә җилдереп кенә илтеп тә куячак. Әмма бу юлы очрашу үзе оештырган түгел, Аксай хуҗасының теләге дә түгел, ә аның рухи мөгаллиме Сабир-бобо теләге белән эшләнә иде. Ул ак чалмалы карт нигә әле рәсми генә фәрман биргән? «Әллә мин аның кул астындагы кешеме?—дип, гадәтенчә гасабиланып алды Сенатор.—Мин йомышка йөгерүче малаймы әллә?»

Ләкин бу үртәлүе кинәт кенә кузгалган шикелле, кинәт кенә сүнде дә: күз алдында кайчандыр биш миллион салынган күн чемодан калыкты, аны Аксайда хан Акмалның казначее Сабир-бобо китереп тоттырган иде! Алдан шарт куеп сөйләшмәсәң дә, акча өчен һәрвакыт җавап бирергә кирәк була. Ә шәрекъта акчаны саный беләләр, ул сиңа партия яки дәүләт акчасын туздыру түгел, партия алдында җавап тотасы юк, ул акча шәхси кешенеке. Бу Сабир-бобо Аксайга ни өчен нәкъ бүген килергә кушты икән? Әйтерсең, Сенаторның Ташкентта эшләре юк, ул бит әле төрмәдән чыккач юньләп ашап-эчеп, рәтләп йоклап та өлгермәгән иде. Бу уйлары бик кызык иде, ул кинәт урыныннан күтәрелде дә утны яндырды. «Әйе, әйе, партия,—дип уйлады ул,—ак киемле тыныч кына диндар картның табышмагы шунда. Димәк, сәбәбен белгәч, очрашуга да яхшылап әзерләнергә кирәк». Сенатор күңелләнә төште, юл сумкасын ачып, иң әүвәл чәй тартмасын чыгарды. Илдә азык-төлек кытлыгы булса да, ул үз гадәтенә тугрылыклы иде: ул кара инглиз чәе «Эрл Грэй—Соры кардинал»ны эчә—аның хуш исен ярата иде. Сумкадан төрле сыйнигъмәтле пакетларны, төргәкләрне-фәләннәрне алганда, Сенатор яраткан хатынын сагынып исенә төшерде. Хатыны аның һәр теләген үтәргә тырышкан, хәтта чәй янында капкаларга кыздырылган миндаль-бадам чикләвеге салырга да онытмаган икән. «Әле кайнаган суга өзеклек юктыр дип ышанам»,—дип уйлап, Сенатор кайнап утырган титан янына китте—йомшак вагонда әле күптәнге тәртип буенча чәйнек белән ике пиала сакланып калган иде.

Чәй эчә-эчә, ул күңелендә туган уен ашыкмый гына тикшерә башлады. Һәммәсе дөрескә чыга: Сабир-бобо КПСС бетерелгәч Сухроб Әкрәмхуҗаев гомерлеккә үз абруй-дәрәҗәсеннән, көченнән дә колак какты дип уйлый, Шәрекътә кешегә бәяне иң башта эшләгән-биләгән урынына карап бәялиләр.

Әйе, акча, ыруглык мөнәсәбәтләре, әшнәлекләр буш сүз түгел, әмма бүгенге тарихи көннәрдә алар гына да җитми әле. Дәүләт белән идарә итәрлек тәҗрибәсе булган, дәүләтчә фикер йөртә алган, халык яратып кабул итәрлек кешеләр кирәк. Мәрхүм Рәшидов нәкъ әнә шундый кеше иде. Ә хәзер Рәшидовка тиң булырлык кеше итеп Сенатор үзен күрә, әлбәттә, Акмал Арипов янәшәсендә—хан Акмалга да анардан башка гына Ташкентта күтәрелергә ирек бирмәячәкләр. Аксай көрәшләр үзегеннән шактый ерак, Аксай ханы үзе дә сәяси көрәшләр, хәйлә-мәкерләрдән озакка аерылып торды. Димәк, башкалада Сухроб Әкрәмхуҗаевтан башка таяныр кешеләре юк дигән сүз. Димәк, Сенатор үзенә боерык биреп, үзен чыбыркылап торучыларга да буйсынмаячак. Шушы уе Сенаторны тәмам тынычландырды: ул хәзер, хан Акмалның рухи мөгаллиме һәм казначее белән очрашкач, үзен ничек тотарга кирәклеген белә иде инде.

—Хакимлек!—диде Сенатор акрын гына, бу сүзнең ымсындыргыч йогынтысына төшенергә теләде ул.—Хакимлек, хакимлек...—дип кабат-кабат тәкърарлый башлады. Мылтыктан аткандай кыска сихри сүз—«хакимлек!». Аның уйлары яна юнәлеш алды: әлегә кадәр ул белгән хәкимлек бүгенге бәйсез суверен дәүләт вәгъдә иткән хакимлекнең кискән тырнагына да тормый иде. Нинди мөмкинлекләр ачылачак бит! Куанычыннан аның тыны кысылды. Парижга, Лондонга, Амстердамга бар, яки Канар, Фиджи утрауларында ял ит—телә генә, берниндин Мәскәүләр белән сөйләшеп-килешеп торасың юк, беркемнән рөхсәт-фәлән аласың юк. Долларлар кирәкме—үз кешеләрең булган финанс министрына яки Дәүләт банкы рәисенә генә шылтырат, кирәксә, Артурга да шылтыратырга була, аның банкында валюта, мөгаен, дәүләт банкысындагыдан күбрәктер дә әле. Мәккәгә хажга барып, гөнаһларыннан арынып кайтырга уйласаң (ә гөнаһлары бик күп аның!), партбилетың, утырган кәнәфиең өчен кан калтырап торырга да кирәкми, акчаңны түлә дә, турыдан-туры Жиддәгә очып барып та төш!

Хәтерендә, кайчандыр Сенатор Аксай тауларындагы Очан-су шарлавыгы янында хан Акмалга төрттеребрәк әйткән иде: янәсе, Рәшидов белән син үз жиреңдә нинди хужа инде—күзгә-күз генә сөйләшкәндә дә артык сүз ычкындырудан куркасыз, Мәскәүгә барып ирешер дип шүрлисез. Ә аның кулы озын, камчысы каты! Шуңа күрә Мәскәү күрсәтмәләре белән генә яшисез, аның кубызына гына биисез.

Хәзер исә Анхордагы Ак йортның бишенче катына менеп утырган кешеләргә нинди мөмкинлекләр ачылачак бит. Хәзер хакимиятне ни Мәскәү, ни Истамбул билгели алмый, барысы да Ташкентта хәл ителә, Югары Совет трибуналарыннан сөйләп кенә дә түгел. Ул хәзер базар-мәйданнарда, сихри таяк белән бер селтәүдә калкып чыккандай күтәрелгән меңләгән мәчетләрдә, шәһәрләрнең барлык мәхәлләләрендә, барлык кышлакларда хәл ителә.

Әле кичә генә кайсы сәясәтче дингә житди итеп карый, үзен Аллаһыга ышанучы итеп саный иде соң? Киресенчә, алласыз-динсезлеге белән мактана, чөнки партия уставы шуны таләп итә иде бит. Ә бүген исә руханиларның халыкка йогынтысын искә алмау—үз-үзеңә куркыныч бер ышану гына. Жомга көнне жәмигъ мәчетендә берәр мулланың бер вәгазе дә партия агитаторларының йөзләгән нотыкларына тора, мөселман диния нәзарәтенең йогынтысын хөкүмәт тә, һәр граждан да сизә, юкса мөфти үзе матбугаттагы, телевидениедәге чыгышларында кат-кат ислам диненә сәясәт ят нәрсә, ул сәясәт белән шөгыльләнмәячәк, дип искәртеп килә. Анысы да дөрес: диния нәзарәте ислам фиркасе—партия төзергә уйласа, хакимиятне кулында тоткан партиянең дә аяк астында жир тетри башлар иде. Хәзерге һәртөрле яңа партияләр, хәрәкәтләр турында әйткән дә юк инде. Ә диния нәзарәтенең бу гамәлне башкарырлык кына маясы бар, зыялы-гыйлемлеге ягыннан да һич тә элекке коммунистлардан ярлырак түгел. Иң мөһиме шул: ул әле үзен халык каршында буяп өлгермәгән, ялган вәгъдәләрдән туйган халык аңа иман китерәчәк, чөнки ислам социаль тигезлек вә гаделлек тәгълиматенең тормышка ашмаган күп кенә фикерләрен кабатлый.

Сухроб Әхмәтович хәтта дин турындагы уйларында да буш фәлсәфә сатмый, ул һәр нәрсәне гамәли эшкә күчерә. Әле дә кесәсендәге блокнотына бик кирәкле сүзләрне теркәп куйды. Әгәр дә ул иртәгә Аксайда бер ун-унике миллион сумны суырып ала алса, Ташкенттагы төзелеп килә торган берәр мәчетне эзләп табар иде. Ул мәчеткә мөфти дә килми калмастыр. Сенатор мәчет файдасына саллы гына сумма салыр, яки аның өчен кыйммәтле келәмнәр-фәләннәр сатып алыр, китапханәсен яңа дини китаплар белән тулыландырыр. Аның бу изге гамәлләре мөфти колагына да барып ирешер, хәзерге авыр заманнарда мондый юмартлыкны һәркем дә эшли алмый бит.

Аның әлеге гамәле вакыты житкәч үзенә диния нәзарәте каршында да юл ачар, мөфтинең хәер-фатыйхасын алу бер дә артык булмастыр...

Азия төненең куе бәрхет караңгылыгын ертып, тиз йөрешле поезд кычкырта-кычкырта алга ыргыла. Тепловозның еракка сузылган көчле нурлары станция-разъездлар тирәсендәге ярлы биналарны яктыртып ала. Юл буендагы бу хәерчелекне болытлар артыннан килеп чыккан тулган ай яктысы да матурлый-бизи алмый, бер-берсенә кысылып-елышып сыенган тар кысан ишегалларында ни агачларга, ни яшелчә бакчаларына урын юк, әйтерсең, бу—җире аз булган Япония... Бары тик ара-тирә берәр чикләвек агачы, яки киртә буендарак ботаклары кискәләнгән зәгыйфь алмагач күренеп кала да, әллә суган, әллә редиска тутәле шәйләнеп уза. Элекке хакимият әһелләре жир кешесен хөрмәт итми иде шул. «Ничек монда яшәмәк кирәк? Халык ничек түзеп тора?»—дип уйлап алды Сенатор, әмма моның сәбәпләрен бер дә эзләп торасы килми иде. Шулай да ул, коммунистларның да, хәзер хакимияткә ыргылган яна көчләрнең дә бәхете бар икән—мондый түзем, берсүзсез буйсынучан, ышанучан халык, мөгаен, башка бер жирдә дә юктыр, дип көрсенеп куйды. Бу халыкка Ленин алтын бәдрәфләр ясарга, Хрущев сиксәненче елларда коммунизмда яшәргә, Горбачев ике меңенче елга һәр гаиләгә фатир төзеп бирергә вәгъдәләр бирә—мескен халык һәркайсына ышана һәм түзем генә көтә...

Сенатор үзенең сәясәткә аяк баскан чагында Аксайда хан Акмалдан алган дәресләрен онытмый. «Иң мөһиме—бервакытта да югалып калмаска кирәк»,—дип өйрәтте аны ике Гертруда—«Хезмәт Герое» иясе.—Хәтта берәр ахмак сүз, яки аннан да яманрагын ычкындырсаң да, анардан баш тартып, сез мине дөрес аңламадыгыз, дип әйтергә була». Моның өчен сүзләрне әйләндереп-тугландырып, озын-озакка сузып, куелган сораулардан кача белергә дә өйрәнү кирәк иде. Хан Акмал фикеренчә, күпме сөйләсә дә, турысын әйтмәү, журналистларның мәкерле сорауларыннан кача белү остасы Горбачев икән. Аксай ханы үзе дә сүз чәкәштерүдә башкаларга биргесез оста булганга, дөньядагы иң күп кешеле партиянең генсекретаре Горби турындагы бу фикерен ул аның сәясәткә аяк баскан елларыннан ук әйтә килде. Хан Акмалның бу сүзләреннән соң ике-өч атна үттеме-юкмы икән, Горбачев сонрак дуслашкан канцлер Коль аны «хөрмәтле немец» дип кенә йөртә башлады, хәтта аның ялганлау осталыгын Геббельсныкына да тиңләп ташлады. Әлбәттә инде, Горбачевның бик нык хәтере калды, ике ил арасындагы мөнәсәбәтләргә күпмедер вакытка салкынлык йөгерде. Дипломатлар һәр ике яктан да бу киеренкелекне йомшартырга тырыштылар.

Әлбәттә, Сенатор бу мәсьәләдә Горбачев белән дә, хан Акмал белән дә ярыша алмый, шулай да сүзен бирмәүдә шактый шомарган кеше иде.

Төрмәдән ирекә чыгар алдыннан ул ике тәүлек гомуми камерада утырды, анда нигездә мәскәүлеләр иде. Биредә аңа беренче сәгатьләреннән үк мәсхәрәле мөнәсәбәт булды. Мөгаен, аны китереп кертүчегә күрәдер, тоткыннар күбрәк Урта Азия турында сүз куертырга тотындылар. Төрмәдә сөйләшер сүзләр тиз бетә. Хәзер исә төрмәдә булсын, ирекә булсын—сүз көрәштерү гел сәясәткә барып төртелә. Менә хәзер дә камерадашлары, кем ничек булдыра, шулай, Азия республикаларының суверенитетын, бәйсезлеген яманлый башладылар. Күпчелек мәскәүлеләр кебек үк, алар ТажикстанныТөрекмәнстан белән, Казакъстанны Кыргызстан белән, Ташкентны Алма-Ата яки Ашхабад белән буташтыра иделәр. Сенатор боларның күзен ачты. Баксаң, Урта Азия республикаларында алтмыш миллионга якын халык яши икән, аларның яртысыннан артыгы әлегә унсигез яшькә дә житмәгән икән, илдәге алтынның илле проценты Үзбәкстанда табыла икән, дөнья базарында бер тонна мамыкка унике тонна бодай сатып алырга мөмкин икән. Уран ятмаларының барысы да диярлек нәкъ менә шушы төбәкләрдә ята икән дә, төсле мәгъдәннәрнен—

бакыр, әлюмин, кургаш, вольфрам, титан, молибден дигәннәренен күп өлеше шушында табыла икән. Менә сезгә Урта Азия!

Сенатор ише сак кешене, мөгаен, кайнар бәхәсләргә тартып та булмас иде, андый бәхәсләрдән сон дустанә тыныч кына сирәк аерылышалар. Әмма менә кемдер тәкәббер генә итеп, Урта Азия халкынын зыялылык ягы чамалы, интеллект сәләтләре түбән, читтән ярдәм итмәгәндә рәтле тормышлары булмас иде, дигәнрәк сүзләр ычкындырды. Бу сүзләрдә, дөреслек булса да, алар Сухроб Әхмәтовичнын йөрәгенә барып кадалды. Ул кабынып китте:

—Мәскәүнен интеллектуаль куәтеннән башка без яши алмаячакбызмы?—дип сораган булды ул. Теге бәндә «әйе» дип баш каккач, сүзен дәвам итте?—Без томана азиатларга ничек ярдәм итәргә җыенасыз сон? Россиянен үзендә паника, курку-шөбһәләнү бит хәзер. Бер генә газет, бер генә телевизион тапшыру, бер генә парламенттагы сөйләшүләр дә курку-өркүсез яшәми түгелме? Мәскәү белән Ленинградның талантлы-акыллы яшьләре дәррәү кубып ни өчен Көнбатышка таялар сон? Долларларга теләсә кайсы илдә, теләсә нинди эштә эшләргә әзер яшь белгечләрнен киту-качуы тагын да ишле булыр иде әле—кесә яклары такыр, авиабилетларнын бәяләренә якын килерлек тә түгел. Шулай булгач, мәскәүле әфәнделәр, безне кызганып утырганчы, әүвәл үзегез турында уйлагыз әле!

## XVI

Иртән поезд төгәл расписание буенча Нәманганга килеп туктагач, Сенатор беразвакытка купеда калып торды, берәр таныш-фәләне белән йөзгә-йөз очрашасы килми иде анын. Яна гына төрмәдән чыккан кешенен Нәманганга шулай тиз сәяхәт кылуы кызыксыну гына тудырып калмас, төрле имеш-мимешләргә дә азык булыр, бу сүзләр, мөгаен, «мәскәүле» прокурорга да барып ирешер иде. Прокурор Сенаторнын кайсы тарафларга юл тотканын шундук аңлап алыр, аннан да яманрагы—хан Акмалнын судта ясаган чыгышы Әкрәмхуҗаевны «Матросская тишина» төрмәсеннән коткарып алу нияте белән эшләнгәнлеге, хәйләкәр бер алым гына булганлыгы ачылыр иде. Шуна күрә Сухроб Әхмәтович вокзал мәйданына килеп чыкканда, мәйдан буш иде инде, бары тик арырак ябык газет киоскасы янында аксыл «Волга» гына тора иде. Кара күзлекле озын гына кеше шул машинага таба юнәлде. Тәрәзәләре карангылатылган көтеп торучы «Волга»нын моторы эшли иде, ул җинел генә кузгалып китте дә, шәһәр үзәгенә таба элдертте.

—Мин инде сез безгә кунакка килүдән баш тарткансыздыр дип уйлый башлаган идем,—диде Исмат елмаеп.—Сез перронга сонгы кеше булып килеп чыктыгыз бит. Ярый әле, мин картка шылтыратып өлгермәгән идем, анын кәефе китәр иде, ул сезне бик көтә...—Алтын тешле шофер, гафу үтенеп, машинасын туктатты. «Волга» эченнән генә әллә Нәманганга, әллә Аксайга кемгәдер шылтыратып, шатланып әйтте:—Кунак килеп житте, бер сәгатьтән сездә булырбыз...—диде.

Кайчандыр шушы юлдан Исмат аны Нәманган-Ташкент поездына китергән иде. Ләкин ул вакытта табигать матурлыкларын карап бару мөмкинлеге булмады. Ул хан Акмал белән очрашуын янадан исенә төшерде, нәрсәдә откан, нәрсәләрдә оттырганын исәпләп чыгарга тырышты. Шунын өстенә, Аксай хуҗасынын ана сонгы мизгелдә генә тоттырган папкадагы кәгазьләр дә тынгы бирмәде. Ул кәгазьләрдә Сенаторга кагылышлы бик күп нәрсәләр язылган, аларны тизрәк алып укыйсы килә иде—кызык, хаким Арипов анын турында нәрсәләр белә икән? Әмма юлда еш очраган, аларны узып-узып киткән машиналар гына исендә калган иде. Ә бу юлы юл буш булып чыкты. Сенатор: «Нишләп машиналар күренми?»—дип сорады. Исмат туп-туры

хәйләсез җавап бирде: «Бензин юк...» Ә Аксайга барып кергәндә, хәтта ишәкләр җигелгән ике арба да очрады. Бу юлы да ул Аксайның Кызыл мәйданын күрәсе итте, Исматка һәйкәл яныннан узарга кушты. Шофер тирән мәгънәле итеп җавап кайтарды:

—Аксайдагы Кызыл мәйданны, Ленин һәйкәлен әйләнеп узып булмый, ул шулай уйлап эшләнгән,—диде. Алтын тешле кол, күрәсең, үз хуҗасының яраткан сүзләрен кабатлагандыр.

Кызыл мәйдан иркенлегенә чыгып та җитмәделәр, Сенатор ирексездән аһылдап куйды: Ленинның таныш һәйкәле каршысында төзелеп беткән диярлек мәчет кукраеп утыра иде. Бары тик кайбер җирләрендәге төзелеш баскычлары белән бер манара янындагы япон автокраны «Като»ның күккә караган угы гына әле биредә ниндидер эшләр дәвам иткәнлегенә ишарәли иде. Якынрак килгәч, ул тагын да гаҗәпләнә төште: Ленин мәчетнең бизәкләп-сырлап эшләнгән биек ишегенә таба чакырулы кулын сузып тора икән, әйтерсең лә, мөселманнарны иртәнге намазга өнди, бу тойгыдан арынып булырлык түгел иде, кунак көлемсерәп тә куйды. Сәер, элекке килүендә үзен кабул итүләрен озаклап көтеп утырганда, мәйдан коточкыч зур булып күренгән иде, хәзер ул сизелми дә, биек гранит пьедесталыннан Ленинны алып ташласаң, ике рухи-дини корылмалар арасындагы ярашып-килешеп торган тәңгәллек тә юкка чыгар төсле. Хан Акмал көне-төне «дини агу» белән көрәшкән юлбашчыны кимсетү-мәсхәрәләү өчен юри шулай эшләткәндер кебек.

Мәчетне хәзерге заманча итеп талантлы кеше ниятләгәндер, һәр хәлдә Сенаторга шулай тоелды. Мондый матур мәчетләрне ул Төркия, Кувейт, Согуд Гарәбстаны кебек чит илләрдә генә күргән иде. Бохара, Сәмәрканд, Хива, Хәрәзмдәге безнең архитекторларның эшләрен болар белән чагыштырып буламы соң?! Болар бит гүзәллекнең үзе! Мәчет манараларының һәр икесе дә биек, төз-матур, челтәрләп эшләнгән, мөгаен, көчле радиоаппаратура да куелгандыр әле. Ә намаз укый торган зур залның гөмбәзе белән ишегалдын япкан түбәнең яхшы цинк калае көмешсыман ялтырап тора иде.

Кунакның ихластан кызыксынып килгәнен чамалап, Исмат «Волга»сын туктатты. Сенатор машинадан төшеп тормады, ян тәрәзә пыяласын гына бераз ачып куйды. Мәчет аңа чынлап та бик ошаган иде, кызганыч, Ташкентта шундый мәчет төземиләр, ул аның төзелешенә акчасын кызганмый салыр иде, андый гүзәл мәчетнең ачылышына, мөгаен, мөфти дә килми калмас иде. Ул кычкырып сорап куйды:

—Бу изге гамәл кем эше соң? Хөкүмәтнекеме, халыкныкымы, диния нәзарәтенекеме?

—Юк, Сухроб-әкә, белмәдегез, бу—Сабир-бобо эше, ул менә бар саклап торган акчасын салды, ул—бай кеше, хан Акмалның бөтен казнасы аның кулында бит. Акча башта гына кирәк булды. Аннары барысы да кушылды: халык та, хакимият тә, көн-төн китереп кенә торалар—акчасын да, төзелеш материалларын да, җиһазларын да. Сезгә дә мәчеткә ниндидер бүләк бирү кирәктер, картның күңеле булыр иде.

—Ул, мөгаен, мәчетне хан Акмал котылып чыккан көндә ачарга ниятлидер. Бәлки әле үз укучысының исемен дә кушар бу мәчеткә...

—Бу хакта сүз кузгатуыгыз ярады әле. Мәчет—картның тормышында иң зур шатлыгы да, борчуы да. Ул төшендә дә мәчетне үз исеме белән атаганнарын күрә. Тирә-якта изгелектә үзенә көндәшләр булмасын дип, ике ел рәттән Мәккәгә хаҗга барды, моның өчен ул Кәгъбәнең изге ташын өченче мәртәбә барып үбәргә дә әзер. Мәчетнең сызым-проектын да шул изге җирләрдән алып кайтты. Аны ана Истамбулдан хаҗга килгән танылган бер архитектор бүләк иткән, алар Мәдинәдә танышкан булганнар икән, архитектор мәчетне

ачу тантанасына килергә дә вәгъдә биргән. Сабир-бобоны белүчеләр, аның хан Акмалга тугрылыклы булуын истә тотып, мәчетне дә хан Акмал хөрмәтенә төзетә дип уйлыйлар. Ләкин һич тә алай түгел. Карт: «Мәчетегез ни хәлдә?»— дип сораганны бик ярата. «Сабир-бобо мәчете төзелеп бетеп килә икән»,— дигәннәрен ишетсә, үлә дә китә инде. Анардан нәрсәдер аласыгыз килсә, моны исегездә тотыгыз...

—Рәхмәт, Исмат. Минем өчен бик кирәкле мәгълүмат бу. Хәзер язмышым ана бәйләнгән. Чынлап та, картның күнелен күрү мәслихәт булыр.

Мәйдан янынннан китеп барышлый, Сенатор һәйкәл ягына янә бер борылып карады, әмма ничек кенә караса да, айван күләгәсендә бронза юлбашчыны күрмәде. Димәк, үзгәртеп кору чорында Аксайда тагын бер «изге» урын юкка чыкты дигән сүз. Аннары ул хан Акмалга дан-хөрмәт, орденнар һәм табыш китергән авыл хуҗалыгы берләшмәсе идарәсенен дүрт катлы бинасына да күз ташлады. «Архиповның кабул итү бүлмәсенә автомобиль белән генә менә торган лифтны сүттеләрме әле?»—дип сорамакчы иде, әмма тыелып калды. Әлбәттә, лифтны да, айванны сүткән кебек, күптән сүтеп, читкә сатып җибәргән иделәр инде. Аны, мөгаен, үзгәртеп кору дулкынында өскә үрләгән берәр түрә үз кәттә йортына ук илтеп куйгандыр. Хәзер мәчетләр генә түгел, кәттә йортлар-коттеджлар да тиз төзелә бит. «Мөгаен, Аксайдагы үзгәртеп коруларның нәтиҗәсен шушы мәйданда гына күреп буладыр»,— дигән уйга килде Сенатор һәм Исматка кузгалып китәргә кушты.

Элекке баруында Акмал Арипов аны алма бакчасы эчендәге йортында, кунаклар кабул итә торган залында каршы алган иде. Икенче көнне алар биек тау өстендәге шарлавыклар янына киттеләр. Ул вакытта утызынчы еллар стилендә салынган аучылар йорты аны үзенең гадилеге, унайлылыгы белән сокландырган иде. Йорт ике катлы, каминлы, бильярд заллы. Верандалары киң-иркен, көннәр матур торганда шунда табын әзерлиләр икән. Киткәндә Сенатор үзенә сүз бирде: әгәр дә хакимияткә менеп утырсам, хан Акмалны куркытып-өркетеп чит илгә җибәрәм дә, бу йортны үземнеке итәм, диде. Бик беләсе килсә дә, Очан-су шарлавыгы янындагы аучылар йортының язмышы турында Исматтан сораштырып тормады. Мөгаен, бу буталчык заманнан файдаланып, хан Акмалны Лубянка подвалларында бөтенләй юкка чыккандыр дип, кемнәрдер бу йортның эчке җиһазларын, бар булган байлыгын талап бетергәннәрдер инде. Ә бит аш бүлмәсендә менә дигән гарәп мебеле, диваннарында ау күренеше төшерелгән зур гобелен келәмнәр бар иде. Бик тәфсилләп җыелган затлы савыт-саба, һәйбәт ау мылтыклары турында сөйләп торасы да юк инде.

Машина, Аксай урамнарында борылгалап йөргәннән сон, шәһәр читендәге яшелеккә күмелгән бер тыкрыкка кереп, яндырылмаган сары кирпеч дувал-коймалы бер катлы йорт янына килеп туктады. Урамнан караганда йорт уңдагы-сулдагы, каршыдагы күрше йортлардан берничек тә аерылып тормый. Әмма Сенатор бу яклардагы гадәтләрне яхшы белә: бирегә байлыгын, мал-мөлкәтенне күрсәтеп, күршеләрдән өстен булып яшәү дигән нәрсә юк. Әле егерменче гасыр башында ук бер акыллы инглиз Шәрекъ турында болай дигән: «Тәрәзәләре ишегалдына гына карый».

Машина килеп туктауга, иске агач капка шыгырдап ачылып китте, көнбатыштагы аэропорт һәм отельләрнең электроника белән идарә итела торган ишекләре, диярсең. Сенаторга ниндидер бер туннельгә барып керделәр шикелле тоелды, чөнки кинәт караңгыланды, кунак, аңлап алды: ишегалды үрмәле чәй розасы катнаш куе булып үскән йөзем куаклары белән капланган, яфраклар арасыннан хәтта кояш нурлары да үтеп керә алырлык түгел иде. Әйе, Шәрекъта әле үз эшенең осталары бетмәгән, Сабир-furbobоның бакчасын да шундый берәр оста карап-тәрбияләп торадыр.

Йорт ишегалдының түрендәрәк тора, аны урамнан да, күрше коймалар аша да күрерлек түгел, гел яшеллеккә, чәчәкләргә күмелгән. Әмма йортның үзеннән дә бигрәк, үзбәкләргә хас булмаганча галәмәт зур-иркен ишегалды исеңне китәрә. Шуңа күрә биек таш нигезгә утыртылган бер катлы бина алай күзгә ташланып тормый, зур подвалы барлыгы гына сизелә. Бары тик якыннанрак карагач кына ачык веранданы челтәрләп эшләнгән баганалары йортның зурлыгын искәртә. Иркен ишегалды куе-тыгыз, мәңге яшел куаклар, шул ук чәй розалары һәм йөземлекләр белән яшел кишәрлекләргә, сукмак-тыкрыкларга бүлгәләнгән, төп юл-аллея да, читтәрәк җирдән калкыбрак торган утыргыч-беседкалар шикелле, караңгы, күләгәле. Кайдадыр челтерәп су акканы ишетелә, саф салкынча һава сизелсә дә, арыклар күренми иде. Искиткеч тынлык хөкем сөрә, Сенатор үзен кешесез-буш йортка алып килделәрме әллә, дип уйлап та бетермәде, верандадагы ишекләрнең берсе ачылып китте. Кунак ишектән чыккан кешенең үзен күреп өлгергәнче, күнитекләренең таныш шыгырдавын ишетте. Борылып карагач, ул үз артындагы алтын тешле кешенең елмаюлы күз карашлары белән очрашты. Бу элекке килүендә хан Акмал боерыгы белән Сенаторны типкәләгән Ибраһим иде. Аны күргәч, Сенаторның кабыргалары сызлап куйгандай булды, шулай да, елмаеп, Ибраһимга таба атлады.

—Әссәламәгаләйкем, Сухроб-әкә, безнең якларга кайтуыгыз котлы булсын!—дип кочаклап алды калыная төшкән, чалара башлаган Ибраһим.

Хан Акмални кулга алганнан соң, Ибраһимның күп җәфалар кичергәнен, якташлары да, хакимият тә бәйләнеп йөргәнен, хәтта берничә ай Ташкентта төрмәдә утырганын да Сенатор ишетеп белә иде. Ибраһимны: «Хан Акмал үз миллионнарын кайда яшерде?»—дип тинтерәткәннәр, әмма ул хуҗасына тугрылыклы булып калган, озын-озак төнге сорау алуларда да бер кәлимә сүз ычкындырмаган. Бүген исә аңа да бәйрәм кебек—төрмәдән Аксайның абруй-дәрәҗәле дус кешесе кайткан бит, димәк, менә-менә хуҗа үзе дә кайтып төшәр.

—Сез бик матур күренәсез!—диде Ибраһим, кунакны күздән кичергәч.—Мин бит сезнең «Матросская тишина»да ничек изаланганыгызны чамалыйм. Үз өлешемә тигәнен дә дошманыма да теләмәс идем.

—Рәхмәт!—диде дулкынланган Сухроб Әхмәтович, үзенә рәхимле теләктәшлек белдергән өчен. Ул кинәт кенә күнеле түрендә Ибраһимга карата берничә ел сакланып килгән ачуының юкка чыкканын тойды. Ә бит Ибраһим аны теге кызыл байраклы бүлмәдә шәп типкәләгән иде. Бу очрашуны өркебрәк көтеп алган Ибраһим да үзен гафу иткәнне сизенде, шуңа күрә көчле куллары белән кунакны янә бер кат кочаклап алды. Ибраһим белән сөйләшеп торганда, Сенатор ирексездән веранда ягына карап-карап алды, андагы ишектән бу гаҗәеп йортның хуҗасы Сабир-бобо үзе күренмәсме дип көтте.

Бу очрашудан Ибраһим да дулкынланган, үзенең гафу ителгәнлеген аңлаган иде. Шулай да ул, кунакның веранда ягына күз ташлаганын абайлагач, аның тизрәк хуҗа белән күрешәсе килгәнен аңлап алды. Сухроб Әхмәтовичның бик тиз хәтере кала торган кеше икәнен белгәнгә күрә, сәгатенә күз төшерде дә, йомшак кына итеп әйтте:

—Хуҗа сезне түземсезлек белән көтә,—диде.—Ләкин хәзер намаз вакыты, бу вакыт бары тик Аллаһы Тәгаләнеке генә, җирдәге берни дә эш аркасында да иртәнге намазны бүләргә ярамый.

—Гафу итегез, мин анысын уйлап бетермәгәнмен, юкса, чамаларга тиеш идем. Юлда без Исмат белән мәчеткә дә кереп чыктык,—диде Сенатор, акланган сымаграк. Әмма күнеленнән куанып куйды, чөнки бу юлы да, теге килүендәге шикелле, озаклап көттерерләрме әллә дип, борчыла да башлаган иде.

—Юлдан соң берәр пиала чәй эчәрсез, бәлки,—дип тәкъдим итте Исмат, кулы белән чатыр түбәле утыргычлар ягына таба ишарәләп.

Өчәүләп шунда таба атладылар. Чатырның идәненә келәмнәр җәелгән, алар өстендә бизәкле курпачлар, мендәрләр ята, ә уртада—тәбәнәк хан-тахта—өстәл тора, кайнар көлчә исеннән табынны әле берничә минут элек кенә корганнарын белеп була иде. Кунакка түрдән урын күрсәттеләр. Сенатор чәйнең тәмлелеген мактады, ана янә Чаткал чишмәләреннән алып кайтылган суны искә төшерделәр. Кыскасы, тегесен-монысын телгә алгалап, иркен генә сөйләшеп утырдылар. Лубянка подвалларында интегүче хан Акмал турында да, әле генә төрмәдән кайткан Сенаторның үзе турында да, хәтта Сабир-бобо турында да сүз кузгатучы булмады. Табындашлар үзләрен гаҗәеп түзем, әдәпле тоттылар. Нинди дә булса җитди сүзне кунак кына башласа башлый алыр иде. «Әйе, хан Акмал кешеләре яхшы өйрәтелгән, аларны хәтта үзгәртеп кору да боза алмаган»,—дип елмаеп уйлады кунак.

Ташкент вә Нәманган көлчәләрен ашыкмый гына мактап ашап утырганда, кинәт кенә барабан каккандай тавыш ишетелде, тавыш йомшак һәм моңлырак иде. Ибраһим белән Исмат шундук җитдиләнеп, икесе бертавыштан:

—Хуҗа намазын бетерде, ул сезне көтә,—диделәр.

Сухроб Әхмәтович үзен өйгә алып керерләр дип уйлаган иде, әмма киресенчә булып чыкты, алар бакча эченә кереп киттеләр, шунда кунак тулы сулы кин генә арыкны күреп алды. Сабир-бобо аларны шау чәчәктәге розалар белән уратылган чатырда көтеп тора иде. Чатыр исә су өстенә үк субайларга куелган икән. Кунакны чатырның кырыйла төшкән келәм җәелгән биек баскычы янына алып килгәч, озатучылар, сүзсез-нисез генә кулларын белән ишарәләп, өскә күтәрелергә куштылар да, үзләре күнитекләрен шыгырдата-шыгырдата, асфальт сукмак буйлап йортка таба юнәлделәр.

Кин арык өстенә корылган чатыр аша иртәнге кояш нурлары үтеп керә, тиз агымсулы тау елгасы өстендә салкынча саф җил тирбәлә, якты һәм рәхәт иде. Чатыр бусагасыннан атлап кергәч, ул бер почмакта уйчан гына дисбе тартып утырган картны күрде. Картның янәшәсендә кызыл агачтан челтәрләп-бизәкләп эшләнгән музыкаль пюпитр шикеллерәк тәбәнәк өстәлчек тора, аның өстенә пергамент кәгазе саргаеп беткән борынгы китап ачып куелган, кайсыдыр битен ефәк тасма белән билгеләп тә куйганнар. «Коръән»,—дип уйлап алды Сенатор һәм ялгышмады. Идән сайгагының йомшак кына шыгырдаганын ишеткәч, карт башын күтәрде, кунакны күреп елмайды да җинел генә урыныннан күтәрелде.

—Әссәламәләйкем, улым, килеп җиттеңме? Ирекә чыгуыңны котлыйм,—дип, кунакны кочаклап алды һәм җилкәләренә суккалап куйды.

Яшенә караганда шактый яшь, боеручан булса да, ягымлы тавышы карап торуга тыныч кына, ябык гәүдәле диндар картка һич ятышмый иде. Сухроб Әхмәтович икеләнеп тә калды, элекке килүендә ул анардан бер авыз сүз дә ишетмәгән һәм телсез чукрактыр дигән уйга килгән иде.

Карт аны бер кысып кочаклый, бер кочагыннан җибәрә, үзе бик нык дулкынлана иде. Сабир-бобоның дулкынлануын тойган Сенатор аның шәрекъчә озаклап күрешүен өзмәде.

Картны үз янында болай якыннан беренче күрүе булды. Сабир-бобо, теге очрашудагы шикелле үк, гел актан гына киенгән. Әмма ак белән ак арасында да аерма бар икән. Йөзе белән картның күкрәгенә төртелмәгән Сенатор аның бик затлы киеменең рәхәт салкынын, тәмле хуш исен тойды. Кием-салымга зур игътибар итә торган Сухроб Әхмәтович моны шундук бәяләп өлгерде, карап торуга кырыс кына киемнең дә үз матурлыгы бар икән шул. Гореф-гадәт буенча исәнлек-саулык, гаилә-балалар турында сораша-сораша, хуҗа кунагын табын янына чакырды, табын, әле алар Исмат һәм Ибраһим белән янә гына чәй эчкән табын шикелле, тәбәнәк хан-тахтага әзерләнгән иде. Өстәлчек Сенаторның артында иде, ул аны кергәндә күрми узган, хәзер инде

йомшак дөя йонынннан эшләнгән курпачка утыргач, чатырны җентекләбрәк күздән кичерде. Чатыр әйбәт җыештырылган, хуҗасының биредә еш булуы сизелеп тора, арырак бер тастымал өстендә Коръән белән япон радиотелефоны «Сони» күренә. Сухроб Әхмәтович үз өендә нәкъ шундый радиотелефонны үзеннән калдырмый, ваннага да алып керә, ишегалдына да алып чыга.

Гадәттә була торган гомуми сорау-сорашуларга җавап бирә-бирә кунак хуҗаны игътибар белән күзәтте, соңгы очрашуларыннан соң карт шактый үзгәргән икән. Теге вакытта нәкъ менә Сабир-бобо таулардагы аучылар йортына бер чемодан акча белән Шубаринга бүләккә шәп кенә жилет алып кергән иде. Карт ничектер яшәреп, тазарып киткән, үз дәрәҗәсен белә, үзен тотышы да бик табигый, күп кенә абруй-дәрәҗәле түрәләр дә ана көнләшеп карарлык иде. «Нәрсәдән шундый үзгәреш булды икән?»—дип уйлады Сенатор, аның күзе салып куелган яшел чалмага төште, карт аны намаз укыганда салгандыр, күрәсең. Әйе, Мәккәгә ике ел рәттән хаҗга барып кайтуы эзсез узмаган. Элек тә үзен бәйсез, горур тота торган карт хәзер тагын да күркәмрәк иде.

Бусагада тавыш-тынсыз күләгә булып кына поднос күтәргән кыз күренде, ул, хан-тахтага чәйнегеп куеп, сүзсез генә чыгып та китте. Сухроб Әхмәтович карт кулыннан чәй салынган пиаланы алгач:

—Мин сезне котларга тиешмен,—диде.—Тормышыгызда бик мөһим зур үзгәрешләр булган икән. Сез һәр мөселманнның иң изге хыялын тормышка ашыргансыз—Мөхәммәт пәйгамбәр галиәссәлам йөргән изге җирләрне, Мәккә белән Мәдинәне күреп, Кәгъбәдәге кара ташка орына алгансыз. Ә инде бу гамәлне ике мәртәбә башкару бик аз кешеләргә генә, чын-чынлап изгеләргә генә насыйп була, мин шундый кеше белән әңгәмәләшеп утыруым өчен бәхетлемен. Бирегә килешли сезнең мәчетегез янында тукталып тордым. Бик гүзәл мәчет—сез диндәшләрегезгә җирдә абруйлы эзегезне калдырасыз, безнең балаларыбызның балалары хәтта дистә-йөз еллардан соң да сезнең исемегезне хөрмәтләрләр. Хәзерге болганчык заманда мәчет салдыру—батырлык ул. Хәзер күпләр үз көнен, үз корсагын гына кайгырта, ә сез кешенең җаны-рухы турында борчыласыз. Мин сезгә сокланып баш иям...

Дулкынлана-дулкынлана шушы сүзләрен тезгәндә Сенатор сиздерми генә картны күзәтеп утырды. Исмат алдамаган икән: «сезнең мәчет», «сезнең исемегез» дигән сүзләр картның йөрәгенә май булып яттылар. Сенатор әңгәмә өчен кирәкле юнәлеш алган иде, Сабир-бобоның аны ни өчен Аксайга чакыртканлыгы бик тиз аңлашылды. Акыллы карт, күрәсең, кунагының бу ашыгыч чакыртудан борчылып утырганын, шулай да сиздермәскә тырышканын аңлады. Аның мәчет өчен бик әйбәт урын сайлау, мәчетнең архитектур матурлыклары турында сокланып сөйләгәннәрен тыңлап утырды да:

—Кадерле Сухроб-җан, сезнең белән шулай кырыс-каты кыланганым өчен гафу итегез инде, гаиләгез-балаларыгыз белән бергә булырга өч көн дә калдырмадым бит. Ләкин сезне сынап-тикшереп карауның башка юлын тапмадым,—диде.—Ә безнең бергә эшлисе эшебез көчле ихтыярлы, авыр хәлләрдә дә сынмас-сыгылмас кешеләрне таләп итә. Мин исә, гөнаһ шомлыгына каршы, сезне төрмә сындырмадымы икән, тәвәккәл эшләргә алынган өчен үкенеп, ваз кичмәдегезме икән, дип уйланган идем. Шуның өстенә Артурның банкын ачканда телевидение хезмәткәрләре белән әңгәмәгез дә тыйнак-сак булды. Әгәр сезне хәзер бик күп хөрмәтле кешеләр утыра торган «Матросская тишина» куркыткан булса, кайчандыр Аксайның ышанычлы кешесе булырга ризалык биргәнегез өчен үкенсәгез, чакыруым белән килеп җитмәссез, дип уйладым. Көрәшләргә әзер, яңа сынауларга әзер, хаталарын төзәтеп, дошманнары белән исәп-хисапны өзәргә әзер кеше генә Аксайга ашкынып килә ала, чөнки ул биредә һәрвакыттагыча ярдәм һәм теләктәшлек таба. Шуна күрә дә миңа сак-тыйнак кылануыгыз

аңлашыла—сез элекке урыныгызга утырырга телисез. Хакимият кагыйдәләре үзгәрмәде, без сезгә акча белән дә, кешеләр белән дә ярдәм итәрбез әле...

Картның чәйнеккә иелгәнен күргәч, кунак жинел сулап куйды, киеренкелеге кимеде. Сенатор үзен ничек кенә яхшы тотса да, ничек кенә батырайса да, Аксайга килү аны борчуга салган иде. Аннары, Миршаб исәпләгәнчә, хан Акмалның акчаларыннан башка хакимияткә омтылу мәгънәсезлек кенә булачак.

—Ләкин бу әле мин сезне Аксайга бер сәбәпсез чакырттым дигән сүз түгел,—дип, кунакка чираттагы чәйле пиаланы суза-суза, сүзен дәвам итте хужа.—Безнең эшләребез муеннан, кадерле Сухроб. Сезнең «дус» прокурорыгыз Камалов Акмалны кулга алганнан соң, авыр йөкне бер үземә тартырга туры килде, ә бу минем яшемдә жинел эш түгел. Иң мөһиме шул—мин акчаларымны саклап кала алдым. Акмал анда, төрмәдә финанс куәтебез беткәндер дип уйлыйдыр, ул бит акчаларның күпчелеге йөз-иллелек булып, яшерен урыннарда сакланганлыгын белә иде. Ләкин мин Павлов реформасын артык зур югалтуларсыз кичердем.. Минем карашымча, Павлов та Мәскәү демократлары күрсәтергә теләгәнчә юләр түгел...

Сенатор янә жинел сулап куйды, ул Аксайдагы казна гыйнвар реформасыннан соң нык зыян күргәндер дип уйлаган иде—Шәрекь кешеләренең акчаларга хирыслыгы билгеле бит.

—Акча бар, кадерле Сухроб жан,—дип дәвам итте Сабир-бобо сүзен, бераз тынлыктан соң.—Бүген төп бурыч—Акмалны төрмәдән йолып алу. Сизенәм, хәзер иң кулай вакыт: Мәскәүдә хакимият юк диярлек, анда эт—баш, сыер—аяк, һәрнәрсә сатыла-сатып алына, бик күп зур түрәләр Көнбатышка йөз тоталар, доллар өчен теләсә нәрсә эшләргә әзерләр... Ә бездә долларлар да житәрлек. Моны белеп торыгыз. Әйтергә кирәк, сезне шуның өчен чакырттым да, ашыгу мәслихәт булыр.

«Сони»ның йомшак зуммеры тавыш бирде, карт, урыныннан күтәрелеп, телефон өстәле янына килде.

—Әйе, әйе, адвокатны әбәттән соң чакырыгыз, поездга бередән бергә китәрләр, аларның сөйләшер сүзләре күп булыр дип уйлыйм...

Сенатор картның сүзләрен игътибар белән тыңлап торды.

—.... Менә шылтыраталар да,—хужа хәйләкәр генә елмаеп куйды.—Ә ашыгуның сәбәбе шул: иртәгә Мәскәүдән Акмалның адвокатлары килеп төшә, миндә тәртип шундый—акчаны алар Аксайга килеп алалар. Бу аларны тәртипле булырга өйрәтә, ә мин барлык эшләрдә дә хәбәрдар булам, мәсьәләләрне телефон аша хәл итәргә яратмыйм. Беләсезме, иске гадәт—һәр нәрсәне күзгә-күз карап эшләргә кирәк. Әмма мин юридик яктан әзерлексез, шуңа күрә ышанычлы булсын өчен бередәге акыллы адвокатларның тагын берсен яллады. Мин аңардан теләсә кайчан сорый алам, ул да мине алдап йөртә алмый, холкымны яхшы белә. Шулай итеп Мәскәү юристларын мин үз адвокатым белән кабул итәм, аннары бергәләп алдагы айга план төзибез. Безнең болай эшләвебез күпме уңышлыдыр, әйтә алмыйм, әмма бер планыбыз уңышлы чыкты...—Карт кинәт кенә сөйләвеннән туктап, янә хәйләкәр елмайды.—Сез һич тә уйлап таба алмас идегез, безнең ул план, Сухроб, сезне азат итү планы иде.—Кунагының гажәпләнүен күргәч, хужа сүзен дәвам итте.—Әйе, әйе, сезне азат итү, Ходай Тәгаләгә шөкер, бу фикергә мине ул китерде. Адвокатларның сөйләүләреннән Союз прокуратурасы Акмал эшен судка тапшыру өчен аерып алганы ачыклангач, мин суд трибунасын сезне аклау өчен булса да файдаланырга кирәк дигән фикергә килдем. Аксай хужасы сезне булган-булмаган әллә нинди гөнаһларда гаепли, Мәскәү койрыгы дип атый, бу хәзер оттырышсыз алым. Ә нотыкны, өтеренә кадәр тикшереп, әлбәттә, адвокатлар язды, сез алар белән берсекөнгә Ташкентта очрашырсыз.

—Рәхмәт, Сабир-бобо, мина ярдәм биредән килер дип һич уйламаган идем,—хисләнгән Сенатор кулын күкрәгенә куйды.—Рәхмәт!

—Без бер эшкә хезмәт итәбез,—диде карт, тыныч кына дисбесен саный-саный.—Сез Акмалны азат итү эшенә ныклап тотынырга тиешсез. Сез юрист. Әбәттән соң бирегә Нәманганнан безнең адвокат килер, ул сезне эш белән таныштырыр, поездга төшкәнче сөйләшеп бетерә алмассыз дип уйладым да, ул сезне Ташкентка хәтле озата барыр дигән фикергә килдем. Юлда бар мәсьәләләрне дә сөйләшеп бетерерсез дип исәплим, берсекөнгә Мәскәү адвокатлары белән очрашканда барлык мәгълүматлар сезнең карамакта булыр, аннары яна мәгълүматлар алырсыз. Нәтиҗәсе тиз булу кирәк. Бүген сезгә, теге чактагы кебек үк, бер чемодан сумнар һәм күп кенә долларлар бирерләр. Без ул долларларны күптән, бер ун еллар элек сатып алган идек. Минемчә, Акмалны азат итү өчен алар бик кирәк булачак. Соңгысы: адвокатларны алда торган бурыч белән ныклап таныштырып, аларны озаткач, бер атнадан сезгә дә Мәскәүгә барырга туры килер, мөгаен. Кирәк булса, үз адвокатларыгызны да бу эшкә тартыгыз, сәләтле егетләр булып чыктылар. Ашыгырга кирәк! Сизеп торам, Россиядә яна революция, анардан да яман гражданнар сугышы өлгереп килә, һәр икесе дә диңгез-диңгез каннар түгелү белән яный. «Реформалар» белән хәерчелеккә житкерелгән халыкның ачуы яман булыр, суд-фәлән дип тормаслар, «Матросская тишина»дагы тоткыннарны атып үтереп бетерерләр, ә безнең Акмалны беренче чиратта инде...

Ярар, житеп торыр, кадерле Сухроб җан, ялыктырырга теләмим. Әйдәгез, бергәләп мәчетнең эчен карап чыгыйк. Әйбәт осталар эшли анда, күңелләрен салып эшлиләр... Ә соңыннан ашап алырбыз, пешекчеләребез сезнең нинди ризыклар ашаганыгызны хәтерләп калганнар,—карт үзенең яшел чалмасына үрелде...

Мәчеттә алар ике сәгатьтән артык йөрделәр, кунак бу мәчетнең тирә-якта нинди йогынтыга ия буласын аңлады, димәк, хан Акмалның хакимлеге дә күп мәртәбәләр көчәячәк. Сухроб Әхмәтович берничә тапкыр прокурор Камалов турында сүз катарга тырышып карады, әмма һич кенә дә җае чыкмый торды. Башына көтелмәгән уй килде: прокурор турында сөйләп торасы да юк, хан Акмалны азат итү прокуратура өчен гел кирәксез эш, моны Аксайда беләләр, Ариповны «мәскәүле» шәхсән үзе кулга алган иде бит. Димәк, үзенең кан дошманы Камаловны бәреп төшерсә, бу әле үзенә файда да була, янәсе, ул моны Акмал Ариповны коткару өчен эшли, Аксай акчалары хакын да чыгара.

«Вакытында теленне тыя белү дә яхшы»,—дип үзен мактап куйды Сенатор, бу эшен ул зур җиңү дип саный, аңа акчаны сорамаса да бирделәр ич.

Поездда хан Акмалның эшләре турында сөйләшеп утырганда Сенаторны бер уй бимазалап торды—бу юлы күпме акча тамыздылар икән, вәгъдә ителгән долларларны салырга онытмаганнармы икән? Адвокат алдында чемоданны ачып карарга кыймады ул. Шуңа күрә, өенә кайтып керүгә бүлмәсенә бикләнде, әмма чемоданны ачып өлгерә алмады, телефон шылтырады. Трубканы алгач, Канзафарның дулкынланган-каушаган тавышын ишетте.

—Ике көн инде сезне эзләп таба алмыйм,—диде Канзафар.—Японецның презентациясендә бик дәрәҗәле кунагын—америкалы кешене урлаганнар. Японец кешеләре, ул төндә бөтен Ташкентны айкап чыксалар да, кунакны таба алмаганнар. Аңа кем ярдәмгә килгәндер дип уйлыйсыз? Башыгызны ватмагыз, берничек тә белә алмаячаксыз. Минем шефым Камалов...

—Моны ничек аңларга?—дип тоныкъ тавыш белән сорады Сенатор. Ул акча тулы чемоданы белән долларлары турында да онытты.

—Үзем дә аңламыйм шул. Бу хәбәр сезгә житди уйланыр өчен...

*Дәвамы киләсе саннарда*



Хәмит
Латыйф

# ГАЛӘМИ ГАМЬ

## Ара

Бер-берсеннән калмый бу тормышта
Үлем белән яшәү арбасы;
Алар бик тә якын һәм ерак та,—
Гүя Җир белән Күк арасы.

* * *

Очар өчен гомер-хыялларда
Кирәк ак канатлы атлар да;
Илдә яшәүләре ничек икән,
Кайгыларың сеңгән ташларга.

* * *

Яшьлектәге атлар чабып китте,
Гомер үтте әллә ниләр күреп;
Күңелләргә сеңгән вакытларның
Хәтер йөри алтын җебен сүтеп.

## Төнге аваз

Арыган җан йокы халәтендә,—
Күңелләргә керә исәрлек.
Төнге үзәннәрдән, шомландырып,
Кош кычкырды—җанны кисәрлек.

## Өмет кузы

Иртәгә дә Кояш чыгар, көннәр туар,
Тормыш тагын мәшәкатен алга куяр;
Вакыт узар, гомер сызар, хыял тузар—
Тик җанымда пыскып янар өмет-кузлар.

---

Хәмит ЛАТЫЙФ (1949)—*рәссам, шагыйрь; «Җыр һәм Күк», «Галәми гамь» исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Туймазы шәһәрендә (Башкортостан) яши.*

***

Тылсымлы моң гүя чыңлый кебек,
Язмыш безне тагын сыный кебек;
Балачагым, үткәннәрдән кайтып,
Тәрәзәмне кагып елый кебек.

## Хәтер-өй

Якты язлар, яшел җәйләр килә,
Ялкынланып җанга өмет иңә;
Кырыс чынлык, әкияти хыял
Тирбәләләр гүя Хәтер-өйдә.

## Ат саклаганда

*(Малай чак хатирәсе)*

Учак яна сүнәр-сүнмәс,
Тирәли шәүлә бии;
Таң җиле әкият сөйли;
Күңелләргә шом үрли,
Уйларда учак көйри.

***

Урманнар да язмыш кебек кара,
Барасы юл чытырманлык аша;
Борма-борма кереп киткән юлдан
Елый-елый өметләрем кача.

## Борынгы җыр

Тыңлап туймас борынгы җыр ишеттем мин,
Күңелемә иңде көлтә-көлтә моңнар.
Яшьле күзләремне сөртә-сөртә
Болыт булып агылдылар еллар.

***

Арыганда, сусаганда төштә
Мин күкләргә ятып су эчәмен;
Җанны яралаган кара үчтә
Күрдем явызлыкның үрчегәнен,—
Якын дус дигәнем
Кыстый-кыстый агу эчергәнен.

## Иске көй

Тыңладым мин, хәтта еладым мин,
Нинди моң ул, диеп, татарда,—
«Карурман»ның уртасында калам,
Үткәннәргә борылып кайтам да.

## Сер бирмәү

Күз чәчрәп, башлар әйләнсә дә,
Егылсам да җиргә ис китеп—
Әрнешләрне ташка әйләндереп
Томырдым мин,
Кысыр елларыма үч итеп.

***

Уйлар таша, уйлар баштан аша,
Мин барамын яман заман аша;
Югаламын йә өстендә, йә астында—
Яши кебек барсы миннән башка.

## Яратылу

Ходай тудырган безне уйлы итеп,
Без шулай калачакбыз... ахирәткә китеп;
Кемгә урын табылыр күкләрдә, кемгә табылмас.—
Күк капусы кемгә ачылыр, кемгә ачылмас.

## Бурыч

Миһербансыз кара көннәрдә дә
Иманыңны саклап каласы;
Җан туңса да, чәчләр агарса да,
Хак эш өчен әле янасы.

## Ярату

Искә төшеп иркәлидер күңелләрне
Хисләремнең галәмнәргә түгелгәне;
Бу ярату—сәгадәткә күмелгәне,
Бер Ходамнан бары миңа бирелгәне.

## Кавышмаган теләк

Зәңгәр яулыгыңның читләреннән
Яктылыкмы әллә саркып кала.
Кавышалмый калган теләгебез
Гомер буе шәфәкъ кебек яна.

Бәхет ишеге
Зөләйхасымы әллә син дөньяның,
Сине күреп, күгенә мендем оҗмахның;
Мендем дә бит... ишекләре келәдә
Син яшәгән фәрештәле почмакның.

## Көнләшү

Чәчкәсе ачылган гөл кебек,
Төн җиткәч, йөрәкләр ачылыр;
Шулардай көнләпме, йолдызлар
Күкләрдән җирләргә атылыр.

## 30 август киче

Офыкларда яна кызыл шәфәкъ—
Үткәннәрнең төсеме ул әллә?
Күз алдына килде дөрләп янган Казан,
Тетрәп киттем, күккә карап шушы мәлдә.

***

Уралам саташкан уйларга,
Ташланам адашкан суларга,
Капланам тау-ташлы юлларга,—
Әйтерсең тәкъдирем шуларда.

## Күргәннәр

Башкаеңны кайда куярсың бит,
Терәкләрен табып куярлык;
Уйлар уйлап акыл җуярлык бит,
Күргәннәрне ташка уярлык.

## Икенчене уйлау

Вакыт уза, гамьсез генә көннәр уза,—
Онытылган бер җан кебек йөзәм уйда.
Аңламыйча мәгънәсен бу дөньяның
Торам басып, башка дөнья күз алдымда.

## Өмет

Хыялында эзләп, кеше бара
Мәңгелеккә, киләчәгенә;
Вакытлыча гына булган бу тормыштан
Ышанмый ул китәчәгенә.

***

Хисләрдә—Идел җиле,
Иманым—күңел йөзе,
Алдымда—дөнья күзе,
Аңымда—Ходай сүзе.

Әрнегән күңел күзе,
Түзелгән еллар йөзе.
Җанымнан үткән инде
Өзелгән өмет көзе.

Ак җилкән



# Йолдыз Миңнуллина

*Йолдыз Миңнуллина—Казан кызы, университет студенты. Шигырьләре көндәлек матбугатта басылып килә. Аларга дөньяны, бүгенге яшәешне рәссамнарча сурәтләү, философларча аңларга тырышу, кызыклы фикерләүләр һәм үзенчәлекле ритмнар хас.*

## ШӘҺӘР ЧАГАННАРЫ

***

**Синең тәрәзәләр күккә карый.**
**Иркә сабый булып**
**ярым үпкә белән—**
**күккә...**
**Шыгыр-шыгыр**
**кыргый шәһәр чаганнарын,**
**шул чаганда көздән калган таган барын**
**син белмисең.**
**Таган тактасына гыйнвар кары**
**хәбәр ташый**
**синең хакта,**
**тәрәзәңә сеңгән бармак эзең**
**октавалар буйлап**
**каттан катка**
**ашыга-оча...**

**Оча бирсен әйдә.**
**Исем китми генә**
**тәрәзәләр саныйм**
**астан өскә—**
**дүрткә кадәр...**

* * *

*Күкнең күкрәгенә хәнҗәр кадап,*
*Җиргә кояш кояр чагым.*
Л. Гыйбадуллина

**Аклы-каралы биюләр.**
**Бүген шәһәр—**
**сыннар иле,**
**сыңар чиләк белән**
**Черек күлдән**
**бирәү**
**(Зөһрә күрә микән?)**
**айга менеп килә.**

Арыганбыз бугай:
«туйга кадәр төзәтергә» теләп,
иләк-күңелләргә кар ятты.
Каты чәйдән бизелгәнме шунда,
тәрәзәләр—Малевич квадраты.
Күкнең күкрәгенә хәнҗәр кадап,
Зөһрә,
кояш агызганчы, аз гына
тын аласы иде, онтыласы иде.
Тик,
бу йөрәк,
исәр,
әллә нинди нәрсә—
тагын кага, тагын азына:
—Сана! Сана! Бер ешлыкта сана!..

...Яз ешлыгы
шәһәр джазында.

## Реквием

*Фирдәвес Хәйруллинага*

Безнең яшәү—
яуган ак кар,
мизгел-мизгел
чакма ташы.
Җиргә сеңгән сулыш тәме,
һава тәме—җилгә каршы.
Җаным-тәнем эреп агар:
яуган ак кар...

Безнең яшәү—
тозлы яңгыр,
шашып шыткан
чыклы чирәм.
Күккә сеңгән күзләр төсе
язмыш эзен бизәп үрә.
Кичләремнең чыңлы чагы—
язгы яңгыр.

Безнең яшәү
дулкын-дулкын:
ява, эри, ага, кибә.
Ялгыз калган яфрак кебек,
җилне телеп, йөрәк тибә,
бер яшьнәтер диеп холкым—
язгы дулкын.

Берни дә юк: төссез һава,
бер үк бозлар эреп ява,
бер үк көнне урый кояш—
бар да мираж.
Берни дә юк, берни дә юк:
безнең яшәү—атылган ук.
Ике дөнья—җир белән күк—
безнең күзләр.

* * *

Азмы
хисләремнең
төзек пәрәвезен
яңгыр кылларыннан
сүтеп үрдең? Түздем.
Тәрәзәләр бүген инде кирәк түгел—
күңел почмагымда
күзләреңнең күге,
күккә каршы—яшен ташы:
сулык-сулык,
чатнар булып.

Җирне күккә теккән җепләр—
синең күңел,
минем күңел—
яңгыр түгел.

Аз-маз
хисләремнең
иләс өрфиясе—
күңел-киергедә
метафора-рәсем...

# «КАЗАН УТЛАРЫ»—2007

## *Чәчмә әсәрләр*

Журналыбызның алдагы саннары укучыларыбызны ниләр белән сөендерәчәк соң?

Күренекле язучыбыз **Фәнис Яруллинның** «Кыйбласызлар» повесте белән яңа елны башлап җибәрәчәкбез.

Тыгыз вә мавыктыргыч, заманча сюжетка корылган бу әсәр дөнья малына кызыгып, азгынлыкка бирелеп кыйбласын югалтучылар хакында.

Соңгы елларда тугры укучыларын тапкан үзенчәлекле прозаик **Рәмзия Габделхакованың** «Нишләттегез Гөлкәйне?!» повестенда үзәкләрне өзәрлек язмышлар бәян ителә.

Актив авторларыбызның берсе—**Фирүзә Җамалетдинова**—«Догалы корт» дигән бик үзенчәлекле повесть белән катнаша.

Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең иҗаты белән таныштыруны алга таба да дәвам итәрбез. Үзбәкстанда яшәп иҗат иткән **Җәүдәт Ильясов** (1929) укучыларга «Согдиана», «Ук һәм Кояш», «Тимгелле үлем», «Алтын бүкән», «Анахита үче» кебек китаплары аша таныш иде. Алдагы саннарның берсендә басылачак «Елан әфсенләүче» романының журнал вариантында шаех, галим, фәйләсуф, шагыйрь **Гомәр Хәйямның** дәверләр кичкән авыр язмышы, уңышлары һәм маҗаралары тасвирлана.

Уфада яшәүче **Гөлнур Якупованың** «Күпер» повесте героеның яшьлек елларында киң катлам укучылар кызыксынырлык серләр бар.

Танылган язучы **Мәдинә Маликова** актуаль проблемаларны мавыктыргыч сюжетка корып бәян итә белә. Бу юлысы да аның «Тылсым» повесте әнә шул характерда.

Татар совет әдәбиятында тарихи проза жанрына нигез салучы олуг язучыбыз **Нурихан Фәттахның** үзе исән чакта дөньяга чыга алмыйча калган «Аклан» романының бер өзеген журналга әзерлибез. Автор аны кырык ел буе язган... Борыңгы Аклан (Аклантида) дигән зур цивилизациядә төрки халыклар гына яшәгән, андагы легендалар, йолалар һәм вакыйгалар бүгенге татар дөньясына аваздаш дигән гипотеза матур әдәбият үрнәге булып тагын бер кат ачыла.

1812 ел. Мәүлетдин гусар французларга каршы сугышканда, авыр яраланып, әсирлеккә төшә. Татар егетенең батырлыгына сокланган Наполеон Бонапарт аны азат итәргә боера...

Егетнең маҗараларын **Зәки Зәйнуллинның** «Мәүлет гусар» исемле тарихи повестеннан укып белерсез.

Болардан тыш, журнал портфелендә дистәләгән язучыларның төрле жанрдагы әсәрләре бар.

Бүгенге укучының калын-калын китаплар укырлык вакыты, ихтыяҗы бармы, роман-трилогияләрне күтәп алырга телиме ул? Озын-озагай итеп язу максатмы, әллә кыскалыктамы осталык?! «Казан утлары»нда басылган кайбер романнарга «журнал варианты» дигән искәрмә куелган икән—моңа инде заман таләбе итеп карарга кирәк. Һәрхәлдә, алга таба да тыгыз күләмле, җыйнак оригиналь әсәрләр өстәлдә чират көтеп ятмаячак, укучы хөкеменә тизрәк барып җитәчәк...

Кыскалык димәктән, «Яңа дәвер кешесе» девизы белән ачылган яңа хикәяләр конкурсы кызганнан кыза бара. Һәм кызларыбыз, һәм ир авторларыбыз бәйгегә бик актив кушылды. Хикәяләрнең күплеге сөендерә. Вакытның чикләнүенә карамыйча, без аларны йомгаклау игълан ителгәннән соң да тәкъдим итеп барырбыз. Языгыз, катнашыгыз, ярышыгыз!..

Рафаэль
Хәким

# ТАТАР РУХЫ

*Совет чорында татар мәктәпләре, татар гәзитләре ябылды, татарча өйдә генә яисә үз ишләрең арасында гына сөйләшергә мөмкин иде. Зыялылар вакыт-вакыт әдәби кичәләргә җыелалар иде, бу кичәләр һәрчак Габдулла Тукайның "Туган тел"ен җырлау белән тәмамлана иде. Бөтен зал, тоталитар системага каршылык белдереп, аягүрә басып, татар гимнына әверелгән "Туган теле"н суза иде.*

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.*

*Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,*
*Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.*

*И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең*
*Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.*

*И туган тел! Синдә булган иң элек кылган догам,*
*Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!*

## Тел

Төрки-татар цивилизациясе гасырлар төпкелендә, Азия төпкелләрендә барлыкка килә. Төрки сөйләмнәрдә аралашучы халыкларны төрлечә атыйлар, әмма аларның уртак теле әллә кайчан, һуннар державасы барлыкка килгәнче үк оешкан. Сергей Кляшторный болай дип яза: "Төрки телле кабиләләр нигездә Үзәк һәм Эчке Монголиядә таралып яшиләр: Байкалдан алып Ордоска кадәр. Тел дифференциациясе процесслары бик катлаулы бара һәм бөтен өлкәләрдә дә бертөрле булмый; төрки һәм монгол кабиләләре күп кенә территорияләрдә катнаш яшиләр; безнең эрага кадәрге II гасыр башына хәтле иран телле юэчжилар күбрәк яшәгән Көнбатыш һәм Үзәк Монголиядә төркиләр шулар белән ут күрше булалар".[102] Тел мең еллардан соң да мәдәният алмашын гаҗәеп рәвештә саклап калучы бәйләгеч буын ул.

Беренче карашка һуннар, борынгы төркиләр, кыпчаклар, татар-монголларның күчмә тормыш белән яшәве, бары тик терлекчелек белән шөгыльләнүе ап-ачык кебек. Әмма әгәр төрки телнең үзәгенә күз салсаң, төркиләрнең баштан ук игенче дә, һөнәрче дә, сәүдәгәр дә булганнарын аңлыйсың.[103] Татарларда борын-борыннан үткәрелеп килгән Сабан туе һәркемгә мәгълүм. Россиядә ул иң популяр бәйрәмнәрнең берсе санала. Бу бәйрәм бик борынгы һәм Исламга кадәр үк

[102] С.Г.Кляшторный, Т.И.Султанов. Государства и народы Евразийских степей. Древность и средневековье. – Спб, 2004, с.54.

[103] Карагыз: Садри Максуди Арсал. Тюркская история и право. – Казань, 2002, сс.34-41.

*Дәвамы. Башы журналыбызның 7-10 саннарында.*

булган. "Сабан" – игенчелек коралы, борынгы төркиләрдә ул "сапан" рәвешендә яшәгән – "сапмак" - өзү, ерту дигән сүздән. "Бодай", "арпа", "тары" сүзләре кебек саф төрки сүзләр барлык төрки сөйләмнәрдә дә бар. Димәк, төркиләрнең бабалары игенчеләр дә булган. "Арык" сүзе дә гомер-гомергә төрки сүз. Димәк ки, төркиләрдә борын заманнарда ук игенчелектә сугару булган. "Ат", "сыер", "угыз" яки "буга" (үгез) шулай ук чыгышы белән төркиләрнеке. "Алтын", "көмеш", "бакыр", "тимер" сүзләре дә барлык төрки-татар сөйләмнәре өчен уртак,башкача әйткәндә, төркиләр элек заманнардан ук - тел калыплашкан дәвердә үк металл кулланганнар һәм һөнәрчеләр булганнар.

Алар формалашкан чакларында ук, мөгаен, игенчелек белән күчмәлекне бергә алып барганнардыр һәм соңыннан гына аның кайбер кабиләләре саф күчмәләргә әверелгәндер. "Күчмәлек, - дип яза Лев Гумилев, - өч мең еллап хөкем сөргән дөньякүләм күренеш. Ул кешенең үзгәрүчән табигать тирәлегенә яраклашу ысулы буларак барлыкка килгән һәм шул ук сәбәпләр аркасында хәзер безнең күз алдыбызда юкка чыга".[104] Тарихның климатның глобаль үзгәрешләренә бәйле билгеле бер чорында (тәгәлрәге – безнең эрага кадәр I меңьеллыкта) кайбер кабиләләр күчмә яки ярымкүчмә тормышны сайлыйлар, әмма телләрендә борынгырак катламнар да сакланып кала. Төрки сөйләмнәрдә йорт һәрвакыт, юртадан аермалы буларак, даими торак урынын белдергән. "Чатыр" – вакытлы торак урыны, аны күчмә төркиләр үзләренең җәйләү урыннарында корганнар. Йорт – утрак төркиләрнең даими яшәү урыны. Йорт тирәли урнашкан корылмаларны борынгы төркиләр "bark" сүзе белән белдергәннәр.[105] "Барак" сүзе рус телендә әлегә кадәр сакланып калган.

Гәрчә Ислам кабул иткәннән соң телдә гарәп сүзләре, ислам нормалары өстенлек итсә дә, иң югары әхлакый кыйммәтләр дә—төркиләрнеке. Башкача әйткәндә, төркиләр алга киткән халык буларак бик борынгы заманнарда оешканнар. Садри Максуди язганча, "төрки телнең гомуми байлыгы төркиләрнең инде тарихкача заманнарда ук мәдәният үсешендә шактый югары дәрәҗәгә ирешүен күрсәтә. Мәгънәви тамырларның байлыгы җәһәтеннән караганда төрки тел - дөньядагы иң бай телләрнең берсе".[106]

Борынгы төрки цивилизациянең югары кимәлдә булуына тагын бер дәлил бар: төркиләр VI йөзнең икенче яртысында үз алфавитларын уйлап чыгаралар, соңыннан ул рун алфавиты дип атала. Дж. Клосон исәпләвенчә, надан төркиләр язма тамгалар системасын үзләре уйлап табарлык хәлдә булмыйлар, алар хәтта согди алфавитын төрки телгә яраклаштыра да алмаслар иде. Моны аларга, имеш, борынгы төрки телне әйбәт белгән культуралы согдилар эшләп биргәннәр.[107] Олжас Сөләйманов исә мондый хәлнең булуы мөмкин түгел ди. "Борынгы төркиләр алфавитның кайбер хәрефләрен күчерсәләр дә, - дип яза ул, - аларны согдилардан түгел, ә бәлки хәрефләре йомры булмаган, линиячел, почмакчыл булган әлифбадан күчергәннәр. Мондыйлар исә безнең эрага кадәр I меңьеллыктагы Алгы Азиядә (финикий һәм арамей язуы) һәм Борынгы Скандинавиядә (рун язуы – безнең эрага кадәр I меңьеллыкның уртасыннан алып безнең эраның I меңьеллыгы азагына кадәр кергән булуы мөмкин дип фаразлана). Әмма төркиләр язуны беренче мәртәбә шушы халыкларның берәрсеннән белгәннәр дип расларга ярамый..."[108] Иң дөресе, мөгаен, борынгы төркиләр, согди алфавитын нигездән үзгәртеп, аларның язу үрнәкләрен үзләренә яраклаштырганнардыр: а)кайбер тамгаларның курсив язылышы аерып язуга алмаштырылган; б) төркиләрдәге ыру тамгаларының һәм идеографик символларның рәвеше йогынтысында, шулай ук, мөгаен, фактура (таш, агач, металл) йогынтысында согди хәрефләренең шома, йомры язылышы геометрияләштерелгән язылышка алмаштырылгандыр; в) согди һәм төрки телләрнең фонетика системасы төрле булганга күрә, согди алфавитының барлык

[104] Л.Н.Гумилев. Ритмы Евразии, с. 512.

[105] Садри Максуди Арсал. Тюркская история и право..., с. 37.

[106] Садри Максуди Арсал. Тюркская история и право..., с. 40.

[107] Карагыз: Олжас Сулейменов. Тюрки в доистории. О происхождении древнетюркских языков и письменностей. –Алматы, 2002, с. 125.

[108] Олжас Сулейменов. Тюрки в доистории..., с. 90.

тамгалары да кабул ителмәгән, охшаш сөгди хәрефләренең фонетик символикасы гына алынган; шуның белән бергә рун алфавиты сөгди язмасында булмаган яңа тамгалар белән баетылган, өлешчә алар - идеографик, өлешчә - хәреф рәвешендә".[109] Шулай итеп, төрки рун язуы бөтенләй яңа оригиналь язмага әверелгән. Ташлардагы, кәгазьләрдәге һәм кыялардагы язулар бу язуны белүчеләрнең шактый күп булуын күрсәтә. Рун язуы дини, эшлекле, хәрби өлкәләрдә, һәм әдәби төстәге язмалар өчен дә кулланылган.

Рун алфавиты белән язылган әдәби ядкярләр барлык төрки халыклар өчен дә уртак. "Рун язмалары теле VII – X гасырларда үз телләрендә һәм диалектларында сөйләшүче төрле төрки кабиләләр – угызлар, уйгырлар, кыргызлар, кимәкләр һәм башкалар файдаланган бердәм һәм стандарт әдәби тел булган, - дип яза Сергей Кляшторный. – Рун язмаларының уртак язма әдәби теле стилистик бердәйлеккә һәм тасвирлау чараларының тотрыклыгына ия, бу аеруча орхон ядкярләрендә күренә. Ядкярләрнең теле һәм әдәби кануны уртак булу борынгы төрки кабиләләр арасында үзара тыгыз бәйләнешләр булуын раслый һәм аларны икенче бер халыкның тел һәм әдәби мирасы дип, тоташ бертөрле этнос булуны күрсәтми, билгеле. Әмма VII гасырда ук инде төркиләр төрле кабиләләргә аңлаешлы бердәм язма телгә ия булганнар. Бу аларның күтәрелү факторларыннан берсе булган.

Орхон ядкярләреннән күренгәнчә, төрки тел йөз ел эчендә бик аз үзгәреш кичергән. Олжас Сөләйманов бу күренешне "төрки сүзнең, төрки телнең феноменаль консерватизмы"[111] дип атый. Төрки сөйләмнәрнең тотрыклыгы һәм якынлыгы аларның алга киткән тел буларак борынгы заманнарда ук оешуы нәтиҗәсе. Трубецкой, төрки телләрнең охшашлыгын аңлатып, болай дип яза: "Һәр телдә, аның тарихы дәвамында шушы тел кичергән һәм телнең үз тарихи үсешенә бәйле механик үзгәрешләр нәтиҗәсендә котылгысыз рәвештә «ялгышлар» һәм «искәрмәләр» барлыкка килә: тел үсешенең теләсә кайсы борынгырак стадиясе өр-яңа стадия белән чагыштырганда "дөресрәк". Әмма төрки телләрдә җанлы сөйләмнең аң төпкелендәге схематик законнарга буйсыну рухы шулкадәр көчле ки, бу рух тарихи процессларның җимергеч йогынтысын бөтенләй диярлек нейтральләштерә; шуңа күрә дә төрки телләрнең хәзерге грамматикалары "искәрмәләрне" белмиләр (яисә белмиләр диярлек), һәм шуңа күрә дә хәзерге төрки телләр шулкадәр бер-берсенә охшаган".[112]

Төркиләр бер үк вакытта ике чирдән интеккәннәр: беренчесе – мәмләкәтчелек (державачылык) сәясәте, үзәкләштерелгән зур империяләр коруга омтылыш булса, икенчесе - кабиләләр арасындагы таркаулык. Төрле чорларда төрлесе өстенлек ала. Шул җирлектә төрки телнең диалектлары һәм сөйләмнәре барлыкка килә. Бу төркиләрнең генә үзенчәлеге дияргә ярамый, билгеле. Бөтен кешелек дөньясы шул юлдан бара. Кемнәрдер империяләр төзи, ә икенче берәүләр аларны җимерә. Бу объектив процесс булганга күрә, җирле мәдәниятләр гомумтөрки мәдәният үсешенә көч-куәт өстәгәнне аңлап, аның белән килешергә генә кирәк, әмма локаль үзенчәлекләрне абсолютлаштыру һәм төрки телләр арасында диварлар кору да хата булыр иде. Британия милләте бар, шул ук вакытта америкалылар да, австралиялеләр дә, яңа зеландиялеләр дә бар. Болар, бәхәссез ки, төрле милләтләр, әмма алар барысы да инглиз телендә сөйләшәләр, бер үк мәдәниятне якын итәләр, ни генә булса да, сөйләмдәге, әдәбияттагы, җирле гореф-гадәтләрдәге аерымлыклар аларга комачауламый, киресенчә, инглиз-саксон цивилизациясен бөтен дөнья мәдәниятендә өстен итеп, баета гына. Әгәр инглизләр һәм америкалылар уртак мәдәният ареалын татарлар белән башкортлар кебек бүлгәли башласалар, инглиз теле бөтендөнья теленә әверелмәс иде.

Тагын да гаҗәбрәк мисал—немец телендә сөйләшүче халыклар. Австрия-

[109] С. Г. Кляшторный. История Центральной Азии и памятники рунического письма. – Санкт-Петербург, 2003, с. 38.

[111] Олжас Сулейменов. Тюрки в доистории..., с. 109.

[112] Н.С.Трубецкой. О туранском элементе в русской культуре. В кн.: Россия между Европой и Азией: Евразийский соблазн. – М., 1993, с. 70.

ләр, баварлар, саксоннар, швабләр, швейцариялеләр h. б. бер-берсеннән шулкадәр аерылып торган диалектларда сөйләшәләр ки, без аларны һичшиксез аерым телләр дип санар идек – татар һәм төрек телләре бер-берсенә күп өлеш якынрак, казакъ, кыргыз, уйгыр телләрен әйтәсе дә юк инде, аларны аңлар өчен татарга тылмач кирәкми. Шуңа да карамастан, баварлар һәм саксоннар, австралиялеләр һәм швейцариялеләр бер үк әдәби телдә язалар. Әгәр үзләренең уртак мәдәни киңлекләреннән баш тартсалар һәм голландлар сыман үз диалектлары нигезендә мөстәкыйль тел булдырсалар, алар глобальләшү чорында зәгыйфьләнеп калырлар иде.

Кырым кенәзе Исмәгыйль Гаспралы үзенең дус-ишләре ярдәмендә XIX гасыр башында беренче татар газетасы "Тәрҗеман" ны чыгарырга рөхсәт ала. Ул үзе уртак төрки тел эшли һәм аның газетасын төрки дөньяның төрле почмакларында яшәүче зыялылар укый. Әмма газета белән бергә тел үзе дә гаип була. Аннан соң бик күп татар газеталары чыга, әмма шуларның берсе дә "төрки" телдә түгел. Кайвакыт матбугат теле гади халыкка аңлашылмый, әмма ул гомумтөрки түгел, татарча була. Гаспралының эксперименты уңышсыз булып чыга.

Гомумәдәби немец теле Лютер тәрҗемә иткән Тәүрат (Библия) нигезендә барлыкка килә. Нәкъ менә шулай ук Коръәндәге гарәп теле дә Гарәп ярымутравының, Төньяк Африкадагы һәм Азиянең төрледән төрле кабиләләре өчен гомумәдәби телгә әверелә. Әгәр заманында Коръәннең төрки-татар теленә тәрҗемәсе булса, ул да, бәлки, шундый ук вазыйфаны үтәгән булыр иде. Әмма ләкин болай булып чыкмаган шул. Муса Бигиев Коръәннең татарчага тәрҗемәсен бастырып чыгарырга тырышып караган, тик, язмыштыр инде, Госман империясенең мөфтие генә түгел, хәтта татар имамнары да моңа каршы чыкканнар. Россия хакимияте бу мәсьәләдә руханиларны бик теләп яклаган. Ислам реформациясе Идел буе һәм Кырым татарларына гына кагылган, аның да барлык катламнарына түгел, шуңа күрә дә Лютер тәҗрибәсен кабатлау мөмкин булмаган.

Бүген ясалма төрки тел оештырып маташуның мәгънәсе юк, шул ук вакытта бер генә төрки диалект та, бер генә төрки сөйләм дә (төрек телен дә кертеп) өстенлек алмаган. Һәр ил, һәр халык үз үсеш юлын сайлаган.

Глобальләшү чорының өстенлекләре булган кебек, милли мәдәниятләргә зыяны да бар. Глобальләшүне нәтиҗәләре буенча Европа реформациясе чоры белән чагыштырырга мөмкин, ул чакта яңа эрага нигез салучы басма китап дөнья күргән. Әмма бүген шуңа охшаш вазыйфаны басма китап түгел, Интернет башкара, гәрчә төркиләр әле элеккегесенең дә азагына барып җитмәсәләр дә, яңа бер Реформация чоры киләчәк әле.

Кеше виртуаль дөньяда торган саен күбрәк яши бирә, ул аның чын тормышына гаять зур йогынты ясый. Киоскка газета алырга барасы юк, ул Интернетка тизрәк килеп җитә, әйберләрне электрон почта аша сатып алырга мөмкин; теләсә нинди китапханәдән куәтлерәк зур-зур мәгълүмат системалары барлыкка килде, алар ярдәмендә укырга гына түгел, күрергә дә, ишетергә дә мөмкин, хәтта башка юллар белән ирешү мөмкин дә булмаган нәрсәләрне дә. Виртуаль музейга кереп, аның залларын, рәсемнәрен, экспонатларын карап була, үзеңә ошаганнарын кәгазьгә бастырып алырга да мөмкин. Якындагы елларда компьютер телевизор да, видеотелефон да, университет та, эш урыны да булачак. Иң алдынгы фирмалар виртуаль коллективлар булдырачак. Һәм бу экзотика түгел, бу – гомуми ихтыяҗ, һәм ул инде ишегебезне шакып тора.

Глобальләшүнең татарлар өчен дә үз өстенлекләре бар. Россия һәм БДБ илләре буйлап чәчелеп яшәгән халыкны гадәти коммуникация чаралары ярдәмендә бергә җыю бик кыен. Интернет һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары моны чагыштырмача очсыз һәм нәтиҗәле башкарырга ярдәм итә. Бу безне коткарачак. Нәкъ менә глобальләшү татар халкын саклап калачак. Интернет аша татар мәдәнияте, кайда яшәвенә карамастан, һәркем өчен ачык булачак. Татарлар аз чыгымнар тотып, чикләрсез, административ киртәләрсез мәгълүматлашу чарасына ия булдылар.

Глобальләшүнең куркыныч якларын күрмәскә тырышу да дөрес булмас иде. Галимнәр фикеренчә, йөз елдан соң өч тел: инглиз, испан һәм кытай телләре өстенлек итәчәк. Калган телләр функциональ яктан локаль булып калачак. Мөгаен, күп кенә телләр, иң гади, иң уңай дип санап, латин графикасына күчәр.

Глобальләшү милли мәдәниятләр аермасын бетерә, аларга инглиз-саксон рәвешләрен көчләп тага. Глобальләшү, кешене иллюзияләр дөньясына җәлеп итеп, субкультураның сәнгать җитештерүенә әверелде. Бар да бер үк нәрсәләр укый, бар да бер үк әйбер тыңлый, бар да бер үк вакыйгалар турында гәпләшә, бертөрле уйлыйлар, джинсы киеп йөриләр, чипсы ашыйлар. Глобальләшү өчен кулланучыларның гомоген массасы бар. Әмма дөнья – супермаркет түгел. Глобальләшүгә каршы җавап йөзеннән этник, дини, төбәк үзенчәлекләре үсешкә омтыла. Дәүләтләргә трансмилли корпорацияләр һәм халыкара оешмалар кулы белән астан да, өстән дә басым ясала, шул ук вакытта трансмилли актерлар демократиядән читтә калалар, аларны сайламыйлар, әмма нәкъ менә алар халыкара һәм милли сәясәтне билгели. Милли дәүләт яңа тенденцияләр басымыннан көчсезләнә бара. Хезмәт күрсәтүләр һәм товарлар либеральләшкән базарга чыктылар һәм мәдәният үсешенә дәүләт ярдәме кимегәннән-кими бара. Дәүләтләр һәм халыклар, үз үзенчәлекләрен коткарырга омтылып, массакүләм ассимиляциядән саклану юлларын эзлиләр.

Инглиз-саксон тарту көченнән гайре дөньяда тагын берсе барлыкка килде, ул да булса - шундый ук ассимиляциячел тарту кыры – Кытай. Көньяк-Көнчыгыш Азия аның көч-кодрәтен үзендә җитәрлек дәрәҗәдә татыды инде. Зур әчке потенциал туплаган әлеге гаять борынгы культураның теләсә нинди халыкны һәм теләсә нинди илне демографик ассимиляцияләргә хәленнән килә. Хәтта Һиндстанда да 150 миллион мөселман конфессиональ азчылык дип санала. Ә Кытай өчен бу - статистик төгәлсезлек кенә. Уйгырларны да кытайлар йотарга мөмкин.

Гарәп дөньясына яисә гарәп мәдәниятенә нигезләнгән мөселман дөньясы да үсеш потенциалын җуйды. Ул – бары тик нефть запасларының зур резервуары гына. Аның фонында чит телле дөнья хәрәкәтчәнрәк күренә, чөнки католицизм контрреформация барышында яңарыш кичерде. Аның географиясе Кытай экспансиясенә каршы торыр өчен уңайлы, ә Төньяк Америка экспансиясе ике яклы кылыч булып чыкты. Латин Америкасы халкы АКШка тулды һәм испан теле чынлыкта илнең көньягында яки Калифорниядә генә түгел, Вашингтон һәм Нью-Йорк кебек зур шәһәрләрдә дә икенче дәүләт теленә әйләнде.

Бу җирлектә панславянлык һәм пантюркизм балалар уенчыгы сыман гына. Панславян идеологиясе – бөтенләй буш нәрсә. Европаның бер өлеше булган католик поляклар гомер-гомергә русларның көндәшләре булдылар. Чехлар һәм словаклар, алай ук актив булмаса да, шул ук миссияне башкардылар. Серблар һәм болгарлар, русларның гомерлек аркадашлары, Германиянең көчле йогынтысын тоеп яшиләр. Германия көнчыгыш җирләрен үзенә яраклаштыргannан соң славян дөньясыннан булган күршеләренә керешәчәк, күршеләре исә словеннар, хорватлар, чехлар, словаклар артыннан бай, тотрыклы һәм техника ягыннан алга киткән дөньяга рәхәтләнеп барып керәчәкләр. Озакламый Украинаның да чираты җитәр.

Пантюркизм исә Россиянең көчсез һәм интеллектуаль яктан ярлы чиновниклары кулында карачкы булып кала бирә. Төркиләрнең үзләре өчен бу интеллектуалларның тар даирәсендә сөйләшү темасы гына булып кала, халык аны аңламый да, белми дә һәм белергә тели микән әле. Славян дөньясы да, төрки дөнья да бөтендөнья глобальләшүен каршыларга әзер түгел.

*Дәвамы киләсе санда*

Тәлгат
Галиуллин

# "БӘРЕЛДЕ ҖАН, СУГЫЛДЫ ҖАН ЯРСЫП..."

(СИБГАТ ХӘКИМ—ШАГЫЙРЬ ҺӘМ ШӘХЕС)

Үзе исән чакта—авыр соры пәлтәсен җыйнак гәүдәсенә салып арабызда йөргәндә һәм китаплары, кайнар табадан төшкән коймаклардай Казанда, Мәскәүдә басылганда һәм ул каләмдәшләренә, бигрәк тә яшь шагыйрьләргә карата җылы сүзен ирештерә торган елларда—С. Хәким иҗаты турында тәнкыйди мәкаләләр, фәнни язмалар чыга, диссертацияләр яклана торды. Аерым алганда Х. Хәйри, Н. Юзиев, Р. Мостафин, Н. Хисамов, З. Рәмиев һ. б. шагыйрьнең хис, кичерешкә өстенлек бирүен, слүбенен халык җырларына хас булуына җыйнаклыгын, садәлеген искәртеп яздылар.



Равил Фәйзуллин бу эзләнүләргә нәтиҗә ясагандай болай ди: "Сибгат Хәким—телдә күп тибрәнгән, язуга күп төшкән исем. Сугыштан соңгы утыз-утыз биш ел эчендә аның иҗатын гел унай яктан бәяләгән дистәләрчә мәкаләләр басылды. Без бу хәлгә—унай бәяләүгә—күнектек тә шикелле инде."

Үзем дә Сибгат ага дөрләткән шигъри учак янында кулымны җылыткалаган, мәдхияви чыгышларымны шактый бастырганмын икән... Әйе әйтелгән, язылган сүзләр дөрес кебек: С. Хәким чыннан да Тукай шигъри мәктәбенең талантлы дәвамчысы, туган як, изге нигез һәм гаделлек җырчысы, халыкчан рухлы самими лирик, замана сулышын чагылдырган эпик колачлы шагыйрь...

Әмма шагыйрь вафатыннан соң (1986) С. Хәким мирасына карата серле, сәер тынлык урнашты. Газета-журналларда мәкаләләр күренми башлады. Сәбәбе нәрсәдә? Плюрализм, фикер төрлелеге чорында шагыйрьнең дәһри Ленинны, аның татар халкы язмышында тоткан урынын күпертеп, хәтта идеаллаштырып сурәтләгән әсәрләре карашны катлауландырдымы, әллә зур иҗатка дөрес бәя бирү өчен ераккарак китеп карау ихтыяҗы үзен сиздерәме? XX гасыр шигъриятендә тирән эз калдырган, заманында әдәби пәйгамбәр дәрәҗәсендә йөргән Сибгат Хәким мирасының асылын, юнәлешен, күңел түрен, ритмик фасылларда сакланган йөрәк тибешләрен ачып бирә һәм аңлата алдыкмы? "Исән чакта бер алдыма, бер артыма төшеп йөргән, изгелек кылган адәми затлар да мине оныттылар", дип шагыйрь рухы безгә рәнҗеп ятмыймы?

Әлбәттә, шагыйрьнең залим Ленинга багышланган, Татарстанның "горурлык хисе" уяткан әсәрләрен, шул дәвер режимын хуплаган язмаларын күрмәмешкә салышып, биредә аның бормалы елга кебек катлаулы иҗатын "турайтып", Тукайга, Ватан сугышына багышланган поэмалары, күңел лирикасы, назлы җырлары турында гына сүз алып бару җиңелрәк булыр иде. Әмма олы шагыйрь иҗаты бербөтен икәнлекне онытмыйча, аның мирасын янача бәяләү ихтыяҗы көн тәртибенә куелуын да истән чыгарырга ярамый. Шагыйрьнең туган аенда (декабрь, 1911 ел) Сибгат аганы шагыйрь һәм шәхес буларак сагыну хисләребез дә әнә шундый эзләнүләр юлына этәрә.

Язучыны үзе яшәгән чордан, мохиттән, әдәби чолганыштан аерып карау берьяклылыкка алып килә. С. Хәким үз шигъри күгенең гөмбәзенә күтәрелгән

чорда—ягъни үткән гасырның 60-80 нче елларында—иҗтимагый-әхлакый тормыш ничаклы ясалма, тынчу, соцреализм басымы көчле булмасын, татар поэзиясе кодрәтле, бәрәкәтле үсеш чорын кичерә. Ерак түгел ул чорны искә төшереп, маякларны барлап үтик. Илленче еллар ахырында С. Хәкимне остазлары итеп таныган, Тукайга да еш кына аның аша килгән Ш. Галиев, Г. Афзал, Х. Камалов, Ә. Баян, И. Юзеевләр буыны поэзия ишеген шакый. Бу төркем аякка басып, беренче-икенче шигырь китапларын укучыга ирештергән мәлдә шигъри мәйданда С. Сөләйманова, Ф. Гыйззәтуллина, Г. Зәйнашева, М. Шабаев, Роберт Әхмәтҗанов кебек исемнәр пәйда була. Күбесе С. Хәкимнең монсу күзләреннән ингән җылы карашын тоеп, каләменнән төшкән ихлас сүзен ишетеп аякка баса. Элгәреләренең үкчәләренә басып килгән Рәшит Әхмәтҗанов, Ф. Сафин, К. Сибгатуллин, З. Насыйбуллин, Ә. Гаделләр кайнар хисләрен әйтергә омтылулары, шигъри сүзгә сизгерлекләре, милләт киләчәге турында ачынып уйланулары белән С. Хәким рухына якын иделәр. Әлеге буын янына "кызу канлы", шау-шулы, эзләнүчән Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Гаташ, Г. Рәхим, Р. Мингалимнәр килеп өстәлде. Иҗат юлларын йолаларны кире кагудан, түр башында урын даулаудан башлаган бу шагыйрьләрне "Бары бер җыр", "Һәр талант үзенчә килсен" кебек мәкаләләре белән "традицион шагыйрь" С. Хәким хуплап чыга. Алардан соң шигърият үсешендә тукталыш туар дип фаразлаган С. Хәким, ялгышуына сөенеп, очына-очына, иҗатка килгән яшь каләмдәшләрен хуплап чыга. "Юк, поэзиядә пауза күренми. Чылбыр буыннарының өзелмәве әйбәт. Бу үзенчәлекле зур төркемгә хәзер Зөлфәт Маликов, Мөдәррис Әгъләмов кебек тагын да яшьрәк иптәшләр килеп кушылды." Бу юллар—Сибгат аганың 1972 елда язылган "Моң барында шигырь бетми" исемле мәкаләсеннән. Алдагы елларда шигъриятькә Х. Әюпов, Э. Шәрифуллина, Р. Вәлиев, Р. Миннуллин, Ә. Мәхмүдов, Б. Рәхимова, Л. Шагыйрьҗан кебек шагыйрьләр аһәңе-моңы килеп кушыла. Биредә аталган һәм әле исемнәре телгә алынмаган бик күпләр остазларының хуплавын ишетеп калалар. Чөнки С. Хәким үзен, Х. Туфан шикелле үк, татар шигърияте үсеше өчен халык, җәмгыять һәм вакыт алдында җаваплы саный, һәр яна әсәрне, язма-басма сүзне җиз иләк—тәнкыйть күзлеге аша—уздырып барырга тырыша. Үз чиратларында татар шагыйрьләре С. Хәкимне мөгаллимнәре санап, аның иҗатына, шәхесенә тирән ихтирам белән карыйлар, ул "ерак" дөньяга күчкәч, аның намена сагыну, үкенү хисләре тулы шигырь юлларын багышлыйлар.

*Һәр чатта шигырь сүгәләр,*
*Мин аларга ни әйтим...*
*Шигырь, димәк үксез калган*
*Хәкимсез калган ятим,*

- дип яза Г. Морат "Ни әйтим" парчасында.

С. Хәким поэзиясе турында фикер йөртү XX гасыр татар шигъриятенең ярты гасыр (1938-1986) дәвамындагы үсеш юлы, аның ил, халык тормышы, милләт язмышы белән яшәве, рухи дөньяга, шәхес табигатенә якынаю юллары һәм югалтулар белән янәшә булса да, эстетик камиллеккә ирешүе хакында сөйләшү дигән сүз. Йөзләрчә шигырь-җыр, дистәләгән поэма-баллада авторы С. Хәким иҗатының чишмә башы шул чор әсәрләре арасында кыя кебек күтәрелеп торган, Тукайга багышланган "Пар ат" поэмасына, яшь шагыйрь каләменнән төшкән лирик аһәңле шигырьләргә барып тоташа. С. Хәким соңгы көннәренәчә "Тукай дәфтәреннән" исемле шигырьләр гөләндәмен тулыландыру, камилләштерү рухы белән яши. Әлбәттә, озын-озак иҗат дәверендә шагыйрь үсә, аның поэзиясенең "холкы", эчке аһәңе үзгәрә, төрләнә, теле, сурәтле фикерләү алымнары чарлана, әмма "Юксыну", "Яратам мин", "Зөбәрҗәт-алтыннарын" кебек тәүге шигырьләрендә үк бөреләнгән индивидуальлеге, "сибгатлеге" саклана.

XX гасыр башының бөек рус шагыйре А. Блок болай дип яза: "Шагыйрь дөньясы аның кабул итү үзенчәлегендә чагыла". Димәк ки, һәр олы шагыйрьнең индивидуальлеге аның тирәлекне, кеше рухын аңлау һәм сурәтләү сыйфатына бәйле, шуннан үсеп чыга. Сүз һәр олы шагыйрь иҗатына хас бихисап төрле кайтавазлар, уртак мәгънәви төсмерләр турында бара.

Татар шигърияте дип аталган олы дәрьяда С.Хәкимнең үз шигъри дөньясы бар. Поэзиясенең үзәгендә шагыйрьнең дөньяны аңлавы, тормыш юлы, шәхес буларак житлегүе, үзе инанган дөреслек, хакыйкать эзләве ята. Аның киеренке әхлакый, рухи уйланулары укучыны 30 нчы еллар атмосферасына, дәһшәтле сугыш елларына алып килә. Аннары илне аякка бастыру, ялган шигарьләргә ышану, идолларга табыну һәм торгынлык елларында милләт, тел язмышы, мәңгелек проблемалар турында уйланулар...

*

Илленче еллар урталарында С. Хәким абруйлы һәм талантлы шагыйрь, "тәртәгә типми" торган тыйнак, тыңлаучан шәхес буларак фирка житәкчеләренең игътибар үзәгенә эләгә. Язучыларның халыкка тәэсиреннән үз мәнфәгатьләрендә файдалануга маһир КПСС өлкә комитеты житәкчеләре Х. Туфан, М. Әмир, Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, К. Нәжми кебек олы сүз осталарына ясалма игътибар күрсәтә белделәр. С. Хәким белән уйнау да шуның ачык мисалы. Аны әүвәл шәһәр советы, аннан Югары Совет депутаты, партиянең өлкә комитеты пленумы әгъзасы "ясаулар" (1955-1967) шуның бер дәлиле.

С. Хәким үзе дә Ленин һәм Татарстан темасын нәкъ шул чорда ижатының төп юнәлеше буларак үстерә (Ильич образына ул 1938 елда ук "Кышкы салкын иде..." шигырендә килә), бу хакта зур бер бәйләм ижат итә: "Күңелем Ленин белән сөйләшә" (1957), "Ленин фәрманы белән" (1958), "Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты" (1961), "Баһавиның моңы" (1963), "Язгыгыз, жир уллары" (1963). Димәк, аның бу төр әсәрләре йомшак һәм ихлас күңелле, Сибгат абыйдан "салон шагыйре", обком "иркәсе" ясау чорында язылалар. Шул елларда ул дәртләнеп, илһамланып, нефть чыгару романтикасын жырлаган "Үрләр аша..." поэмасын яза. Татарстан жиреннән ургылып чыккан кара алтынның "Дуслык" торбасы буйлап чит илгә агуын хуплый, сугышта үлгән янар Ярулласын авыр хезмәт вахтасына алыштырган Халидәне хуплый. "Дәверләр капкасы" поэмасында КамАЗ төзүне бөек жиңү итеп сурәтли (исеме генә дә ни тора!).

Шул рәвешле, С. Хәким шигъриятендә бер-берсеннән шактый аерылып торган, фәнни тәфсилләүне сораган ике юнәлеш, ике катлам (ижтимагый-сәяси таләпләр тегермәненә су койган һәм күңел лирикасы, Тукай рухын үзәккә алган әсәрләр) янәшә яши.

Ижатта "автор аңы бердәмлеге булу шарт" дигән таләп бар әдәбият белемендә. С. Хәким шигъриятендә бу үтәләме икән? Әш шулай тора: шагыйрь идеология йогынтысына бирелеп, Ленин, Мулланур кебек объективлашкан образлар тудырганда, читтән ингән караш колы кебегрәк күзаллана, образ автор арасында якынлык кими. Бу төр әсәрләрендә автор үз шәхси хисләрен тукымага индерергә тырышса да, ул сурәтләү объекты түгел, теләк-өметне, ният-ышанычны реаль чынбарлык итеп күрергә тырышкан утопик зат буларак алга килеп баса.

Үзе яхшы белгән, күңел нурын салган Тукай, Жәлил, Ибраһим Йосфи, авылдашы Сәләхи ("Сары капкалы йорт"), Ибәт ("Ибәт"), Хәйрулла ("Хәйрулла") кебек образларны ижат иткәндә исә, автор аңы бердәмлеге саклану нәтижәсендә, тәэсирле, самими алымнар, рух гармониясе лирик герой белән автор арасындагы чикне "эретә". Шулай да С. Хәким мирасын бербөтен итеп күз алдына китерергә мөмкинлек биргән берничә үзенчәлекне исәпкә алырга кирәктер. Әйткәнебезчә, "...егерменче гасырның иң явыз бәндәсе Ленин"ны (А. Гыйләжев) изгеләштереп ижат иткән әсәрләрендә дә С. Хәким үзәккә татар халкының асыл сыйфатларын үзенә туплаган, моңга, назлы хискә ихтыяж сизгән Хисами, Баһави, Рәхимә, туры Сафа кебек шәхесләрне күтәрә, татар кешесе мәнфәгатьләре турында онытмый. Ижатының халыкчанлыгы, шигъри сүзгә, ритм һәм рифмага таләпчәнлеге С. Хәкимне конъюктур әсәрләр авторы дәрәжәсенә төшерми. Икенчедән, милләтенең, туган теленең ачы язмышын тирәнтен аңлаган нечкә хисле, нәзберек тоемлы С. Хәкимдә "Батмаска туган Баттал" (Р. Фәйзуллин) кыюлыгы, тәвәккәллеге булмаса да, ул Советлар илендәге бәхетле тормыш турында В. Лебедев-Кумач, Ә. Ерикәй,

Г. Латыйп, М. Хөсәен кебек ялтыравык шигырь-җырлар сырлау юлына басмый. "Халыклар атасы" (укы: палачы) Джугашвилига, башка түрәләргә багышлап та шигырь язмады кебек.

Шунысы да игътибарга лаек: Ленин белән бәйле темага өстән төшерелгән кинәш буенча мөрәҗәгать итмәгәнлеген исбатларга теләгәндәй, шагыйрь хакимият белән татулыгы кимегәч тә, кызыгырлык үҗәтлек белән, каты агачны тишәргә алынган тукран кебек, иҗатының соңгы чорында да, 1917 ел инкыйлабы узаманын исенә төшерә. Вафатына берничә ел калгач, 80 нче еллар башында "Туган як җилләренең мин...", "Мин читтә шагыйрь булалмам" кебек нечкә лирик хисле, ихласлылык үрнәге булырдай шигырьләре янәшәсендә, "Кокушкинодагы фонарьлар" әсәрен бастыра. Бирелә шундый сорауның куелуы табигый: гади татар авылында туып-үскән, утны-суны кичкән, югары белемле, милләте өчен җан атып йөргән шагыйрь С. Хәким Ленинның буйсынган милләтләргә нисбәтән урыс патшалары алып барган империячел сәясәтен, республика төзегәндә татар халкы күпләп яшәгән төбәкләрне башка өлкәләрдә калдыруын аңламадымы, большевиклар юлбашчысының татарларга күрсәткән "ярдәменә" ихластан ышандымы яисә ул чор таләбенә яраклаштымы?

"Республикам минем, Татарстан, Син тугансың—безгә сан булган", дип язганда, Сибгат ага фирка байларын, хәллерәк каләм ияләрен генә күздә тотмагандыр дип уйлыйсы килә. Туктаусыз сәяхәт кылып, укучылары, (күбрәк авыл кешеләре, яшьләр) белән очрашып, аралашып яшәгән шагыйрь "өлкән" милләт кешеләре генә түгел, үзебезнең манкорт түрәләр дә "Татария" дип мыскыллап йөргән өлкәнең ни дәрәҗәдә ирекле, нефть сатудан килгән акчаларның күпмесе гади татар кешесенең кесәсен "ертып" керүен, игенченең матди хәлен сизми, күрми калмагандыр... Әлбәттә, шагыйрь үз халкына изгелек, мул, азат тормыш тели, Ленин идеяләренең шуны тормышка ашырасына сабыйлар ихласлылыгы белән ышана. "Халык белән Ленин остазым" формуласына "Мин Ленинча татар булып яшим,—Бар язмышым белән татармын", дигән ачыкламыш кертә ул "Республикам турындагы декрет..." шигырендә. Димәк, С. Хәким ниятнең гамәлгә ашуын күрергә теләп, романтик пафоска, медитатив халәткә керә, өстән индерелгән концепциягә ышануы да үзен сиздерә.

"Индустриаль" мәүзугка багышланган, эшче темасына "сәлам кыстырган" поэмаларында ("Үрләр аша...", "Дәверләр капкасы"), система сәясәтен хуплаган беришле шигырьләрендә ул "кара алтын" табучыларны, КамАЗ төзүчеләрне шәһәрткә күмеп, "элеккеге колонияләргә" ярдәм кулын сузган "бай" Татарстанны мактый да, "аңына килеп", лирикасында бу гамәлләрнең тискәре якларын, яшәешебезгә, табигатькә китергән зыяннарын күңел күзе белән күрә башлый. Безне бәхет юлына алып чыгарга тиешле яңалыкларны ул бер инләүдә кечкенә күренгән, әмма эффектлы детальдә "чеметеп" ала: "Нефтьле җирдә кыен шул авылның казларына". Юк, ул нефть чыгару начар, кирәкми дими. Мондый көфер нәтиҗәдән Аллам сакласын! Тик менә Татарстанның мал-туар, кош-корт, кешеләре яшәгән ямьле урыннары, көмеш сулы чишмә-инешләре пычрана икән шул... Бигрәк тә татар кешесе мәҗүсилек чорында ук табынган, чисталык, пакьлек символы, балачак исталеге булып җанга кереп калган казга да җайсыз икән шул... Казларга кыенлык килү—табигатьне рәнҗетү, болын-әрәмәлекләрне, чәчүлек кырларын пычрату халыкның табигый яшәешенә, тамырына балта чабу дигән сүз бит инде ул!

"Дәверләр капкасы"нда КамАЗ төзелешен татар тарихы белән бәйләп, яна катлам эшче сыйныфы тууны, мәһабәт биналарны ул мөкиббән киткәндәй сурәтли дә, яңалыкның гасырлар дәвамында калыплашкан тормышны җимерүен, әхлакый кануннарны бетерүен аңлап, күңел лирикасында укучыны сискәндерә, уйландыра. "Сүтеләчәк йорт...", "Кучәргә тиешле өйнең..." шигырьләрендә лирик герой олы төзелешнең әйләнә-тирәгә, бу төбәктә элек-электән яшәгән кешеләргә китергән җимерү, туздыру көчен күрсәтеп, ватылырга тиешле өй, йорт, киселәчәк йөз еллык тирәк образ-символлары аша күңелләргә шом, вәсвәсә сала. "Дәверләр капкасы"ндагы елмаюны, шатлыкны сагыш, мәңгелек нигезләргә селтәнү тудырган хәсрәт, югалту хисе алыштыра.

*Сутеләчәк йорт өстендә*
*Тын ай тора;*
*Айга тотынып,—*
*Зарын сөйләп*
*Тургай тора.*

Өйне ватарга, юкка чыгарырга килгән кранны шагыйрь чебеш дошманы—явыз тилгәнгә тиңли.

*Мин—сабый, жәлләп чебешне,*
*Кранга тамак кырам.*

Йөз яшьлек тирәк урынына "киеме-өсте юка" яшь юкәне күчереп утырталар. Лирик герой аның язмышы, киләчәге өчен борчыла. Урыныннан кузгалган, күчкән үсемлек (кеше дә) тамыры ныгый алмыйча интегәчәк иң.

*Китәрме? Белмим, ни әйтер*
*Туган җирнең туфрагы.*

"Яңа шәһәрдә яшь юкә..." шигырендә Туган туфрак образы яңа мәгънә төсмеренә байый.

Алтмышынчы еллар ахырында С. Хәким иҗатына эчке канәгатьсезлек, сагышлы аһәң, монсу борчылу, экзистенциаль үкенеч үтеп керә; бу—хыялларның тормышка ашмавын, татар теленең таралыш даирәсе елдан-ел тарая баруны аңлаудан туган драматик кичерешләр иде. Күңел газапларын эченә алган әлеге борылыш "Васыятьләр" (1969), "Кырыгынчы бүлмә" (1971) поэмаларында һәм бигрәк тә шул чор лирикасында ачык гәүдәләнеш таба. Җил, ай, биләү, рәшә, әкият кебек ачкыч сүзләрнең психологик код дәрәҗәсенә күтәрелүе—шагыйрьнең дөнья барышы, халык, милләт язмышы турында уйлануларын сөземтәсе. Дөньяның бездән калачагын, гомернең кыскалыгын аңлагач, уйлану фәлсәфәсе туа, төшенкелек рухың көчәя. Серен аңлау сират күперен чыгуга тиң булган "зәңгәр тартма" образының килеп керүе дә гыйбрәтле фал:

*Ачкычы юк зәңгәр тартма,*
*Астында чылтырый тиеннәр.*

Бу юлларны милләт киләчәге турында уйлану, үз байлыгына үзен хуҗа була алмау дип шәрехләргә дә мөмкин. Ясалма, тыштан ялтыравык, эчтән кылтыравык тормыш та шагыйрьне туйдыра бугай. Бер шигырен "Күңелем, минем, ачык сөйләш син...", дип атавы тикмәгә түгелдер.

Тар, кысан читлектән чыгып, бәйсезлеккә ирешкән, эш-гамәлләрен туган телләрендә алып барган халыкларга киң күңелле, бәйнәлмилəл С. Хәким ихтирам белән, хәтта көнләшеп тә карый. Фикер сөрешеннән, юл астында төсмерләнгән мәгънәдән азатлыкка омтылыш табигый ихтыяҗ икәнлекне сиздерә лирик зат.

*Азат халык...*
*Тауларына карыйм.*
*Күрә алмам килер җәйсез дип,*
*Кешеләрнең... хәтта тауларның*
*Йөзләренә чыккан бәйсезлек.*
("Тоям артта...").

Татар шагыйре дә чегән арбасыннан төшеп калган, Җир-Ватансыз, яклаучысыз кеше түгел. Дөнья халыклары алдында җебеп төшеп, абруен югалтасы килми аның. Таяныч ноктасы, горурлык чыганагы буларак мәгърур Идел елгасы алыну табигый. "Тоям артта бөек Идел барын, Тоям артта Ватан, чик барын", - ди шагыйрь,

"козырь тузын" чыгарып салып. Артында мул сулы олы елга торса да, Ходай бәндәсенә жан тынычлыгы, туганнарның аңлавы, дусларның жылы карашы... яшәү дигән төшенчәнең эчтәлеген тәшкил иткән башка биниһая күп нәрсә кирәк икән... Ә шулар арасында иң мөһиме ни соң? Шигыренең ахырында автор иң газиз төшенчәне калкытып куя.

*Саулык кирәк, сәламәтлек кирәк,*
*Барыннан да бигрәк азатлык!*

Жаны азатлыкка омтылып, туган халкына бәйсезлек даулап, шул ук вакытта билгеле бер кысада калу мәжбүрияте лирик затның бәгырен телгәли. Мул сулардан, куе урманлы тигезлекләрдән шифа, илһам алып үскән татар шигъриятендә олы тауларга ихтирам зур, алар еш кына азатлык, бәйсезлек символы мәгънәсен алалар. "Таулар биеклеген югалтмыйлар, алар күккә кадалганнар!" – дип яза Р. Фәйзуллин "Кайсын пигы" шигырендә. Ә Күк ул—Раббыбыз галәмнәр белән идарә итә торган бөек һәм серле, илаһи һәм мөкаддәс көч. "Тау һәм кеше биегәя бара бер-берләрен әгәр аңласа",—дип өстәп, шагыйрь күк олылыгын таулар аша кешегә индерү турында хыяллана.

С. Хәкимнең "Рәсүлнең артында таулар..." шигырендә дә "тау" азатлык, мөстәкыйльлек алып килүче көч дәрәжәсенә күтәрелә. Авар шагыйре Дагстанның биек тауларын, бормалы-сырмалы юлларын, халкына хас хикмәтләрне жырлап шөһрәт казанды, олы шигъри мәйданга чыкты.

*Рәсүлнең артында таулар,*
*Биек-биек таулар ич...*
*Таяныч кирәк язганда,*
*Кайда минем таяныч?*

Татар халкы яшәгән төбәкләрдә Чатыр тауы, Урал итәге булса да, алар Кавказ белән ярыша алмыйлар, бигрәк тә милләтебезнең холкын-фигылен, яшәү рәвешен билгеләүдә таулар хәлиткеч көч булырга дәгъва итә алмыйлар.

Соң безнең шагыйрь язарына азыкны каян таба? Мактанырлык, илһамын уятып жибәрерлек нәрсәсе бар соң аның? Туган жиренә гашыйк шагыйрь (башкача ул шагыйрь була да алмый) шунда нужа себеркесен сөйрәп яшәгән кешеләр игътибар итмәгән гап-гади күренештә матурлык чыганагы һәм "яклаучысын" күреп ала:

*Ул мине белми, мин – аны,*
*Тыны да юк, өне дә,*
*Ышаныч биреп шул әрем*
*Күз алдыма элнә.*

Көтелмәгән һәм гыйбрәтле янәшәлек. Биредә сүз остасы, рәсем киндерендәге төсле, түбәләре күккә ашкан таулар кырыена кечтеки генә әремне китереп куя. Бер карауда сәеррәк күренгән бу күршелектә ижатчының тормышны, гүзәллекне аңлау, сурәтле фикерләү үзенчәлеге, туган жиренә чиксез мәхәббәте, милли үзаны чагыла. С. Хәкимнең тауларга кызыгуын, көнләшүен Г. Афзал үзебезне кимсетү түгелме дип аңлап, безнең файдага "сөйләүче" үз дәлилләрен китерә.

*Гамзатов артында таулар...*
*Синең артыңда да тау бар,*
*Тау битеннән кул болгыйлар*
*Кол Гали һәм Мөхәммәдьяр.*
("Таулар". Сибгат Хәкимгә).

Алдагы юлларда Г.Афзал "Тургайлар сайраган күктә Утыз Имәни елмая", Габделжәббар сәламли, "Берүзе биек тау булып, Тукай тора кулын сузып", дип

татар шигъриятенең югары кимәлле, таудай биек булуын раслаучы мисалларын шигырь тәсбихенә тезеп китә. Әлбәттә, остазы белән алып барган бу бәхәстә поэзиябезнең чал тарихлы, шөһрәтле булуын аның алтын баганалары аша күрсәтүендә Г. Афзал хаклы. Ул—максималист, "кытыгын китергән" фикерен өздереп, биткә бәреп әйтә.

С. Хәкимне дә татар поэзиясе үрләрен танымауда, әйләнеп үтүдә гаепләве кыен. Гомере буенча, инде шагыйрь буларак танылып, дәреслек битләрендә урын алгач та, ул үзен бөек Тукайның гап-гади укучысы дип санады, остазының образын шигъриятгә калдыру рухы белән яшәде. Шагыйрьнең соңгы еллар лирикасында Тукай татар халкы хыялланган бәйсез, ирекле тормыш символына тәңгәлләштерелә.

*Килде Тукай, килде шагыйрь җырлап*
*Хөр тойгыны, азат тойгыны.*
*Тукай, Тукай—татар халкының ул*
*Бугазында газап төере...*
("Килде Тукай...").

С. Хәким халкына игелек теләп яшәсә дә, анарда Г. Афзал үҗәтлеге, усаллыгы юк, коммунистлар фиркасе әгъзасы булу ("Партиядә стажым өч дистә", 1972) аны һәрдаим "тәртипкә" чакырып, чабуыннан тартып тора. Әмма шул ук чорда җан әрнүен, бәгырь сыкравын, күңел ыңгырашуын чагылдырган "Бәрелде жан..." кебек—төн йөрәкләрне дә уятырлык шигырьләрен иҗат итә.

*Бәрелде җан, сугылды җан ярсып,*
*Читлеге тар, кысан, сыймады.*
*Нәрсә җитми, кая омтыла ул,*
*Кешеләргә аңлат син аны...,*

—дип язганда шагыйрь илдә хөкем сөргән тынчу торгынлыкка да киная ясагандай тоела. Тар читлекне өнәмәве, үз-үзеннән канәгать булмавы да сизелеп тора.

С. Хәким яшәгән, иҗат иткән сәвит чорында милләт, милләт язмышы, телнең киләчәге, таралыш даирәсе кебек сүз-төшенчәләр кулланылмый гына түгел, милләтче гыйбарәсе хакимият дошманының синонимы булып йөрде. Бу атама-мәгънәләрне шигырьдә куллану баш түбәндә Дамокл кылычын тотып торган кылны өзеп төшерү белән бер иде. С. Хәким фиркагә тугрылыгын искә төшереп, раслап торса да, ул үзенең тарих тарафыннан җәберләнгән, кимсетелгән, хәзер дә хокуклары киселгән халык баласы икәнен бер мизгелгә дә онытмый, чикләвекнең кабыгын төше белән бутамый.

*Бер тирәдә гел әйләнде гомер,*
*Бер тирәдә—шуңа бар моңым.*
*Тар-тар ди ул, үртәп искә төшерә*
*Сукмагымның минем тарлыгын.*
("Тартар").

Татар сүзен имгәтеп, "тар-тар, Тартария" дип, мәгънә бозып, халкының үткәненә, тарихына, бүгенге яшәешенә яла ягучыларны каһәрләп, рәнҗеп, "дөньяда тар булса да, кабатланмас сукмагың буйлап атлау насыйп булсын иде" дигән фикер уздыра шагыйрь.

С. Хәким каләме тудырган лирик каһарманның үз-үзен тотышында татар халкына хас тарихи сыйфат-билгеләр, менәз (характер) үзенчәлекләрен тану кыен түгел. Бер урында ул иркәләнеп, "мескенләнеп", үзен кечерәйтеп алса, шунда ук—заманында империя тоткан, мөстәкыйль дәүләте булган халык онытгы икәнлеге исенә төшүгә—горурлык, эрелек хисе башын калкыта. "Борынгы, иске Веймарда..." шигырендә үзен "Мин кечкенә тавышлы" татар баласы дип атаса, "Тау өстендә тора..."да исә, "Җимерелгән империяләр, чорлар Җилкәсендә басып ял иттем" — дип, масаеп куя.

Бу чор лирикасында вакыт агышын сиземләү кискенләшкән саен, гомуми инсани, күнелгә якын яшәеш рухын калкытып куйган әхлакый-фәлсәфи әсәрләре күбәя. Адәм баласы фани дөньяда нинди генә бай һәм күкрәге орденнар-медальләр белән тулы атаклы шәхес булып, дәртле тормыш алып бармасын—гомеренең соңгы баскычында ул барыбер рухи ялгызлыкка дучар, "өстен көчләрнең" ярдәменә мохтаҗ. Дөнья сүз сәнгатенә хас төшенкелек, сагыш, өметсезлек – чарасыз көчсезлек нәтиҗәсе. Җирдәге яшәешнең вакытлы икәнлеген аңлау тудырган "югалып калу" фәлсәфәсе С. Хәкимнең "Минем таныш өянкеләр", "Алмагач", "Тыкырык башында иске йорт" шигырьләрендә үзен сиздереп үтсә, "Арышның саргылт серкәсендә..." пессимистик хис үзәк мотив буларак калка: "Мин бу җирнең вакытлы кунагы... күк".

Рухи һәм физик халәтенең мактанырлык түгеллеген искәртү аша, лирик каһарман мәхәббәте ташып торган, саф хисле яшьлек еллары хатирәсенә кайта ("Кайда ул бергә ашкынган, бергә шаулаган көннәр?"). Шигъри юлларга талгын моңсулык йөгерә.

*Йөрәктән сагыш белән моң*
*Ярсып кан тама төсле,*
*Урманы калдырып киткән*
*Ялгыз карама төсле.*
("Карама").

Үлем һәм үлемсезлек кебек мәңгелек хакыйкатьләр турында уйлану С.Хәкимне җиһанны бар иткән, хәрәкәткә китергән иң бөек затка—Ходайга—ялвару, үзенне ахыр чиктә аның хозурына тапшыру котылгысызлыгы фикеренә алып килә. Мәңгелек һәм гомернең соңгы аккордлары турында уйланганда күкрәк кесәсен кымтырыклап торган партбилет, фирка алдында җавап тоту бурычы да онытыла. Раббыбызга мөрәҗәгать итүнең кемдер бәйләнмәслек сәбәбе дә табыла. Янәсе аның Арчада сабан туенда буласы килә һәм ул Алладан ялварып сорый. "Ходайдан мин үтенәм: кичектер", "Ходайдан мин сорыйм: алданрак яки соңрак, димен, ал җаным", "Ходайдан мин...". Лиризм, кешелекле моң, ихласлылык, сәнгатьчә камил аһәң бу шигырьне С. Хәким каләменнән төшкән бүтән шедеврлар белән бер рәткә куя.

"Ходайдан мин..." шигыреннән эчтәлегеннән күренгәнчә, С. Хәким катып калган атеист, марксизмга табынган агач коммунист булмаган, тормыш юлының ахыры кай тарафларда хәл ителәсен аңлап, догаларын укып яшәгән икән. Табигатьне, тереклекнең тажы—кешене—бар иткән Раббыбызга мөрәҗәгать, аерым шәхес гомеренең тарих өчен бер мизгел генә булуын аңлау әсәрләргә мәҗүси-медитатив һәм фаҗигаи төсмер бөрки. Гомер азагы турында уйлану, язмышның Ходай карамагында икәнен аңлау XX гасыр хәятенең астын өскә китергән явызларны оныттыра, шигырь юлларына табигый самимилек, эчкерсез нәзакәтлелек үтеп керә. Күнеленә иман рухы ингән лирик зат халык мәнфәгатьләре турында уйламый, кайгыртмый булдыра алмый.

*Кешегә әйләнә кеше,*
*Әйтерсең алышынган,*
*Яңадан туа күк кеше*
*Миллионнар язмышыннан.*
("Ветеран").

Күнелен биләгән ярсу, үкенечле, сагышлы хисләр өермәсен тәртипкә салуда, укучыга житкерүдә аның таянычы—туган табигать, яшәгән мохите, газиз якташлары, кыскасы, җанга якын төшенчәләр. Туып-үскән өйнең җылысы, йорт янында үскән юкәләр, балачакның сафлыгы, әнисенең назлы иркәләве—барысы бергә "яшәү мәгънәсе" дигән төшенчәнең эчтәлеген хасил итә. Кеше белән табигать арасындагы якынлык соң чиккә җиткерелә, шул ук вакытта табигатьтәге гармония каршылыклар бердәмлеген дә тудыра.

*Иске тегермән таллары*
*Таныр күк, абайлар күк;*
*Тегермән чираты көтеп*
*Утырган агайлар күк.*
("Иске тегермән таллары...").

Шагыйрьнең кеше язмышы белән табигать тормышы арасындагы якынлык турында уйлануларын эченә алган бу шигырьгә лирик аһән, ашыкмыйча, салмак кына сөйләшү артында сиземләнгән эчке яну, җыйнаклык, төгәллек, һәр сүзне ана гына тиеш булган урынына "утырта" белү хас.

*Сезгә эндәшми мин кемгә*
*Эндәшим, өянкеләр?*
*Җитте минем дә сезнең күк*
*Картайдым дияр көннәр.*
("Минем таныш өянкеләр").

Өянкеләрдән җавап көтмәсә дә (риторик эндәштән бу таләп ителми), шагыйрь табигать күрке өянкеләргә якын сердәш дип, дустанә мөрәҗәгать итә, рухи халәтен табигатькә ышанып тапшыра.

*

С. Хәкимнең шигъри палитрасында элгәреләрнең, остазларының сурәтләре, чордаш каләмдәшләренең образлар галереясы үзе бер юнәлеш тәшкил итә. Юк, аның бу төр әсәрләре соңгы елларда йогышлы һәм зарарлы күренешкә әверелгән туган көн, юбилей форсатыннан чыгып, заказ белән язылган гадәти багышлаулар, такмак-такмазалар түгел. Аларда шагыйрьнең зәвыгы, дөньяга карашы, рухияте, поэзиянең җәмгыятьтә тоткан урынын аңлау, бәяләү дәрәҗәсе чагыла. Җанына, сурәтле фикерләү үзенчәлегенә иң якын остазы Тукайның үзәктә торуы табигый. С. Хәким олы шигърияткә Тукай турындагы әсәрләре белән килеп кереп ("Пар ат", "Шагыйрьнең балачагы"), шул исемне кабатлап шигъри һәм тормыш юлын тәмамлады ("Кырыгынчы бүлмә", "Тукай дәфтәреннән"). Тукайдан кала аның өчен буй һәм колач җитмәслек биеклек—Туфан. "Туфанны мон баскан, пәрдә аша Кар өстенә төшкән моннары" дип, өлкән каләмдәшенең рухи халәтен әйтеп бирә дә, хис экспрессиясен романтик биеклеккә күтәреп, гомуми нәтиҗәсен ясый:

*Сөенәм: әле Пушкиннардан тыш,*
*Тукайлы бу дөнья, Туфанлы.*
("Төнге ике. Өстәл, кәгазь, кара").

С. Хәким кадерле каләмдәшенең иҗатына багышлап дистәгә якын мәкалә яза, "Туфан дәфтәреннән" шигъри юлламасын кайта-кайта, еллар дәвамында иҗат итә. Шигъри тәрәккыяткә гомерләрен багышлаган олы затлар С. Хәким өчен үлемсез, алар безнең арабызда, киңәшләре, илаһи рухлары белән барыр юлыбызны яктыртып торалар. Шартлылык алымы исә еллар бизмәнен алып ташлый:

*Чыкты да әйтте карт Гете:*
*Бераз гына көт, энем!*
("Борынгы, иске Веймарда...")
*Берлинда олы мәҗлеснең*
*Җәлил утыра түрендә.*
("Берлинда, Дуслык йортында").

Тәҗрибәсе үскән, тормыш барышын аңлау дәрәҗәсе тирәнәйгән саен С. Хәкимнең шигъри кумирлары сафы ишәя бара. Пушкин, Лермонтов, Некрасов, Гете янына XX гасыр башы символизм поэзиясенең бөек вәкиле А. Блок өстәлә.

Дөньяга карашы һәм поэтикасы катлаулы, каршылыклы булган идеалист шәхес иҗатының асылын татар шагыйре берничә юлга сыйдырган: "Тонык та, серле дә булып яшәде миндә Блок". Чыннан да, тормышында, иҗатында сәер, тылсымлы, "теге дөнья" могҗизасына тартылып, үзе хыялый, икенчел чынбарлык тудырган Блок большевикларның дәһшәтле, куркыныч гамәлләрендә шомлы, тынгысыз күнеленә якынлык таба. "Унике" поэмасында, 1917 ел инкыйлабына дини мәгънә салып, 12 апостолны Христос җитәкчелегендә, кызыл байрак күтәртеп һәм ач этне аларга тагып ("позади голодный пес"), урамга "чыгара". С. Хәким күзаллавында: Блок апостоллары Ватан сугышы чорында гаделлекне яклап, "фронтта еракта калыктылар". Ә инде сугыш тәмамланып, җир шарында тынычлык урнашкач "...бөтен җиһанны Берүзе тота Блок". Бу шартлы образ Блок поэзиясенең бөеклегенә ишарә генә түгел, ул бүгенге катлаулы, буталчык яшәешебезне дә күз алдында тота сыман. Үз каләмдәшләренә бәясендә исә С. Хәким кырыс, усал, чөнки мәҗлесләрдә дуслар күп булса да, "Киңәшергә дисәң—Кутуйлар юк, Таянырга Фатих, Мусалар", - ди шагыйрь "Мәҗлесләрдә шагыйрьләр..." әсәрендә.

Төрле чор шагыйрьләре эзләнүләренә, бигрәк тә татар поэзиясенең тотрыклы ачышларына таянып, С. Хәким шигырьнең композициясен, сурәтләү чараларын төрләндерү, баету юнәлешендә туктаусыз эзләнә, үзен пластик ритмика остасы итеп таныта. Ул шәргый фигыльләрне, шәкли мөмкинлекләрне, онытыла барган сүзләрне әйләнешкә кертеп, шигырь калыбының яңадан-яңа мөмкинлекләрен ача. Әйтик, башлангыч чор иҗатында дүрт юлдан торган 10-9 иҗекле строфага, нигездә тартык авазга тәмамланган кафиягә (рифма) өстенлек бирсә, иҗади алгарыш барышында ритмик рәсемне баету, төрләндерү хәстәрен күрә. Сугыш чоры лирикасында диалог, мөрәҗәгать, риторик эндәш алымнарыннан мул файдалана ("Тор, иптәш, тор, дим йокыннан", "Һава сугышы"). "Туган җир" әсәрендә нигезйортка самими мәхәббәтен чагылдыруны 8-5 ле йөгерек ритмик сурәткә ышанып тапшыруны кулай күрсә, популяр җыр булып киткән, хатын-кыз исеме атамага чыгарылган (кеше исемен әйтеп шигырь язу—аның яраткан алымы) "Һаҗирә"дә төп фикерен исемне кабатлау, сорау-эндәш аша кичерешне эзлекле ачуга ирешә. Мондый йөгерек өслүб шигырьне җанландыра, монсу хисне җиңеп, шатлыкны гомуми интонация дәрәҗәсенә күтәрергә мөмкинлек бирә.

*Син бәхетле иттең безне,*
*Һаҗирә!*
*Һаҗирә!*
*Үтә үз гомерең синең*
*Кай җирдә,*
*Кай җирдә?*

"Өзелгәнсең сиреньнән" дә ритмик рәсем тагын да катлауланa. Чәчәк образын төрле сүтезмәләрдә кояш нурларыдай уйнату аша ул кичереш үсешен эзлекле, дәвамлы күренеш итеп сурәтләүгә ирешә.

*Яши миндә*
*синең тавыш,*
*синең сагыш,*
*синең сүз.*
*Мөмкин түгел:*
*ничек таныш,*
*ничек кавыш*
*сиреньсез.*

"Мин шагыйрьне алып кайтам..." исемле әсәре Ә. Фәйзинең гәүдәсен Мәскәүдән Казанга алып кайту унае белән язылган. Үкенеч, сагыш, югалтуның олылыгы һәм Ә. Фәйзинең эзләнүчән, экспериментатор шагыйрь булуы табигый рәвештә 10-6 иҗекле шигырь юлларын сорый.

*Мин шагыйрьне алып кайтам безнең*
*Мәскәү поездында.*
*Бик кыска кебек юлым минем,*
*Гүя бик озын да.*

Соңгы чор иҗатында С. Хәким шигырь техникасын катлауландыру турында баш ватмыйча, афористик төгәллеккә ирешү, фикерне мөмкин чаклы ачыграк, җетерәк итеп кыска мәйданга сыйдыру юлларын эзли.

Шул рәвешле, С. Хәким лирикасында халыкка, милли нигезләргә якынлык әһәмиятсез күренгән детальләрдә, ритмик төрлелектә, тел берәмлекләренә игътибарлылыкта күренә. Аны башка бер шагыйрь белән дә алыштырып яисә бутап булмый. Ул күнеле белән үзгәрешләр булырга тиешлекне сиземләп яшәсә дә, "үзгәртеп кору" дигән чорны күрә алмады. Әмма ул кешене Алласыз, динсез иткән җәмгыять шартларында да—СССР дип аталган, үсешендә катып калган, аз санлы милләтләрне акула кебек йота барган илдә дә—халык, тел язмышына нисбәтән үз карашларын киная, табигать символлары аша булса да сиздереп, "болай булырга тиеш түгел" дигән иманда яшәде һәм иҗат итте.

С. Хәким XX гасыр татар шигърияте үсешендә тирән эз калдырган талантлы, кеше кичерешләрен ачунын тирән серләренә үтеп кергән, тел тылсымын сиземләп иҗат иткән олы сүз осталарыбызнын берсе иде. Катлаулы, каршылыклы чоңгыллар очраса да, С. Хәким флюгер кебек җил уңаена борылмады, кыйбласын үзгәртмәде, туган халкына, газиз милләтенә ихластан хезмәт итте. Сибгат ага белән азмы-күпме аралашкан, холкын, дөнья барышына мөнәсәбәтен күзаллаган кеше буларак, шуны раслый алам: ул ярарга тырышып, ясалма елмаюны (татар хәйләкәрлеге исәпкә керми) белмәде, ихласлылык, теләсә нинди шартларда үзе булып калу—аның ихтирам уятучы сыйфатларыннан иде.

Сибгат ага үзе исән чакта ук анын турында агай-эне арасында шактый мәзәк йөрде. Алар шагыйрьнең үз-үзен тотышына, сөйләү манерасына, сәләтсез бәгъзеләрнең Язучылар берлегенә үрмәләвенә нисбәтән тормыштан алынган йөремсәкләр иде. Әмма С. Хәкимне рәнҗеткәннәрен, анын тормышына, яшәү рәвешенә тап төшергәннәрен ишеткәнем булмады. Җанлы мәзәкләр тууның бер серен М. Галиев бик төгәл ачып бирә: "Сибгат аганың кәгазьгә карамыйча гына ясаган үтемле чыгышлары безне әсир итә, кайбер хикмәтле сүзләрен отып алып, соңыннан сөйләп йөрер өчен җирлек була иде..." ("Рух", 2005)

Анын хәзерге чор биеклегеннән караганда сәяси ярашу буларак күренгән әсәрләре дә халык мәнфәгатьләре белән яшәү дигән олы һәм изге максатка ирешүне үзенчә аңлавыннан туган хасиятләр иде. Шуна күрә С. Хәким поэзиясе аклауга да, төзәтүгә дә мохтаҗ түгел. Р. Фәйзуллин искәрткәнчә, "...Сибгат Хәким—мәшһүр Казан артының илгә игелек күрсәткән данлы бер улы" иде.

# ...ЯШИСЕ КИЛӘ

Фирая Зыятдинованың бу китабы мине иң әүвәле исеме белән үзенә җәлеп итте: «Утның яшисе килә».* Нибары өч сүз. Ләкин шушы өч сүз артында тирән мәгънә, шигъри символ, табигать белән кеше арасындагы күзгә күренмәс бәйләнешләр посып ятканын тоемлау кыен түгел. Чөнки:

*Ут җаны да кеше җаны кебек—*
*Яшәүләрдән мәңге туймавы...*




Китап ике бүлектән тора һәм аларының да исеменә мәгънәле, гуманистик фикер салынган: «Кеше булып калыйк!», «Кояшка үреләм!» Девиз булырдай әлеге сүзләр һич тә битараф калдырмый, магнит сыман үзенә тарта, тормыш-яшәеш матурлыгына чакыра.

Автор беренче бүлектәге иҗат җимешләрен үзенең укучысына «лирик-фәлсәфи шигырьләр» дип тәкъдим итә. Моның белән килешергә кирәктер. Чынлап та, шигъри үрнәкләрдә лирика белән тормыш-яшәеш хакындагы фәлсәфи уйланулар табигый рәвештә үрелеп, бер-берсен баетып бара. Ә монарга этәргеч—авыл һәм табигать баласы булу, тормышка мәхәббәт, матурлыкка кайнар омтылыш. Җөмләдән, истә калырдай менә кайбер юллар:

*Туган туфрак кирәк миңа,*
*Тургайлар җыры кирәк!*
*Ятып кочаклап еларга*
*Арышлар кыры кирәк!*

Яки:

*Хакыйкатьнең ачы баланын*
*Татлы җимеш диеп кабармын,*
*Изге ният белән бирсәләр...*

Фәлсәфә димәктән, ачык әйтергә кирәк, Фирая Зыятдинова Шәрык яисә Европа күләмендәге кинлеккә дәгъва итми. Аның тормышчан, хатын-кызларга хас хисси, борчулы үз «фәлсәфәсе» бар, бу агым аның иҗатында шактый ачык чагылыш таба. Шагыйрә, борчылып, тормыштагы яхшылыклар янәшәсендә ни өчен яманлыклар да бар икән? дигән мәңгелек сорауларга җавап эзли, шуларның күбесен уйлану, гыйбрәт алу өчен укучы хөкеменә калдырырга да онытмый.

Тормышның без (ирләр) күрмәгән төрле төсмерләрен, шатлык, газап, тетрәнүләрен хатын-кыз шагыйрәләр күбрәк әйтеп бирәдер сыман. Безнең татар поэзиясендә моның ачык мисаллары җитәрлек. Мина калса, алар бер-берсен «почти» кабатламый шикелле, һәрберсенен—үз хәяты, шатлык һәм борчулары, үз моннары-гамьнәре...

Бу җәһәттән Ф. Зыятдинова иҗатындагы аерым бер үзенчәлекне билгеләп үтмичә мөмкин түгел. Аның иҗатына, тормышчан җылылык, яктылык, мәрхәмәт белән бергә, күп нәрсәләргә сизгер булган сагыш-моңсулык мотивлары да бик еш саркылып керә.

*Ак һәм кара бергә очрашканда*
*Күзләремә яшьләр килеп тула.*
*Җанның телә һаман бер үк сорау:*
*Нигә болай корылган соң дөнья?*

Пессимизм белән оптимизм янәшә, диләр. Шулайдыр ул. Ләкин тормышның катлаулы, катмарлы көрәшендә аларның кайсы батыр калырга тиеш? Көчле рухлылар—җиңү ягында. Фирая Зыятдинова да әнә шушы хакыйкатьне алга сөрә. Минем (һәм бик күпләр дә дип уйлыйм) аның шәхси тормышында байтак зур күңелсезлекләр, фаҗигалар

Фирая Зыятдинова. «Утның яшисе килә». Татарстан китап нәшрияты. 2005.

барын ишеткән бар иде. Менә шуларның йогынтысын, елак кайтавазын һәм төшенкелекне аның иҗатында күрмәдем шикелле. Монысы да бик мөһим. Чөнки, аның әйтүенчә, «Кеше үз хәлләрен үзе генә белә...» Безнең лирик геройны кыен чакларда су, һава, ут, иман, кауры болытлар коткара, авырлыклардан аралап кала. Шуларның тормышчан бөтен кырыслыгын без ике юллыкта очрата алабыз:

*Авыр—дөньяларда яшәүләре...*
*Ә шулай да рәхәт!*

(«Рәхмәт!»)

Ак каеннарны, талларны, тупыл яисә имәннәрне үзенең иҗатында кайсы гына шагыйрьләр мактамаган икән! Фирая-ның иҗади хәзинәсендә дә үзе генә белгән, үзе генә яраткан ике сурәт-образ бар: болар—Кояш һәм Ут. Икесе дә дөньялыкның бер учагыннан диярлек. Шагыйрә иҗатында алар менә ничегрәк чагылыш таба:

*Киереп ач, әйдә, тәрәзләрне,—*
*Бер елмаеп кара Кояшка!*

*Кояшның бер җылы нурын күрсәм,*
*Күккә менәр идем тотынып.*

*Янсак яныйк, көлгә калыйк, әйдә,*
*Тик яратып китик дөньядан.*

Кояшның, символ-образ буларак, шагыйрә иҗатында шулай күп урын алуын ничек аңларга, нәрсә дип бәяләргә? Начаргамы, яхшыгамы юрарга моны? Есенин бит әнә үзенең «ак каеннары» белән рус поэзиясен әллә кайларга чаклы күтәрде, шуның белән Ватан темасының әйдәүчесенә әверелде. Шуның кебек, һәркемнең үз кояшы, үз күге. «Кояшка үреләм!» дип чаң кага икән, АКШ һәм Израильнең сугыш чукмарлары бомбага үрелгән заманда Ана кешенең кояшка үрелүе бик тә табигый, мактау вә хөрмәткә лаеклы гамәл ләбаса... Яшәүгә сусаган гөлләр һәм кешеләр генә әнә шулай кояшка таба үрелә ала.

Фәлсәфи уйланулары Фирая Зыятдинова иҗатына саран рәвештәрәк саркып керә, күп очракта сорау-аптырап калу рәвешендәрәк бирелә. Хатын-кызлар иҗатына фәлсәфи тыгызлык, фикер тирәнлеге кирәкмидер дә, бәлки? Алай дисәң, Анна Ахматованың тыгыз-саллы фәлсәфи шигырьләрен кайсы бизмәнгә салып үлчәргә кирәк?.. Уйланырлык урын бар бу җәһәттән...

Фирая Зыятдинова үзенең хисләрен күп очракта табигать төсмерләре белән бәйләп аңлата: «Бөтен җирдә көмеш монсулык». Аның иҗатындагы төп лейтмотив—табигатькә, кешеләргә, матурлыкка, Аналарга мәхәббәт. Балалар өчен язган шигырьләрендә дә ул Кояш образын читләтеп узмый: бала өчен әбисе, дәү әнисе—«өйдәге Кояш».

Шагыйрә иҗатындагы кимчелекле, житешсез якларны да әйтеп узу дөрес булыр. Урыны-урыны белән такмазага, «альбомный»га тартым шигырьләр дә юк түгел китапта. Җыентыкка байтак кына җыр текстларының кертелүе дә бик урынлы дип әйтәсе килә. Ләкин болары инде—башка тема.

Шулай да сүзне танылган җырчы Вафирә Гыйззәтуллина башкаруында популярлык казанган, китапта урын алган «Китмим әле яшьлегемнән» дигән җыр сүзләре белән тәмамлыйсы килә:

*Без бит җиргә якты, җылы*
*Ямь өстәргә яратылган.*
*Китмим әле яшьлегемнән—*
*Яз гөлләре арасыннан.*

Тормышка ямь өстәп китеп баручыларны онытмасак икән.

**Рәшат НИЗАМИ**

# ТУКАЙ ТУРЫНДА...

Күптән түгел татар милләте һәм башка халыклар Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулуны тантаналы шартларда билгеләп үттеләр. Табигый, бу датага әзерлек күп юнәлешләрдә барды. Шуларның берсе татар матбугатының эшчәнлеге: күпләрнең тырышлыгы белән альбомнар, китаплар, буклетлар һ. б. басылды. Ә бу очракта сүз шуларның берсе—шагыйрь Рөстәм Акъегет тарафыннан төзелгән «Тукай... Дөнья халыклары» дигән җыентык турында барачак. Бераз алга китеп булса да, шуны әйтү урынлы булыр кебек: Акъегет бөтен бер фәнни-тикшеренү институты башкара торган эшне берүзе үтәп чыккан. Һәм бу һич тә күпертеп әйтү түгел. Казакъстанда, мәсәлән, бары тик Абай иҗатын өйрәнү белән генә шөгыльләнүче махсус фәнни оешма бар...



Җыентык Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең кереш сүзе белән ачыла. Ул болай ди: «Без егерменче гасырда Тукай белән яшәдек, егерме беренче гасырга да аның белән атлап кердек. Тукай мирасы яшәгәндә, милләтебез дә яшәр, татар халкы милләт булып яшәгәндә, Тукай да яшәр».

Ә менә монысы җыентыкны төзүче сүзләре: «...Тукай, нинди генә сәяси җилләр исмәсен, нинди генә буталышчуалышлар булмасын, пьедестальдә горур басып торуын дәвам итә... Шагыйрь Равил Фәйзуллин язганча, «халык аның алдында баш ия, пәйгамбәр урынына күреп табына, илаһи күкләренә күтәреп, киләчәге өчен өлге итә».

Моның сере нәрсәдә? Хикмәт нидә? Төрле телләрдә сөйләшүче, төрле кыйтгаларда яшәүче халыклар ни өчен Тукайны үзләренеке дип кабул итәләр, уйлыйлар икән? Болар җиңел сораулар түгел. Әмма җыентыкта, ниндидер күләмдә булса да, аларга җавап бар кебек: илнең, дөньяның төрле почмакларында, төрле заманнарда яшәүче галимнәр, язучылар, журналистлар, җәмәгать эшлеклеләре—үзара сөйләшеп куйгандай—Тукайның бөеклек серен ачалар, аның иҗатына иң югары бәя бирәләр. (Сүз уңаенда—бу җыентык төзелмәгән булса, мөгаен, анда тупланган материалларның иң зур күпчелеген белми калыр идек. Чөнки алар төрле урыннарда сакланганнар. Радиодагыларның исә якын елларда бөтенләй юкка чыгуы да ихтимал.)

Тукай шуны яхшы белгән: халык буларак милләт саклансын өчен аның теле гамәлдә булырга тиеш. Бу—Америка ачу түгел. Бөек рус галиме К. Д. Ушинский (1824—1870) үзенең бер хезмәтендә «теле бетү белән ул халык үзе дә юкка чыга» ди һәм шул фикерен раслау өчен бик күп мисаллар китерә. Без бүген дә аның шулай икәнен белеп-күреп торабыз. Парламентыбыз татар телен дәүләт теле дип игълан итте. Әмма аңа карап кына телебезнең хәле һич тә уңай якка үзгәрми. Үкенечле хәл—безне дөнья белә, хәтта—БМО ЮНЕСКОсы, дөньядагы 6500 телнең 14-ен халыкара аралашу телләре дип, игълан итте. Алар түбәндәгеләр: инглиз, француз, немец, итальян, испан, португал, гарәп, рус, татар, япон, кытай, һинд, урду (Пакистан), бенгал (Бангладеш) телләре... Әй, син татар теле!..

Дөрес, башка төрле теория дә бар: дәүләте булмаган халыкның (димәк, теленең дә) киләчәге юк. Әмма чынбарлык теорияләрдән дә көчле икән. Мәсәлән, безнең эрага кадәр үк Рим легионерлары тарафыннан басып алынган Израиль дәүләте икенче бөтендөнья сугышыннан соң аякка басты. Онытылып бетә язган иврит теле дәүләт теле дип игълан ителде. Монда төп фактор булып яһүдиләрнең югары милли аңга ия булуы торды. Хәзер бу ил—Якын Көнчыгыштагы иң алга киткән

Тукай... : Дөнья халыклары Тукай турында / Төзүчесе Р. Акъегет. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2006.

дәүләтләрнең берсе. Яки тагын мисал— Скандинавия ярым утравында саам-лопарь дигән аз санлы халык бар. Шуны саклау, үстерү теләге белән Швеция, Норвегия, Финляндия дәүләтләре әллә никадәр эшлекле чаралар күрәләр... Заманында, Америка кыйтгасын басып алганда, европалылар, каршылыкларын сындырабыз дип, бихисап кызыл тәнлеләрне—индеецларны юк итәләр, резервуарларга куалар. Ә бүген АКШтагы иң абруйлы халык дип кызыл тәнлеләр санала һәм аларга интеллектуаль үсеш, гомумән тормыш дәрәҗәсен югары дәрәҗәдә тоту өчен бихисап практик чаралар күрелә.

Инде Россия шартларына, аның төп халкының мең еллар буе формалашкан менталитетына («бу илнең хуҗасы мин генә» дип горурлануы беркемгә дә сер түгел...) килгәндә, һәм, объектив фикер йөрткәндә, хәлләр шактый катлаулы һәм перспективада бу нәрсә Россиянең таркалуына китерергә мөмкин.

Әмма шунысы хак: татарлар бервакытта да Россиянең таркалуын теләмәделәр һәм дөнья тәҗрибәсенә таянып, Россияне бары тик Чын Федератив төзелеш кенә саклап калачак, дигән позициядә тордылар һәм әле дә торалар (дәүләт төзелешенең конфедерация варианты да бар. Әмма урыс халкы моны аңлау дәрәҗәсендә түгел әле...). Дөрес юл: федерация шартларында гына татар халкы милләт булып сакланачак... Тукай, читләтебрәк булса да «Хөррият хакында», «Дустларга бер сүз», «Иттифак хакында», «Китмибез!» «Туган тел», «Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» кебек әсәрләрендә югарыда әйтелгән идеяне күз алдында тота.

Тукайның шигърияте ңә кучкәнче тагын бер бик мөһим темага әһәмият бирүебез күп нәрсәләрне ачыкларга ярдәм итәр кебек. Р. Акъегет төзегән җыентыкта чыгыш ясаучылар Тукайны бөек шагыйрь дип кенә күз алдына китерәләр. Моның бер сәбәбе шулдыр—классигыбызның публицистикасы, прозасы соңгы елларга кадәр үз телебездә генә кала бирде. Әмма—«Тукай—шагыйрь генә түгел, ул—публицист һәм журналист, тәнкыйтьче, фольклорчы, сәясәтче, педагог та... Тукай Россия кинлекләренә, дөнья кыйтгаларына сибелгән татарны туплап, бербөтен итеп тотучы көч тә. Шуңа күрә аның әсәрләрен уку, белү, күңел хәзинәсе итү—һәр татарның вөҗдани бурычы» (профессор, академик Хатыйп Миннегулов сүзләре әлеге җыентыкның 93 битендә).

Тукайның публицистика, прозага багышланган махсус томнары белән танышкач (анда тупланган хезмәтләрнең саны 300гә җитә...), күңел ышанмый тора: бер югары уку йорты да тәмамламаган, диссертацияләр якламаган яшь кешенең искиткеч тирән белемгә ия булуына гаҗәпләнми мөмкин түгел! Аның публицистик чыгышларында философиягә, сәясәткә, дипломатиягә, тарихка, политэкономиягә, юриспруденциягә, педагогикага, психологиягә, журналистикага, лингвистикага, филологиягә, махсус хәрби белемнәргә мөрәҗәгать итүе ярылып ята. Бу уңайдан уннарча мисаллар китереп булыр иде. Әмма мона язманың күләме мөмкинлек бирми. Шуңа күрә аерым мисаллар китерү белән генә чикләнергә туры килә. Аларның да сәясәткә багышланганнарына.

1904 елда Япониягә каршы Россия сугыш башлый. «Партриот-шовинистлар» «кысык күзле япошкаларны» «бүрек белән бәреп тә җиңәргә» хыялланалар. Армия командующие генерал Куропаткин ин элек үзен кайгырта, махсус тимер юл вагонында сыерлар тота, чөнки ул әле генә савылган сөтне ярата... Японнар Порт-Артурны диңгездән утка тоталар. Балтыйк диңгезеннән бөтен дөньяны әйләнеп Ерак Көнчыгышка килеп җиткән «бөек» армада, Цусима бугазында японнар тарафыннан су төбенә җибәрелә. Тукай шул фактларны истә тотып фельетон яза... Шагыйрьнең ялкынлы «укларыннан» Төркия солтаны Әбделхәмит тә, Монако бөек кнәзе дә читтә калмыйлар. Үтә шовинистик позициядә торучы урыс дәүләте эшлеклеләре Гучков, Победоносцев, Столыпин, Дурнов кебекләргә дә Тукай сатирик ут ача.

...1910 елда шагыйрьнең «Халык әдәбияты» дигән китабы дөнья күрә. Бу китапка материаллар булып Тукайның халык алдында укыган лекцияләре хезмәт итә. Шул ук елда аның «Халык дошманы» дигән китабы да басыла. Шагыйрьнең кредосы болай: «Белергә кирәк ки, халык җырлары халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгеләре. Бу—бертөрле сихерле көзгеләр. Чөнки халыкның бер генә җыруын тотып нечкәләсән,

шөбһәсез, аның халәте рухиясен, нәрсә уйлаганын вә ни хакында нинди фикердә икәнен белеп буладыр»,—ди ул....— Дөрестән әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул»—дип тә өсти.

Табигый, Р. Акъегет төзегән бу җыентыкка Тукай публицистикасы, прозасы кермәгән. Чөнки бурыч бөтенләй башкада: Тукай феномены, аның бөеклегенә багышланган күпсанлы шәхесләрнен—язучыларның, журналистларның, галимнәрнең, җәмәгать эшлеклеләренең чыгышларын бер урынга туплау. Әйтергә кирәк, Акъегет бу миссияне әйбәт үтәп чыга алган, Тукайга карата булган «конъюнктур бәяләрне» «фильтр аша үткәргән».

Китапка 171 кешенең фикере тупланган. Алар—төрле кыйтгаларда яшәүче, төрле телләрдә сөйләшүче күренекле шәхесләр. Беренче сүзне Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәримгә бирик. Ул болай ди: «Тукай дигән могҗизаның төп сере нәрсәдә соң? Тукай дигән могҗизаның төп сере шунда: ул үзенең бөек талантын дөнья мәдәниятенең казанышлары белән баета алды. Шул талантка, байлыкка баш булып, аны халык тормышының, заманының иң төп, иң олы юлы белән алып китте, алсыз-ялсыз хезмәт иттерде. Аны үзенә соклану, яки кызык өчен генә сүзләр уйнату кебек буш, мәгънәсез нәрсәләргә исраф кылмады... Башкорт халкына килгәндә, башкорт халкы Тукай алдында муеннан бурычлы. Ул башкорт халкы мөгаллимнәренең берсе һәм иң күренеклесе булды. Башкорт әдәбиятына остазлык итүчеләрнең атаклысы һәм якыны булды».

Күпмилләтле Кавказ вәкиле, Кабардино-Балкариянең халык шагыйре Кайсын Кулиев сүзләре: «Төрки телләрдә язган язучыларның татар әдәбиятын өйрәнмәгәннәре юктыр дип беләм мин... Тукай—иң олуг уртак шагыйрьләребезнең берсе... Ул безнең сөекле шагыйребез генә түгел, халыкларны берләштерүче күпер дә».

Күпсанлы Дәүләт премияләре лауреаты, озак еллар буе Россия Язучылар берлеге җитәкчесе булган Сергей Михалков үзенең бер чыгышында түбәндәгеләргә басым ясады: «Габдулла Тукай был страстным публицистом и лириком, журналистом и ученым, он был основоположником татарской профессиональной детской литературы и создателем нового всенародного литературного языка. Вместе с тем, Тукай был беспощадным и страстным сатириком. Сатире Тукая я хочу уделять особое внимание. В его произведениях, созданных в этом жанре, хорошо представлены и тонкий юмор, и иносказания, и беспощадная эпиграмма, бичевание бесчинства эксплуататоров всех мастей».

Әзәрбайҗан шагыйре Бәхтияр Ваһабзадә болай дип нәтиҗә ясый: Инглиз халкын—бөек Шекспирсыз, рус халкын—Пушкинсыз, алманнарны—Гетесыз, әзәрбайҗаннарны Сабирсыз күз алдына китереп булмаган кебек, татар халкын да Тукайдан башка анлавы мөмкин түгел. Чөнки аларның һәркайсы—үз халкының рухына, символ-эмблемасына әверелгән алыплар».

Татар язучылары, шагыйрьләре арасында «Тукай белән иң нык авыручы» Сибгат Хәкимгә сүз бирмәсәк, һич тә дөрес булмас иде. Ул болай ди: «Тукай—бөтен рухы белән милли шагыйрь. Тукай кебек татар халкына якын бер генә шагыйрь дә юк... Минем күнелдә тагын тирән эз калдырган бер нәрсә—Тукайның гражданлыгы. Хакыйкать, халыкчанлык бергә кушылган. Тукай шомартмый, ярашмый, яраштырмый, фикеренә хилафлык итми, юлыннан чигенми, үз сүзләре белән әйтсәк, үзенең мәсләгенә тугры, иҗатында да, шәхси тормышында да шушы принципларга ахырынача тугры».

Бу язма президентыбыз Минтимер Шәймиевнең җыентык өчен тәкъдим ителгән кереш сүзе белән башланган иде. Әйдә, без аның икенче өлешен дә китерик: «Тукайның кыска гына иҗат гомерендә язган шигырьләре бүген дә актуаль һәм бүгенге көнгә аваздаш. Бөтен рухы һәм аһәңе белән халыкчан Тукай шигърияте үз заманында ук милли чикләрне үтеп чыкты, безнең татар халкы бүген дә Тукай белән билгеле халык»,—ди Минтимер Шәрипович. Моңа тулысынча кушылып, сүзне шагыйрьнең үзенә бирик:

*И туган тел, и матур тел,*
*әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп нәрсә белдем*
*син туган тел аркылы.*

**Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ**

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ТӘРЕ ҺӘМ АҢА ТАБЫНУ*** – Христиан диненең символы булып хезмәт итә торган нәрсә һәм аның тамгасы. "Тәре" сүзенең этимологиясен Р.Әхмәтьянов "мәҗүси алла, тәңре" сүзенә бәйли, кайбер керәшен авторлары да "тәре" сүзен "тәңре" сүзенә тәңгәлләштерәләр. Татар телендә шушы ук мәгънәдә "хач" сүзе дә кулланыла, анысы исә "хаҗ" сүзенә барып ялгана диләр (кара: *Аджи*). Керәшеннәрдә "тәре" сүзе "икона" мәгънәсендә йөри, "Татарча-урысча сүзлек"тә дә (1931) аның русчасы "икона, образ, крест" дип бирелгән. Урта гасырларда кыпчаклар тәрене хач дип атаганнар. "Тәре" сүзенең татар телендә тискәре мәгънә алуы кыпчакларның бер өлеше христиан булуына бәйләп аңлатыла (Р.Әхмәтьянов). Мордва-каратайлар сөйләше телендә *тәре тамга* – миң мәгънәсенә ия икән. Христиан буларак, алар бу сүзне уңай мәгънәдә аңларга тиеш.

Танылган тарихчы һәм этнограф Ч.Вәлиханов тәңречелек тарафдарларын XIX гасырда Казакъстанда да очраткан әле. Әгәр, мәсәлән, сөт түгелә калса, тәңрече "тәре ясаган һәм баш игән". Морад Аджи тәңречеләрнең тәре ясап чукынуны да христианнардагыча түгел дип яза: алар бармакларын чеметемләп түгел, бәлки баш бармакны атсыз бармак белән тоташтырып, маңгайларына якын китерәләр икән. Ихтимал, монда баш һәм атсыз бармаклар ясаган түгәрәк кояшны, ә туры килеш калган башка бармаклар һәм беләк кояш нурларын сурәтли торгандыр, чөнки тәңречеләр ясаган хачларның да үзәгендә кояш түгәрәге булган.

Ә әрмәннәр Алтай төркиләрендәге тигез чатлы тәре символын канунлаштырып, аның исемен – "хач" сүзен дә саклаганнар (Морад Аджи).

IV гасырга кадәр – кыпчаклар килгәнче – христианнар тәре дигән нәрсәне бөтенләй белмәгәннәр дигән фикер дә бар. Хәтта Морад Аджи: "Европа тәрене төркиләрдән алган", – дип раслауга кадәр барып җитә.

Чиркәү әһелләре бу символ тәрегә кадаклап үтерелгән Иисус Христның газаплы үлемен чагылдыра дип раслыйлар. Тәре христиан гыйбадәтханәләренең түбә башында тора, аны христианнар муеннарына асып йөртәләр. Гомумән, христиан дине йолалары тәредән башка үткәрелми дияргә мөмкин.

Ләкин, әйткәнебезчә, христианнарга кадәр күп элек төрле халыкларда тәрегә табыну булган инде. Мәс., Борынгы Мисырда һәм Бабилда, Һиндстанда һәм Иранда, Яңа Зеландиядә һәм Көньяк Америкада тәре табыну объекты булган. Кайбер галимнәр борынгы дәвердә кешеләр утны ике агач кисәген чалыштырып куеп бер-берсенә ышку юлы белән тапканнар һәм шушы коралны (ягъни тәрене) аллалаштырганнар дип тә уйлыйлар.

Әйтеп кителгәнчә, беренче христианнар әле тәрегә табынмаганнар, киресенчә, тәрегә мәҗүсилек билгесе дип түбәнсетеп караганнар. Тәре фәкать IV гасырдан гына христианлык символы булып исәпләнә башлый.

Христос тәрегә кадаклап үтерелгән дигән сүз дә тарихи дөреслеккә туры килми. Ул заманнарда җинаятьчеләрне тәрегә түгел, бәлки грек алфавитындагы "Т" ("тау") хәрефе сыман очына аркылы агач беркетелгән баганага кадаклый торган булганнар. Чиркәү әһелләреннән берсе, Тертуллиан: "Грекларның "тау" хәрефе түгел, бәлки безнең латин "t" хәрефе тәрене сурәтли", – дигән. Дөрес, хәзерге чиркәү әһелләре һәртөрле формадагы тәрене дә чын тәре дип исәплиләр. Шуны да әйтеп китик, католиклар дүрт

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче саныннан басылып килә.*

җәпле тәрене, ә православный христианнар алты һәм сигез җәпле тәрене таныйлар. Православный христианнар тәресендә бер аркылыча кыйгач урнашкан булып, имештер, бер очы белән күкләрне, икенче очы белән җирне күрсәтә, ә иң түбәндәге ай урагы сыман деталь, кайберәүләр уйлаганча, мөселман аеның җиңелеп аста калуын күрсәтми, бәлки тәрегә кадакланган Христның каны тамган табакны сурәтли. Әлбәттә, болар барысы да соңрак уйлап чыгарылган әкият, хыял җимешләре генә. Христиан философиясендә тәренең горизонталь сызыгы хатын-кыз, җир, материя аспектын сурәтли, вертикаль сызык исә ирлек аспекты, иҗади башлангыч, күк һәм рухны белдерә дигән фикер очрый. Ике сызык кисешкән ноктада бу аспектлар бергә кушылалар һәм энергия чыганагына әйләнәләр, шуннан дөнья барлык дүрт тарафка таба үсә башлый икән.

Безнең эраның IV гасырында Константин I нең әнисе императрица Елена Иерусалимда Иисусны газаплап үтергән җирдә казу эшләре вакытында өч агач тәре тапкан дип хәбәр итүче чыганаклар бар. Императрица ниндидер бер үлгән кеше мәетен бу тәреләр янына китереп карагач, тәреләрнең икесенең берниндидә тәэсире булмаган, ә өченчесе янында әлеге кеше терелгән имеш. Елена шушы тәренең бер кисәген Константинга җибәргән, ә ул, үз чиратында, аны Римга юллаган һәм тәре фрагменты, изге нәрсә сыйфатында, Ватиканда бүгенгә кадәр саклана икән. Тәренең калган кисәкләрен Елена кабат җиргә күмдергән. Шуннан соң христианлыкта тәрегә табыну кертелә. Ә Иисусның хачка кадакланган сурәте VIII гасырда гына күренә башлый.

IX гасырга карый торган мәшһүр "кельт тәресе"нә "Бисмилләһи-р-рахмәни-р-рахим" дип гарәпчә язылган. Кайбер галимнәр моны көнбатышка үтеп кергән суфичылык йогынтысына бәйләп аңлаталар.

Кайбер христиан дине тармакларында тәрегә табыну кире кагыла (баптистларда, адвентистларда, башка протестант чиркәүләрендә).

Татарча чыганакларда муенга тага торган тәрене *камира* дип атау очрый. Тәре тагуны "аркылы тагу" дип әйтү дә бар.

***ТӘРЕ ЯУЛАРЫ, ТӘРЕ СӘФӘРЛӘРЕ*** *тар.* – Урта гасырларда Европада христиан фанатикларының, бик күп гаскәр туплап, үзләре инанганча, христиан диненең бишеге булган Фәләстыйнны һәм Якын Шәрыкне мөселманнардан азат итү максаты белән оештырган яулары. Тәре яуларын *хач сугышлары* дип атау да очрый.

Озак вакытлар буена христианнар табына торган Иисус Христос дәфен кылынган Фәләстыйн җирләре гарәпләр кулында була һәм алар Христ табутына сәҗдә кылырга килгән христианнарны тоткарлыксыз үткәрәләр. 1078 елда Үзәк Азиядән килгән төрки сәлҗүкләр, Багдадны җимереп, Иерусалимне алалар. Сәлҗүкләр дә Ислам динен кабул иткән булалар. Ләкин алар христиан сәфәрчеләренә юлны биклиләр. Шуннан соң, атап әйткәндә 1095 елның 28 ноябрендә, Рим папасы Урбан II собор җыелышында христианнарны кулларына корал алырга һәм "Алла Табуты"н азат итәргә чакырып, Христның: "Үз-үзеңнән ваз кич, кулыңа тәре ал һәм минем арттан бар" дигән өндәмәсен кабатлый.

Шуннан соң өч ай да үтми, 40-50 мең кешедән торган гаять зур халык төркеме "тәре сәфәре"нә чыга. Аларны монах Петр Пустынник һәм Вальтер исемле ярлы рыцарь җитәкли. Анда катнашучыларны гарәпләр *әһле салиб* дип атаганнар. Тәре йөртүчеләр юл уңаенда җирле халыкны талап барганнар һәм алар Константинополь капкасы төбендә күренгәч, Византия императоры тәре йөртүчеләрне тизрәк Азия ярына чыгару ягын караган. Ләкин башлыча кара халыктан торган бу әтрәк-әләмнәрне Анталия төрекләре кырып салганнар.

Ул арада рыцарьларның тәре явы оештырыла. Аны папа 1096 елның 15 августында башларга карар кыла. Юлда азык-төлек белән тәэмин итү ансатрак булсын өчен тәре йөртүчеләр дүрт юл белән китәләр. Аларның гаскәре, ихтимал, 1 миллионга җиткән булгандыр. Күбәүләр үзләре белән хатыннарын, бала-чагаларын, хезмәтчеләрен, хәтта йорт хайваннарын да алганнар. Анталия ягына чыккач, тәре йөртүчеләр сигез ай буена Антиохия кирмәнен чолганышта тоталар. Аны алу белән, үзләре дә чолганышта калалар, ләкин төрекләр һөҗүмен кире кайтаралар. Сәфәргә чыгып өч ел үткәч, 1099 елның 6 июнендә, исән калган тәре йөртүчеләр (барысы 40 000 чамасы кеше) Иерусалимгә килеп җитәләр һәм аны чолгап алалар. 1099 елның 15 июлендә, җомга көнне көндезге сәгать 3 тә – Иисус Христос үлгән көнне һәм үлгән сәгатьтә алар шәһәр диварлары

аша үтеп керәләр. Шәһәрне саклаучы гарнизон һәм халык юк ителә, шәһәр талана. Тәре йөртүчеләр Иерусалим корольлеге төзеп, хакимиятне үзләренең иң абруйлы командирлары Готфрид Бульонскийга тапшыралар. Шуннан соң тәре йөртүчеләр 100 ел буена диярлек бөтен Фәләстыйндагы вәзгыятьне үз кулларында тоталар, мәчетне чиркәүгә әйләндерәләр, ишеге янына Христос сынын, гөмбәзенә тәре бастырып куялар.

Тәре яулары XI гасырның ахырыннан XIII гасырның соңгы чирегенә кадәр, ягъни ике йөз ел диярлек дәвам иткән. Барысы сигез яу булган дип исәпләнелә. Көнбатыш рыцарьлары "көнбатышны, христиан динен мөселманнардан саклау хакына" дигән сылтау белән Шәрыктә — Кече Азиядә, Сүриядә, Фәләстыйнда, Мисырда яулап алу сәясәте үткәргәннәр. Инде XII гасырда ук һәм бигрәк тә XIII гасырда тәре яуларының идеологиясе үзгәрешләр кичерә. Мәс., папа Иннокентий III көньяк Франция альбигойларына каршы яу оештыра, Григорий IX чакыруы буенча төньяк немец феодаллары баш күтәргән үз крәстиәннәренә каршы "сәфәр чыгалар". Немец рыцарьларының "Дранг нах остен" ("Көнчыгышка басым ясау") сәясәте тормышка ашырыла, алар грек җирләрендә, Көнчыгыш һәм Көньяк Балтыйк буенда, Төньяк-Көнбатыш Русьта яулап алу сугышлары алып баралар. 1421-31 елларда папа Мартин V Төньяк Италия крәстиәннәренә каршы тәре явы игълан итә.

Ләкин шуның белән бергә, XVI гасырга тикле Европада халык тәре яулары традициясе сакланып килә әле. Тарихка самими балалардан, көтүчеләрдән, игенчеләрдән һәм ярлы һөнәрчеләрдән торган "яулар" да билгеле.

Өченче тәре явы гаскәрен Мисыр солтаны *Сәлахетдин Йосыф Әюби* тар-мар китереп, 1187 елда Иерусалимны азат иткән һәм тәре йөртүчеләр диңгез буендагы Жан д'Арк кальгасына (Акра) чигенергә мәҗбүр булганнар. Солтан мәчетне әүвәлге хәленә кайтара, Христосның алтын сыны чыгарып ташлана, ә гөмбәздәге тәре урынына ай куела.

1270 елда Тунискә каршы юнәлдерелгән сигезенче яу вакытында тәре йөртүчеләрне җитәкләгән король Изге Людовик шәһәр диварлары янында ваба авыруыннан үлә. Яу җиңелү белән тәмамлана.

XIV-XVI гасырларда тәре яулары Балкан ярымутравына басып кергән госманлыларга каршы оештырыла. 1396 елда госманлылар төрле илләрнең берләштерелгән рыцарь гаскәрен җиңәләр. 1444 елда госманлыларга каршы яуны ләх короле Владислав III җитәкли. Варна янындагы сугышта тәре йөртүчеләр тар-мар ителә. 1453 елның 23 маенда солтан Мәхмүд II Константинопольне ала. 1517 елда госманлылар мәмлүкләрнең Сүрия-Мисыр дәүләтен буйсындыралар.

Тәре яулары идеологиясе тиз генә тынычланмый әле. Мәс., мәшһүр философ Ф.Бэкон "Изге сугыш турында әңгәмә" дигән хезмәтендә колониаль һәм төрекләргә каршы сугышларны аклый һәм аларны канунлаштыру зарур дип язып чыга. Ләкин Ж.-Ж.Руссо, Ф.Вольтер, Э.Гиббон, У.Робертсон кебек күренекле затлар тәре яуларын "диннән акыл чуалу", "кешенең ахмаклыгына әкәмәт бер һәйкәл", "канлы шашыну" дип атыйлар, аларның тарихыннан ачы итеп көләләр.

Шуны әйтергә кирәк, тәре яулары идеологиясе соңрак та кара көчләргә, колонизаторларга турылыклы хезмәт итте.

Тагы шунысы хак, тәре яулары күпме генә зыян китермәсен, Наполеонның Мисырны яулап алуы Исламга күбрәк зарар салган. Бу яктан караганда, "Наполеон мөселман булганмы?" дигән сорау кую гомумән урынсыз һәм мантыйкка сыймый.

Тагын кара: ***САРЫ ТӘРЕ ЯВЫ.***

***ТӘРҖЕМАН*** *г.* — Тәрҗемәче, тылмач. Сәгыйть Хәлфинең 1778 елда Мәскәү университеты типографиясендә басылган "Әлифба" китабының титул битенә түбәндәгеләр язылган: "Әлифба. Татар дилинең әлифбиенең тәхкыйк язылган хәрефләре вә иҗекләре бителмеш. Казан гимназияләренең остазы вә Адмирал канторының тәрҗеманы Сәгыйд Хәлфәи углы илә вә Казан кальгасындагы меллалар илә шул ук гимназияләрдә каралмыш вә макталмыш." // *Сүз — күңелнең тәрҗеманы.*

***ТӘСБИХ*** *г.* — Шул ук *сөбха.* Гарәпчә "мактау" мәгънәсендәге сүз. *"Сөбхан Аллаһ"* дигән гыйбарәне кабатлау. Риваятьләргә караганда, Идрис галәйһиссәлам һәр көн 12 мең тәсбих әйтә торган булган.

Зикерне санау өчен кулланыла торган "тәсбих мәрҗәнен" дә тәсбих (дисбе) дип

йөртәләр (гарәпчә тулы исеме — "әл-мисбат әл-вирдийят"). Тәсбих Аллаһының мактаулы исемнәре санынча — 99 төймәдән гыйбарәт, алар өч тигез өлешкә бүленеп бер җепкә тезелгәннәр. Йөзенче зуррак төймә — *шаһданә* яки *нишанә* халыкта тәсбихнең *мулласы* яки *Мәрйәм анасы* ("мәрйәмәнәсе") дип тә атала. Ихтимал, соңгысы тәсбих төймәләрен еш кына мәрҗәмана агачыннан (байбай, мәрҗән агачы, карга миләше) кисеп ясауга бәйледер. Баштарак зикерне санар өчен вак чакматашлар (чуерташлар) һәм хөрмә төшләре дә кулланганнар һәм бу Мөхәммәд галәйһиссәламга мәгълүм булган. Шулай булгач, зикер кәлимәләренең санын исәпкә алу өчен мәрҗән итеп тезелгән тәсбихне дә, чәчмә ташларны да куллanyрга ярый дигән сүз. Суфилар тәсбихы йөз илле төймәле, унбиш нишанәле (зур төймәле). Мөселманнарда утыз өч яки илле төймәле, өч яки биш нишанәле тәсбихлар таралган була.

Югары катлау кулланган тәсбихлар асыл ташлардан ясалган була. Мәс., Иван Калитаның биографиясен язган Николай Борисов Алтын Урда ханы Үзбәк турында: "ляжүрд (лазурит) дисбесен тартып, кымыз капкалап утыра иде", — дип тасвирлый.

Гомумән, тәсбих тарту гадәте Һиндстанда килеп чыккан дип уйлыйлар. Мөселманнарда беренче тапкыр тәсбих Әбү Нувайсның шигырендә телгә алына (миляди 808-813 еллар). Ләкин баштарак тәсбихны хатын-кызлар (суфиялар) гына кулланганнар. Тәсбих тарту Будда динен тотучыларда һәм католикларда да бар. XV гасырга тәсбих мөселман илләрендә киң таралыш алган.

Суфилар телендә тәсбих мәрҗәне шайтанны сuктыра торган камчы дип аталган.

Мисырда һәм Согуд Гарәбстанында намаздан соң тәсбих тартмыйлар икән, чөнки ул дингә соңрак кергән һәм анда бидгать гамәл булып санала.

Тәсбих (дисбе) асылда функциональ яктан борынгы *"санар такта"*га (рустагы "счеты"-чут) тәңгәл.

Язучы Нурихан Фәттах Крит утравында табылган мәшһүр Фест дискысын "дисбе" дип атый. Моның өчен аңа ышанычсыз арифметик гамәлләр башкарырга туры килә: дисктагы "сүзләр" санын 100 гә тутыру өчен аңа бер яктагыларын икегә тапкырлап (33х2=66), шуңа икенче яктагы "сүзләр" санын (34) кушарга кирәк була. Мондый ысул белән барганда, 66 санының ахырына янә бер 6 лык өстәп, шайтани 666 санын хасил итәргә дә мөмкин, әлбәттә. Әмма иң әүвәле 3 мең яшьлек дискны дисбе дип атау хронология белән сыешмый.

Шәрәфәтле иманыңны зикер-тәсбих белән сакла. Мөнәҗәттән.

Ваһһабиларның тәсбихтән файдалануны тыюын да әйтеп китәргә кирәк.

// *Тәсбих әйтү. Тәсбих санау.*

***ТӘҮБӘ*** *г.* — Ярамаган гамәлне эшләмәскә сүз бирү, кылган гөнаһларың өчен үкенү һәм Аллаһыдан ярлыкавын сорау. Тәүбә итү, асылда, безнең Аллаһ белән очрашуыбыз дигән сүз. Тәүбә — дога кылу кебек үк, безне Аллаһыга якынайта. Тәүбә итү безнең күңелебезне, кальбебезне пакьләндерә һәм безне чын мәгънәсендә үзгәртә.

Мөхәммәд Пәйгамбәр: "Әй, кешеләр, Аллаһка тәүбә итегез, мин бер көндә йөз мәртәбә тәүбә итәм," — дигән. (Мөслим.)

Тәүбә кылырга хакы булмаган адәм баласы юк.

Шартлары булган тәүбә белән югалмый торган гөнаһ юк.

Гөнаһтан тәүбә итүче кеше гөнаһсыз кеше мисалында булыр.

"Картаеп көч беткәч кенә тәүбә итү ул — тәүбә түгел, андый тәүбәне Аллаһ кабул итми, андый тәүбә үлемнән куркып кына тәүбә итү була. Кяфир хәлендә үлгән кешеләрне дә, тәүбә итми үлгән кешеләрне дә Аллаһ гафу итми, алар үлем галәмәтләре күренә башлагач кына иман китереп вә тәүбә итеп маташырлар, һич файдасы булмас, аларга каты газап булыр" ("Ниса":18).

Үлгәннән соң тәүбә юк, ди халык та.

Христианлыкта рухани каршына килеп тәүбә итү һәм гөнаһлардан пакьләнү йоласы яшәп килә. Дөрес, протестантлар бу мәрасимне кире кагалар, алар мондый ярлыкауны акча бәрабәренә сатып алынган индульгенциягә тиңлиләр һәм чынлыкта психотерапия сеансы булган тәүбәнең шифалы тәэсиреннән мәхрүм калалар.

// *Тәүбәи нәсух* — гөнаһны бүтән бер дә кабатламас өчен кылынган тәүбә.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Бишна

Бишна авылы Яшел Үзән районында, Яшел Үзән шәһәреннән 38 чакрым ераклыкта урнашкан. Бишна үзе авыл жирле үзидарә үзәге.

А. Артемьев жыентыгындагы (XIX йөз) мәгълүматларга караганда, авылда 40 хужалык булып, ислам динендәге 140 ир-ат һәм 169 хатын-кыз исәпләнгән. Анда бер мәчет һәм почта станциясе булган. Н. Н. Вечеслав хезмәтендә (1878) Бишна искә алына. Андагы 52 хужалыкта 253 ир-ат һәм 241 хатын-кыз яшәгән. Авылда бер агач мәчет һәм шырпы ясый торган ике кярханә булган. 1898 елгы чыганакта Бишна авылында татарлар яшәве әйтелә. К. П. Берстель китабында (1908) Бишна авылында 433 татар яшәгәнлеге искәртелә. Бишнага И. А. Износков (1885) мондый сыйфатлама бирә. Чар (Царевококшай) элемтә юлына урнашкан бу авылдагы 52 хужалыкта ислам динендәге элекке хөкүмәт крәстиәннәре (200 ир-ат һәм 280 хатын-кыз) яши. Алар Бишна авыл жәмгыятенә керәләр. Тормыш-көнкүрешләре уртача. Аяк киемнәре тегү һәм шырпы ясау белән шөгыльләнәләр.

Бишна сүзе нәрсә аңлата соң? 1973 елда Бишна авылы аксакалларыннан язып алынган, авыл тарихы белән бәйләнешле риваятьне китерик.

Элек бу тирәләрне кара урманнар чолгап алган булган. Анда төрле кыргый жанварлар яшәгән, жиләк-жимеш һәм башка табигать нигъмәтләре үскән. Элекке авыл урынында алан жәелеп яткан, зәңгәр чишмә аккан. Менә шушы урынга кешеләр килеп утырган. Биек тау башына урнашкан авыл халкы басу ачкан, ягъни урманны төпләп, чәчүлек жирләр хәзерләгән. Шулай итеп, авыл исеме биек ышнадан—Бишна булып калган. Тартыклар арасында урнашкан сузыклар кыскару татар теленә хас күренеш.

Борынгы бабаларның башта килеп утырган урыны тау итәгендә булган. Авыл халкы тау башына бүреләрдән куркып күчкән дип сөйлиләр. Тау астында 1 гектар мәйданлы керәшен зираты барлыгы билгеле. Димәк, авыл халкы чукындырылган, ләкин алар янадан ислам диненә кире кайтканнар. Авылның мәчетен Казан бае салдырган. Бишна авылы халкы «Кабан» исемле жыен бәйрәме үткәргән. Нугай юлы өстендәге Бишна авылы Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле.

Бишна авылына нисбәтле географик атамалар байтак. Атамаларның кайберләре белән танышыйк. Озын буй, Ташлы елга елдан-ел саега. Элек болыннарда билдән печән үскән, хәзер исә бер ишләре сөрелгән, икенчеләре ташланган. Кәрим чокыры, Астагы болын, Сармас, Үзән, Такырбай болыннарының элекке халәтен хәзер кире кайтарып булмый.

Иске зират дип йөртелгән зиратны авыл зурлап һәм хөрмәтләп искә ала. Иске авыл урынында хәзер дә кайчандыр авыл булганлыгын күрсәтә торган эзләр бар. Бу авыл кешеләре Бишнага үзәннән күчеп килгәннәр. Бишна авылында ташлыктан бик матур чишмә чыга, алар шуңа кызыкканнар. Элек үзәндә зур авыл булган.

Әйшә тавы турында кыйсса бар. Анда борынгы каберлекләр булган. Юл салганда ул урыннан кеше сөякләре чыккан һәм аларны Бикет авылы зиратына илтеп

*Башы журналыбызның 6 санында.*

күмгәннәр. Ослан тавын икенче төрле Алып чабата каккан җир дип йөрткәннәр. Гадәттә, борынгылыкка китә торган авыллар басуында очрый торган мондый исемдәге таулар башка төбәкләрдә дә, әйтик, Башкортстанда, Пермь өлкәсендә дә бар. Бу гаҗәп түгел, чөнки билгеле тарихи сәбәпләр аркасында татарлар төрле урыннарга сибелгәннәр һәм, үзләре белән туган туфракларын ала алмасалар да, күңелләренә сеңгән атамаларны алып киткәннәр.

«Алып тавы» дигән риваятьтә болай сөйләнә: «Борын-борын заманда карт белән карчык булган. Аларның уллары да булган. Уллары кырга чыгып киткәч, карт белән карчык өйдә сөйләшәләр икән.

—Җил идем, давыл идем, җиде көндә бер ыштан тегеп бетердем,—дип карчык сөйләнә, ди. Шулай сөйләшеп торганда, уллары кырдан кайткан. Бер кесәсенә бер кеше белән атын салган, бер кесәсенә арбаларын, сукаларын тутырып кайтып кергән.

—Менә, әти, бер корт таптым, җир ертып йөри иде,—дип, әтиләренә кесәсеннән теге кешене алып күрсәткән.

—Улым, кайдан алдың, шунда илтеп куй, корт түгел бу, шундый вак кавемнәр чыккан, без эре нәселләр, бетәбез хәзер үлеп,—дигән әтисе.

Малай, алып кайткан әйберләрен кире кесәсенә тутырып, каян тапкан шунда илтеп куйган. Безнең авылдан ерак түгел, Шалкан Көек чокыры дигән җирдә Алып тавы бар. Шул чокыр буйлатып илтеп куйган бу теге әйберләрне. Ул чокыр бик тирән, бик ямьле, әле дә бар, чатлы-чатлы, хәзер колхоз көтүе йөри анда, элек зур-зур кибәннәр салып, печән чаба торган идек, җиләкләр җыя торган идек. Егерме-утызынчы елларны җир җиләкләре күп була торган иде анда, без бәләкәй чакта...»

Алып тавы... Гадәттән тыш зур гәүдәле мифик пәһлеваннар—Алыплар турындагы легендалар татар халкы арасында киң таралган. Гадәттә, бу әсәрләр конкрет бер җирлеккә, күп очракта авыллар янындагы таулар, калкулыкларга бәйле рәвештә сөйләнәләр һәм ул таулар йә «Алып таулары», йә «Алып чабатасын каккан тау» дип аталалар. Үз вакытында татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри болай дип язган иде: «Безнең Болгар йортында кайсы гына авылга барсаң да, Алып турында бер хикәят бар. Күп авылларда мәшһүрдер. Кырларында бер мәхәсрәк (күркәмрәк) тау булса, Алып чабатасын каккан дип хикәя кылалар» *(К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Ике томда. 1 том.—Казан, 1974, 81 бит).*

Бу авылда күренекле татар теле белгече, филология фәннәре кандидаты, Ватан сугышында катнашкан, иртә вафат булган Каюм Сабир улы Сабиров туган.

*Дәвамы киләсе саннарда*

---

# Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

# «КАЗАН УТЛАРЫ»—2007

## Фән

### Мәрҗани китапханәсенең яңа табылган тагын бер өлеше

Татар халкының күренекле тарихчысы һәм дин галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең бай китапханәсе 1920 ел янгынында тулаем юкка чыкканлыгы турындагы хәбәрнең дөреслеккә туры килеп бетмәве соңгы елларда расланган иде. Ягъни аның китапханәсенең аерым өлешләре табылды. 2004 елда «Мәрҗани китапханәсе» дип аталган махсус хезмәт тә дөнья күрде. Шуннан соң галим китапханәсенең тагын бер өлеше табылды.

Яңа табылган китапларның күпчелеге Мәрҗанинең үз әсәрләре, аларның буш битләренә Шиһабетдин хәзрәт төрле фикерләрен дә язып куйган. Арада үзе язган «Әй, Шиһаби, куй дәгави...» дип башлана торган сатирик шигыре дә кызыклы.

Олуг галимебез китапханәсенең бу өлеше кайда саклаган? Аны кемнәр тапкан? Нинди китаплар? Сатирик шигыре нәрсә унаеннан язылган? Болар турында тулырак мәгълүматны журналның киләсе елгы саннарының берсендә табарсыз.

### Ватан газабы

Адәм баласы туган авылына сөргенгә җибәрелә аламы? Ала икән шул. Кайда ничектер, ләкин татарларга шактый газаплар чиктергән безнең ватанда булган хәл ул.

Гыйззәтулла хәзрәтнең өлкән улы Әхмәди бертуган ике энесе белән бергә динне саклап көрәшкәннәре өчен 1877 елда унар елга сөргенгә хөкем ителгәннәр. Әхмәди мулла кара урманнар эчендәге Нократ исемле борынгы татар авылында сөргендә булган һәм шунда никахланган. Тоткынлыктан азат ителгәч хатыны һәм яңа туган бер яшьлек улы Батыргәрәй белән туган төбәгенә кайткан.

Гомерләр уза... 1930 нчы еллар килеп житә. Авыл мәчетен саклап калу өчен тырышкан гайрәтле Батыргәрәй Әхмәди улы кулга алынып 9 елга сөргенгә җибәрелә һәм, ни гаҗәп, хөкем срогын уздыру өчен Нократка—илле еллап элек үзе дөньяга килгән авылга эләгә.

Капма-каршы ике төрле хакимият чорында, бер үк Ватанда, бер үк сәбәп аркасында татар башы җәфа чигә...

Газап-җәфаларда да сынмыйча, ата-баба җирендә яшәп килүче бу нәселнең хәзерге бихисап дәвамчылары Гаяз Исхакыйның «Зөләйха»сын кат-кат тамаша кылалар, күзләре чылана... Чыланмыйча, андагы хәзрәт образында алар газиз бабаларының гәүдәләнешен күрәләр бит.

Әлеге мәкаләдә, аерым бер нәселнең дин һәм иман өчен күргәннәре документаль чыганакларга нигезләнеп тасвирлана.

**—Президентыбыз игълан иткән Әдәбият һәм сәнгать елы тәгәлләнеп килә. Безнең «Казан утлары» журналы әдәбият, мәдәниятебез тормышын игътибар үзәгендә тотарга тырыша. Җөмләдән, журналыбызның 3-нче санында баш редактор Равил Фәйзуллин белән Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең бүгенге мәдәниятнең торышы һәм перспективалары турында тәфсилле әңгәмәсе басылып чыкты. Анда, әдәбият-сәнгатькә кайгыртучан мөнәсәбәт, аерым бер елны билгеләп үткәндә генә түгел, дәүләтнең, җәмәгатьчелекнең һәрдаим күз уңында булырга тиешлеге әйтелгән иде.**

**Зур оешманың җитәкчесе буларак, Сезгә мөрәҗәгать итәбез: Әдәбият һәм сәнгать елы ничегрәк узды дип санийсыз, канәгатьлек хисе бармы? Сезнең тарафтан күңелгә хуш килерлек нинди әһәмиятле чаралар үткәрелде һәм нинди проблемалар күз уңыннан төшеп калды?**



**Ринат ТАҖЕТДИНОВ,** ***Россия һәм Татарстанның халык артисты, Татарстанның Театр әһелләре берлеге рәисе:***

—Театр җәмәгатьчелеге Президентыбызның 2006 елны Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан итүен куаныч белән кабул итте.

Шул уңайдан безнең иҗат оешмасы үзенең тәкъдимнәрен әзерләде һәм үткәреләчәк чаралар программасын билгеләде.

Безнең карашыбызча, шулар арасында иң кызыклысы—театрларда эшләүче артистларыбызның мөстәкыйль эшләрен Актерлар йортында күрсәтү-хуплау иде. Бу программа нигезендә ТЮЗ (театр юного зрителя) артистлары Татарстанның халык артисты, режиссер Роман Ерыгин җитәкчелегендә Саймонның «Сотня за услугу» («Хезмәт өчен йөз тәнкә») дигән пьесасын сәхнәгә чыгардылар. Аннары бу спектакль Петрозаводск шәһәрендәге «Ламбушка» фестивалендә дә күрсәтелде, призлы урынга лаек булды.

Кама аръягында театр фестивале үткәргәннән соң Ильтани Илялова иҗат кешеләренең эшчәнлеген бәяләде, аларның социаль һәм матди яктан бик түбән дәрәҗәдә булулары хакында язып чыкты.

Бөтенесен санап чыгу мөмкин түгел. Әмма әйтәсе килә: октябрь аенда без Чаллы, Бөгелмә, Әлмәт, Минзәлә районнарында театр рәссамнарының күргәзмәсен тамашачыга тәкъдим итә алдык.

Безнең әле татар милли театрыбызның 100 еллыгына багышланган конференция дә үткәрәсебез бар. Юбилей уңаеннан газета-журналларыбыз битләрендә һаман диярлек языла килә, шуңа күрә аларның һәммәсенә тукталу кирәкмәстер.

Шуның белән бергә, әле күптән түгел кабул ителгән хөкүмәти законнарның кайбер актларында иҗат оешмаларының, шул исәптән театр әһелләре мәнфәгатьләрен кысрыклау, аларны финанс җәһәтеннән хәерчегә калдыру, мөмкинлекләрен чикләү гамәлләре нык борчый безне. Әйтик, мәдәният оешмаларына карата кайбер ташламалар ясалуын нигә инде тыярга кирәк иде?

Җөмләдән, Татарстан Министрлар кабинетының 14 август, 2006 елгы «Бюджет чыгымнарының файдасын һәм нәтиҗәләрен күтәрү» дигән 419 нчы карарында барлык иҗат берләшмәләренең бюджет чыганакларын өзү турында сүз әйтелә. Бу—безнеңчә бер уйласаң, иҗат ирегенә бирү шикеллерәк, икенче карасаң—матди яктан басым ясау. Ләкин дәүләт ярдәменнән башка бер генә театр да аягында нык торачак түгел.

Театр оешмасы—иҗади бер җәмгыять. Аны матди байлыклар тудыра һәм ифрат зур керемнәр ала торган завод-фабрикалар белән бертигез дәрәҗәгә куярга ярамый. Мәгълүм булганча, Артист, Режиссер, Язучы, Музыкант, Рәссам—милли хәзинә. Без бу хәзинәне дәүләт дәрәҗәсендә кадерләп саклый белсәк иде!

Менә шунлыктан мәдәният оешмаларына кагылышлы, аларны гамәлдәге льгота-ташламалардан мәхрүм итүгә юнәлгән Министрлар Кабинетының алда әйтеп кителгән карарын, һичшиксез, яңабаштан карарга кирәк.

*Сентябрь, 2006.*



**Илфак ИБРАҺИМОВ**, ***шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге рәисе:***

—Әдәбият һәм сәнгать елы дип билгеләнгән 2006 ел үзенең мәгънәви бәйләнешы белән аеруча әһәмиятле булды. Күренекле шәхесләребезнең юбилейларын гына алыйк—Муса Җәлилнең 100 еллыгы, Габдулла Тукайның 120 еллыгы... Бу ике даһиның исеме бөтен татар халкының байрагына әверелде һәм халкыбызны берләштерүгә, туган телебезнең җәмгыятьтәге урынын, ролен тагын да үстерүгә унай этәргеч ясады.

Җәлил һәм Тукайның юбилейларын Дөньяның күп почмакларында, дистәләрчә илләр-төбәкләрдә үткәреп, без халкыбыз сафын янәдән бер барладык, аларның рухы ныклыгын, яшәү көче-куәтенең зурлыгын күрдек...

Каләмдәшләребез Казакъстан, Белоруссия, Латвия, Украина, Әзәрбайҗан, Германия кебек илләрдә, Оренбур, Екатеринбург, Чабаксар, Төмән, Чиләбе, Ульян, Киров өлкәләре һәм калаларында дистәләрчә мең милләттәшләребез белән очрашып, аларга Ана телебездә—Тукай телендә—без Бар, без Исән, безнең әдәбиятыбыз, сәнгатебез исән, без киләчәктә дә бар булырга, бай булырга тырышыйк дип кайттык. Минем үземә дә Җәлил, Тукай юбилейларына мөнәсәбәтле рәвештә башкалабыз Мәскәүдә, Петербурда, ут күршеләребез—Уфада, Пермь, Ижау калаларында... Төркия һәм Кытайда булырга туры килде...

Әдәбият һәм сәнгать елы үзебезнең Республикабызда да мәгънәле чаралар белән билгеләп үтелә. Казан, Яр Чаллы, Арчада гына түгел, Республикабызның Азнакай, Әлки, Актаныш районнарында татар әдәбияты көннәре узды. Декабрь аенда Акмулланың 175 еллыгына багышланган чаралар үтәчәк. Шулай ук көз-кыш айларында тагын 15ләп әдипнең иҗат кичәләрен үткәрү күздә тотыла. Әйткәнемчә, мин фәкать юбилейларга гына тукталдым. Ә инде Язучылар берлегенең иҗат секцияләрендә, әдәби редакцияләрендә, радио-телевидениеларда, китапханәләрдә күп төрле мәдәни-оештыру чараларын әйтәсе дә юк.

Язучы шагыйрьләребезнең иҗат активлыгы бик югары. 2005 елда гына да Татарстан китап нәшриятында, «Мәгариф», «Рухият» нәшриятларында рус һәм татар телләрендә 100 дән артык язучыбызның әсәрләре басылып чыкты. Быел тәрҗемә эшендә шактый алгарыш булды.

Әдәбият-сәнгать елы унаеннан башкарылган эшләрнең барысын да санап чыгу мөмкин түгел. Гомумиләштереп шуны әйтергә кирәк: әлеге чаралар сүз сәнгатенә булган игътибарны бермә-бер арттырды, газета-журналларга язылу, китап тарату эшендә дә җанлану сизелде. Һәрхәлдә, халкыбыз күңелендә Китап дигән изге төшенчәгә ихтирамлы караш, аның рухи азык булуын аңлау бар.

Ә инде проблемаларга килгәндә, алар да бик күп булып, киләчәккә план-бурычлар рәвешендә күрсәтер идем. Белгәнебезчә, татар халкы гомер-гомергә китаплы, укымышлы булды. Соңгы чорда, илдәге сәяси-икътисади үзгәрешләр тәэсирендә, әлеге матур казанышган читләшү күзәтелә. Күпгасырлык матур традицияне янартасы, һәр татар йортын, гаиләсен китаплы-журналлы итәсе иде. Моның бер юлы булып Татарстан хөкүмәтенең озак вакытка исәпләнгән «Әдәби укулар» программасын эшләү һәм тормышка ашыру тора.

Милли әдәбиятны пропагандалау максатында, дәүләт нәшриятларында чыккан һәр китапның кибетләргә, китапханәләргә кайтарылуына ирешү, татар әдәбияты фондын янарту да мөһим бурычлардан санала. Бу уңайдан, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты белән берлектә, Россия төбәкләрендәге милли-мәдәни мөхтәриятләрдә милли әдәбиятны тарату буенча махсус программа эшләү дә сорала.

«Яңа гасыр» телеканалы һәм радиосы татар әдәбиятын һәм сәнгатен пропагандалаучы үзәкләрнең берсе булырга тиеш дип саныйм, шуңлыктан әлеге телерадиокомпание белән хезмәттәшлекне үстерү, уртак проектлар эшләү дә—өлгергән мәсьәлә.

Гомумән, әдәбият-сәнгатьне үстерү—татар һәм республикабыздагы башка халыклар өчен рухи-мәдәни янарышның мөһим бер тармагы. Без бу эштә Татарстан республикасы җитәкчеләренең зур ярдәменә таянып, башка иҗат берлекләре белән иңгә-иң торып эшләргә тырышабыз.

*Сентябрь, 2006.*

# «КАЗАН УТЛАРЫ»—2007

## Публицистика

**Ш. Яһүдин.** Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм законнарында милли үзенчәлекләрне искә алу. *Мәкалә.*

**А. Филиппов.** Зилчә буйларыннан Тилчәгә. (Атом казаны өстендә бер ел.) *Истәлек.*
«Чиләбе атом бомбасы заводы шартлау нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан рядовой солдат күргәннәрнең йөздән берен генә булса да уртаклашырга телим...».

**К. Шакиров.** Курку. Уйланулар.
«Галимнәр дә аңлап җиткермәгән кичереш бу. Мин күп мәртәбәләр бик куркыныч хәлләрдә булдым...»

**Т. Вафин.** *Мәкруһлар.*
«Әмәйгөл әби»е белән журналда «Тормыш язган хикәяләр» сериясен башлап җибәргән авторыбыз көчләп чукындырылып, кире ислам диненә кайткан милләттәшләребез турында тетрәндергеч тарихи-документаль әсәр язган.

---

## Әдипне ак сагышка салган зат—табылды!

Журналыбызның быелгы 3 нче санында Рәйсә Юсупованың «Ак сагыш иясе» исеме белән күренекле драматург Шәриф Хөсәенов турында очерк-хатирәсе басылган иде. Без ел буена укучыларыбыздан рәхмәт сүзләре ишеттек. Күпләрне Шәриф Хөсәеновның тәүге һәм бердәнбер мәхәббәте—Зөлфә язмышы да кызыксындырды, кат-кат «Тапсын иде аны автор» дигән теләк белдерелде.

Шул ук авторның «Күкләрдән иңгән мәхәббәт» дип исемләнгән язмасында укучы күп кенә сорауларына җавапны... «Мәхәббәт сагышы» героинясының үзеннән алыр.

«...—Ленинградтагы очрашуыбыз да, әйтәм бит, язмыш бүләге. Ленинград хәрби медицина академиясенең белем күтәрү курсларына килү белән безне, хәрби корабльгә «төяп», Кронштадтка экскурсиягә алып бардылар. Корабльгә утыру—сират күпере кичү белән бер булды; һәр документның өтер-ноктасына кадәр кат-кат тикшереп теңкәгә тиделәр. Кергәч нәрсәгәдер сөялүем, корабль янындагы мәхшәрне күзәтә башлавым исемдә. Кемнеңдер җылы, йомшак карашын тоеп борылуым һәм елмаеп торучы Шәрифне күреп, Ходаем, саташам ахрысы, диеп уйлавым да хәтердә әле. Шуннан соң минем өчен вакыт туктады. Кая баруыбыз, ни өчен баруыбыз—боларның берсенең дә әһәмияте юк иде инде...».

*Сара Садыйкованың туына 100 ел*

# САНДУГАЧТАЙ САРА АПАБЫЗ...

Сара Садыйкова... Жыр һәм музыка сәнгатен сөючеләр өчен бик тә якын, калерле, данлы исем бу.

Байтак еллар узганнан соң, иҗтимагый тормышыбызда янача үзгәрешләр башланганнан соң гына аның иҗатын бәяләүдә бөтен тулылыгы белән хаклык, гаделлек өстенлек алды. Сөекле композиторы, җырчы сандугачына халкының кайнар мәхәббәте еллар үткән саен арта, тирәнәя баруын тоеп, Татарстан хөкүмәте Сара Садыйкова иҗатын сонарып, ягъни вафатыннан соң булса да, иң зур югарылыкка күтәрде: 1990 елның 20 апрель карары белән ана Республикабызның иң зур бүләге—Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.



Композиторның чишмә төсле чылтырап аккан моңлы иҗаты халкыбыз күңелендә һаман яшь, матурлыкка, сафлыкка, мәхәббәткә рухландыра.

Әле егерме генә ел элек теге яки бу концертка, юбилей йә булмаса музыка-шигърият кичәсенә аяк бассам, мин, һичшиксез, һәм һәрвакыт диярлек бик күптәнге танышым—кечерәк кенә зифа буйлы, мөлаем ачык йөзле, башына табигый-гүзәл, безгә таныш «мәңгелек» калфагын элгән Сара ханым Садыйковага юлыга торган идем...

Ә чынлап торып танышуыбыз үткән гасырның 70 нче еллар башында булды. Мин ул вакытта Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлап, Казан телестудиясенең музыкаль тапшырулар редакциясенә мөхәррир булып эшкә урнашкан идем. Әлбәттә, һәр житәкче дә, янындагы хезмәткәр дә яна редактордан яна адым, сүз, тапшыру көтә. Баш мөхәррир, өстәвенә диктор Әминә ханым Сафиуллина белән бергә без «Хатлар укыганда» исемле музыкаль тапшырулар циклын башлап җибәрдек... Бераздан безнең бу тапшыруыбыз татар телевидениесенең иң популяр тапшыруына әверелеп китте. Хатлар да, үтенечләр дә йөзәрләп килә башлады! Тапшыруның оештыручы-язучы авторы һәм редакторы буларак, мин көне-төне шул хатлар белән мәшгуль идем. Алардагы кызыклы теләк-тәкъдимнәрне истә тотып, без студиягә халык яраткан авторларны, җырчы-башкаручыларны да чакыра башладык. Моның өчен миңа, яшь егеткә, бөтен Казанны йөреп-айкап-өйрәнеп чыгарга туры килә иде. Һәр җырчының, һәр авторның үз аулак йорты-фатиры бар бит... Башта аны эзләп табарга, хуҗасын туры китереп, очрашырга кирәк. Аннан соң гына, җайлы-мөлаем әңгәмә корып, тапшыруга киләчәк мөхтәрәм кунакның төп фикерен, мөһим ризалыгын алырга өмет туа...

Ул елларда композитор Сара Садыйкова җырлары бик популяр һәм киң таралган иде. Аларны сорап, радиога, телестудиягә Илебезнең төрле төбәкләреннән меңләгән хат-үтенеч явып тора иде.

Ә бу оста артистка-җырчы ханымның тәүге җырын минем әтием Әхмәт илленче еллар башында ук Казаннан кайткач, гармунда уйнап, җырлап күрсәткән иде. Әле дә исемдә: бу искиткеч аһәнле, матур яңгырашлы көй «Син кайларда йөрисең икән?» дип башланып китә иде. Милли музыкада ул чакларда танго, фокстрот ритмында яңгыраган көйләр әле бик сирәк иде шул. Фасил абыем аны шунда ук отып алды да, Лесхоз клубында баянда уйнап, яшьләрне биетергә үк керешге!

Безнең әти, лесхозның баш бухгалтеры буларак, ай саен Казанга, урман хуҗалыгы министрлыгына айлык отчетын бирергә бара торган иде. Ә кич булдымы, әтиебез инде иң яраткан урынында—Горький урамындагы Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында! Бигрәк тә үзе табынган һәм яраткан Салих Сәйдәшев музыка язган спектакльләргә кабат-кабат йөрергә ярата торган иде ул. Өенә кайткач та, кулына ундүрт телле гармунын алып, отып калган көй-арияләрне, марш-биюләрне уйнап, шатлана-рухлана. Салих абыйның үзен дә яхшы белә, аның белән еш күрешә дә икән. Сара Садыйкованы да бик күптәннән белгән, Галия Кайбицкая белән Сара апа җырлаган яңа көйләрне рухланып сөенеп уйный торган иде. Ә Сара җырчы гына түгел, композитор да икән бит әле! Бераздан әти, Казан кучтәнәче итеп, әниебез Бибисара һәм калган биш баласына Казан йолдызы Сараның «Сөмбел» (М. Фәйзи сүз.) «Язгы сулар акканда», «Айлы кичтә», «Яңа ел таңы» кебек яңа, матур көйләрен алып кайта башлады! Фасил абый ул матур яңгырашлы көйләрне шундук отып алып, баянда уйнап, бөтен авыл-бистәне шаккаттыра башлады...

Әйтергә кирәк, Сара Садыйкова үзенең җырларын соңрак, остазы һәм табынган авторы Салих ага Сәйдәшевтән соң яза башлады. (Хәер, бергә эшләгән коллегасы Шакир ага Мәҗитов та бит иҗат эшенә Салих абыйсын югалткач кына керешге).

Җыр-моңга сусаган халык «Хуш, авылым», «Көтәм сине» кебек моңнарга табына, янадан күрәеп, канат кагына торган иде. Күп тә үтмәде, бөтен җыр остазлары табынган һәм шул ук Әхмәт Ерикәй сүзләренә Сара апа «Җилфер-җилфер» җырын да язып куймасынмы! Кечкенәдән үк нәфис сүз-шигырьгә, музыка-моң-көйгә гашыйк Сара, үскәч, артистка-иҗатчы булырга тели. Моңа моңлы җанлы аһәнле әтисе Гариф та каршы килми, хуплый-табына гына... Яшь кыз берничә ел татар драма театрында артистка булып эшли, яраткан Сәйдәше белән таныша, аның моңнарын көйли. Ә бераздан аны, башка сәләтле татар артистлары белән бергә, Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы яңа оешкан татар опера студиясенең җыр-вокал классына укырга, тәҗрибә тупларга җибәрәләр. Ул анда Сәйдәш-Җәлилләр белән бергә аралашып яши.

Ә бит әле япь-яшь вакытында ук егерме яшен тутырып килгән Сара тәүге милли операбыз—Солтан Габәши, Газиз Әлмөхәммәтовлар иҗат иткән «Сания» операсында төп партияне башкару бәхетенә ирешә!

Һәм менә Җәлилләр белән бергә, дусты-коллегасы Галия Кайбицкаяны да ияртеп, Сара 1939 елны тора-бара Муса Җәлил исемен йөртәчәк Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсенең төп солисткаларыннан берсе булып эшли башлый. Йомшак, нәфис тембрлы, үтә гүзәл, ягымлы тавышлы, үзе дә курчак кебек матур Сараны бәхетле тамашачы тәүге музыкаль спектакльләрдә күреп-ишетеп, таң калып карый-тыңлый, соклана, кул чаба! Кыска гына вакыт эчендә ул «Галиябану», «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», «Кандыр буе», «Ил» кебек спектакльләрдә истә калырлык образлар тудыра.

Тәүге милли «Качкын» операсында да төп партияләрнең берсен Сара Садыйкова башкара. Сәләтле җырчы-солисткага шул ук 1939 елны Татарстанның атказанган артисткасы дигән мактаулы исем бирәләр. Остазы Җәлил кебек, Сара Садыйкова да 1941 елда башланган канлы, дәһшәтле сугышта күп кенә хыялларын, якын кешеләрен җуя. Спектакльләрдә уйный-катнаша алмаса да, тырыш, үзсүзле Сара Казанда эшче яшьләр арасында гаять әһәмиятле һәм кирәкле эш алып бара. Яшь һәвәскәрләр белән бергә үзе дә Казанда, республикада, бөтен илдә йөзләгән концерт-тамашалар биреп, халыкның Җиңү рухын күтәреп йөри. Нәкъ менә үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә күрсәткән тырыш хезмәте өчен ул Мәскәүдә үткән татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы уңае белән «Аеруча хезмәт күрсәткәне өчен» медале белән дә бүләкләнә.

Сара апа гомере буе эшче яшьләр белән башлап җибәргән изге, күркәм эшен өзлексез рәвештә һәм гаять уңышлы алып бара. Әле мин телестудиядә эшләгән

елларда да, аннан сонрак та ул «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсенен ул чакта нәкъ Казан каласы үзәге—Бауман урамында урнашкан М. Горький исемендәге клубта хор житәкчесе булып эшли иде.

Шулай да инде бу елларда бик еш радиодан да, сәхнәдән дә бер-бер артлы Сара апанын гүзәл жырлары янгырап тора башлый. Халык шагыйре Сибгат Хәким сүзләренә генә дә Сара апа унга якын жыр язарга өлгерә. Арада «Муса», «Артеллерист Гыйлфан» кебек сугыш батырларына багышланганнары, «Әй язмыш, язмыш», «Мин беренче чәчәкләрне эзлим» сыман фәлсәфи янгырашлы, «Син йөрәктә минем, Арча», «Уразай» кебек төбәкләргә багышланган һәм гаять популярлашып киткән шедеврлар да байтак. Гөлшат Зәйнашева шигырьләрен дә бик ярата, үз итеп карый торган иде Сара апа. «Үз илемдә», «Идел суы ага торыр», «Ак пароход» һәм «Без—Казан кызлары», «Яшь күнел», «Һәйкәл жыры»—бу унышлы ижат дуэтынын кайсыберләре генә. Хәер, «жыр остасы» булып киткән Гөлшаттан «жыр комганы» Мостафа Ногман да калышмый. Төз, озын буйлы, кара бөдрә чәчле Мостафанын рәвеше Сара апаны анын сүзләренә «Солдатым», «Институт баскычлары» кебек махсус ижат жимешләрен тудырырга илһам-дәрт бирә... Ә инде туган жиренә, татар авылына ихлас гашыйк остабикә бер-бер артлы «Туган авылыма», «Актаныш таннары», «Арча кичләре», «Балкый Шаймөрзә утлары» кебек гүзәл әсәрләрне дә тудыргач, Сара апа халык күнелен ихлас кочып-сарып ала кебек!

Хәер, шигърияткә гашыйк, үзе дә жаны белән шагыйрә булган Сара ханым ерак дусты, мөлаем Мостай ага Кәримне дә, Себердән, сөргеннән исән-сау кайткан жан дусты Хәсән Туфанны да онытып бетерми. Урал якларына ул «Өченче көн тоташ кар ява» кебек монлы хатирәләрен жибәрә, ә якташына «Туган туфрак», «Казан кичләре» кебек шигырьләрен жыр итеп, жырлап-көйләп тапшыра.

Күпне күргән Нәби Дәүлине дә («Татарстан—минем Республикам», «Уфа ни өчен матур»), гариб, әмма хөр жанлы Гамил Афзалны да («Дөнья матур, дөнья кин», «Әлли-бәлли, былбылым») онытып бетерми ул. Бу жырлары белән аксакалларны да, халыкны да сөендерә, күнелен күтәрә, рухын сафландыра.

Әлбәттә, Сара апанын күнеленә хуш килгән каләм ияләре байтак. Әмма арада, Илсөяр Ганиева кебек, үз исеме ук жырлап торганнары да бар бит! Жан дустына Сара апа бер-бер артлы «Кайтыгыз, торналар!«, «Йөрәк сере», «Ник сонладын» кебек ихлас мон чишмәләрен ачып жибәрә.

Жан дусты, ихлас күнелле Илдарына да (Юзеев инде!) Сара ханым »Кайтам инде», «Бөркет турында жыр» кебек шедеврлар бүләк итеп калдырырга өлгерә. Ачык йөзле, ачык жанлы Сара апа үзенә үтенеч белән килгән һич бер ижат кешесен дә кире борып жибәрми. Нәтижәдә, көтеп алынган «Комсомол жыры», «Яшьлек эзләре» (Мансур Шиһапов шигырьләре) кебек көн калагына сугып язылган, йәисә «Горурлыгым», «Исә жилләр» (Нурмөхәммәт Хисамов шигырьләре) шикелле чын күнелдән бәреп чыккан монлы ядкарьләр туа. Боларга өстәп, Әхмәт Рәшитов сүзләренә язылган, чын халык жырлары булып хәтер-жанга сенеп калган «Беренче мәхәббәт», «Язгы гөлем» кебек һәм гүзәл һәм популяр көйләрне дә искә төшерик...

Әлбәттә, Сара Садыйкованын жыр ижаты гаять бай һәм күпкырлы. Арада Г. Рәхим («Ветераннар»), З. Вәли («Иртәнге нур»), М. Галиев («Безнен буын»), Р. Юнысов («Туй жыры»), Р. Фазлыев («Ешрак яз, әнкәй, хатларынны») Ш. Маннапов («Керфегенә тамармын мин...»), С. Шәрипов («Алпар таннары»), С. Шакир («Балтачым—туган ягым») кебек заказ буенчарак язылганнары да байтак... Әмма чын ижатчы, саф күнелле, аек акыллы ханым боларак, Сара апа бу көйләрне ижат итәргә дә жанын-гакылын кызганмый, рухланып-илһамланып яза!

Арада үзе кебек чал чәчле, мәшһүр әдипләр дә очрап куйгалый кайчак. Күптәнге танышы, ижаттәш дусты, театрга гашыйк драматург Риза ага Ишморат белән дә ул монлы хатирә итеп «Әй, ямьле син, Минзәлә ягы» кебек ихлас монлы жыр тудыра. Роберт Миннуллиннын «Әнкәй» жыры да үзенең янача янгырашы, аһәне белән күптән таныш, жанга сенгән «Әниемә хат», «Әниемнен жылы кочагы»н кабатламый бит, шөкер.

Ә бит Сара апанын гел бер үзе генә язган «Мөслим тугайлары» кебек шедевры да бар әле! Күрәсен, серле, монлы Мөслим яклары Сара ханымнын жанын да сарып алырга өлгергән!



*Сара Садыйкова язучыларыбыз арасында. 1980 ел.*

Хәер, монда шаккатырлык бер нәрсә дә юк. Моның өчен, Сара Садыйкованың үзе кебек саф җанлы, олы, эчкерсез күңелле ихлас зат, шәхес булырга гына кирәк!

Мин кечкенәдән үк белгән Сара апам кайсыдыр ягы белән мәрхүм әнием Сара (Бибисарага) охшаган кебек иде. Әниебез дә яшь чакта нәкъ шундый ук нечкә тавышлы җырчы булган. Моңга, шигъриятькә гашыйк, халкыбызның бөтен җыр-көйләрен, Тукай-Такташ шигырен яттан белгән моңлы-тыйнак мөлаем зат иде ул. Иң яраткан әдибе—Гомәр Бәширов иде. Хәер, Сара апа да бу олуг әдип, күркәм затка битараф түгел—моны ул үз иҗаты белән дә раслады.

Нәкъ менә Сара апаны эзләп, халык кушуы буенча мин берзаманны юлга чыктым. Мәшһүр җырчы, композиторның өй-фатирын бик озак эзләдем. Ниһаять, елга портына барганда уң кул якта, тимер юл күперенә җиткәндәрәк, эчтә, Кәрим Тинчурин урамы башындарак биш катлы «хрущевка»да урнашкан, беренче каттагы кечкенә, караңгы гына бер фатирны эзләп таптым һәм, дулкынланып, звонокка бастым...

Ишекне башына шул ук калфагын элгән, кечкенә генә, ачык йөзле бер әби ачты! Нәкъ афиша-фотолардагы мөлаем, ачык, елмаючан Сара апа! Ә ул мине исемемне әйткәч кенә танып алды:

—Ә-ә-ә, теге аксак-туксак, гаҗәп затлы моңлы Фасил энесе икән... бераз аңа да, әтиең Әхмәтгалигә дә охшагансың, тик син күбрәк аның карчыгы Сарага тартымырак бугай... Алайсам, Сара малае ич син, димәк, минем үз улым шикелле, фронтовик Әхмәтгали улы! Гармунда уйныйсыңмы? Җәл, уйнамыйсың икән. Ә җырлыйсыңмы? Миңа кайчандыр артистларның кайсыдыр сөйләгән иде: анда, Саба урманында, клубта концерт башлаганчы 4-5 яшьлек «Рафис-бәләкәй артист»ны җырлаталар дип, димәк, син икәнсең ул, юкка гына музыкаль редакциядә эшләмисеңдер алайсам. Абыең Фасил-гарип, моң-зар, сагыш иясе, композитор шуна күрә. Ә син кем? Шагыйрь? Менә сиңа «м-ә-ә!» Әйдә, бер шигыреңне сөйләп күрсәт алайсам, абыең да сүзләренә берәр җыр язгандыр әле... Юк! дисеңме? Ничек инде бу? Очраганда әйтәм әле Фасилгә, язсын!

Ә менә мин сиңа үземнең иң яңа, иң матур җырымны җырлап күрсәтәм, әйдә, уз, утыр түргәрәк! Бу җыр «Җидегән чишмә» дип атала. Аны бик танылган зат язган. Менә сиңа сынау: кем язган бу гүзәл текстны?

Сара апа, пианино артына утырып, яңа көен уйнап, җырларга кереште... Гаҗәп,

нинди матур, халыкчан көй, сүзләре дә бик матур! Ә кем шигыре соң?

Озак баш ваттым: Мәхмүт Хөсәен дә, Мостафа Ногман да, Әхмәт Ерикәй дә түгел! Аптырагач, Сара апага:

—Моны, минемчә, атаклы «Тукай» романы авторы, үзе әйбәт, көчле дә булган Әхмәт Фәйзи исемле шагыйрь язган булса кирәк!

—Фикер орлыгың бар, энем!—дип, күзләрен кысып, якты елмаеп куйды Сара апа.—Чыннан да, бу автор да көчле прозаик, тик шагыйрьлегең генә гомере буе яшереп йөргән кебек...

—Кем соң инде ул, яшерен егет?

—Кем булсын? Гомәр Бәширов, укытучы-остазың Мөхәммәт Мәһдиевнең бабасы, ягъни хатынының әтисе!

Сара апаның бу хикмәтле бүләге мине таң калдырды! Чыннан да, нинди гүзәл җыр—«Җидегән чишмә» кебек шедевр туган бит. Менә сиңа карт Гомәр Бәшир! Яшьләрне дә уздырып җибәргән бит «Намус» иясе!

Сара апа мине тиз генә кайтарып җибәрмәде, мин дә ана үтенечемне сөйләп бирдем, «Хатлар укыганда» тапшыруына чакырдым. Мөлаем Сара «әнием» мине ашатып-эчертеп, тукталышка кадәр озатып та куйды. Тапшыруга килеп, бик истәлекле, кызыклы, гыйбрәтле интервью бирде. Аның яңа җырын—«Җидегән чишмә»не бик матур итеп җырчы Рабига Сибгатуллина җырлап бирде. Тиздән бу җыр бик киң таралды, гаҗәеп популярлык казанды. Сара апа белән алга таба еш күрешә-сөйләшә-аралаша башладык. Бераздан аңа да Татарстан урамындагы өч биек йортларның берсеннән менә дигән шәп фатир бирделәр. Композиторлар берлегенең рәисе итеп Нәҗип Җиһанов урынына Мирсәет Яруллин, аның урынбасары итеп Фасил Әхмәтов сайлануга, йөзләгән гүзәл җыр авторы Сара Садыйкованы да композиторлар Союзы әгъзасы итеп алдылар, ниһаять... Кызганыч, ул чорда инде мәңге «һәвәскәр» булып калган Шакир Мәҗитов, Арслан Батыршин, Фәтхерахман Әхмәдиевләр кебек гүзәл җыр осталары якты дөньядан киткәннәр иде. Ә безнең тиңсез Сара апа көйләре дә, аның нурлы йөзе дә һаман сәхнә түрендә, һаман безнең күңелләрдә елмаеп тора!

*Карыйм да мин моңсу-матур йөзгә,*
*Сагыш сарган шомырт күзләргә,*
*Күңелемне сагыну-сагыш сара,*
*Чыгып китәм аны эзләргә!*

*Һәр балконнан, ачык тәрәзәдән*
*Ишетәм күк халкым Сарасын.*
*Күңелен рухландырып, яшәртергә*
*Тапкан татар кирәк чарасын...*

**Рафис ӘХМӘТ**

# МӘЙДАНГА ИЛТКӘН ЮЛ

«Язмыш һәм узмыш» дигән истәлек авторы—50 ел гомерен театр белән бәйләгән кеше. Шуның 5 елы—Щепкин исемендәге театр училищесының татар студиясендә уку, 45 елы—Камал театрында эшләү. Ул—Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Тукай бүләге лауреаты.

Сабакташларына эпиграммалар язган Равил Шәрәфиев Әзһәр Шакиров турында болай ди:

*Щепкинчылар арасында*
*Иң яшебез син идең.*
*Иң акыллы, иң хәйләкәр,*
*Иң картыбыз син бүген.*

Аксакал, ягъни!

Һөнәри осталыгы олы исемнәр һәм халык мәхәббәте белән расланган актерны башка хезмәттәшләреннән иң нык аерып торган сыйфат турында сөйләүдән алда сигез ел элек «Казан утлары»нда чыккан бер әңгәмәне искә төшерик әле.

Драматург, актер һәм режиссер гәпләшә. Сүз җебе милли хәрәкәткә килеп ялгангач, режиссер болай ди: «Хәзерге актив милләтчеләр «милләт» сүзен әйтергә курыккан вакытта да театр татарча сөйләшә иде... Без урамга чыгып кычкырып йөрмәдек, әмма һәрвакыт татар теленең чисталыгы өчен көрәштек, татар моңын, гореф-гадәтен күрсәттек...»

Татар сәхнәсендә татарча сөйләшкән өчен рәхмәт анысы. Ләкин...

Габдулла ага Шамуков искә төште. «Казан утлары»ның иске төпләмәләрендә аның язган ике әйберсе саклана. Икесе дә шәпләп өйрәнеп, күп вакыт сарыф итеп язылган. Берсе—1969 елда КПСС Үзәк комитетына, СССРның һәм РСФСРның мәгариф министрларына җибәрелгән хат тексты. Анда ул Россиядә күпчелек милли мәктәпләр тоташтан рус теленә күчерелүнең бөтен зарарлы нәтиҗәләрен ачып сала. Сөембикә манарасы турындагы мәкаләсе дә татар гамен гамьләп язылган. Мондый да четерекле, хәтәр өстәмә мәшәкать данлыклы актерга нигә кирәк булган соң?

1991 елның Татарстан өчен хәлиткеч көннәрендә Илдус Әхмәтҗанов шагыйрь абыйсы белән Ирек мәйданындагы сәяси ачлыкка ни дип кушылган әле? Татар моңы житмәгәнгә яки сәхнәдә татарча чиста сөйләшмәгәнгә түгелдер ич?

«Урамга чыгып кычкырып йөрү» дигәннән. Ирек мәйданында үткән бер митинг истән чыкмый. Митинг инде сүнеп-сүрелеп бара иде. Чөнки 3-4 әйбәт кенә чыгыштан соң халык бик белмәгән, сөйләү осталыклары да, фикерләре дә чамалы булган милләтпәрвәрләр нотык тотты. Шулвакытны микрофон каршына Әзһәр Шакиров чыгып басты. Шигырь-мазар укырга дип дәшкәннәрдер инде.

—Газиз милләттәшләр!

Таныш һәм тансык көчле, куе тавыш киң мәйданны яңгыратты. Юк, үз сүзләрен әйтә. Ихластан—бәгырь түреннән чыкканны сөйли. Бәгырь түренә үтеп керерлек итеп. Гәүдәдә, кул селтәп җибәрүләрендә, тавышында олпатлык, мәгърүрлек бар. Гайрәтле хак сүзне сәхнәдә Пугачев һәм Туктамыш хан булып та яшәгән кеше авызыннан ишетү гел бүтән икән бит ул.

1990-92 елларда мәйдан ораннарыннан хакими тәрәзәләр зыңлап тормаса, татар мәңге горурланып искә алырлык закон-карарлар кабул ителер идеме икән? Һәм дә танылган шәхесләребез, Балтыйк буе республикаларындагы кебек күпләп чыгып, мәйданның куәтен унлата-йөзләтә арттырган булса, аларның барын да җуяр идек микән? Кемнәрнеңдер гомум ирекне шәхси милеккә алмаштыруына юл куяр идек микән?

Кызганыч ки, күп, бик күп зыялыларыбыз, шул җөмләдән, татар теле, татар

мәдәнияте исәбенә тамак туйдырганнары да, туксанынчы еллар дулкынын өстән шома гына үткәреп җибәрделәр.

Сөттән ак, судан пакь күренгән бер иш кешеләр бар. Татарнын кайгы-гамьнәре турында сөйли башладынмы, алар, чирканган сыман, сүзне башка нәрсәгә күчерә. Ләкин бит... Туган халкың, милләтеңә карата намуслы түгел икәнсең, син гомумән дә намуслы кеше түгел инде.

Әзһәр Шакировны исә мәйданда тагын күп тапкырлар очратырга һәм тыңларга насыйп булды әле. Кемнәрдер татар мәйданына теге дулкын белән килеп, шунын белән китеп тә барсалар, Әзһәрнең килүе күп элегрәк башланып, ихлас һәм ныклы булды. Бу ул язган истәлектән, дә күренә. Театр елъязмасына кирәклек, укучыларыбызны елмайтырлык та, уйландырырлык та вакыйгалар бар анда.

**Рәфикъ ЮНЫС**

---



Әзһәр
Шакиров

## ЯЗМЫШ ҺӘМ УЗМЫШ

(АРТИСТ ЯЗМАЛАРЫ)

*Кеше фәкать үләре алдыннан гына нәрсә эшләргә кирәк булганлыгын аңлап ала.*

Адәм балаларының язмышлары төрлечә була дигән гыйбарәгә ничек ышанмыйсың: егерме йортлы кечкенә генә бер авылдан чыккан ике артист 40 ел буена Г. Камал исемендәге татар Академия театрында эшләсен әле! Болардан берсе—Нәҗибә ханым Ихсанова, икенчесе мин идем.

Челтерәп аккан чишмәләрне, таллар, зирек агачлары, әкерен генә аккан инешне күз алдыгызга китерегез. Тау битләрендә кызарып пешкән җиләкләр, исле гөлләр, мәтрүшкәләр—кыскасы, санап бетергесез төрле-төрле үлән, чәчәкләр. Өйдән ишек алдына чыккач та, синең җаныңны шушы матурлык билəп ала. Бер сүз белән әйткәндә, үзенә күрә бер оҗмах инде. Урманында җаның ни тели—бар да бар: чикләвек, миләш, шомырт, карлыган, кура җиләге, сирәк кенә булса да, чиясенә кадәр табарга була. Иң кадерлесе: ул җирләрне машина, трактор таптамаган, анда зур көтүләр кермәгән, табигать ничек бар, шулай сакланган. Су буйларында «Йомыры күл», «Җирән күл» дигән чокырлар бар, тирәнлеге ике-өч, киңлеге өч-дүрт метр. Шул суларда кушбаш балыклары йөзеп йөри, нинди зурлыкта икәнен

---

Әзһәр ШАКИРОВ (1940)—*Татарстанның һәм Россиянең халык артисты. Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

бөтен матурлыгы белән күреп була. Шуларга сокланып, кызыгып, ничек кенә тотарга икән дип уйлап, көннең узып киткәнен дә сизми каласың.

Мин үземнең авылдашларымны менә шул чиста суларда йөзгән балыкларга охшатам. Чыннан да, авыл кешесенең чисталыгы, намуслы булуы әллә кайдан күренеп тора. Безнең авыл кешесе турында сөйләп тә, язып та тормыйм. Мин авылда аракы эчеп, сүгенеп йөргән кешене күрмәдем, хәтерләмим. Эчәргә, бәлки, мөмкинлеге булмагандыр, әмма ояты да бар иде.

Безгә кайда да булса укырга кирәк ич инде дип, үзебезне Казанга, институтка укырга керергә әзерлибез. Моның өчен колхоздан белешмә алырга кирәк. Сине колхоз укырга җибәрергә рөхсәт бирә, дип. Колхоз рәисе Кәнәгать абый артыннан басуда, сөргән кара җирдә:

«Кәнәгать абый! Кәнәгать абый! Зинһар, справка бир инде»,—дип, җылый-җылый Нәҗибә белән чапканым әле дә хәтеремдә. Ул ат өстеннән генә: «Әгәр без сезне колхоздан җибәрсәк, монда эшләргә кем кала?»—дип, котыбызны алган иде. Рәхмәт инде, бик ялынгач, язып бирде.

Паспорт алуым да хәтеремә бик уелып калган. Безнең авылдан район үзәге Тымытыкка кадәр 40 чакырым. Иртән иртүк Нәҗибә белән җәяү чыгып киттек. Бер чабабыз, бер йөгерәбез. Ниһаять, көндезгә әбәткә барып җиттек. Милиция, паспорт бүлеге дигән язуны күргәч, котым алынды. Керергәме, кермәскәме дип озак азапландым. Нәҗибә алып кереп китте. Паспорт бирә торган бер апа миңа карап торды да: «Юк, энем, сиңа паспорт биреп булмас, кыяфәтең паспортка төшәрлек түгел. Кара инде бу күлмәгеңне, кара инде бу чалбарыңны, аягыңда бер нәрсәң дә юк. Яланаяк паспорт алырга килмиләр. Совет паспортын синең кебек хәерчеләргә бирмиләр. Ул—Совет гражданинының горурлыгы. Бар, кире авылыңа кайтып, кәчтүм, ак күлмәк, аягыңа ботинка киеп кил»,—диде. Мин нишләргә дә белмичә, ап-ак булып каттым, бер сүз эндәшергә куркып, күләргә дә, җыларга да белмичә басып торам. Шуннан түзмәдем: «Апа, безнең авыл моннан кырык чакырым бит, мин ничек кайтып килим? Аннан соң мин авылда паспортлы кешене күрмәдем дә. Миңа ничек киенергә кирәк икәнен әйтмәделәр»,—дип елап җибәрдем. Шунда фотога төшерүче бер абый мине җәлләп алып чыгып китте. «Ярый, бик, борчылма, аягың белән чалбарың күренми анда. Күлмәгең бик искергән, кәнишне. Анысын гына табармын, шуны киярсең»,—дип, җанны тынычландырды.

Хәзер инде ул паспортны кайчан алганымны хәтерләмим. Әллә шул көнне алдык, әллә яңадан килеп. Ә менә шул ук көнне 40 чакырымны тагын җәяүләп кайтканым һаман да исемдә. Чуар Абдул авылының колхоз бакчасыннан кишер урлап, туйганчы ашадык.

Минем бәләкәй чагымда авылыбызда тыңлыйм дисәң радио да юк, театр артистларын, җырчыларны да күрергә насыйп булмады. Ә без Яңа елны, Октябрь бәйрәмен барыбер үзебезчә матур итеп, концертлар белән каршы ала торган идек. Мин үзем ул чакларда сакаурак шикелле, кечкенә гәүдәле булганга күрә, сәхнәдә күренүемә халык эче катып көлә иде. Яман кычкырып сөйлим, ни әйткәнемне аңламыйлар, шуңа күрә халык көлгән саен боларны көлдертәсем килеп тора.

Үзем дә сизмәстән, Ходай Тәгалә мине, шулай итеп, театр дигән иҗтиһадка әкренләп әзерләгән, күрәсең. Туры килүе кирәк бит: без унынчы сыйныфны тәмамлаган елны татар артистлары әзерләү өчен Мәскәүдәге Щепкин исемендәге театр училищесына укучылар җыялар икән дигән хәбәр иңде.

Казанда Горький урамындагы татар академия театры бинасына кергәч, минем исем-акылым китте: тышта шундый эссе, ә монда сап-салкын. Җитмәсә безнең документларны кабул итүче абый (ул Татарстанның халык артисты Һидият Солтанов булган):

—Энем, синең буең бик кечкенә. Артистлар озын буйлы, матур булырга тиешләр,—диде.

Мин әллә ни каушап калмастан:

—Абый, мин үсәм әле. Минем абыйлар синнән дә зурлар,—дигәч, ул шушы сүзгә рәхәтләнеп көлде дә, Нәҗибә белән минем документларны алып калды.

Менә имтихан вакыты да килеп җитте. Беренче мәртәбә матур кызларны,



*Сулдан уңга: Ф. Әхтәмова, Р. Шәрәфи, Г. Исәнгулова, Ә. Шакиров, Н. Ихсанова, Р. Таҗетдинов, Н. Дунаев.*

чибәр егетләрне күреп шаккаттым: Наил Дунаев, Ринат Таҗетдинов, Хәмзә Бәдертдинов, Хәмбел Закиров. Гомумән, минем ише уналты яшьлек чандыр бер малай белән чагыштырганда болар инде бөтенләй бүтән кешеләр шикелле иде. Менә шулар белән ярышып, артист булам дип кара әле син! Имтиханга кияргә дә җүнле кием-салым юк. Ярый әле җизни тиешле кеше үзенең күлмәге белән чалбарын биреп торган иде. Аякка кияр нәрсә дә юк бит. Чөнки Казанга барышлый бик көчле яңгыр явып, аяк киемнәребезгә кап-кара балчык чабатадай ябышкан, кайтарып алмалы түгел. Атларлык булмый башлагач, ул аяк киемнәребезне Нәҗибә белән бергә Рангазар күпере астына төштек тә яшереп калдырдык—кайтышлый кире алырбыз, янәсе.

Әле иң кызыгын сөйләргә онытканмын: Сарманнан машинага утырып, Чаллыга килеп төштек. Әйткәнемчә, аяклар тездән кара балчыкка ябышып каткан. Чаллы пристанендә аякларны, битләрне юып, пароходка утырабыз. Мин инде билет алып тормадым, халык белән буталып, ык-мык килеп, пароходка кереп киттем. Күрәм, билет тикшерә башладылар. Тиз генә пароходның гомердә дә кеше керә алмый торган бер җиренә кереп постым. Монда кеше бар дип, әлбәттә, беркем дә уйламаячак. Өч-дүрт сәгать узгач, караңгы төште. Шуннан соң гына хәлен белергә Нәҗибә янына килдем. Ул минем билетсыз икәнемне белми бит, күз алдына да китерә алмый. Ничек инде курыкмыйча пароходка билетсыз керергә мөмкин? Мин үзем дә нәрсә эшләгәнемне аңлап, куркуымнан калтыранып тора идем. Нәҗибә: «Син нәрсә, авырыйсыңмы әллә?»—дип сорады. Юк, мин әйтәм, әз генә калтырата, яңгырда салкын тигән ахрысы, дим.

Менә Казанга да килеп җиттек. Трaптан төшкәндә зур гына гәүдәле бер урыс егете билетларны тикшереп тора. Нишләргә белмичә, чиратымда аптырап торам. Мине халык этә-төртә алга таба этә башлады. «Ну что стоишь? Глухой что ли?»—диешәләр. Билетларны тикшерүче урыс янына китереп бастырдылар. Ул миннән билет сорый, мин, авызымны ачып, бер сүз дә әйтә алмыйм, аякларым атламый. Гомеремдә беренче мәртәбә урамга чыккан сарык бәрәне кебек, аптырап карап торам. Шуннан соң бу кеше минем арт ягыма китереп типте дә очып киттем инде. Фанер сандыгым ачылып китеп, әни биргән йомыркалар төрлесетөрле якка тәгәрәште. Китап битенә әйбәтләп төргәнгә, барысы да ватылып бетмәгән иде әле. Нәҗибә: «Нәрсә булды? Бик озак тордың»,—ди. Мин әйтәм, билетымны югалтканмын, таба алмадым, дим. «Әйдә инде тиз бул, әнә трамвай кузгала». Кая,

без утырганчы, трамвай кузгалып та китте. Артыннан чабабыз да чабабыз. Үзебез: «Туктагыз, туктагыз инде!—дип кычкырабыз. Белмим, әллә тукталыш булды, әллә кешеләр зур сандыклар күтәргән яланаяк авыл балаларын җәлләп микән, трамвайны туктаттылар. Монда да билет саталар икән, урысча «билет алыгыз» дип, янымнан бер апа ике-өч мәртәбә узып китте. Шуннан кыяфәтемә карап торды да, кулын селтәп, җирәнгән кыяфәттә урынына барып утырды.

Менә хәзер минем хәлемне күз алдыгызга китереп карагыз инде. Шулай да мин бу хакта артык пошынмадым, ничек булса да кермен, бәлки, кызганырлар әле, дип уйладым. Ул вакытта кешенең төс-кыяфәте, кигән киеме театрда нинди урын тотканын мин каян белим дә аңлыйм ди инде?

Укырга кергәч, әти-әнигә үземнең артист булырга укуымны бик озак гомерләр әйтмичә оялып йөрдем. Чөнки алар минем артистлыкка җыенуымны күз алдына да китерә алмаслар иде. Үз баланны ун ел буена җәфаланып укыт-укыт та, үзең белмәгән-күрмәгән шөгыльгә укырга җибәр, имеш. Әгәр дә мин йә укытучы, йә врач, йә колхоз председателе булырга укыйм дисәм, алар мине аңларлар иде аңлавын. Инде менә хәзер уйлап куям да аптырап торам: әти-әнидән: «Улым, нигә анда укыйсың?»—дип бер авыз сүз ишетмәдем. Рәхмәт яусын аларга, урыннары оҗмахта булсын.

Шулай, Равил Шәрәфиев белән бергә Мәскәү урамы буенча беренче мәртәбә дәрескә барабыз. Мин, гомер күрмәгән матур биек йортларны карый-карый бара торгач, маңгаем белән нәрсәгәдер шундый килеп бәрелгәнмен ки, күземнән утлар күренде; борынымнан шарлап кан киткән. Җирдә ятам. Ул арада тирә-юньгә халык җыелган. Нишләдең, нәрсә булды, дип сорыйлар. «Гомердә мондый матур йортларны күргәнем юк иде, шуларны карап җыгылдым»,—дип әйтә алмыйм бит инде. «Ялгыш аягым таеп китте дә сөрлегеп егылдым.»—дидем.



*Сулдан уңга: Әзһәр Шакиров, Марсель Сәлимҗанов, язучы Леонид Леонов.*

Җитмәсә шушы хәл аркасында дәрескә соңга калдык. Хәмбел Закиров:—Әгәр тагын бер мәртәбә соңга калсагыз, училищедан кудыртам,—дип котны алды.

Инде бер заманны Мәскәүнең Зур театрына «Иван Сусанин» операсын тыңларга бардык. Әлеге бинаның тышкы, эчке матурлыгына шаклар каттым. Бигрәк тә сәхнәдәгеләрнең кычкырып-акырып җырлауларына карата: «Нигә инде болар гади генә сөйләшмиләр икән?»—дим. Ә инде сәхнәгә матур ике ат килеп чыккач, бөтенләй аптырап калдым, сөенечемнән күземә яшьләр килде, авылны күргәндәй булдым. «Карагыз кара! Нинди матур атлар!»—дип сикереп торып, янымдагы тамашачыларга төртә-төртә күрсәтәм. Кайберәүләр көлешә, мине ишарәләп, күршедәге бер апа кисәтү ясады. Әй, мин әйтәм, менә нинди була икән ул опера, дим.

Бер студенттан опера белән опереттаның аермасы нәрсәдә дип сорыйлар да, ул: «Опера—мужчина, оперетта—женщина»,—дип җавап биргән. Мин дә нәкъ шул студент хәлендә идем инде.

1957 елда Татар академия театры Мәскәүгә гастрольгә килгәч, үз гомеремдә беренче мәртәбә татар театры спектаклен күрү насыйп булды. Спектакльгә бернинди билетлар калмаган, тамаша залы тулы. Шунда мин дә «Хуҗа Насретдин» спектаклендәге Җиһангир ханның яугире булып катнаштым. Режиссер Шириаздан ага Сарымсаков:

—Сез яман көчле, кыргый сугышчыларны уйныйсыз, сездән барысы да куркып, коты алынып, калтырап торырга тиешләр. Карагыз аны!—диде.

Без Равил Шәрәфиев белән Хужа Насретдинның хатынын кулга алырга тиешле. Әлеге рольдә бик талантлы, өлкән артистка Фатыйма апа Камалова уйный иде. Без аңа шундый итеп—акырып-бакырып, кыргыйларча ташланганбыз ки, Фатыйма апаның сәхнә идәнендә:

—Әй, балалар! Үтердегез-үтердегез, - дип өзгәләнә-өзгәләнә әйткән сүзләре әле дә хәтеремдә.

Сөякләрен ничек сындырып бетермәгәнбездер.

Шул ук спектакльдә Хәлил ага Әбҗәлиловның Хужа Насретдин ролендә уйнавын гомеремдә дә онытасым юк. Шәрәфи белән Хан сараенда ханның әмеренә теләсә кемнең башын чабып өзәргә әзер торган куркыныч кыяфәтле явыз сакчылар кыяфәтендә басып торабыз. Шунда Хәлил аганың уеныннан икебезнең дә авызлар җырылган. Сәхнәдә онытылып торып шырык-шырык көләбез. Югыйсә, тукта инде, без бит—сугышчылар! Безнең сәхнәдә шулай көлгәнне белсәләр үтерәчәкләр бит инде. Үз-үзебезне көчкә-көчкә тыеп калабыз. Сәхнәдәге артистлар бөтен нәрсәләрен онытып көлә икән, тамашачы нигә көлми калсын.

Талантлы артистның ничек уйнаганын мин менә шунда күрдем инде.

Без укыганда Әзәрбәйҗан, Үзбәк, Казакъ, Төрекмән, Таҗик театрларын карарга туры килде. Шулар куйган спектакльләр арасында безнең татар академия театрына тиңнәр юк иде. Бәлки, моңа Мәскәү татарларының күп булып, агылып-агылып килүләре дә ярдәм иткәндер. Әйтик, «Зәңгәр шәл» спектакле белән гастрольләрне япканда тамашачы шундый күп иде ки, театр бинасын хәтта атлы милиция саклады.

Менә шунда минем күңелемдә татар театрына, артистларына бик зур хөрмәтем уянды да инде. «Үз артистларыбыз да урыс артистларыннан ким уйнамыйлар икән», - дигән уй башыма керде. Халыкның сәнгатен, талантын билгеләгәндә шуны әйтәсем килә: сан исәбеннән күп булмаган милләтләрнең дә зур талантлары бар. Әйтик, Чыңгыз Айтматов, Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиев, Мостай Кәрим... саный китсәң, алар шактый. Татар театры да рус дөньясында югалып калмады, үз урынын тапты; чөнки татар халкының җанында, канында бер «җен утыра»: ул—театр уйнау. Мин театрны безнең тамашачы кебек яраткан милләтне белмим. Театрда 40 ел гомерем узгач, шуны әйтә алам: әгәр дә татар театры булмаса, милләтнең язмышы бик күңелсез булыр иде. Әле кайчан гына, Советлар Союзында бер генә милләт булырга тиеш, дип килделәр: ул да булса—«советский народ», ягъни бөек рус халкы. Шул вакытта без татарлар татарча сөйләшергә оялып, татар баласы булуыбыздан хурланып, ничек кенә булса да рус булырга тырыша идек. Хәтта шуңа кадәр барып җиттек ки, ана телен белмәгән бер-бер бала иң укымышлы санала иде.»Минем улым татарчасын бөтенләй онытты»,—дип, ата-аналары горурланып сөйләүне дәрәҗә санарга кереште. Безнең мескенлегебез, наданлыгыбыз менә шул вакыттан калды бит. Ничә йөз еллар буена сакланып килгән газиз ана теленнән, гореф-гадәтләреннән, иманыннан баш тартып кара әле син! Башында мие булган аңлы кеше шуны эшләр хәлгә төшсен әле! Безне шуңа өйрәттеләр, без үзебезнең «икенче сортлы» халык икәнлегебезгә, кол булганыбызга шулкадәр дә күнектерелгәнбез ки, бүтән тормышны күз алдына да китерә алмастайга әйләнгәнбез.

Театрда туганнарыбыз, дусларыбыз белән очрашабыз, бер-беребезгә хөрмәт уяна иде. Мәскәү, Ленинград, Алма-Ата, Ташкент, Фрунзе, Чиләбе, Свердловск шәһәрләрендәге тамашачы безне, иң зур кунакларны кабул иткәндәй, бәйрәм төсендә каршы ала иде. Аларның күңелендә, йөрәгендә милли хисләр уяна, моңнары кузгала, артистларның уенына горурлану, үз ана телендә спектакльләр карау аларның җанына рәхәтлек бирә торган иде. Әлбәттә, моны һичкем дә сөйләп йөрмәде, ә бәлки үз күңелендә генә йөртте. Татар халкы милләт буларак юкка чыгарга торганда, язмышның иң авыр вакытында мин үз гомеремне татар театрына биргән һәм, кулымнан килгәнчә, хезмәт иткәнем өчен күңелемдә үзгә бер горурлык хисе кичерәм. Минем белән бергә укыган шәриктәшләремнән башка татар театрын күз алдына китерү бик тә кыен булыр иде.

*Ахыры киләсе санда*

# «ИНДЕ ҮЛСӘМ ДӘ БУЛА...»

## МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ. КӨНДӘЛЕК СӘХИФӘЛӘРЕ

*Мөхәммәт Мәһдиев көндәлеген тарих өчен язмаган һәм "күптомлыкның фәләненче томына керер" дип тә исәп тотмаган. Ләкин язучының шәхси тормышына кагылышлы фактлар, аның уй-фикерләре, эчке кичерешләре иҗатын һәм язмышын тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Шул максаттан укучыларга көндәлекнең иң кызыклы сәхифәләрен тәкъдим итәргә булдык.*

*Гомумән алганда, бу язмалар бик чуар, алар көндәлек кысасына сыеп та бетми. Монда: тормышта күргән вак детальләрдән туган образлар, хикмәтле сүзләр, кызыклы яки аянычлы хәлләр, халык авыз иҗаты әсәрләре (җырлар, такмаклар, әйтемнәр), әдәби әсәрләрдән (проза, поэзия), шул рәттән рус һәм чит ил язучылары иҗатыннан цитаталар, күңел халәтенә шул мизгелдә тәңгәл килгән шигырьләр, җырлар, бөек затларның әйткән сүзләре, үзенең кешеләр һәм яшәү хакындагы фикерләре, уйланулары, тормышында булган вакыйгалар һ. б. Язмаларның бер өлеше киләчәк иҗаты өчен материалдыр.*

*Көндәлек язмалары хронологик тәртиптә урнашмаган. Авторның, күрәсең, үзенең нниндидер бер эчке тәртибе булган... Соңгы язмасының датасы—1995 елның 18 марты.*

**Гәүһәр ХӘСӘНОВА**

**1974.** Бүген соңгы экзаменнарны алып тиз генә поездга утырып авылга киттек, балалар янына. Курса станциясеннән басуга чыккач гаҗәпкә калдым: андый биек куе арыш басуын күргәнем юк иде. Арыш серкәләнгән, биеклеге ике метрга якын. Бал исе, салат исе килә... Бу минутта миннән дә бәхетле кеше юк иде. Язмыш миннән андый минутларны күпсенмәсен иде. Алла да.

**1974.** Бүген мин авылга кайтып килмәкче булдым... Быел көз коры, бик җылы килде. Хәзергә каләр көндез 20-25, төнлә 10-15 градус җылы, бөркү, коры һава. Тәннең тыны бетә, бөтен дөньяны төтенсыман сөрем баскан, тузан болыты йөри. Нниндидер афәт, ил өстенә килгән бәхетсезлекне хәтерләтә. Кәефләр начар, тән борчыла.

...Безнен урманның бер почмагы мине гел борчып тора. Сугыш вакытында җиләккә баргач мин гел шунда чыгу ягын каера идем. Анда җиләк тә булмый иде. Телефонлы олы юл кырыендагы бер квартал почмагы ул. Анда башлары корган карт юкәләр, биек-биек юкәләр. Аларның башында күке, тилгән кебек кошлар утыра. Телефонлы юл сузылып инкүлекләр аша еракка китә. Аның ике очы ике дөньяга алып бара: берсе—Мөрәле ягына, анда ачлык, сазлык, фәкыйрьлек, караңгы урман, еланнар, мунчала күле, бүре оялары—караңгы!

Икенче ягы олы таш юлга таба сузыла. Кояшлы көннәрдә ул як еракларга чакырып зәңгәр-аяз булып күренеп тора. Шул юкә төпләренә сөялеп, ятып мин күккә карый, еракка, таш юлга карый идем, ерак-еракларга китәсе килә иде. Мин бик ерак илләрдә, ерак җирләрдә булдым. Менә хәзер йөрәкне телеп-телеп сагыш кайный, шул юкә төпләренә барып утырасы килә. Һиндстанга барып кайтып була, әмма әнә шул—авылдан 3 чакрым ераклыктагы юкә төбен күрмәгәнгә ничә еллар. Шунда барсам бер жан тынычланыр иде кебек.

**1977, IX.**

В. Солоухинның "Капля росы" дигән романын укыйм. Әгәр безнең авыл турында язсаң, болай булыр иде.

1. Бик ерактан кайтканда кышкы бураннарда Сафыйларның уты күренә иде. Сафый хатыны белән апасы юлда очрамый калмыйлар иде. Багана умарталар, комган белән җиләккә бару, савыт-саба юк, чишмә белән яши—рухи дөньясы. Иске мунчаларында җен бар, таллар утырта, кара чыршы, карга оясы, зирекләр, Югары су буенда ул утырткан таллар.

2. Гатият абзый, затлы рәвеш. Уральск тормышын сөйли, суыкта скерт салганда үрдәк кыздырып ашау турында тәмләп сөйли, авызга егып салалар ди.

Тәкә сөзгәнне шәпләп сөйли...

3. Мәрфугатти. Җиләккә йөри. Аерым күлмәге бар.

4. Зөлфия—талант. Газиз хатыны ничек кычыткан белән чакты. Юмартлыгы. Кыр үрдәге дип кеше үрдәген. Сугыш вакытында авырый башлады.

5. Хәдичәтти. Артистка. Мәгъсүмне мәче алырга чыгара. Мине яна күлмәк кигәч. Мансур белән без көнбагыш башын урлагач әни янына кереп. Ике малайсыз калды.

6. Нотфи. Бездә кунак, әйдәгез.

7. Әскый. Безнең ат сезнең келәттә юкмы? Әллә нинди көннәр булыр әле, Шәвәли... дип бригадирны тынычландырып сүндерә ут булып килеп кергәч.

8. Хәлил абзый. Кибеттә кыяр тота, илле генә грамм кабып куя. Тегүче—военком, РИК председателе һ. б.


Бәрәңге чергәч—көне туры килмәде. Кайтып кергәндә балалар койма өстендә бәрәңге боламыгы ашап утыралар. Малае алдынгы тракторист.

9. Насый—Биби. Берсе историк, икенчесе врач. Черемховода су кызыл. Бибинур аяк бозылса, сыер бозауламаса һ. б.

10. Безнең әни бөтен кешенең серен үзенә сеңдереп дөньядан китте.

11. Әптел абзый. Каланчада герман пленын сөйли.

12. Гәптрәкыйп. Баланы мичкә тыгу. Сәгыйдуллалар өендә жылавы. Сугыш вакытында мина ипи ашатуы.



13. Ат куу. Көлтә кертү. Болында беренче тапкыр печән чабу.

14. Клуб җимерелү.

15. 1943 елда колхоз бәйрәме. Ногман, Нигаж бииләр.

16. Тупы урманы, юкәлек, ...төплек арты, таллык юлы, чырагач, визир юлы, казган юл. Төп чыгару.

...

авылга бүре килүне язарга. Аннан ничек итеп мин бүре күрдем:

1. Борчак урлаганда—утлар.
2. Кәнүшни янында.
3. 9 бүре.

...

Кызлар ничек су коеналар иде—төнлә, буада, чишенеп. Шунда нинди серлелек бар иде.

Ничек итеп ...н. не кыйнадылар. (Набордан калган өчен). Калган егетне запросто кыйныйлар иде. Бер янгын. Ничек итеп мин бәрәңге бакчасында утырдым. Әти алып чыгып утыртты.

Минем 2 нче тапкыр отпускага кайту. Ишек алды, әни, ул әчеткән бал. Ул мине ничек көткән.

*"Мин ни эшлим аларның киләчәкләре белән! Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасы тора. Миңа хәзерге вакыт кадерле. Хәзерем шулай мәгънәле булганда, миңа киләчәкне-миләчәкне уйлау хәрам иде". Тукай, 4, 217.* Да! Нишлим мин аларның вак-төяге белән!

*"Яшь егет белән карт кеше һичбер вакытта килешә алмаслар. Аларның табигатьләре бөтенләй бер-берсенә башка була. Бер үк эшкә алар икесе ике төрле карыйлар." Гоголь.*

*"Яшьлекнең бөтен матурлыгы аның һәр теләгәнен эшли алуында түгел, бәлки яшь чакта һәрнәрсәне эшли алыр төсле күренүдәдер." Тургенев.*

(Әти архивыннан. 1923 елгы татар календаре, 13 сентябрь).

*Беда стране, где раб и льстец*
*Одни приближены к престолу,*
*А небом избранный певец*
*Молчит, потупя очи долу.*
Пушкин "Друзьям".

*Александр Вампилов говорил: "Писать надо о том, от чего не спится по ночам".*

*"Бәхет вак-төяк шатлыклардан җыела. Вак-төяк шатлыкларның күплеге бәхетне тәшкил итә". Ницше.*

*"Кто берется за частное вопросы без предварительного решения общих, тот неминуемо будет на каждом шагу бессознательно для себя "натыкаться" на эти общие вопросы." В. И. Ленин.*

Язучының иҗат кичәсе була. Ахырдан банкеты да була. Әнә шунда калучылар хатыннары белән башкаларга, калмаучыларга, киенеп кайтырга җыенучыларга мыскыллы елмаю белән карап басып торалар. Язучы үзе дә киенсына. Аһ, тегене чакырасы калган икән... Аһ, моны. Ә кайберләренә шатланып карый: әһә, менә мин сиңа үземнең мөнәсәбәтемне белдердем, ди.

*"Кешенең үз гомере буена тапкан иң зур табышы—турылыклы дуслар". 1884 ел. К. Насыйри.*

Хатын-кыз психологиясе. Ял йортында синең бүлмәңне җыештырган санитарка ял көнне мең мәшәкать белән шул ук пляжга килә. Менә, ди, күрегез, мин тегеләй генә эшләп йөрим, ә мин болай да була беләм. Су коенуның аңа кирәге юк. Хатын-кыз лыжада да шулай. Теге төп максат аның өчен һәрвакыт иң ахыргы әһәмиятсез максат булып кала.

Кара манып язудан беренче башлап американлылар баш тартты. Янәсе, вакыт күп китә. Толстой, Шекспир, Шоу, Ибсен—карага манып язганнар. Ашыгып язган аркасында бүгенге америка язучыларының нинди әсәрен рәхәтләнеп укыган бар соң?

Карага манып алу баш миенең эшчәнлегенә бер ритм бирә, һава бирә.

Бер иләс-миләс кеше апасының туенда җизнәсенә болай җырлаган:

*Борын чөеп йөргән идең,*
*Әллә кемне алмадың.*

Бер хатын-кыз—бары тик хатын-кыз гына. Икәү булсалар—дуслар яки дошманнар.

Өчәү булса—дуслар. Өчтән артып китсә—хатын-кызлыктан чыгып коллективка әйләнәләр. Бу коллектив эчендә вак-төяк группачыклар, ярым-йорты, ике якка да карый торган группачыклар була. Әмма инде болар—коч. Хатын-кыз гына түгел.

1947 елнын августында Яна Чуриледа карточкага дип ипи алырга чират тордым. Трофейный велосипед белән идем. Шул көнге кадәр (кайтканда) зәнгәр күкне, шул көнге кадәр сары башаклы иркен басуны бүтән күрмәдем. Багажникта бер бөтен түгәрәк ипи иде, иген басуы шулкадәр матур иде, я алла, шул басулар әле дә исәнме, күк һаман шулай зәнгәрме? Бу турыда бер хикәя язарга иде. Лирик. Барып чыгармы икән?

**1978** ел, 31 декабрьдә температура 46$^0$ салкынлык булды. Ин түбән температура Оймяконда (53), аннан—Татарстанда. Татарстанда ин түбәне—Арчада, Казаннын Совет районында—46$^0$ иртән, көндез 43. Биектауда—52.

Йа Хода, кош-кортларга, начар абзардагы терлек-туарга шәфкатьле бул! Ялгыз хатыннарга, суык өйдәге үгиләргә, ятимнәргә мәрхәмәтле бул!

Борынгы кешеләрдә тавыш, бугаз бик көчле булгандыр. Чөнки алар кырда, урманда яшәгәннәр. Тавыш белән аралашканнар.

Хәзерге кешенен микрофоннан кычкырырга яратуы—борынгы кешеләргә кайтырга теләүләре. Зов предков.

Аракы эчкән, тәмәке тарткан кешеләрнен фәлсәфәсе: кешегә табигать тарафыннан күпме программировать ителгән—шунын кадәр яши. Әнә фәлән кеше... дип эчкән-тарткан кешеләрдән берәр мисал. Эчеп үлгән кешене галәттә мисалга алмыйлар. Эчмәгән, тартмаган кешене дә (сәламәт булса) телгә алмыйлар.

Сеже мәктәбендә 45-48 елларда классический урта белем бирәләр иде. Бер егет—военрук—турында сөйлиләр иде: тәртипсез классны (9 кл) урамга чыгарып тезгән дә (малайларны) битне өшетә торган буранда йөзләре белән җилгә каршы тоткан. Тегеләрнен битләре өши икән, ә бу "смирно" командасынын нәрсә икәнен күрсәткән. Шул группадан бик күп егетләр ахырдан офицер булырга укырга киттеләр.

Борынгы заманда йола хәрәкәт, эш белән башкарылган. Мәсәлән, янгыр чакыру. Бераздан мона сүз, тел катышкан. Һәм эш-хәрәкәтне сүз этеп, кысрыклап чыгарган.

Безнен заманда кайбер мәсьәләләр нәкъ шуна кайтып калды: эш, гамәл урынына җыелышларда матур сүз генә сөйлибез—шул житә.

1944 елмы? 1945 ме? Көлтә скертләгәндә мин үз гомеремдә беренче тапкыр басу түрендә торналар белән очрашкан идем. Шул вакыттагы хисләр—бер хикәялек. Мин, әни, өйдә ашау—яна бәрәнге—хочется выжить!—Шундый көннәр, өметле көннәр. Бөтен кайгы—тамак туйдыру. Әмма яшәү өчен өметләр зур—басу тулы ашлык, бәрәнге. Торналар биек, зәнгәрсыман каурыйлы икән. Мин алар янында борчак чүмәләләрен йөккә тояп йөрим икән, аларны күрмим икән. Кемдер әйтте. Мин сәнәк тоткан көе алар янына йөгереп киллдем—алар салмак кына күтәрелеп очып киттеләр. Бу картина гомергә хәтеремдә калды. Бу—беренче тапкыр "күк" белән очрашу иде.

1943 елгы Арча—Күпербаш юлын язарга. Телефон баганалары ничек сызгыралар. Без әни белән печән сатарга киллдек, чана тартып. Зәйнәпбикә апаларда ничек куңдык, базарда чүмеч ала яздык. Кайтышлый Күпербашка кереп чәй эчтек. Юл буе телефон чыбыклары сызгырды, андый җил әле дә бармы? Шуны ишеткәнем юк...

*Дәвамы киләсе санда*

# КЫЙММӘТЛЕ ЯДКӘРЛӘР

Татар иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдырган мәшһүр Габденнасыйр Курсавиның (1776—1812) тууына быел 230 ел тулды. Аның дини-фәлсәфи карашлары һәм хезмәтләре Шиһабетдин Мәрҗанидән алып хәзергәчә галимнәрнең игътибар үзәгендә. Курсавиның фәлсәфи әсәрләреннән «Әл-иршад лил-гыйбад» (Тугры юлга өндәү) исемле хезмәте аеруча зур әһәмияткә ия. Гарәп телендә язылган бу әсәр әле дә татар һәм чит ил галимнәре тарафыннан өйрәнелә, тәрҗемәләре чыгып тора.

Габденнасыйр Курсавиның шигъри әсәрләр иҗат итүе турында сүзләр йөргәләсә дә, шигырьләре тәгаен генә билгеле түгел иде. Мәгълүм булганча, ул хаҗ сәфәренә чыккач Истанбулда ваба авыруына дучар булып, шунда якты дөнья белән хушлашкан. Аның нәкъ менә шул соңгы көннәренә бәйле, Габденнасыйр Курсави үзе иҗат иткән шигъри юллар дип теркәлгән язмалар тапкан идек. XIX гасырның беренче яртысына карый торган, шактый таушалган, язулары күренер-күренмәс хәлдәге, ләкин фактик яктан бик кыйммәтле бу кульязма битләрдә «Хәзрәте Габденнасыйр әл-Курсавиның Исламбулда тагун зәхмәте тигәч әйткән бәетләре, кабләл-мәүт (ягъни, вафатына кадәр—Р. М.)» дип, ике шигырь тексты язылган. 1812 елда Истанбулда вафат булып калган Габденнасыйр хәзрәтнең бу шигырьләрен аның юлдашлары яисә танышлары (татар хаҗилары, сәүдәгәрләр) кәгазьгә теркәп, бу язмалар, күрәсең, алар аша безнең җирлеккә кайтып ирешкән. Курсави шигырьләре язылган кульязма битләрне Яшел Үзән шәһәрендә яшәгән галим-педагог Шәриф ага Сайкиннан 1994 елда башка язма истәлекләр белән бергә алып, Татарстан Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә тапшырдык. Әлеге шигъри әсәрләр турында тәүге мәртәбә «Казан утлары» журналында (2002.—№3.—131 бит) берничә сүз белән генә хәбәр биреп үтелгән иде.

Шигырьләрнең икесендә дә, үз чорына хас булганча, гарәп һәм фарсы сүзләрен автор мул кулланган. Фикере тирән, чагыштырулары үтемле. Мәгънәви яктан ике шигырьнең дә темалары уртак: фанилык һәм мәңгелек, яшәүнең максаты, ватан кадере...

Беренче шигырьдә Ходайның тәкъдиренә каршы бер көч тә юклыгы, меңләгән кешенең алдан күрүчәнлеге белән дә, тоташ корыч һәм тимердән пулатлар төзелеп, меңләгән сакчылар куелса да—һичничек тәкъдирдән котылып булмавы турында сүз бара. Курсави бу шигыренең соңгы юлларында ватаннан читтә шаһ булуга караганда, үз илендә фәкыйрь булу өстенрәк дигән фикерен кистереп әйткән.

Икенче шигырьдә тормышның кадерен белү өчен дөньядан киткәннәрне искә алуның әһәмияте, дөнья мөлкәтенең бетүе искәртелә. Адәм баласының фани дөньядан китәчәген уйламыйча, мәңгелеккә килгәндәй гамәл кылуы, әмма мөлкәт байлыгы түгел, күңел байлыгы мөһимрәк булуы белдерелә.

Габденнасыйр Курсавиның бу шигырьләре—ике йөз еллар элек яшәгән мөселман татар фикер иясенең шигъри куәсен дә дәлилли торган кыйммәтле ядкәр.

**Раиф МӘРДАНОВ**



# Габденнасыйр Курсави

* * *

**(Беренче шигырь)**

**Хәкиме мотлак Аллаһның әзәлдә улса тәкъдире,**
**Мөфид улмаз һәзаре әрбаб ки гакълың раиә тәдбире.**
**Сәрасәр җәүшан пулат илә кат-кат кем кисә,**
**Котылмаз кеше җәһед итсә, Ходаның улса тәкъдире.**
**Тимердән кальгалар йапса, ки мең-мең пасибан куйса,**
**Кеше мәныг әйләмәз, форсаты казадан әзәлдән тире.**
**Дийаре горбәт эчендә кеше шаһ улмадин даим**
**Йәнә кәндү дийарендә кәря улмасы әфзалдыр.**

* * *

**(Икенче шигырь)**

**Зийарәт әйләгел әһле кобури,**
**Ки кальбең йад идә ул мәүте шури.**
**Зийарәт әйлә гяһ-гяһ ихтыяри**
**Варисәрсән дөрре ахыр изтыйрари.**
**Беләсән кадерене шайәд хәйатнең,**
**Дөшенәсән кайденә һәм салихатнең.**
**(Хә)раб улмакдадыр җисме маһийәти**
**Дилар мәгъмүр идә ул руйи зәмини.**
**Фәнадин рихләтен һич итмәйүб йад,**
**Дилар дөнйа хәрабен, идә абад.**
**Күңел милке илә «ийәкә нәгъбүд»**
**Дисә үлдем, кемә улыр тәгаббүд.**

---

хәкиме мотлак — чиксез гыйлем иясе; әзәл — мәңгелек; мөфид улмаз — файдасы булмас; һәзаре әрбаб — мең кеше; раиә тәдбир — алдан күрү; сәрасәр җәүшан пулат — тоташ корычтан коелган; җәһед — тырышу; пасибан — сакчы; мәныг әйләмәз — котыла алмас; тир — язмыш, тәкъдир; дийаре горбәт — ватаннан читтә; улмадин — булудан; кәндү — үз; кәря — юньсез, фәкыйрь; әфзал — артык.

әһле кобури — кабер әһелләре; кальбең — күңелең; мәүте шури — бәхетсез мәетләр; гяһ-гяһ — кайвакыт; варисәрсән — барсаң; дөрре — кадерләләр; изтыйрари — мәҗбүри; хәйат — тормыш, яшәү; дөшенәсән — төшенәсең, аңлыйсың; кайд — беркетелү, язылу; салихәт — изге гамәлләр; җисме маһийәти — табигый сыйфатлы җисем; дилар мәгъмүр идә — бизи, хушландыра; руйи зәмини — җир йөзе; фәнадин рихләт — фани дөньядан күчү; итмәйүб — итмичә; дилар — бизи; идә абад — мәңгелек итә; «ийәкә нәгъбүд» — сиңа, ягъни Аллага гына түбәнчелек белән табынабыз (Коръәннең «Фатиха» сүрәсеннән); кемә улыр — кемгә булыр; тәгаббүд — Аллага хезмәт итүче.

Әдип, юрист, педагог һәм тәрҗемәче, нахакка репрессияләнгән татар зыялысы Мөхәммәтнәҗип Латыйп улы Хәлфиннең (1886—1937) тууына быел 120 ел тулды. XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында аның әдәби тәнкыйть һәм тарихи мәкаләләре басылган, тәрҗемә иткән әсәрләре дә бар. Н. Хәлфиннең 1913 елда «Аң» журналында дөнья күргән бер мәкаләсен укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.

Нәҗип
Хәлфин

# 1913 НЧЕ ЕЛДА ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

Быел эчендә безнең шагыйрьләр[1] арасында күп кенә үзгәрешләр булды, һәм, игътибар итеп карасаң, шагыйрьләремезнең, һәркаюсының диерлек, берәм-берәм нәфис әдәбияттан гади әдәбиятка, шигырь вә сәнгать почмагыннан дөнья вә гарыз (идея)[2] чатына таба күчкәнен күрәсең. Ихтыярлымы, ихтыярсызмы, шагыйрьләремез шигырьгә вә нәфасәткә хезмәтне ташлап, бер мәсләккә, бер фикергә хезмәт итүне артык итә башладылар. Гүя милли тормышны шигъри сурәттә мәңгеләштерүгә караганда, милләтнең көндәлек кирәкләрен вә елдан-ел үзгәреп тора торган дөньяви ихтыяҗларын үтәү шагыйрьләремез өчен әһәмиятлерәк, гүя андый көндәлек эшләргә шагыйрьләрдән башка кеше юк вә гүя шагыйрьләргә шундый кара хезмәттән башка эш юк.

Кайбер шагыйрьләремезнең болай дөнья эшләренә бәйләнүләре элек тә бар иде. Г. Камал күптән «Йолдыз»да хезмәт итә, Сәгыйть Рәмиев күптән инде «Идел»гә кереп югалган иде. Ләкин быелгы кадәр көлли (гомуми) афәт һичбер вакыт булганы юк иде. 1912 нче елның азагында Фатих Әмирханның «Кояш»ка керүе белән башланган бу бәла бөтен 1913 нче ел буенча дәвам итте һәм ел азагында гына Галимҗан Ибраһимовның «Аң»га секретарь булуы белән тәмам булды. Тукайны без бөтенләй югалттык. Гаяз әфәнде «Ил» белән багланды. Шулай итеп, «Болгар кызы Айсылу» иясеннән (авторыннан)[3] башка шагыйрьләремез, һәркаюсы диерлек, акрынлап шигырь, ибдаг (иҗат итү), хыял вә күк галәменнән матбугат, фикер, мәсләк, үгет галәменә күчеп беттеләр.

Дөрес, вакытлы матбугатка якын тору башка милләт шагыйрьләрендә дә булган вә булып тора. Ләкин анлардагы якынлык бөтенләй икенче рәвештә. Анларның бер гәзитә вә журналга катнашулары яна әсәрләрен әүвәл мәртәбә шул гәзитә вә журналларда басып чыгару мәгънәсе белән генә. Бездәге кебек гәзитә вә журналларның кара эшләрен эшләү вә анларның фикер вә мәсләкләрен таратырга тырышу мәгънәсе белән түгел.

Менә безнең шагыйрьләрне һәлак иткән нәрсә шул дөнья гарызына (мәшәкатенә) хезмәт итү булды инде. Бердән, шагыйрь көндәлек эшләргә бирелеп китеп, нәфасәт галәмене онытып җибәрә. Әгәр эш шулай булмаса, «Хәят»ның икенче бүлеге вә «Урталыкта» белән «Мулла бабай»ның дәвамы китап базарында күренерләр иде... Икенчедән, гәзитә эшләрендә шагыйрьләр фикер вә мәсләккә бирелеп китәләр, кайчан исә бер матбугат эшеннән бушангач, яки аның белән бер вакытта ук кире шигырьгә кайткан тәкъдирдә дә, анлар үзләренең гәзитә вә журнал идарәләрендә гадәтләнеп

---

[1] Автор бу мәкаләсендә шагыйрь сүзен әдип һәм иҗат әһеле, ә шигырь сүзен әдәби әсәр мәгънәсендә кулланган.

[2] Тексттагы җәяләр эчендәге сүзләргә аңлатмалар безнең тарафтан бирелде. – Р.М.

[3] Мәҗит Гафури күздә тотыла.

киткән фикерләреннән аерыла алмый башлыйлар. Анларның шигырьләре гарыздан гали (идеядән өстенрәк) тора алмый; шуның белән бергә шигырьлек кыйммәтләре дә, табигый, кими. Шагыйрьләр вак эшләр белән чуалып үзләре вакланып китәләр. Мәсәлән, танчылык—бер мәсләк иде. Вакытында Гаяз әфәнде шуның һәм газитәсенең башында торды. Аның шул вакытта һәм аннан бераз соңрак язган нәрсәләреннән һаман танчылык исе килеп барды. Ул үзенең әсәрләрендә гел шул «жир вә ирек» өчен «тартышырга» кирәк дигән фикердән чыгып яза иде. Табигый, анларда танчылык нихәтле куәтле булса, анларның шигырьлеге дә шул нисбәттә зәгыйфь була иде. Бара торгач милли шагыйремез танчылык мәсләген ташлады. Андый вак гарызлардан югары тора, тормыш кирәкләренә битараф карый башлады, һәм шул вакытта гына аның әсәрләре чын шигырьгә әверелде.

Менә шушы иң куәтле шагыйрьләремезнең гәзитә вә журнал идарәләренә таралып бетүләренә вә шул идарәдәге вак тәэсирләргә бирелүләренә сәбәп нәрсә соң? Шагыйрьләр үзләреме монар сәбәп, әллә анларның шигырьдә вә халкымыз арасында тоткан урыннарымы? Әгәр шагыйрьләремез һәммә әйтәсе сүзләрен әйтеп бетергән булсалар, әгәр анлар милли тормышта бер дә яңа ләүхәләр (темалар) тапмасалар, әгәр анларга илһам киселгән булса, без анларны «вакытын белеп шигырь белән бәхилләштеләр» диер идек. Ләкин болай әйтергә һичбер жай юк. Чөнки Фатих вә Гаяз әфәнделәрнең башлап куйган вә тәмам итмәгән хикәя вә романнары бар. Димәк, анларның күңелендә тормышның әлегә хәтле мәңгеләштерелмәгән ләүхәләре тасвир ителгән, башында идеяләре туган инде, бары кәгазьгә генә беркетәсе калган. Тагы зурысының яше кырыкка житмәгән шагыйрьләремезне «картайдылар, арыдылар» дип әйтергә дә мөмкин түгел.

Инде әдәбияте нәфисәнең (матур әдәбиятның) вә шагыйрьләремезнең милләт эчендә тоткан урынына килсәк, без монда да шигырьдән вакытлы матбугатны артык итәргә һичбер вәжеһ (сәбәп) таба алмыймыз. Әллә инде бездә нәфис әдәбият гражданлык правасы алмады? Әллә инде Гаяз, Фатих вә Галимжан әфәнделәр халкымыз тарафыннан сөелеп укылмыйлар? Дөрес, моннан ун ел элек басылган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әле һаман сатылып бетмәгән. Шулай да без, һич булмаса бу өч шагыйремезнең үзләренең әсәрләре белән тәэмин ителүләренә ышанамыз. Вакытлы матбугат әдәбиятка караганда яхшырак тәэмин итәр дип тә күңелемез китми.

Вакытында Фатих Кәрими, «Сәлимә» иясе[4] һәм Садрый Максуди да әдәбиятка якын тордылар. Хәзер инде анларның шигырьдән никадәр ераклашканнарын күрәмез. Шөйлә (шулай ук) инде Сәгыйть Рәмиев, Фатих Әмирхан, Гаяз вә Галимжан әфәнделәр дә тегеләр эзеннән китәрләр микәнни? Юк, юк, мона һич ышанасы килми. Монда бер табигатьнең кызулыгымы дим, тормышның вакытлы тәэсиреме—әллә ни бер нәрсә генә бар. Шаять, 1914 нче ел чын шагыйрьләремезне үз эшләренә вә табигый вазифаларына кайтарыр.

1913 нче елда сандугачлар, «өмидле каләмнәр» беленмәде. Искеләре икенче эш белән шөгыльләнделәр. Хәлбуки, милли тормыш бик кызу адымнар белән алга бара, яңа типлар чыгалар, искеләре югалалар; анлар әдәбиятка хәзер кермәсәләр, ун-егерме елдан анларны кайтарып алуы мөмкин булмас. Тормыштагы үзгәреш эзе югалыр. Шуңа күрә, шагыйрьләрнең үз эшләре белән шөгыльләнүләре хәзерге көндә бигрәк тә әһәмиятле. Тормышның бик күп ягына әле әдәбиятның кулы тигәне юк. Нәфис әдәбиятымызның башка милләт әдәбияты белән ярышырлык вә укучыларны ят әдәбият тәэсиреннән вә әсирлегеннән саклый алырлык яхшырганы вә баеганы тагы юк. Эш шулай була торып, дөнья белән бик булышкан шагыйрьләремезгә ошбу сүзләрне әйтәсе килә: сезгә талант гәзитәләрдә кызу мәкаләләр язар өчен түгел, бәлки урынына сарыф итәр өчен бирелгән. Шималь төреге (татар) әдәбиятына нигез салдыңыз да, инде үзенез шуны ярты юлда ташлап китәсез. Үзенезнең табигый бурычыңызны үтәвенез сезнең шушы төсле буламы?

*«Аң» журналы.—1914.—№ 1.—11-12 битләр.*

Текстны басмага әзерләүче—**Раиф МӘРДАНОВ**

---

[4] Ризаэтдин Фәхретдин күздә тотыла.

# В

**ВӘЛИ** (Вәлиуллин) Зиннәт Сәгый улы (8.3.1924, Тәтеш кантоны Шәпкә а.), язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1968). 1959-70 елларда Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, 1970-76 тә Таткниготоргта китап таратучы булып эшли. Әдәби һәм журналистлык эшчәнлеге б-н 1943 тән шөгыльләнә. «Юл ачык» (1965) пьесасы, балалар өчен «Югалган алма» (1954), «Балан бәлеше» (1963), «Җирдәге йолдызлар» (1965), «Исәнме, кызым» (1967) исемле хикәя җыентыклары авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары б-н бүләкләнә.

**ВӘЛИДЕВА** (Вәлидия) Мәфтуха (1894-1925) шагыйрә. «Күңел бүләкләре» (1915) исемле шигъри җыентык авторы. Җыентыкка 32 шигырь урнаштырылган, шигырьләрнең төп темасы – хатын-кызның гаиләдәге хокукый тигезсезлеге. В. гаилә бары мәхәббәт нигезендә генә төзелергә тиеш дип саный. Шагыйрә табигатькә дан җырлый, кешеләрдә ихласлык, киң күңеллелек сыйфатларын мактый, бер үк вакытта тормышта бу сыйфатларның сирәк очравына, яшәештә гармония юклыкка күңеле сызлануларын тасвирлый.

Әсәрләре: Гамь // Мирас. 1998. N 4.

Әд.: Бурнашева З. Татар хатын кызлары хәрәкәте тарихыннан. К., 1971; Мәфтуха Вәлидия (1894-1925) // Өмет йолдызлары. К., 1988.

*З.З.Рәмиев.*

**ВӘЛИЕВ** Мансур Хаҗи улы (1.1.1948, Әгерҗе р-ны Баржы а.), язучы, әдәби тәнкыйтьче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1975-81 елларда «Идел» альманахы мөхәррире, 1981 дән «Казан утлары» ж-лында әдәби тәнкыйть бүлеге мөдире. Хәзерге әдәби процессны бәяләүгә, анализлауга багышланган тәнкыйть мәкаләләре тупланган «Яшьләр мәйданга чыга» (1978), «Табарга һәм югалтмаска» (1982), «Каһарманнар кирәк!» (1990), «Гасыр ахырында» (1993), «Тукайлар рухы» (1998), «Тормыш дулкыннары» (2005) китаплары авторы. «Үзәгең өзелгәндә» (1987), «Качу» (1993), «Мәхәббәт мажаралары» (1997-99), «Идел яры» (2003) повестьларында бүгенге көннең рухи-әхлакый проблемаларын күтәрә.

Әд.: Еники Ә. М.Вәлиев // Казан утлары. 1978. N3; Маннапов С. Ачкыч эзләдем // Тамыр тирәнлеген яфрак тоя. К., 1988; Гамбәр Н. Аккош күлендә утлар // Казан утлары. 1988. N1. Заһидуллина Д. Дөньяга хыялый-моңсу караш // Яңа дулкында. К., 2006.

**ВӘЛИЕВ** Мөдәррис Харис улы (псевд. Салих Маннапов) (30.5.1953, Әлки р-ны Яңа Камка а.), әдәби тәнкыйтьче, шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989). М. Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты (2003), филология фәннәре кандидаты (2002), Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1976-79 елларда «Татарстан яшьләре» г-тасында хәбәрче, бүлек мөдире була. 1979-89 да «Казан утлары» ж-лында өлкән мөхәррир, җаваплы сәркәтип, баш мөхәррир урынбасары вазифаларын башкара. 1989-92 дә Татарстан китап нәшрияты баш мөхәррире, 1992 дән ТР «Мәгариф» милли китап нәшрияты директоры. «Сезгә ышанам» (1984), «Тамыр тирәнлеген яфрак тоя» (1988), «Возвращение звезды» (1992) «Гамәл дәфтәре» (2003) исемле әдәби тәнкыйть мәкаләләре җыентыклары, татар китабын бастыру мәсьәләләренә багышланган «Китап» (2000) җыентыгы, «Яшьлектән хат» (1998) исемле шигырь китабы, нәшрият эшенә багышланган фәнни-педагогик хезмәтләр, уку әсбаплары авторы. Чуаш язучысы М.Юхманың «Кунгош – птица бессмертия» («Көнгыш – үлемсезлек кошы», 1987), З.Фәтхетдиновның «Резидент – Чёрная вдова» («Үлем элмәге», 1991) романнарын татар теленә тәрҗемә итә.

Әд.: Фәйзуллин Р. Кайту // Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т.4; Мостафин Р.

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.*

Йөрәк җылысы белән // Татарстан яшьләре. 1985. 25 май; Нәҗми Н. Тирәнлеккә тою // Кызыл таң. 1988. 15 дек.; Шәрәфетдинов Г. Китап эчләрендә «Китап» // Мәдәни җомга. 2002. 13 апр.

**ВӘЛИЕВ** Равил Вәли улы (20.8.1942, Арча р-ны Яңа Кенәр а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). 1969 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1970-92 елларда төрле газета-журнал редакцияләрендә, Чаллы, Алабуга шәһәр радиоларында мөхәррир булып эшли. 1993 тән «Шәһри Казан» г-тасында бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип, 2003 тән баш мөхәррир урынбасары. «Шәһәр булсын бүләгем» исемле беренче документаль повесте 1973 тә басыла. «Таяну ноктасы» (1978), «Көчле агым» (1984) дигән очерклар җыентыкларында, повесть һәм хикәяләре тупланган «Мәңгелек ут җылысы» (1986) китапларында төзүчеләр һәм КамАЗ з-ды эшчеләренең истә калырлык образларын тудыра, Бөек Ватан сугышы елларында халыкның тылдагы фидакарь хезмәтен чагылдыра. Геройлары ихлас күңелле, хезмәт сөючән, ярдәмчел һәм шәфкатьле, мәхәббәтләренә тугры кешеләр. В. ш. у. тарих, әдәбият һәм сәнгать өлкәсенә караган күп кенә мәкаләләр авторы.

Әсәр.: Җөй. К., 2002; Олуг хан ярлыгы. К., 2005.

Әд.: Рәшитов Ә. Бизәлмәгән хакыйкать // Социалистик Татарстан. 1974. 11 май; Баянов Ә. Безнең сафка // Казан утлары. 1980. N1; Әгъзамов Ф. Таяну ноктасы // Үзәктә кеше: Очеркларыбыз турында. К., 1981.

**ВӘЛИЕВ** Разил Исмәгыйль улы (4.1.1947, Ширәмәт р-ны Ташлык а.), язучы, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1990, 1997). М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (1972, Мәскәү). 1972-76 елларда «Ялкын» ж-лында әдәби хезмәткәр, 1976-81 дә җаваплы сәркәтип. 1981-84 тә ТАССР Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җаваплы сәркәтибе. 1986-2000 дә ТР Милли китапханәсе директоры, бер үк вакытта 1990-95 тә ТР ЮСның Милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссия рәисе. 2000 елдан ТР Дәүләт Советының Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе. Әсәрләре 1960 елларда басыла башлый. Төп жанры — шигърият. В. — гражданлык хисләрен ачык белдерүче шагыйрьләрдән. Ул «Зәңгәр кабырчыклар» (1971) дигән беренче шигырьләр китабы б-н үк үзен әхлакый проблемалар турында тирән уйланучы шагыйрь итеп танытты. «Яшен тамыры» (1977), «Ядкарь» (1987), «Кышкы учак» (1994) җыентыклары дөнья күргәч, тәнкыйтьчеләр аны «рухлы фикер шагыйре» дип бәяләде. В. поэзиясенең төп тематикасы — туган җир, табигатьне саклау, Җир-Ана язмышы өчен борчылу; шигырьләре көчле идеяләргә, романтик хисләргә бай. Аның шигырьләренең аһәңлеге танылган татар композиторларының игътибарын җәлеп итә. Ф.Әхмәтов, Р.Яхин, М.Яруллин, Р.Абдуллин, Л.Батыр-Болгари, Р.Ахиярова, Ш.Тимербулатов һ.б. б-н берлектә иҗат ителгән йөзгә якын җыры «Бер алманы бишкә бүләек» (1992), «Определение любви» (1984) җыентыкларына керә. В.нең балаларга атап язылган «Хыялый Мияубикә» (1976), «Кайтаваз кайда яши?» (1994) шигырь китапларына балаларга хас эчкерсезлек, гади, агымлы тел хас. В. тәрҗемәсендә дөнья халыклары әкиятләре тупланган китаплар «Тылсымлы чишмә» (1984), «Иң озын әкият» (1994) исеме б-н дөнья күрә. Проза өлкәсендә В.ның яраткан жанры — документаль характердагы кыска, җыйнак повесть. Яшь солдатның батырлыгы турында «Яшисе килә» повесте (1982; русчага тәрҗемәсе — «Жить хочется!», 1983) М.Җәлил исем. ТАССР бүләгенә лаек була, кабатлап басыла. «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» (1989), «И машина, машина, җитте минем башыма» (1990) комедияләре Татар драма һәм комедия т-ры сәхнәсендә уйнала. В. публицист буларак та билгеле: 1983 тә «Күкләр биек» исемле очерклар китабын нәшер итә. Аның әсәрләре рус, башкорт телләренә тәрҗемә ителгән. В. — Татар ПЕН-Үзәген оештыручыларның берсе һәм 1995 тән аның вице-президенты. 1990-95 тә ТР ЮС депутаты, 1995 тән ТР халык депутаты.

Әсәр.: Зимние яблоки. Стихи. К., 1999; Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 1999-2000.

Әд.: Мустафин Р. Из песни слова не выкинешь // Советская Татария. 1993. 6 апр.; Галиев М. Язмышка рәхмәт // Казан утлары. 1997. N1; Хәйри Ә. Рухи мирасыбыз сакчысы // Мәдәни җомга. 1997. 21 февр.

*Р.А.Мостафин.*

**ВӘЛИЕВ** Фәйзи (Фәйзерахман) (1892, Шәрип а., хәзерге Башкортстанның Кушнаренко р-ны — 1941), язучы. «Галия» мәдрәсәсен тәмамлый. Озак еллар Уфа губернасы һ.б. өлкәләрнең мәгариф оешмаларында, партия һәм совет органнарында эшли. 1910-11 елларда «Шура» ж-лында, «Вакыт» г-тасында басылган шигырьләре б-н таныла. «Урал буйлары» (1914) исемле беренче проза әсәрендә Урал табигатен тасвирлый, аның җир асты байлыкларын кешеләр файдасына юнәлтергә кирәк дигән уй-хисләре б-н уртаклаша. Шул елларда иҗат ителгән «Бер тиен» (1914) һ.б. хикәяләрендә гади кешеләрнең тормышчан образларын тудыра. «Намаз» (1916), «Җырлыйлар» (1917), «Ирһан учитель» (1918) хикәяләре 1 нче бөтендөнья сугышына бәйле вакыйгаларга багышланган. «Көймәдә» (1918) хикәясендә романтик мәхәббәт темасы үзенчәлекле чагылыш таба. В.нең аерым хикәяләре «Идел буе әдәбияты» исемле 1918 елда чыккан күмәк җыентыкка кертелгәннәр. В.нең халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю юнәлешендә дә хезмәтләре бар.

Әсәрләре: Фәйзи хикәяләре. К., 1918; Урал буйлары. Бер тиен. Ирһан-учитель. Кәмәлә // Башкорт әдәбияты. XX быуат башы. Өфө, 1984. Б. 288-307; Өмидле күңелдән: Шигырьләр. // Мирас. 1998. N4.

Әд.: Кудаш С. Сигезнең берсе // Совет Башкортстаны. 1973. 5 гыйнв.

*З.З. Рәмиев*

**ВӘЛИЕВА** Венера Сәлах кызы (6.4.1935, Башкорстан Респ-касы Кушнаренко р-ны Кушнаренко а.), тәрҗемәче, шагыйрә. Казан ун-тын тәмамлый (1957). 1969-83 елларда Мәскәү электрон техникасы ин-тында укыта. Беренче тәрҗемәләре матбугатта 1977 дә басыла башлый. Татар теленнән Г.Тукай, Дәрдеменд, М.Җәлил, Х.Туфан, Ф.Кәрим, С.Хәким, Р.Харис, Р.Фәйзуллина, Г.Рәхим, Зөлфәт, Н.Измайлова, Г.Садә, немец теленнән Һ. Һейне, Л.Фюрнберг, Э.Штритматтер, молдован теленнән П.Боцу, балкар теленнән К.Кулиев, әрмән теленнән Г.Эмин, башкорт теленнән Р.Бикбаев, Т.Йосыпов шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итә. «Сизенү» («Предчувствие», 1989), «Саф нота» («Чистая нота», 1999), «Исәнләшү» («Перекличка», 2001) китаплары авторы.

**ВӘЛИЕВА** Резеда Тәфкәлүн кызы (1.5.1930, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Кыйгы р-ны Дүшәмбикә а.), шагыйрә, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1952). 1952-85 елларда Татарстан китап нәшриятында яшьләр-балалар редакциясе мөхәррире. Балалар һәм өлкәннәр өчен язылган 30 дан артык шигырь һәм поэмалар җыентыклары авторы: «Минем дусларым (1960), «Канатлы җайдак» (1966), «Зәңгәр алан әкияте» (1971), «Әниемә бүләк» (1978), «Шиңмәс чәчәкләр» (1983), «Дәү әнигә барабыз» (1994), «Нәниләр китабы» (2000), «Без нәни игенчеләр» (2001), «Кояшлы яңгыр» (2003), «Песня о поэте» (2005) һ.б. В. шигырьләре тематик яктан төрле, лирик аһәңнәргә бай, алар балаларда туган як табигатенә, үз халкына мәхәббәт тәрбияли, кыю, тапкыр, хезмәт сөючән булырга өнди. Дөньяны поэтик күзаллау В.ның проза әсәрләренә дә хас. Сугыш чоры авылы балалары тормышы, аларның үзара мөнәсәбәте, гади кешеләрнең шәфкатьлелеге, кешелеклеге чагылыш тапкан «Якты яр» повесте (1985) шундыйлардан. «Китмә, сөю» (1998) җыентыгына кергән «Якты йолдызым» поэмасында тол калган фронтовик хатынының күңел матурлыгы, намуслылыгы сурәтләнә. В. әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә эшли. Ул Л.Воронованың «Старшая сестра» («Дәү апа», 1965), Н.Верзилинның «По следам Робинзона» («Робинзон эзләреннән», 1958), Н.Поповның «Юность Андрея» («Андрейның яшьлеге», 1960), Л.Смилянскийның «Сашко»сын (1961), А.Бартоның «Наш праздник» («Безнең бәйрәм», 1980), С.Михалковның «Мы с приятелем» («Дустым белән икебез», 1981) хикәя һәм шигырь җыентыкларын татар теленә тәрҗемә итә. Популяр җыр текстлары авторы. «Яраттым шул, яраттым» (2001), «Татар кызы» (2002), «Оч, син, җырым» исемле ноталы җырлар китаплары да дөнья күрде.

Әсәр.: Күңелем гөлләре. К., 2002; Якты ярда калган балачак. К., 2005.

Әд.: Нигъмәтуллин Э. Балалар дөньясына кереп // Социалистик Татарстан. 1981. 4 июль; Ихсанова Л. Яңа китап — яңа сөенеч // Шәһри Казан. 1994. 30 дек.; Гаташ Р. Яшьлеккә тугры шагыйрә // Казан утлары. 2000. N5.

*Г.М.Габделхакова*

*Дәвамы киләсе саннарда*

# «КАЗАН УТЛАРЫ» – 2007

## *Ак җилкән*

*Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, сезнең сәхифә бу!*

**Ф. Солтанов.** Һәйкәл.
Монарчы үзара сугышып яшәгән авыл яшьләре һәм солдатлар бу һәйкәлне Арарат тавының биек түбәсендә бергәләп куялар. Тик моның өчен әүвәл анда менәсе була әле...

**М. Төхфәтуллин.** Башны салларга салып...
Хатыны һәм балалары белән велосипедта Россиянең «Алтын бөжра»сын ураган, Агыйделдән салда ун тапкыр агып төшкән романтик җан язмалары.

### Тэтчерның кайтуы

«... Гади генә эт түгел иде ул—минем Тэтчерым. Татар һәм рус телләрендә сөйләшкәнне аңлый, хәтта ки уй-теләкне дә тою, сизү сәләтенә ия.



...Беркөнне иртә белән мин иремә улыбызның дипломлы килеш һаман эш табалмый йөрүен искәрттем. Ирем:

—Дөрес әйтәсең, Искәндәрнең эш проблемасын хәл итәргә кирәк!—дип сөйләнә-сөйләнә киенә дә башлады.

—«Эшең» бетергәч тә өйгә кертеп җибәрерсең,—дип, мин аңа Тэтчерны да иярттем.

Ике сәгатьтән соң ирем үзе генә кайтып керде.

—Тэтчер кайда?!—дидем мин бусагада ук.

—Бәй, кермәдемени? Мин бит аны лифтка утыртып кертеп җибәргән идем.

Бергәләп эзли башладык: йорт тирәсен әйләнәбез, очраган бер кешедән сорашабыз—юк, берәү дә белми, беркем дә күрмәгән безнең Тэтчерыбызны!

Аптыраган бер мәлдә сигезенче подъездан Марс исемле эте белән Динис дигән үсмер чыкты һәм туп-туры безнең янга килде:

—Әллә Тэтчерны эзлисезме? Мин аны бая, ике сәгатьләр элек күрдем. Ул безнең остановкада 9 нчы трамвайны көтеп утыра иде.

—Ничек инде ул—9 нчы трамвайны?!

—Мин 14 нче трамвайдан төштем. Тэтчер анда утырмады. Ә моның артыннан 9 нчы килә иде.

...Без 9 нчы трамвайда улыбыз Искәндәр янына ашыктык.

Ишекне Тэтчер белән бергәләп улыбыз ачты.

—Димәк, Искәндәрнең эш проблемасын Искәндәр янында, аның фатирында хәл итәбез дип уйладың инде син, ә, Тэтчер?—диде ирем һәм көлеп җибәрде...»

Бу юллар, кадерле укучыларыбыз, **Рәисә Юсуповаңың** журналыбыз аша сезгә ирешәчәк әдәби-документаль очеркыннан алынды.

Язмада бу акыллы җанны урлап Ижау каласына алып китүләре дә, урлаучыларыннан качып, аның өч ай һәм өч көн дәвамында Казанга, өенә кайтуы да бәян ителә.

**«Ак җилкән» сәхифәләрен бергәләп әзерлик, яшь дуслар. Үзегезне борчыган, гаҗәпләндергән, сокландырган нәрсәләр турында языгыз.**

*Альберт Яхинга 75 яшь*

# ФОРМУЛАЛЫ ӘДӘБИЯТ

Университетта укытты ул безне. Аудиториягә жил-жил атлап керә, башка укытучылар кебек хәл-әхвәл сорашып тормый, шундук лекциясен башлый. Студентларны «батыру», каныгу ише нәрсәләрнен эзе дә юк. Гомумән, Альберт абый безне бөтенләй күрми дә төсле. Анын һәр хәрәкәтеннән каядыр ашыгу сизелә. Гүя ул ниндидер ачыш ясаган һәм аны тиз-тиз бүтәннәргә житкерергә омтыла шикелле.



Сизенүебез урынлы булган. Альберт Яхин, чынлап та моңарчы бүтәннәрнен төшенә дә кермәгән фикерләр, яңа идеяләр белән янып йөргән... Ул укыткан лекция курсы «Татар фольклоры нигезләре» дип аталса да, никтер без математикадагы кебек формулалар өйрәнә башладык. Баксаң, әкиятнен дә формуласы була икән. Әйтик, һәркемгә таныш «Ак бүре» әкиятенеке мондый: A/B+C=B/A. Берәр нәрсә аңладыгызмы? Ә ул болай: A—тискәре, B—унай персонажлар. Башта явыз көчләр яхшыларны кыерсыта, ягъни дию пәрие кызны урлый, соныннан киресенчә—егет диюне жинә. C—яхшылыкка илтүче вакыйгалар, персонажлар. Гап-гади, әйе бит?

Дүртенче курста тагын Альберт абый белән очрашырга туры килде. Бусында мәктәптә әдәбият белемен яңача укытырга өйрәндек. Килеп керүгә Альберт абый тактага акбур белән сызык сызды:

—Озынмы бу, кыскамы?

Аптырашып калдык. Жавап бирүче табылмады. Укытучыбыз сызыкнын янәшәсенә икенче бер—озынрак сызык сызды.

—Ә хәзер ничек?

—Кыска!

—Ә-ә-әнә... Урамдагы агачны күрәсезме? Биекме ул, тәбәнәкме?

—Янәшәсендә бүтән агач юк ич, чагыштырырга,—диде бер кыз юаш кына.

—Ә хәтер нәрсәгә?..

Әдәби әсәргә бәя биргәндә дә берьяклы гына фикер йөртергә ярамый икән. Һәрвакыт чагыштыру булырга тиеш.

...Ике хәерче очрашкан.

—Нихәл?—ди беренчесе.

—Хәлләр әйбәт түгел—өйдә тамчы да ашарга юк, ничәнче көн ачтан тилмерәм,—ди икенчесе.

—И-и-и... Синен хәлен әйбәт икән әле,—дигән беренчесе (бер караганда ничек әйбәт булсын инде!)—Минем дә бер тамчы ашарыма юк, ләкин өстәвенә өемдә кунак утыра...

Аннан сон Альберт абый инде без ятлап бетергән классик әсәрләрнен эчтәлеген яңача аңларга өйрәтте. Баксаң, һәр әсәрнен дә объектив һәм субъектив эчтәлеге була икән. Объектив—әсәрдә язылган туп-туры эчтәлек, субъективы исә жөмләләрдә күренмәсә дә, автор әйтергә теләгән фикер. Мисалга Такташнын бер шигырен алдык:

*А, партия,*
*Синең иртәгәңә бару өчен*
*Авырлыклар аша үтү кирәксә,*
*Безнең бүген күргән авырлыклар*
*Җиңүең өчен файда бирәлсә,*

*Шатлыгым да, янар яшьлегем дә,*
*Җырларым да сиңа булсыннар...*

«Мона кадәр бу шигырь партиягә дан җырлаучы дип әйтелеп килендә,—ди Альберт абый.—Ләкин бу алай түгел. Такташ «файда бирер» дими, «бирәлсә», ди, ягъни ул партиягә шиген белдерә...»

Кызык әлбәттә! Килешергә мөмкин бу ачыш белән, килешмәскә, ләкин барыбер кызык.

Үткән гасырның туксанынчы еллар башында кайбер мәктәпләр әдәбият белемен Альберт Яхинның яңа методикасы буенча укыта башлады. Кемнәрдер моны аңлап җиткермәде, кемнәрдер анларга, ягъни «башны эшләтергә» теләмәде, «үзем дә төшенмәгән нәрсәне ничек укучыларга аңлатыйм» диючеләр дә табылды. Шулай да, Казандагы бөтен татар гимназияләре дә диярлек «Яхинча» укытуга күчеп бетте. Аннары бу процесс әкренләп район мәктәпләрендә җәелде. Галим үзе тәҗрибәләрен Питрәч районындагы Шәле мәктәбендә алып барды.

«Монарчы без укучыларга информация генә сөйләдек,—ди Альберт абый.—Ягъни, балалар әсәрне укып чыгалар да, робот кебек шуны яттан сөйлиләр. Без аларны уйларга, иҗади эшкә өйрәтмәдек. Шуна күрә минем программаның яналыгы—укучыны мөстәкыйль эшләргә, әдәби әсәрләргә анализ ясарга өйрәтү».

Каян килгән соң Альберт абыйга мондый фикерләр? Монарчы тыныч кына укытылган әдәбият белемен төбе-тамыры белән актарып ташлап, аны яңача кору идеясе тиктомалдан гына тумагандыр бит? Әйдәгез, язучының биографиясенә күз салыйк әле.

1931 елның 8 ноябрендә Арча районы, Арча поселогында туа ул. 1949 елда урта мәктәпне, 1954 елда КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Аннары дүрт ел—аспирантура... 1959 елда А. Яхин «Чаян»га—республика сатира журналына эшкә килә. 16 ел гомере шунда уза аның—тугыз ел җаваплы секретарь һәм җиде ел баш редактор булып эшли. Ул чорда ике телдә чыгучы «Чаян»ның тиражы миллионга якын(!) данәгә җитә, элеккеге СССРның бөтен төбәкләрендә укыйлар аны.1975 елда Альберт Яхин журналдан китә һәм КДУның тарих-филология факультетында татар әдәбияты кафедрасын җитәкли.

Әдәбият тарихына игътибары аспирантурада укыганда ук башлана аның. Гражданнар сугышы каһарманы Шамил Усманов турында бай материал туплап, соңыннан шуның нигезендә ике китап һәм Аяз Гыйләҗев белән берлектә «Шамил Усманов» дигән тарихи драмасын яза. Драма Г. Камал театры репертуарына кертелеп озак еллар уңыш белән бара һәм театр тәнкыйтендә әйбәт спектакль дип бәяләнә.

Алтмышынчы еллардан башлап, А. Яхин язучы буларак, аеруча юмор-сатира жанрында активлык күрсәтә. «Чаян», «Сәнәк», «Крокодил» журналларында аның дистәләрчә сатирик хикәяләре һәм фельетоннары дөнья күрә. Язучы аларда тормыштагы бюрократизм калдыкларын чыбыркылый һәм кечкенә генә вакыйга-эпизодка да зур мәгънә сала бара.

Сиксәненче еллар башында Альберт Яхин ныклап торып әдәби-фәнни тикшеренү эшләренә керешә. Башта ул әлеге хезмәтен юмор-сатира жанрына бәйләп алып бара. Аның «Мәзәк жанрын өйрәнү тәҗрибәсеннән» һәм «Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе» исемле хезмәтләре нәкъ шул елларда дөнья күрә. Еллар дәвамында тупланган уй-фикерләр, идеяләр, ачышлар шулай итеп «ирекке» чыга башлый.

«Әдәбият дәресенең өч максаты булырга тиеш,—диде Альберт абый бер дәрестә.—Беренчесе: информация бирү.Укучылар әсәрне укыйлар һәм укытучыга төп-төгәл итеп эчтәлеген сөйләп бирәләр. Язучының биографиясе дә, әсәрнең сюжеты, кереш, йомгагы да шушында сыеп бетә. Икенчесе: фәнни аппарат. Бирелә әдәби әсәргә, язучы иҗатына һәм чорга анализ ясау алымнары өйрәнелә. Өченчесе: балаларны әдәбиятны яратырга өйрәтү».

Минемчә, тоташ бер институт башкара торган хезмәтне Альберт Яхин кыска гына вакыт эчендә берүзе ерып чыга алды: 4 тән башлап 11 нче класска кадәр әдәбият дәреслеген яңача язды. Ничек шаккатмыйсың һәм сокланмыйсың инде бу кешегә?

Аңа һич тә үз яшен бирмәссен. Хәзер дә йөгереп кенә йөри ул. Әле дә яңа проектлар, яңа идеяләр белән яна. Саулык, күңел күтәренкелеге телик үзенә.

**Алмаз ГЫЙМАДИЕВ**

## Шәһидә Максудовага 80 яшь

Язучы һәм тәрҗемәче Максудова Шәһидә Габдрахман кызы 1926 елның 29 ноябрендә Әгерҗе районының Уразай авылында мулла гаиләсендә туа. Сигезьеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Минзәлә шәһәрендә укытучылар әзерләү курсларында укый һәм үзенең хезмәт юлын Әгерҗе районының Салагыш мәктәбендә укытучы буларак башлый. Ләкин яшьтән үк әдәбият-сәнгатькә гашыйк кызның күңеле ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнми. Ул башкалабызга килеп урта белем ала, 1947 елны Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Студент елларында Гариф Ахунов белән таныша һәм 1951 елны аңа кияүгә чыга.

Университетны уңышлы тәмамлаганнан соң, 1952 елдан «Пионер» (хәзерге «Ялкын») журналында хатлар бүлеге мөдире, 1954-57 елларда Татарстан китап палатасында библиограф, 1960-68 елларда Әлмәт шәһәр китапханәсендә, 1969дан алып озак еллар дәвамында Татарстан Язучылар берлегендә китапханәче булып эшли.

Шәһидә Максудова үзенең әдәби эшчәнлеген тәрҗемәдән башлый. Л. Толстойның балалар өчен язган хикәяләре тупланган беренче китабы 1953 елны Татарстан китап нәшриятында басылып чыга. Аннары дистә еллар дәвамында язучы тәрҗемәсендә рус, башкорт, казакъ, каракалпак язучыларының әсәрләре дөнья күрә. Алар арасында Л. Антоновның «Аленка» исемле повесте һәм хикәяләре, В. Чивилихинның «Урман-чытырман», казакъ әдипләреннән С. Санбаевның «Аруана»сы һәм А. Кекильбаевның «Хатынгол балладасы», шулай ук И. Ракша, А. Емельянов, И. Друце хикәяләре һ. б. бар.

Шәһидә ханым лирик шигырьләр авторы да. Аның әдәбиятка кагылышлы мәкаләләре республика газеталарында, «Казан утлары», «Сөембикә», «Идел» журналларында басыла килә.

Язучы буларак, «Минем кала алуым» дигән беренче повесте—1970, ә «Асылбикәне җирләгәндә» исемлесе 1997 елда «Казан утлары»нда дөнья күрделәр. 1974 елны «Минем кала алуым» («Я и город белокаменный») улы Рәшит Ахунов тәрҗемәсендә «Волга» журналында рус телендә дә басылып чыкты. Күптән түгел Татарстан китап нәшриятында язучының әлеге повестьлары аерым китап булып та укучыларга барып иреште.

Шәһидә Максудова 1993 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, псевдоним-тәхәллүсе—Гөлшәһидә.

Шәһидә ханымның гаиләсе дә—ире күренекле әдип Гариф Ахунов (2000 елны вафат), улы Рәшит, кызы Наилә—язмышларын әдәби иҗат белән бәйләгән затлар. 2005 елны Татарстан китап нәшриятында язучының тууына 80 ел тулу уңаеннан, замандашларының хатирәләре, фоторәсемнәр тупланган «Гариф Ахунов: истәлекләр» дигән китап-альбом басылып чыккан иде. Аны төзүчеләр—Ш. Максудова һәм кызы Н. Ахунова.

Бүгенге көндә Шәһидә Максудова гаилә архивын туплау, аларны укучылар игътибарына җиткерү белән мәшгуль.

**«Казан утлары» журналы коллективы әдибәне олы юбилее белән ихлас котлый, аңа саулык-сәламәтлек, иҗади уңышлар тели.**

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

*Хөрмәтле укучыларыбыз!*

*2007 елның беренче яртысы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә. «Казан утлары»ның индексы—**73210**, Татарстанда ярты елга язылу бәясе **162 сум**.*

*Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан быел да абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем—фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.*

*Казанлылар журналга «Горпечать» киосгларында языла алалар. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була. Фатирыгызда почта әрҗәсе бик үк ышанычлы булмаса, сезгә моннан да кулай ысул юк.*

*«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!*

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

**Казан утлары** (наименование издания) — Количество комплектов

на 2007 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|

на ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

**Казан утлары** (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ______ руб. ______ коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ______ руб. ______ коп. | |

на 2007 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)



Әмирхан Еники һәм Фәридә Кудашева. Уфа. 1994 ел.



Нәфыйгов Рәфикъ Измаил улы (1928 — 2001) — күренекле галим, тарихчы. Журналыбызның даими авторы, 60-70 нче елларда редколлегия әгъзасы булып та торды.



Аяз Гыйләҗев Баграж авылы (Зәй районы халкына рәхмәт йөзеннән әти-әниләре истәлегенә төзекләндерелгән чишмә янында. 1995 ел.



*Риза Ишморат, Марсель Сәлимҗанов, Леонид Леонов. 1983 ел.*



*«Казан утлары» журналында озак еллар эшләгән шагыйрь, прозаик Маннапов Шамил Мәгъйүз улы (1938).*




*Мөдәррис Әгъләмгә 50 яшь тулу уңаеннан җырчы Гөлзада Сафиуллина котлый. 1996 ел.*

## «АЛТЫН МӨНБӘР» ДӨНЬЯ ЯУЛЫЙ

10-15 сентябрь көннәрендә Казанда икенче тапкыр «Алтын мөнбәр» Халыкара мөселман киносы фестивале уздырылды. Диндә һәм сәясәттә үзара сизгер һәм итагатьле булуны үзләренә девиз итеп алган һәм дөньякүләм танылган кино төшерүчеләр, режиссер һәм артистлар катнашты бу бәйрәмдә. Алар Мәскәүдән тыш, Әзәрбәйҗан, Иран, Һиндстан, Төркия, Фәләстыйн, Әфганстан, Бөекбритания, Италия кебек илләрдән килгән иде.

Фестиваль С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Коръән сүрәләрен уку белән башланып китте. Татарстан премьер-министры урынбасары, мәдәният министры Зилә Вәлиева кунакларга мөрәҗәгать итеп: «Бөтен каршылыклар бер-беренне анламаудан килеп чыга. «Алтын мөнбәр»не мин анлашу мәйданы итеп күрәм»,—диде.

«Фестивальдә барысы да үзара аңлашу, килешү өчен эшләнгән»,—диде Россиянең мөфтиләр советы рәисе Равил Гайнетдин. Ул фестивальнең кешеләрдә изгелек, шәфкать, сабырлык кебек сыйфатларны тәрбияләүгә юнәлтелгән белән башкалардан аерылып торуы турында әйтте. Фестиваль кысаларында күрсәтелгән 13 нәфис һәм 16 документаль фильм нәкъ менә шундый хисләр белән сугарылган иде.

15 сентябрь көнне «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә «Алтын мөнбәр» халыкара мөселман кинофестивален ябу тантанасы узды. Шәрык дөньясы тормышын чагылдырган фильмнарны атна буе караган тамашачы һәм жюри иҗатчыларга тиешле бәяне бирде һәм җиңүчеләрне ачыклады.

Фестивальнең иң әйбәт уен фильмы дип Иран режиссеры Азизолла Хәмиднезадә куйган «Салкыннан тамган күз яше» табылды. Аның режиссерына фестивальнең төп призы—«Алтын мөнбәр» сыны тапшырылды. Тагын алты сынга нәфис кинофильмнарның авторлары лаек булды. Аларның берсе—«Иң яхшы оператор эше өчен» дигәне «Бабайлар сандыгы» (Кыргызстан) фильмы операторы Дмитрий Ермаковка бирелде. Бу фильм шулай ук ТР Президенты М.Ш. Шәймиевнең «Кино сәнгатендә гуманизм өчен» дигән махсус бүләгенә дә лаек булды. «Нәфис фильм өчен иң яхшы сценарий» номинациясендә бүләк «Дала экспрессы» (Казакъстан) фильмының сценарий авторы Фоат Әхмәтовка тапшырылды. Биш мультфильм арасыннан «Әл-Фатиха сүрәсе» (Россия) дигәне иң яхшысы дип табылды. Документаль фильмнар арасыннан «Үзгәрешләр дәверенә хас төсләр» фильмының сценарий авторлары Андрей Шелков һәм Равил Бохараевка да «Алтын мөнбәр» сыннары тапшырылды. «Эльдорадо» дигән фильм (Катар) «Иң әйбәт фильм-репортаж» номинациясендә, ә «Памир территориясе» (Әфганстан) дигәне документаль фильмнар арасында иң яхшысы дип табылды.

Фестивальнең жюри рәисе, күренекле кинорежиссер Вадим Әбдрәшитов «Кино сәнгатенә керткән зур өлеш өчен» дигән приз белән бүләкләнде.

## ПРЕЗИДЕНТ БҮЛӘКЛӘР ТАПШЫРДЫ

8 сентябрьдә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев «Казан утлары» журналы баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллинга, Премьер-министрның беренче урынбасары Равил Моратовка һәм Татарстанның халык артисты, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры солисткасы Венера Ганиевага Россия Федерациясенең «Дуслык» орденын тапшырды. Казан Кремлендә үткән тантанада шулай ук республиканың башка күренекле шәхесләре—юристлар, икътисадчылар, төзүчеләр, фән һәм мәдәният әһелләренә дә Россиянең һәм Татарстанның Дәүләт бүләкләре тапшырылды. «Дәүләт бүләкләренә лаек булучылар - барысы да тырыш хезмәтләре белән үзләренең талантларын тормышка ашыручы, республиканың социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертүче кешеләр»,—дип билгеләп үтте Минтимер Шәймиев.

## РОССИЯ ИСЛАМ ҮЗӘГЕНӘ — 15 ЕЛ

«Казан-Эрмитаж» үзәгендә Россия Ислам мәдәнияте Үзәгенең күчмә утырышы булып узды.

Әлеге Үзәк моннан 15 ел элек Мәскәүдә Абдул-Вахед Ниязов җитәкчелегендә оеша һәм озакламый Бөтенроссия оешмасы статусы ала.

«Беренче бүлекчә нәкъ менә Татарстанда оешты,—диде Үзәкнең президенты Абдул-Вахед Ниязов. - Казан мөселманнарының Исламны ничек анлаулары күпләргә

үрнәк булып тора. «Алтын мөнбәр» халыкара фестиваленен нәкъ менә Казанда үткәрелүе дә шул хакта сөйли. Татарстан чын мәгънәсендә толерантлык үрнәге күрсәтә».

Киноәмәдә Россия Мөфтиләр советы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин дә катнашты. Чыгышында ул бу мөһим башлангычны тагын да кинрәк җәелдерергә кирәклегенә басым ясады. Мәсәлән, Калининград шәһәрендә мәһабәт чиркәү калкып чыккан, ә мәчет һаман юк.

Фәләстиннен Россиядәге илчесе Бакир Аблел Мунем дә әлеге чарада сүз алып, Үзәкнен киләсе утырышын Фәләстиндә үткәрергә тәкъдим итте.

### ӘЛМӘТТӘ ӘДӘБИЯТ БӘЙРӘМЕ

Әлмәттә узган әдәби очрашулар вакытында күпләр бу шәһәрне рухият каласы дип атады. Ә бу очрашулар күренекле шагыйрә Сажидә Сөләйманованың тууына 80 ел тулуга һәм «Татнефть» ачык акционерлар җәмгыятенен «Рухият» янарыш фонды гамәлгә куйган яна әдәби бүләкне—Сажидә Сөләйманова исемендәге премияләрне һәм алдынгы укучы яшьләргә махсус стипендияләрне тапшыруга багышланган иде.

Тантаналар Әлмәттә 3 октябрьдә, шагыйрәнен туган көнендә, анын исеме белән аталган урамда, ана куелган һәйкәл-бюст янында башланып китте. Шушы калада эшләп, яшәп иҗат иткән әдипләр - Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов һәм Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзал торган йорт диварына истәлек тактасы кую, Әлмәтнен Ризаэтдин Фәхретдин исемендәге татар гимназиясе укучылары һәм укытучылары белән очрашу бу кояшлы көннен бер бизәге булды. Әлмәткә әлеге тантаналар унаеннан Казаннан һәм күрше-тирә төбәкләрдән язучыларның, сәнгать әһелләренен, галимнәрнен һәм хәбәрче-журналистларның зур бер төркеме килгән иде. Әдипләр Т. Миннуллин, Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, М. Галиев, Р. Вәлиев, Р. Миннуллин, З. Мансуров, Ә. Гаффар, Ж. Дәрзаман, Ш. Жиһангирова, Н. Гыйматдинова, Р. Корбан, Татарстан китап нәшрияты директоры Д. Шакиров, радио һәм телевидение, газета һәм журналларның хәбәрчеләре Әлмәтнен чынлап та рухият шәһәренә әйләнеп баруын билгеләп үттеләр. Әлмәттә Әдәбият көннәрен Язучылар берлегенен Әлмәт оешмасы җитәкчесе Д. Салихов ачып җибәрде.

Кичен Әлмәт дәүләт драма театрында С. Сөләйманова исемендәге әдәби премияне һәм стипендияләрне тапшыру тантанасы булды. Лауреатларны һәм стипендиатларны Әлмәт муниципаль районы башлыгы Р. Әбүбәкеров, «Рухият» янарыш фонды рәисе, «Татнефть» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры урынбасары Р. Мөхәммәдиев котлады. Сажидә Сөләйманова исемендәге премиягә беренче булып быел шагыйрәләр Флера Гыйззәтуллина, Роза Кожевникова, прозаик Фоат Садриев лаек булды. Кызыксындыру премияләре Илсөяр Иксанова, Рәмзия Габделхакова, Нияз Акмалга бирелде.

Премияләрне һәм укучы яшьләргә стипендияләрне тапшырганда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. Ибраһимов Сажидә Сөләйманова исемендәге премияне булдырган, рухи янарышка зур өлеш керткән өчен «Татнефть» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры Ш. Тәхаутдинов исеменә, Әлмәт шәһәре җитәкчелегенә, «Рухият» фондына Язучылар оешмасының рәхмәт хатлары юллавын әйтте.

### КАМАЛ ТЕАТРЫ ЛОНДОНДА

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры Лондонда гастрольдә булып кайтты. Татарстаннан килгән кунакларга чыгыш ясар өчен Бөекбритания башкаласының иң яхшы сәхнәләреннән берсе бирелде.

Гастрольләр Г. Камал пьесасы буенча сәхнәләштергән «Беренче театр» спектакле белән ачылды. Спектакль алдыннан сәфәрне оештыручыларның берсе—шагыйрь, тәрҗемәче һәм драматург Равил Бохараев тамашачыларны артистлар белән таныштырды, 100 еллыгын билгеләп үтәргә җыенучы татар профессиональ театры сәхнәсендә куела торган спектакльләр турында сөйләде.

Тантанада Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты. Үз чыгышында ул 19-20 октябрьдә ТР Президенты М. Шәймиев катнашында Лондонда узачак Татарстан Республикасының I инвестицион форумы хакында әйтеп үтте, хәзерге вакытта Лондонның күп кенә музейларында мөселман мәдәниятенә багышланган күргәзмәләр әзерләнүен хәбәр итте.

Гастрольләр ачылу тантанасында Бөекбритания бизнес-элитасы, җирле татар диаспорасы вәкилләре катнашты. Биредә яшәүче татарларның әлегә үз мәркәзе юк, шуңлыктан театр тамашалары аларның милли мәдәниятка якынаюында бер адым булачак. Спектакльдән соң Татарстан сәнгать осталары тамашачыларга концерт күрсәтте.

Милли классикадан тыш, камаллылар З. Хәкимнен «Телсез күке» һәм Р. Бохараевның «Тимер борчак» әсәрләре буенча куелган спектакльләрне дә тамашачыларга тәкъдим итте. Алар турыдан-туры инглизчәгә тәрҗемә ителеп барды.

### АНСАМБЛЬ ЛИТВАДА

Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбле мәдәниятебезне таныту максатыннан, Литваның Висагинас шәһәренә фестивальгә барды.

Ансамбльнен җитәкчесе—Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов.

Алар шулай ук Соколка һәм Белосток

шәһәрләрендә чыгыш ясаганнар. Шулай ук Польшада татарлар берлеге оешуның 80 еллык юбилеенда һәм Польша татарлары турындагы күргәзмәдә катнашканнар.

### БЕЗНЕКЕЛӘР—ТӨРКИ ДӘҮЛӘТЛӘР КОРЫЛТАЕНДА

Төркиянен Анталия төбәгендәге Кәмәр шәһәрендә Төрки дәүләтләр һәм җәмгыятьләрнең дуслык, кардәшлек һәм хезмәттәшлек корылтаеның чираттагы—унынчы җыены булды.

1993 елдан бирле үткәрелеп килгән әлеге чара Төркия Премьер-министры Рәҗәп Таип Әрдоган ярдәме белән гамәлгә ашырыла. Корылтайда Әзәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Төркмәнстан, Таҗикстан, Монголия, Төньяк Кипр кебек илләрдән рәсми делегацияләр, Татарстан, Башкортстан, Балкария республикаларыннан иҗтимагый оешма вәкилләре катнашты. Республикабыздан анда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты вәкилләре һәм галимнәр Дамир Исхаков, Фәридә Гаффарова барган иде.

### «ВАКЫТ»КА—100 ЕЛ

21-22 сентябрьдә Оренбургта «Вакыт» газетасының 100 еллыгы: Оренбургнын вакытлы татар матбугаты» темасына төбәкара фәнни-гамәли конференция узды.

Конференция Оренбургта 1906-1918 елларда нәшер ителгән «Вакыт» дип аталган беренче татар газетасының 100 еллык юбилеен бәйрәм итү кысаларында оештырылган. Чараны оештыручылар—Оренбург өлкәсенен Мәгълүмати сәясәт, иҗтимагый һәм тышкы элемтәләр министрлыгы, Оренбургнын төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте.

Конференциядә 1905-1918 елларда Оренбургта вакытлы татар матбугаты басылу, Оренбургта татар журналистикасы барлыкка килү тарихы, Оренбург өлкәсендә милләтара дуслыкны ныгытуда «Вакыт» газетасының роле турында фикер алышу булды. Форумда катнашучылар электрон коммуникацияләр үсеше һәм дөньякүләм глобальләшү барганда татар телен саклап калу кебек әһәмиятле теманы игътибар үзәгенә алды.

### КИТАПЛАР БҮЛӘК АЛА

«Мәгариф» нәшрияты чыгарган балалар китаплары Республика Милли китапханәсе уздыра торган «Ел китабы» конкурсында һәр елны диярлек беренче урыннарны алып килә.

Әлеге нәшриятта дөнья күргән ике китапның: Рафаил Газизовның «Бүләгем» исемле китабы — Г. Х. Андерсен исемендәге Халыкара дипломга, Әхәт Мушинскийнын «Әнәс-Ананас һәм башкалар» китабы Россиянен «Күнел түрендәге хыял» Милли балалар әдәби бүләгенә лаек булганын хәбәр иткән идек инде.

Әле шушы көннәрдә генә нәшриятнын баш рәссамы Лилия Золондинова Мәскәүдән куанычлы хәбәр алып кайтты. Яшүсмерләр һәм балалар китабының «Ал җилкән» Бөтенроссия конкурсында Габдулла Тукайның «Кәҗә белән Сарык әкияте» китабы Мактау грамотасы белән бүләкләнгән. Татар, рус, инглиз телләрендә нәшер ителгән бу китапны А. Алиш исемендәге балалар иҗаты үзәгенен яшь рәссамнары бизәгән.

Әкиятне русчага Равил Бохараев, инглизчәгә Айдар Шәмсетдинов тәрҗемә иткән, редакторы—Люция Гыйззәтуллина.

### БУБЫЙЛАР МИРАСЫ—ХАЛКЫБЫЗ ХӘЗИНӘСЕ

Әгерже районының Иж-Бубый авылында «Бубыйлар мирасы—халкыбыз хәзинәсе» дип аталган фәнни-гамәли конференция булып үтте. Ул шушы авылда мәдрәсә оештырылуның 225 еллыгына багышланып уздырылды. Бәйрәм чараларында Казан һәм Чаллыдан, Ижау, Түбән Кама һәм Әгерже шәһәрләреннән, тирә-як авыллардан милли зыялылар һәм сәясәтчеләр, галимнәр, язучылар, хакимият вәкилләре катнашты.

Конференциядә төп докладларны «Иж-Бубый мәдрәсәсе - мәгърифәт учагы» дигән темага филология фәннәре кандидаты Раиф Мәрдәнов һәм «Габдулла Бубыйның язма мирасы» дигән темага тарих фәннәре кандидаты Альта Мәхмүтова ясады. Конференциядә шулай ук Әгерже районы башлыгы Ф. Габбасов, язучы Ф. Бәйрәмова, Татарстанның фән һәм мәгариф министры урынбасары Д. Мостафин һ. б. катнашты һәм чыгыш ясады.

Фәнни-гамәли конференция ахырында Бубый мәдрәсәсе тарихын өйрәнү һәм бүгенге көндә дә анын традицияләрен дәвам итү буенча махсус резолюция кабул ителде, анда бертуган Бубыйлар яшәгән йортны музей итү, Габдулла, Гобәйдулла һәм Мөхлисә Бубыйларның фәнни, әдәби, педагогик, дини, публицистик мирасларын халыкка кайтару, соңгы 15 ел эчендә бу темага уздырылган конференция материалларын аерым җыентык итеп чыгару, Бубыйлар мәдрәсәсен тәмамлаган шәхесләр тарихын өйрәнү зарурлыгы турында әйтелде. Шулай ук Иж-Бубый авылында яңадан мәдрәсә ачу, бертуган Бубыйлар турында әдәби әсәрләр язу, фильмнар төшерү кирәклеге турында да тәкъдимнәр булды.

### ЯУШИРМӘДӘ КОНФЕРЕНЦИЯ

Сентябрь ахырларында Чистай районының Яуширмә авылында (Г. Исхакый туган авыл) «Татарстанның Кама аръягы төбәгендә тарихи-археологик тикшеренүләр һәм музей - туган якны өйрәнү эше» дигән фәнни-гамәли конференция булып узды. Конференцияне оештыручылар—Чистай муниципаль районы һәм шәһәре хакимияте,

мәдәният һәм мәгариф идарәсе, Яуширмә авылындагы Гаяз Исхакый музей-йорты, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты һәм Мәржани исемендәге тарих институты.

Конференциядә катнашучылар Кама арьягы төбәгендә А. Борһанов һәм Н. Нәбиуллин җитәкчелегендә үткәрелгән археологик тикшеренүләр нәтиҗәсен югары бәяләде. Археологик эшләр барышында, аерым алганда, Җукәтау, Актау, Тубылгытау, Иске Нократ шәһәрлекләре җирлегендә Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы һәм XYII-XIX гасырларга караган яңа материаллар табылды.

## ЮБИЛЕЙГА — ТАРИХ МУЗЕЕ

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында тарих музее ачылды. Быел университетка 130 ел тулды. Музей оештыру шушы күренекле вакыйгага багышланган.

Тарих музее экспозицияләре «Юл башы: Казан укытучылык институты (1876-1918)», «Казан педагогика институты (1918-1919)», «Халык мәгарифе югары институты», «Көнчыгыш педагогика институты», «Татар педагогика институты (1931-1934)», «Казан дәүләт педагогика институты Бөек Ватан сугышы елларында», «Вузның ректорлары», «Күренекле чыгарылышлар», «ТДГПУ - вузның өр-яңа тарихы» кебек тематик бүлекләрдә тәкъдим ителгән. Шулай ук бирелә, беренче тапкыр буларак, шушы уку йортыннан оештырылган экспедицияләрнең Урта Азия, Түбән Идел буе һәм Татарстан районнары территорияләрендә эзләп тапкан үзенчәлекле археологик табылдыкларының коллекциясе дә тәкъдим ителгән.

Музей белән тарихчы, тарих фәннәре кандидаты Л. Краева җитәкчелек итәчәк. Тарих һәм этноархеология кафедрасы мөдире, галим Альберт Борһанов сүзләренчә, алга таба университетта Идел һәм Урал буе тарихы, борынгы һәм урта гасыр археологиясенә багышланган аерым музей ачарга ниятлиләр.

Казанның «Туран» фонды белән «Эбиволь» җәмгыяте әлеге тарих музеена татар милли киемнәре, декоратив-гамәли сәнгать әйберләре бүләк иткән.

## МОСТАЙ КӘРИМНЕ ИСКӘ АЛУ

Уфа шәһәрендә Башкортстанның халык шагыйре, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин һәм Дәүләт премияләре лауреаты Мостай Кәримнең вафат булуына 1 ел тулуга багышланган чаралар үткәрелде. Аларда Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис һәм Роберт Миннуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Әлфәт Закирҗанов катнашты.

Татар язучылары М. Кәрим исемендәге башкорт гимназиясендә укучылар белән очрашты, аннары аларны Башкортстан язучылары, шәһәр һәм район җитәкчеләре белән берлектә Мостай Кәрим фатирында әдипнең кызы Әлфия һәм улы Илгиз кабул итте.

Кич белән М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театры бинасында искә алу кичәсе үткәрелде. Анда Мостай Кәрим турында истәлекләр сөйләнде, аның шигырьләре укылды, әдип яраткан җырлар яңгырады.

## ЯҢА ДИРЕКТОР

29 сентябрьдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми җыелышында институтның яңа директорын сайладылар. Ул—монарчы Министрлар Кабинетында халыклар телләрен үстерү бүлеге башлыгы булып эшләгән филология фәннәре докторы Ким Миннуллин.

## ӘРМӘН РӘССАМЫ БЕЗНЕҢ ХАКТА

5 октябрьдән ТР Милли музеенда әрмән рәссамы Геворг Мшецинның шәхси күргәзмәсе эшли башлады. 2006 ел Россиядә Әрмәнстан елы уңаеннан, Татарстан Милли музее белән Ереванның Сергей Параҗданов Дәүләт музее үзара иҗади һәм фәнни хезмәттәшлек турында килешү төзелгән иде. Бу—Казандагы «Луйс» Әрмән мәдәнияте җәмгыяте белән ТР Милли музееның өченче проекты.

Г. Мшеци Әрмәнстанда яшәгәндә үк Татарстан мәдәнияте, Казан архитектурасы белән кызыксына торган була. Шул вакытта ук рәссам Татарстан башкаласына багышланган коллажлар сериясен иҗат итә. 2005 елда, Казанның 1000 еллыгы уңаеннан, Геворг Мшецинның хезмәтләре «Казан» милли-мәдәни үзәгендә күрсәтелә. Әлеге күргәзмәдән соң, рәссамда бүгенге һәм Иске Казан турында рәсемнәр иҗат итү теләге туа. Хыялын тормышка ашыру өчен ул Казанга килә, беркадәр вакыт биредә яши һәм иҗат итә. Аның Казан һәм аның кешеләренә багышланган 20 дән артык картина-коллажлары Милли музейда күреп була.

## ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ ИСТӘЛЕГЕНӘ

15 сентябрьдә Казанның Островский урамындагы 4 нче йорт диварына күренекле драматург, артист һәм режиссер Таҗи Гыйззәткә истәлек тактасы куелды.

Бу йортта Таҗи Гыйззәт 1929-1953 елларда яшәгән. Аның татар театр сәхнәсендә зур уңыш белән барган әсәрләре «Ташкыннар», «Наемщик», «Мактаулы заман», «Изге аманәт», «Бишбүләк» һәм башка бик күп пьесалары әнә шул чорда язылган.

Күренекле драматург яшәгән йортка истәлек тактасы кую тантанасына киң җәмәгатьчелек, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты галимнәре һәм студентлары,

Г. Камал һәм К. Тинчурин исемендәге театрларның артистлары, язучылар һәм мәдәният хезмәткәрләре җыелган иде. Анда Театр әһелләре берлеге идарәсе рәисе Ринат Таҗетдинов, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, драматург Ризван Хәмид, Таҗи Гыйззәтнең улы, философия фәннәре докторы профессор Казбек Гыйззәт, драматургның туган ягы—Әгерҗе районының Барҗы-Умга авылы җирле үзидарәсе рәисе Зөлфәт Нуриев һ. б. чыгыш ясады. Истәлек тактасын ачуга багышланган җыенны Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов алып барды.

Истәлек тактасының авторы—скульптор Мәхмүт Гасыймов.

### ӘДИП ИҖАТЫНЫҢ ДӘВАМЫ

Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең туган авылы Гөберчәктә, аның музее белән янәшәдә өр-яңа мәктәп ачылды.

Мөхәммәт Мәһдиевнең авылдашлары-якташлары, Арчадан һәм Казаннан килгән кунаклар язучыны тагын бер кат зурлап искә алды, аның таланты алдында баш иде. Район хакимияте башлыгы Алмас Нәзиров әйткәнчә, бу мәктәп ачу гына түгел, Мөхәммәт Мәһдиев йөргән эзләрне янарту да иде.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов яңа мәктәп укучыларына язучыларыбызның өр-яңа китапларын бүләк итте. «Монда, бу мәктәптә укучылар—бәхетле балалар, алар телебезне, милләтебезне саклаучылар булыр»,—дип ышаныч белдерде ул.

Арча урман хуҗалыгы директоры Шамил Хәйруллин, «Ак Барс-Агро» хуҗалыгының генераль директоры Шәйдулла Сәләхов, Арча агач эшкәртү пункты житәкчесе Вәкъкас Зыятдинов, Мөдәррис Ибраһимов җитәкчелегендәге төзүчеләр бригадасы—бу мәктәпнең ачылуына зур өлеш керткән кешеләр.

Мәктәп ачу тантанасына Мөхәммәт Мәһдиевнең хатыны Лилия ханым һәм кызы Гәүһәр дә кайткан иде.

Әдәбиятта Мөхәммәт Мәһдиевнең үз мәктәбе—иҗат мәктәбе бар иде. Туган авылында ачылган мәктәп исә—шул олы иҗатының матур бер дәвамы...

### «АЗАТЛЫК» РАДИОСЫНДА ЯҢА ДИРЕКТОР

Чехиянең Прага шәһәрендә урнашкан «Азатлык» радиосындагы татар-башкорт редакциясенә яңа директор билгеләнде.

Ул—әлегә кадәр радиода директорның урынбасары булган Рим Гыйльфанов. Тыңлаучыларга исә ул Кәрим Камал буларак таныш.

«Азатлык» радиосы татар һәм башкорт телләрендә инде 1953 елдан бирле сөйли. Аның чит илләрдә һәм Россия төбәкләрендә 25 хәбәрчесе, Казанда үз мәгълүмат бюросы бар.

Радио тыңлаучыларга риясыз һәм төгәл мәгълүмат бирү, шуның аша җәмгыятьтә ирекле вә хөр фикер булдыру максатына тугрылыклы кала.

### МАКТАУЛЫ ИСЕМ


Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә керткән зур өлеше өчен драматург **Гыйләҗев Мансур Аяз улына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Беренче кар».

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Шәһидә Максудова**.

# Яңа китаплар




**Илшат Вәлиулла.** Һәр шагыйрь—бер дәрья. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. —Казан: Тат. кит. нәшр., 208 б. Тиражы—1000 данә.

Яшь тәнкыйтьче Илшат Вәлиулланың беренче зур тупланмасы бу. Китапта бүгенге татар шигъриятендә әйдәп баручы шагыйрьләрнең (Р. Фәйзуллин, Роб. Әхмәтҗан, М. Әгъләм, Р. Гаташ, Л. Шагыйрьҗан, Г. Морат) иҗатлары анализлана, аларның фәкать үзләренә генә хас үзенчәлекләре тасвирлана. Шунысы игътибарга лаек: авторның күзәтүләре монарчы стереотип рәвештә килгән бәяләрдән шактый ук аерыла да. Мәкаләләрнең исемнәре дә шигъри һәм оригиналь: «Шигърияттә Моң һәм Сабантуй рухы», «Көнбатыштан Көнчыгышка гомер озынлыгындагы юл», «Чынбарлыкның түзеп булмас җинеллеге», «Безгә бер Хәбәр кирәк!», «Кай йөрәктән килә бу моң?», «Әлмисакны сагыну»...

Китапта шулай ук яшь шагыйрьләр—Р. Аймәт, М. Закир, Л. Янсуар, Г. Сәлим, Э. Афзаловалар турында да мәкаләләр урын алган.




**Чыңгыз Мусин.** Гомер юлы. Шигырьләр. —Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. —160 б. Тиражы—1000 данә.

Әгерҗе якларында яшәп иҗат итүче шагыйрь Чыңгыз Мусинның исеме укучыларга газета-журнал битләрендә һәм аерым китап булып басылган әсәрләре аша яхшы таныш. Әле яңа гына дөнья күргән бу китабына авторның төрле елларда язылган лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланган. Житди кичерешләргә бай булган әлеге җыентык шигырь сөючеләр күңеленә хуш килер дип уйлыйбыз.

Китапның мөхәррире—Илһам Ногманов, рәссамы—Йосыф Вәлиәхмәтов.



Шәһидә Максудова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)